# КАЗАН УТЛАРЫ

10
ОКТЯБРЬ
1979

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА
ПИСАТЕЛЕЙ
ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

**10**
ОКТЯБРЬ
1979


## Бу санда


Р. ФӘЙЗУЛЛИН. Яңа шигырьләр . . . . . . . 3
М. ХӘБИБУЛЛИН. Хәтер ярлары. Повесть . . . 7
Г. МИНСКИЙ. Хикәяләр . . . . . . . . . . . 82
ГОСМАН САДӘ. Бүләккә әтәч. Шигырьләр . . 94
Б. СӨЛӘЙМАНОВ. Казаннан китәр алдыннан. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . 96

ОЧЕРКЛАР

М. НАСЫЙБУЛЛИН. Чакырылган кунак . . . . 97

КЛАССИК ПОЭЗИЯДӘН ҮРНӘКЛӘР

Һенрих Һейне шигырьләре . . . . . . . . . 107

1979 ЕЛ — ХАЛЫКАРА БАЛАЛАР ЕЛЫ

М. МӘХМҮТОВ. Сабыйларның бәхете хакына . 111
«Ялкын» журналы битләреннән . . . . . . . 117
«Яшь ленинчы» газетасы битләреннән . . . . 120
Р. МИҢНУЛЛИН. Качышлы уйнаганда. Шигырьләр 123
Ф. ШӘФИГУЛЛИН. Ерактамы, якындамы! Хикәя . 125
З. НУРИ. Зурлар турында... нәниләр. Шигырьләр 128

ТАТАРСТАННЫҢ 60 ЕЛЛЫГЫНА

Р. ӘХМӘТҖАНОВ. Республикам шагыйрьләре. Шигырь . . . . . . . . . . . . . . . 132
М. АБДУЛЛИН. Татар эшчеләр хәрәкәте һәм «советология» . . . . . . . . . . . . . 133
Т. БИКТИМЕРОВА. Егерменче елларда хатын-кызлар хәрәкәте . . . . . . . . . . . . . 138

МОСТАЙ КӘРИМГӘ 60 ЯШЬ

М. КӘРИМ. Ашыкма килергә, картлыгым. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . 144

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Г. МУХАНОВ. Әдәби процесс һәм социалистик яшәү рәвеше . . . . . . . . . . . . . 149
М. ВӘЛИЕВ. Кешелеклелек өчен көрәшү . . . 157
Г. ИВЛЕВ. Рөстәм Кутуйның лирик прозасы . . 162



КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

КИТАП КҮЗӘТҮ

**Р. МОСТАФИН.** Аналарның чәче ник агара! . . 167
**Н. ХИСАМОВ.** Яңарыш чишмәләре . . . . . 170

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

**М. ГАЙНЕТДИНОВ.** Дастаннар китабы . . . . 172
Габдерәхим Утыз Имәнинең тууына 225 ел . . 176
Безнең сафка . . . . . . . . . . . . . 179

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

**Р. ШИРИЯЗДАНОВ.** Яхъя Халитовка 50 яшь . . 181
**Т. ӘЙДИ.** Тылмач кына түгел . . . . . . . . 183

ТӨРЛЕСЕННӘН

**А. СӘЙФЕТДИНОВ.** Көрәштә балкыган гомер . 187

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 189

Редакциянең адресы. Казань, 420066, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар: баш редактор — 3-07-60, баш редактор урынбасары — 3-07-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-61, поэзия бүлеге — 3-07-61, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-63, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Баш редактор: **Зәки Нури**

Редколлегия: **Әхсән Баянов** (баш редактор урынбасары), **Шамил Бикчурин, Аяз Гыйләҗев, Марсель Зарипов, Зөлфәт, Шәйхи Маннур, Фәрваз Миңнуллин, Туфан Миңнуллин, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Кояш Тимбикова** (җаваплы секретарь), **Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.**

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, Т. Шакирҗанова*

Производствога бирелде 21/VI-1979 ел. Басарга кул куелды 12/IX-1979 ел. ПФ 09034. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 83300 экз. Заказ Ц-250. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1979 ел.

## Равил Фәйзуллин

# ЯҢА ШИГЫРЬЛӘР

●

«Тагын кич...» — диеп офтанма —
иртән туар яңа таң!
Исән генә булсын сине
тудырган анаң-атаң!

Афәт килеп җилгә очса
тир түгеп тапкан малың —
бик кайгырма. Исән булсын
гомергә дигән ярың!

Кайгы килсә сыгылып төшмә!
Ул — бик авыр булса да.
Исән булсын Туган илең —
кайтып егылыр бусагаң!

«Гомерләр үтте...» — дип сызма,
телгәләп үз-үзеңне.
Гел яшим дисәң, кан чәчеп,
таркатма нигезеңне!

●

Дулкыннар ярсына! Котыра!
Диңгездә кайдадыр һәлакәт...
Ә ярда бер гамьсез талгынлык.
Көн — кояш. Ком җылы. Һәм рәхәт!

... Бер читтә өч көчек талаша.
Ырылдап тешлиләр бер-берсен.
Комлыкта тәгәрәп әйләнгән
очкалак каурый-йон өчен...

●

Чәчәккә кунды бал корты
бал өчен.
Чибәрне сөйде яшь егет
дан өчен.

Дошманына бал кортының
ук хәтәр!
Юхалыкка эремә, егет,
шул кадәр!

... Үлән арасында үле
корт ята.
Башын игән ирне тик җил
юата...

•

Иделләрдә саллар таралган...

Учак урыннарын ташу юган...
Саф хисләрне еллар талаган...

Иделләрдә саллар таралган.
Бар, син җыеп кара ярлардан!..

•

Дуслар тыныч: кирәктә дә дәшми.
Карап тора, аңлап тора...

... Ятлар сизгер, колак шомартып,
ялгышыңны аулап тора.

## Ни мәгънә?

Ни мәгънә шәп киемнән —
аны кем дә күрмәсә?
Ни мәгънә сау тәнеңнән —
кем дә кадрен белмәсә?

Ни мәгънә тау менүдән —
кем дә сәламләмәсә?
Ни мәгънә эч сереңнән —
аны кем дә белмәсә?

## Август

Җәй — җәядәй киерелгән соңгы чиккә:
җирдән — күккә,
яшеллектән — зәңгәрлеккә...

Зеңли үләннәр. Дым кимегән саен — авазлар нечкә...
Иртәнге томан сарыла керфекләргә.
Чәчәкләр тулышкан. Таҗларының һәрберсендә —
ким дигәндә берәр кояш!
Чалгы кискән җиләкләрдә шәфәкъләр каны.
Балыклар сикереп Иделдә салават күпере ясыйлар.
Игеннәр өстендә — рәшәләрнең саубуллашу биюләре.

... Канат ныгыткан яшь сыерчыклар
очышлар ясый кыйбла ягына.

## Диңгез комлыгында япа-ялгыз...

Җентекләп, озак карап тордым комның бөртекләренә.
Ә баксаң, аларны юньләп юк икән бит күргән дә!
Гүя үземне таныдым тәңре-Җирнең тәнендә.
Исемнәр генә бүтәнчә: аның — ком, минем — бәндә.

## Сурәт

Яшел тугай уртасында
күгәрченнәр күл кебек!
Пырхылдап күтәрелделәр —
ахры, миннән өркенеп.

Алкаланып, дулкынланып
очалар зәңгәр күктә!
Каурыйлары чабак сыман
калдылар чирәмлектә...

●

Яланнарга чыксаң, ялгыз чыкма,
дус-ишләрең булсын юлдашың!

... Иптәш булып якты йолдыз янсын,
япа-ялгыз калгач бер башың...

## Тургай

Бак та уйла: гыйбрәт бу —
шагыйрь белән җырчыга!
Җыр белән күтәрә Җирне
гаугасыз-даусыз гына...

## Март. Урманда кыш белән хушлашу

Сау бул!
Сау бул, ак йөзле Кышым!

Каеннарның яшьле күкрәге...

Имәннәрдә ядрә бөреләр
яшел аваз белән пышылдыйлар күк:
«Очрашырбыз кипкән яфрак булгач!
Җилләр белән
карларыңа каршы барырбыз...»

## Калды...

*Фольклор экспедициясе истәлеге*
*Римгә.*

Әрәмәдә аланнар калды...
Аланнарда баланнар калды...
Баланлыкта сылу яр калды...

Киткәндә, озатып
офыкта кыр калды...
Күңелдә җыр калды:
«... Төннәр уртасында буй кыз еглый,
үткән эшләренә үкенеп!..»

## Бер нәсихәт

Арсландай басып үләндә йөр!
Һәм лачындай оча ал җилпенеп!
Нужаларны күтәр сулар кебек!
Хәсрәтләрне йота ал Җир кебек!

●

Күпме матур яфрак агачта!

Күшеккән кошны ышыклаган
яфраклар ямьлерәк!

Күпме чибәр хатын дөньяда!

Бала үстереп сулышкан
хатын-кыз чибәррәк!..

## Уяну

Сихри төндә йөрдек икәү ак атларда!
Ал офыктай җуйдым сине таң атканда!..

... Ярым айнып төштән, чыксам өй алдына —
тышта суык яңгыр ява талгын гына.

## Мөсәгыйт Хәбибуллин

# ХӘТЕР ЯРЛАРЫ

ПОВЕСТЬ

1



Кичкә таба аяклар тала, көнозын бер каттан икенче катка күтәрелә-төшә, палатадан палатага йөри-йөри, эшендә булган мәшәкатьләрне барлый-барлый, Халисә балтырларында зыңлау тоя, аз гына буш вакыт тидеме, врачлар бүлмәсенә керә, авырулар тарихларын язарга керешү алдыннан, урындык артына ята төшеп, бер тын ял итеп ала: тәненә тымызык кына рәхәтлек иңә, ә бераздан аның зиһене сафланып, кәефе ачылып ук китә. Күз алдыннан эшләгән эшләре, караган-баккан авырулары уза, аннары тагын башкарыласы эшләрен барлый.

Җиденче палатада ятучы сиксән алты яшьтәге әбине улы килеп алам дип ышандырды. Халисә папкалар арасыннан карчыкның сырхау тарихын эзләп тапты. Сиксән яшьне тутырып, туксанны вакларга керешкән әбекәйдә склерозның иң авыр төре. Ай буе больницада ятып дәваланудан соң бераз хәле аруланса да, инде аңа беркайчан да элеккеге сәламәтлеге кайтмас. Әбекәйгә чын мәгънәсендә картлык килгән. Картлык дигәнең кипкән елга кебек бит ул — бер киптеме, аңа шунда ук корыган елга исемен тагалар.

Кайчан да булса Халисә дә шулай картаер микән?

Күңел бик тә, бик тә яшь, ә гомер уза. Әмма Халисә нидер көтә, ашыкмый. Ана бәхете — балада, диләр бит. Әллә чынлап та шулай микән? Урам-скверга һава суларга чыктымы, я кулына нәниен күтәргән, я бала арбасын тәгәрәтеп килгән ананы күрүгә Халисә тегеләрдән ихлас күңелдән көнләшеп куя. Дөрес, эштә бу тойгы онытылып тора. Кулы тиеп, үзе биргән шифалы дарулардан савыккан һәм якты йөз белән, мең-мең рәхмәтләр әйтеп, больницадан чыгып киткән авыруларны озатып калу үзе бер бәхет иде. Күп вакытта сәламәтләнгән авыруларны туганнары, агай-энеләре килеп ала, бергәләшеп куанышалар, алар йөзендәге шатлык Халисәгә дә күчә, һәм ул шушындый минутларда аерата зур бәхет кичерә иде. Ләкин кеше бәхете сине кышкы кояш кебек кенә җылыта икән, өйгә кайтып кердеме, янә күңелендә нидер кузгалып куюын тоя. Юк инде, җитәрдер, аңа бала кирәк,

үзе табып, үзе багып үстерәсе бала кирәк. Шунсыз аңа тынычлык килмәстер...

Шулар турында уйлана-йөри торгач, Халисә бер нәрсәгә ачык төшенде: адәм баласы үз бәхетенең бер өлешен хезмәтендә тапса, икенче бер өлешен, бәлкем әле иң зур өлешендер, гаиләсендә, иңгә-иң килеп, синең мендәреңә башын куеп йоклаган кешесендә һәм шул уртак бәхеттән туган балада табадыр. Кемдер, кайчандыр Халисәгә: «Баласыз гаилә ул гаилә түгел, ике адәмнең бердәм союзы гына»,— дип әйткән иде. Шулай булганда Гайсә белән алар союздаш җаннар гына булып чыгалар түгелме соң? Дөньядагы бөтен хатын-кызга кагылган, ким куйганда иман итеп кабул итәрдәй бер хакыйкать бар: нинди генә югары урыннарда утырмасын, башкарган хезмәте нинди генә җаваплы һәм дәрәҗәле булмасын, хатын-кыз һәр чак хатын-кыз булып калырга, һич югы, бер бала анасы булырга тиеш.

Халисә көрсенеп куйды, өстәл яныннан күтәрелеп, тәрәзә каршына килеп басты.

Күз карашына рәхәт иңдереп, зәп-зәңгәр күк йөзендә җәймә хәтле генә күгелҗем болытлар йөзә. Болыт күләгәләре җир өстеннән йөзеп бара-бара да өй стеналарына барып орына, югарыга таба үрли, түбә өсләрен капшап, янә түбән генә йөгереп китә. Больница ишегалдында савыга башлаган авырулар йөри. Поликлиника ягыннан больница бинасына чаклы сузылган тротуардан Гайсә белән хирургия сестрасы Нәзилә килә. Гайсә кызга кызып-кызып нидер сөйли, ул да түгел, алар туктап калалар. Гайсә кызның терсәгенә кагыла — нидер сорыймы, үтенәме... Нәзилә, башын кырын салган килеш, дикъкать белән тыңлый. Тыңлый-тыңлый да тыенкы, итагатьле генә елмаеп куя, аннары, хирург абыйсы белән килешеп булса кирәк, ияк кагып тора башлый. Кызның йөзендә, кыска җиңле ак халатында — каен яфраклары арасыннан төшкән кояш таңкәләре. Менә каен ябалдашлары әкрен генә искән җилгә селкенеп ала һәм кыз өстендәге «көмеш таңкәләр» дәррәү биешә башлыйлар. Шул мәлдә ул инеш буендагы басмада алтын тарак белән чәчен тарап утыручы су кызын хәтерләтә.

Халисә карашын поликлиника түбәсендә йөренгән күгәрченнәргә күчерә. Күгәрченнәр, сөйләшеп куйгандай, пар-пар торалар. Берәүсе канат-каурыйларын кабартып, сөйгәне тирәли әйләнә-тулгана кинәнде-кинәнде дә, мутлануы чиктән ашкачмы, тагы да һавалана төшеп, гөрли-гөрли үбешә башлады.

Көнләшерлек итеп сөешәләр кошлар.. Халисә көрсенеп куйды. Янә Гайсә белән Нәзилә басып торган җиргә карады. Ләкин алар анда юклар иде инде. Агачлар арасыннан култыклашкан кыз белән егет килеп чыктылар. Егетнең уң кулы гипста, яулык белән муенына аскан. «Менә язмыш нишли кеше белән,— Халисә үзалдына елмаеп куйды.— Иртәгә язылышырга барабыз дип кенә торганда егет мотоциклдан егылып кулын сындырган бит». Шул чакта, ни сәбәпледер, Халисәнең кияүгә чыгуы күз алдына килде. Соңгы курста кияүгә чыгуның модага кереп барган чагы, үзе белән бер шәһәрдән килеп бер курста укучы, үз гомерендә Халисә артыннан шәүләдәй йөргән Гайсә аның кулын сорады. Бер уйлаганда институтны тәмамлаганчы сабыр итәргә дә булган иде дә, тик әллә нигә бик тиз генә риза булды да куйды. Гомер ялгыз калырмын дип курыктымы? Алай дисәң, курыкмады да кебек. Үлеп яратмаса да, начар кеше сорамый иде кулын. Бүген-иртәгә хирург булырга тора, шуның өстенә, өйләнешсәләр, бер больницада эшләячәкләр, җитмәсә, туган шәһәрләренә эшкә кайтачаклар иде. Инде бергә, бер больницада да эшләгәч, квартира алулары да җиңелрәк булачак. Бу якны Гайсә әллә кайчан ук уйлап куйган икән. Халисәгә булган мәхәббәтен әнә шул сүздән башлады. Халисәнең көткәне болар гына түгел иде, әлбәттә. Ләкин аңа Гайсәнең заман кешелә-

ренә хас хирыслык белән эш йөртүгә ошады. Хәер, ул ире буласы кешедән моннан кимен көтмәгән дә иде. Тик менә кайтып, бер больницага урнашып, тиз арада квартира алып эшли башлагач, күңелгә әллә ниткән рәнҗү килде: бергә эшләүнең уңай яклары булган кебек, күңелне кимсетә, рәнҗетә торган яман яклары бар икән — бергә эшкә чыгып китәсең, бер больницада, бер бинада эшлисең, шунда көнен үтә, шулай ук бергә эштән кайтасың, бергәләп аш пешерәсең, бер өстәл янына утырып ашыйсың, бергәләп телевизор карыйсың, бер мендәргә баш куеп йоклыйсың... Тансыклап көтеп алыр кешең калмый, йөрәктәге изге хис тупаслана, тора-бара бөтенләй юкка чыга. Кемгә ничектер, гел бергә булып ирен зарыгып көтеп алу хисеннән мәхрүм ителгән Халисә, аерата соңгы вакытта, ярык тагарак янында утырып калган балыкчы карчыгы сыман хис итә башлады үзен. Хатын-кызның күбесе бу язмышны теләп ала, үзен алар рәтенә кертмәсә дә, Халисәнең дә күңеленә шомлы уйлар килгәләштергәли. «Иялләшеп, гадәтләнеп, җиңел тормышка исәп тотып кына чыкмадыммы бу Гайсәгә?» Һәм ул шундый чакларда мәктәп елларындагы гаҗәеп төстә саф һәм изге булып хәтердә калган яшьлек мәхәббәте — Нәүфәлне искә төшерә. Кайчак балалык самимилеге, яшьлек дуамаллыгы белән мөлдерәмә тулы мәктәп елларындагы мәхәббәте иң изге, иң эчкерсез булган кебек тоела башлый'аңа. Шундый минутларда ирдәге хатынга моңсу булып китә. Аннары хыялый-романтик уйларыннан арынып, җиргә төшә һәм үз-үзенә гаҗәпләнеп: «Тилекәй, ниемә юк өчен ут йоткан булып кыланасың инде. Җитмәсме?» — ди. Шулай дисә дә, үз-үзен шулай тиргәсә дә, барыбер яшьлек мәхәббәтен онытa алмады ул, чынын гына әйткәндә, онытасы да килми Халисәнең фаҗига белән очланган ул мәхәббәтне.

Кайларда йөри микән шул Нәүфәл? Кем булып эшли, кемгә өйләнде икән? Бер барып күрсәң иде үзен. Читтән генә булса да карап торсаң иде...

Халисә үзен Нәүфәл алдында гаепле саный. Егет белән булган фаҗигадә аның гаебе зур, бик зур. Халисә моны бик әйбәт белә. Шул ук вакытта Нәүфәлне дә бик үк аклап бетерәсе килми иде. Аңына килүгә үк Халисәне кабул итәргә теләмәде, аннары, больницадан чыгуга, һичкемгә әйтми, кай тарафларгадыр китеп баруы болай да үз-үзен кая куярга белми кайгырган кызны сулардан алып, утларга салды, бәгырьләрен телде. Ни генә булмасын, Халисәгә Нәүфәл белән бергә булган минутларын хәтерләү рәхәт, тормыш ыгы-зыгысыннан ярсып киткәләгән күңелне сафландыра. «Юк, үкенмә. Үкенмә, Халисә, ул изге хис сине дә читләтеп үтмәде», — дип үз-үзен юата торган иде.

Бүлмәгә шыпырт кына берәү керде, керде дә шулай ук шыпырт кына:

— Халисә акыллым, сөенче әйтимме үзеңә, — диде. — Кичә кич белән Нәүфәл кайтып төште, Чөгәдәй карт күргән...

Нәкъ менә аның турында уйланып торганда, Нәүфәл исемен ишетүгә Халисә башта сискәнеп китте. Әйләнеп карамаса да, сөенче җиткерүчене таныды ул, ләкин никтер бу көтелмәгән хәбәр китерүченең йөзен дә күрәсе килде. Әйе, шул үзе, больницада няня булып эшләүче Җәмилә иде ул. Җәмиләнең озынча йөзендә елмаю балкый. әмма Халисәнең кырыс чыраен күрүгә, ул елмаю ирен читенә качте. Кайчандыр әтиләре белән күрше яшәгән Җәмилә, Нәүфәл белән Халисә арасындагы фаҗигале мәхәббәтне һәм шул мәхәббәт аркасында үлемнән чак калган егетне белә, белә генәме, булган хәлне хәтта үз тирәсендәгеләргә бәет сыманрак итеп сөйләштергәли дә иде. Ул аны Нәүфәл белән Халисәнең исемнәрен әйтмичә генә бәян итә. Шуңа карамастан, бу хикәятне тыңлаучыларның күбесе белә, әмма белсәләр дә, Җәмилә аңа сөйләгән саен яңадан-яңа буяулар өсти бар-

гангамы, бик рәхәтләнеп, дикъкать белән тыңлыйлар иде. Шул минутларда Халисә килеп чыкса, Җәмилә сүзен кинәт кенә икенчегә борып: «И-и, бөтенләй онытып җибәргәнмен, фәлән палатага чәй кертәсем бар ие», — дип, ашыга-кабалана китеп барыр иде.

— Һаман өйләнмәгән икән әле, бичаракай, — диде Җәмилә.

Ниһаять, Халисә телгә килде:

— Җәмилә апа, сез эштәме, әллә күршегезгә гайбәт сатарга кердегезме?!

Тавышын күтәребрәк, кычкырыбрак әйтте бугай, Җәмилә, корт чаккандай сискәнеп, ишекне ачты һәм ничек шыпырт кына килеп кергән булса, шулай чыгып та китте.

Халисә битләре кайнарлануын тоеп чигәләренә ябышты, зиһенен җыя алмый торды, аннары ни кылырга белми гаҗизләнә калды. «Кайтса соң! Нигә болай нервыланам соң әле?! Минә дигән әйбәт ирем бар. Ул мине сабыр гына, тыныч кына ярата. Шашар дәрәҗәгә җитеп яраткан мәхәббәтеңнең үтүенә еллар узды түгелме инде, юләрем. Әле өзгәләнгән буласың. Ә моңа кадәр исеңә төшердеңме, төннәрен йокыдан уянып, шашар дәрәҗәгә җитеп сагындыңмы, юксындыңмы, үткәнең өчен үкендеңме, үртәлдеңме, мәгарәгә юлыккан бәрәүдәй, вакыт-вакыт чыгар ишекләр табалмыйча миңгерәүләнеп йөрдеңме?!. Әйе, йөрдем, йөрдем, үкендем, үртәлдем, яшьлегем юләрлеге белән эшләп ташлаган явызлыгым өчен гаҗиз башымны кайларга куяр урын таба алмый еладым, сагышландым — булган фаҗига күз алдыма килгән саен йөрәгем кысылды, бәгырем телгәләнде. Эзләп табып, алларына тезләнеп, гафу үтенәселәрем килгән чаклар да аз булмадымы?! Ә ул китте дә югалды. Менә хәзер, ничәмә еллар үткәч, йөрәктәге яраларны яңартып, яңадан кайтып төшкән. Нәүфәл, Нәүфәл, гафу итәрсең бит син мине! Кем белгән, кем белгән ул эт сиңа шулай ташланыр дип. Мин сине куркытырга гына теләгән идем бит, Нәүфәл. Кара кан эчендә ятуларың күз алдыма килгән саен бәгырьләрем әле булса ничек телгәләнүен белсәң икән! Белсәң икән?! Ярый әле, бәхеткә каршы, шул секундта диярлек капкадан әти кайтып керде һәм сине машинасы белән больницага алып китте. Алай булмаганда... мин кеше үтерүче булыр идем, Нәүфәл!..»

## 2

— Кадыйр Сөнгатович, контрольгә куелган утыз өченче скважина тоташ су бирә башлады. Баш геолог белән баш инженер да мондалар...

Кадыйр промысел мөдире телефоннан әйткән сүзләрнең асылына төшенә алмыйча торды. Күңеле белән ул моңа әзер түгел иде әле. Әллә инде колакка бик ят хәбәр булгангамы, ул, бер мәл һични аңламастан, эшен дәвам итте, ләкин колак читенә эләгеп калган хәвефле хәбәр, бер минут үтүгә, зиһенен гүя кисәү белән көйдереп алды: «... утыз өченче скважина тоташ су бирә башлады», — дип кабатлады ул эшнең асылына төшенгәндәй. Шунда ук күңеленә яман бер шом инде, бу шомның ул кайчан да булса киләсен белә иде, ләкин бүген түгел, айдан-айга планны арттырып үтәп барганда түгел. Мондый чакта бит коллективка премияләр дә эләгеп куйгалый. Квартал планы тулуга бик аз гына калгач әнә нишләде: кинәт ятмадан нефть алу күзгә күренеп кими башлады. Контрольгә куелган скважиналардан тоташ су килә. Болай булганда гамәлдә булган күп кенә скважиналарны туктатырга туры киләчәк. Ә Берләшмә нефть таләп итә. Тагын, һич югы, бер-ике елга гына җир маен суырту бүгенгечә дәвам иткән булса, күпме нефть алынган булыр иде! Кем белә, яхшы эшләгәне

өчен ул арада Кадыйрны да күләгәдә калдырмаслар иде. Кадыйр урыныннан торып ишеккә таба атлады.

Дөресен әйтергә кирәк, скважина янына барыр юлга чыккач та, инеш буендагы очы зәңгәр һавага төбәлгән челтәрле вышканы күргәч тә, машинадан төшеп, биредәге кешеләр белән сүзсез генә күрешкән чакта да, махсус казылган казан сыман чокырга дүрт дюймлы торбадан гөҗләп-күбекләнеп агып яткан саргылт ят суга күзе төшкәч тә кабинетта ук күңеленә иңгән шом кимемәде, киресенчә, мондагы күренешнең асылына төшенә барган саен, ул хәвеф, тагы да үсә, зурая, көчәя барып, үзенең югары ноктасына җитте: Кадыйрның йөрәге кысылып алды, ул һични күрмәс күзләре белән болганчык суга кабат текәлде. Кемгә ничек, аңа гаять авыр иде моны күрүе.

Тик бер ара узгач кына Кадыйр тирә-янындагыларга — баш инженер Идрисовка, баш геолог Сибирцевка, промысел мөдиренә күз йөртеп чыкты. Хәвефнең асылына төшенү, идарә өчен фаҗига булган бу хәлгә инану аларга да җиңел түгел иде, күрәсең. Алай дисәң, баш инженер бер дә ах килеп борчылмый сыман. Промысел мөдире Идрисовка кулын селти-селти нидер аңлатырга тырыша, нәрсәнедер ачыкларга телиме, баш инженерның күзләренә төбәлеп, сөйләвеннән туктап, җавап көтә. Әмма баш инженер бер якка да дәшмәгәч, сабыры төкәнеп, янә кулын болгый-болгый нидер аңлатырга керешә иде. Әйе, промысел мөдиренең үз кайгысы кайгы — тоташ су бирә башлаган скважиналарны тизрәк гамәлдән алдыру. Аннары промыселга төшерелгән план киметеләчәк. Мөдир манарасыннан гына караган кешегә бу бик тә мөһим һәм житди хәл булса да, идарә башында утыручы Кадыйрга бер дә җиңел түгел иде. Чөнки Кадыйр биредәгеләрнең барысыннан да биегрәк манара кешесе бит, тоташ су бирә башлаган скважиналар идарәнең тез астына сугасын, аның бөтен фаҗигасен бер баш геолог Сибирцев белсә беләдер. Әнә ул Сибирцев, бер урынга кадаклангган сыман, болганчык суга караган да уйга чумган, аның һәр чак, һәр мәлдәге сабыр йөзендә чын мәгънәсендә борчылу чалымнары. Әйбәт белгеч буларак, ул аңлый булса кирәк: ятма сүнүгә таба бара. Тиз арада ул гына түгел, биредәге барча белгечләрнең дә монда кирәге калмас, ямьле инеш буенда кукраеп утырган челтәрле вышканы да кискәләп металлоломга озатырлар, җир астына күмелгән үрмәкүч пәрәвезедәй торбаларның беришесен казып алырлар, байтагы исә мәңгегә җир куенында калыр... Скважиналар тирәсендәге чокыр-чакырлар күмелер, тигезләнер, сөрелер, ә бер-ике яздан меңләгән тонна кара алтын биреп яткан җирләрдә дулкынланып игеннәр үсәр. Гомумән, кечкенә район үзәгендә чирек гасыр эчендә калкып чыккан шәһәр киңәю һәм үсүдән туктар, анда яшәүче меңләгән белгечләр исә яңа ачылган нефть төбәкләренә күчеп китәрләр. Ә биредә барысы да утырып калыр. Ничәмә-ничә миллионнарга төшереп салынган нефть кудыру, нефть эшкәртү корылмалары да, гаять зур установкалар да, промысел биналары да, катламга су кудыру станцияләре дә — һәммәсе дә хәрабәгә әверелер, яисә иген игүче, терлек үстерүче совхозларга бирелер. Билгеле инде, оптимистлар да табылыр. Бу чарасыз хәл, безгә кадәр дә, бездән соң да шулай булган һәм шулай булачак, диярләр. Кадыйр кебек соңгы чиккәчә өмет белән яшәүчеләр дә табылыр. Табылмыйча булмас. Әмма кем генә менә бүген, монда басып торучы кайсы белгеч кенә әйтә алыр икән ятмада күпме нефть калганлыгын да, аның күпмесен алып булачагын? Бәлкем ике-өч айдан ятма бөтенләй сүнеп куяр, ә бәлкем тагын уннарча еллар шушы ятмадан нефть суыртырбыз. Моның шулай буласына ышанса, бер баш геолог ышанадыр. Ләкин бер баш геологның гына ышануыннан ни файда?! Теге вакытта катламга кислота белән тәэсир итәргә дигән ысул белән җенләнеп йөргәндә, Берләшмә рөхсәтеннән башка дияргә була (бер Кудрявцевка гына хәбәр иткән иде

Кадыйр), Кадыйр баш геологка ысуляны сынап карарга ризалыгын биргән иде, тау инспекциясе эшне сизеп алып, әйбәтләп туктаттылар, әитмәсә, Кадыйрга каты шелтә алырга туры килде. Дөньядагы бөтен табылган ятмаларда да илле процентка чаклы нефть алынмыйча кала. Шул калган нефтьне җир куеныннан алу турында уннарча идеяләр йөри, ләкин берсенә дә ышанып керешерлек түгел. Уңайлары бар, әмма зур чыгымга бәйле. Билгеле, катламның нефть бирү сәләтен үстерү юнәлешендә Кадыйр җитәкләгән идарә дә шактый эшләр башкарды. Тик бер генәсе дә тиешле һәм көткән нәтиҗәне бирмәде. Шуннан соң өмет өзелде.

«Әллә соң барысына да кул селтәп, Төмән якларына китеп барыргамы?» — дип уйланды Кадыйр һәм, шушы уеннан арына алмыйча, тау итәгендәге күрше скважинаны күздән кичерде. Кайчан гына әле бу җирләргә мәңгегә килгән кебек йөри иде. Кайчан гына әле алар эшкәрткән ятмада җир мае мәңге бетмәс кебек иде. Болай буласын ул чакны күз алдына китереп караучы да булмады шул. Нефтьне күпме булдыра алганча суырттылар да суырттылар, технологияне бозган чаклары да булгалады. Гүя җир дә, кайчан да булса нефть бетәсе ятма да аларныкы түгел иде.

Кадыйр каш астыннан гына скважина тирәсендәгеләргә янә күз йөртеп чыкты. Шул чагында ул бирердәге кешеләрнең сөйләшүләрендә ишетелгән, чырайларына, кыяфәтләренә үк ингән, бер сүз белән генә әйтеп тә, аңлатып та бирә алмастай киеренкелек барлыгын белде. Гүя алар мәет тирәли басканнар да, яман хәвефле хәлдән һәлак булган берәү белән хушлашалар иде. «Ә бит бу, чынлап та, шулай, — дип уйлады Кадыйр. — Бүген алар өчен дә, минем өчен дә бу скважина үлде, шушы сәгатьтән, ә бәлкем әле шушы минуттан ук бу «кое» инде бер литр да җир мае бирмәс. И-х, ә бит кайбер оптимист геологларның прогнозларына караганда, бу ятмадан кимендә тагын ун елга якын нефть суыртырга тиеш идек. Әйбәт прогнозларны, фәнни яктан начар нигезләнгән идеяләрне биргән агайларның күбесе доктор исеме алды, ә ятма исә алар исәп тоткан нефтьнең яртысын да бирмәстән сүнә башлады...»

Кадыйр Әмировка аерата авыр иде. Хезмәтен ул нәкъ менә шул идарәдә гади оператордан башлады. Шул вакытта ук инде ул ятмада кайчан да булса нефть бетәсен белә иде. Ләкин үзе идарә начальнигы булгач түгел, кварталдан-кварталга макталып килгәндә түгел.

Кадыйр кул тирәсендәге белгечләргә янә күз йөртеп чыкты. «Әйе, бу барыбыз өчен дә фаҗига,» — дип, Сибирцевка таба кузгалды.

— Михалыч, юкка агызмаска, суны ябарга кирәк, җҗ-ии-рр-не пычч-рра-та! «Бу ни тагын, нигә болай тиктомалга, мәктәп елларындагы кебек тотлыга башладым әле, нигә болай каушыйм?»

Идарә начальнигының тотлыга башлавына баш геолог та аптырабрак калды бугай, бер тын Кадыйрның күзләренә текәлеп карап торды. Ләкин шигәюен сиздермәде.

— Пычрак су гына түгел бу, Кадыйр Сөнгатович, гарәп экиятчесе шешәсеннән чыккан җен, — баш геолог, каерылып, промысел мөдиренә дәште. — Задвижканы ябыгыз да, скважинаны гамәлдән алу өчен документлар хәзерләгез.

— Вышкаларны, трап-мерникларны кисәкләргә һәм тиз арада металломга озатырга, — дип боерды алар янына килеп баскан баш инженер Идрисов. — Металлолом тапшыру планың үтәлде дип уйла, — диде ул промысел мөдиренә һәм һич урынсыз кеткелдәп көлеп куйды.

Кадыйр баш инженер ягына күз агын актарып карап алды. Әмма бер сүз дә әйтмәде. Урыны бу түгел иде. Шулай да: «Мона үгез үлсә — ит, арба ватылса — утын», — дип, ачуы чыгуын сиздererлек итеп:

— Вышкага, трап-мерникларга кагылмый торыгыз, — дип боерды. — Ашыкмагыз әле ул хәтле, иптәш Идрисов, һәммә нәрсәне гамәлдән сызарга.— Һәм, Идрисов белән сүзе бетүен аңлатып, баш геологка таба борылды: — Иптәш Сибирцев, бөтен булган мәгълүматларыгыз белән ике-өч көннән миңа керегез, — диде.

Машина тирбәлә-тирбәлә олы юлга чыкты, шоферы аның белән сөйләшмәде, начальнигының кәефе юклыгын иртән иртүк шәйләп алган егет, шуңа күрәме, автомобиле олы юлга чыгуга, аны шактый зур тизлек белән куалап китте.

— Әкренрәк кайт әле, әллә нигә кәеф китеп тора, — диде аңа Кадыйр, машина йөртүчесе ягына карамый гына. Шофер тизлекне баса төште, юлның уң ягынарак алды. Шул мәлдә, ут өереп, аларны ике жиңел машина узып китте. Шунысына гаҗәпләнә калды шофер: кәефе юк чакта шефы, киресенчә, җил кудырта торган иде, бүген исә акрын кайтырга куша.

— Идарәгәме?

— Идарәгә, — диде Кадыйр, күзен машина астына тасмадай шуып килгән юлдан алмыйча. «Әллә соң ашыга төштекме? Илгә «кара алтын» күпләп кирәк диделәр — күпләп бирдек, ятманы рәхимсезрәк эшкәрткән чаклар да булгалады, нефтькә ияреп кыйммәте исәпкә алынмаган газ чыкты, аны яндырдык, җилгә очырдык, җыймадык, эшкәртмәдек. Бактың исә, ул газыбыз да гаять кыйммәтле чимал булган икән. Хәзер әнә бер Әлмәт газ заводы гына да тәүлегенә меңләгән кубометр чимал эшкәртә. Ә бит ул газны бер-ике ел алданрак эшкәртергә керешкәндә дәүләтебез күпме файда алачак иде»,— дип уйланды Кадыйр, нигәдер өметсезләнеп.

Кадыйр боларның барысы турында бик әйбәт белсә дә, үзалдына сөйләнә торды. Җавап көтмәде ул. Һәр чорның үз техник мөмкинлеге, үз кыенлыгы була. Кешелек алдына куелган кыенлыкларны бары тик прогресс, фәнни-техник яктан җитлеккәнлек хәл итә. Ни генә булмасын, күңел дигәнең булган хәл белән нигәдер ризалашасы килми. Катламда каласы илле процент нефтьнең һич югы ун-унбиш процентын алу өчен иртәрәк керешергә кирәк булган. Никтер әлек Кадыйрның башына бер дә мондый уйлар йөгермәде. Уңай гына тәкъдимнәрдән баш тарткан чаклары да булмады түгел. Эше, мәшәкате күп иде, я шактый чыгым соралды. Бәлкем әле хәзер дә соң түгелдер. «Кара алтын» чишмәләрен юмартландыру юлларын эзләргә кирәк. Бик кирәк!

Юлның ике ягында да ак каеннар тезелеп киткән. Әле куе яшел төскә кереп җитмәгән яфракларда кояш нурлары уйный, ул да түгел, агач башларын чайкап, җил йөгереп уза һәм шул тирәдәге зәңгәрлек кисәк кенә күк гөмбәзенә барып тоташа. Төньяк тарафта өер-өер күксел-соры болытлар күренә. «Эшләр болайга таба дәвам итсә, тиздән безгә дә Төмән якларына китәргә туры килмәгәе, — дип куйды Кадыйр үзалдына. — Ятмаларның егәрлеләре төньяк-көнбатыш Себердә хәзер, Төмәндә. Их, төшеп карасаң икән шул девон катламына, ятманың мәгарә эчен яктыртып, томаланып калган нефть күлләрен барлап чыксаң икән. Менә кая нефть чыгаруда сикереш, менә кайчан башланыр иде җир маен алуда яңа этап... Ә Төмән якларына китәсе килми. Килми генә бит, шайтан алгыры. Ничек килсен ди! Канатны монда чыгарды, монда җитәкче булуга ирешә. Өстенә дан-шөһрәтләр ишелеп килмәсә дә, күңеле белән сизә-тоя иде — анысына да озак калмаган. Ә бит чын җитәкче кешегә колач җәеп эшләрдәй мәйдан булмаган хәлдә, ул көне белән гадиләшә, тиз арада югары даирәдә утыручы агайлар өчен провинция җитәкчесенә әверелә. Аңа игътибар итми, аны күрми башлыйлар. Идарә начальнигы булып килер алдыннан дөнья күргән берәү әйткән иде ана: «Җитәкчелеккә омтылсаң, вакланма, колачлы идеялар белән эш ит», — дип. Хак әйткән икән. Промыселда гади

инженер булып эшләгәндә дә, аннан акрын гына идарә тирәсенә үрмәләгәч тә, ниһаять, идарә начальнигы булып күтәрелгәч тә — беркайчан да Кадыйр ул кешенең киңәшен онытмады. Онытмады, әмма начальник булып алуга, дәвергә тиң колачлы идеяләр белән дә янмады.

Идарә начальнигы булганчы да, хәзер дә Кадыйр акыллы киңәшчегә мохтаҗ иде. Бүген кем бирер аңа киңәшне? Кудрявцевмы? Ләкин Кадыйр әллә нигә яратып бетерми иде шул кешене.

Кудрявцев. Ә бит алар бер институтны тәмамлаган кешеләр. Бер курста укыдылар, хәтта бер кызны икәүләп яраттылар. Ул гынамы, институт тәмамлагач, бер Берләшмәгә эшкә килделәр. Килә-килүгә, Кудрявцев үзен яхшы яктан күрсәтеп тә алды. Нефтьне махсус установкада җылытып судан һәм тоздан аеру өчен яңа ысул тәкъдим итте. Берләшмә өчен генә түгел, ил күләмендә шактый файда бирәсе бу ысулны белгечләр күтәреп алдылар һәм бер рәттән Кудрявцев та Берләшмәгә күчеп утырды. Кадыйр шул хәтлесен дә белә: яңа төр установканың идеясен Кудрявцевның хатыны Наташа биргән. Әмма тәкъдим Кудрявцев тарафыннан гына куела һәм дан-шөһрәткә, әлбәттә, ул гына лаек була ала. Хәзер энә нефть житештерү начальнигы. Хатыны Наташаны да онытмадылар, Берләшмәнең геология бүлегенә начальник итеп куйдылар.

Кудрявцевны өнәмәү Кадыйрда институттан ук калды. Әйтелгәнчә, башта алар икесе бер кызны яраттылар. Яраттылар, әмма кыз соңгы чиктә Кудрявцевны сайлады. Ләкин бер шуның өчен генә ачу тотмый иде Кадыйр аңа, яшьлектә яраткан кызың башка берәүгә кияүгә чыккан өчен гомер буена ачу тоту, ким дигәндә, ахмаклык булыр иде. Гади генә әйткәндә, төп сәбәбе ул түгел иде, әмма дә ки бу хәлне оныту да мөмкин түгел, ул, тутык корты кебек, һәр чак күңелне кымтырыклап тора. Кыскасы, ни өчен Кудрявцевны яратмавын ул кинәт кенә әйтеп бирә алмас иде. Чынлап та, алар арасындагы киеренке мөнәсәбәтнең сәбәбе Кадыйрның әлегә чаклы Наташага булган мәхәббәтеме әллә?.. Әйтсәң, кеше ышанмаслык хәл бит. Күпме еллар үтте, күпме сулар акты, күпме нефть алынды шул гомер эчендә, ә ул, дивана, әле дә булса шул хатынга мәхәббәт белән яна дисәң?.. Юк инде, үткән эшкә — салават, ә менә Наташаны күрүгә күңеле актарыла да китә. Хатынның турыдан-туры шул турыда үзенә әйтүдән чак кына тыелып кала.

Ике ир арасындагы киеренке мөнәсәбәт хәтта хатыннары үзара танышып, дуслашып, йөрешеп киткәч тә бик аз үзгәрде. Кудрявцев аның турында ни уйлый торгандыр, әмма Кадыйрның күңелендә үпкәрәнҗүгә хас юшкын утыра, кырык бишне тутырып узды, онытасы иде, онытырга бик вакыт, тик никтер һич онытып булмый. Ике араны йомшарту өчен бергә эшләп уздырган гомер дә бик житкән бит, югыйсә, әмма күңел барыбер ризалашмый. Дөрес, соңгы вакытта Кадыйрны пошаманга салган бер хәл булып алды. Ике ана танышып, үзара йөрешеп, дуслашып киткәч, Кудрявцевның улы Сережа көн аралаш диярлек Гөлүсә янына йөри башлады. Күреп кенә түгел, бу хәлнең ни белән бетәсен җаны-тәне белән сизеп алган Кадыйр, ике яшь йөрәктә бөреләнә башлаган мәхәббәтне бер чабуда өзәргә булды.

— Ни калган бу Сережага биредә, — дип, тиктомалга хатыны Зөһрәгә ябырылды ул. — Атна саен ике арага килеп сара. Якын арамы? Әлмәт хәтле Әлмәттән. Эшлиме хет үзе! Эшләми дәмени әле... Ә мотоциклны кем акчасына алган?..

— Атасы алып биргәндер, — дип кенә куйды Зөһрә, иренең нигә ачуы чыгуын абайламыйрак торды. Әмма зирәк хатын ирнең сүз сөрешен шәйләп алуга, авыз чите белән генә елмаеп куйды да: — Туктале! Нигә әле син урта гасыр картлары сыман сукрана башладың. Әллә соң унҗиде яшьлек кызыңны бик астында тотар идеңме?!

— Ә син унны да тәмамламаган кызыңны тотып кияүгә бирер идеңме?! Тутырып кайтканны көтәсеңме! Эзе булмасын кыз тирәсендә ул сорнайның, — дип кырт кисте Кадыйр. Тик аның кырт кисеп ташлавыннан һични үзгәрмәде. Сережа «Ява» мотоциклына атланып, Гөлүсә янына көн аралаш килеп йөрүен дәвам итте. Гөлүсә аны капка янына йөгереп чыгып каршы алды, шлем кигән килеш аякларын бер якка салындырып утырып, чатка кадәр мотоциклда озата барды. Моны күреп, Кадыйр яңак итен чәйнәде, кашын-күзен җимерде, ләкин өйдәге чүпне тиз генә урамга чыгарып түгәргә ашыкмады. Кеше ни әйтер? Наташа ни уйлар?.. Шул ук вакытта күзенә Сережа чалынган саен, үз-үзенә урын таба алмый изаланды...

Машинадан төшкәч тә, озын коридордан кабинетына узганда да Кадыйр берәүгә дә күтәрелеп карамады. Бүген аның бер кем белән сөйләшәсе дә, бер кемне күрәсе дә килми иде.



3

Туган якның туфрагы гына түгел, һавасы да шифалы икән. Автобус шәһәргә якынаюга, Нәүфәл ачык тәрәзәдән башын тыгып, шифер түбәле бишәр катлы йортлар тезелеп киткән якка карады. Туып-үскән өен күрмәсә дә, ул үзендә сәер бер дулкынлану тойды. Күз алдына әнисе килде. Гүя анасы аны ишегалдына чыгып көтеп тора, гүя үсеп-киңәеп, ир уртасы ук булмаса да, буйга ныгып киткән улын танымый маташа һәм янәшәсендәге күршесенә: «Синең күзләрең үткенрәк, кем Шәмсениса, бирегә таба килүче кем ул? Йөрүләре минем Нәүфәлнекенә охшаган», — дигән була. Ләкин ана улын күптән таныган, күңелен тынычландыру өчен генә күршесе белән сөйләнә икән. Нәүфәлнең күз алдына янә бер сурәт килеп баса: улының тавышын ишетүгә, әнисе кабаланакаударлана аңа каршы килә, әмма улының кәкре муенын күрүгә, кисәк туктап кала, шикләнеп куя сыман. Ул да түгел, йөгереп килеп кочаклый, сагыну-кызгану хисе белән өртелгән күз яше белән елый, ә үзе Нәүфәлнең муенындагы җөйләрне капшаштыра. «Балакаем, нигә инде шул гомерләр кайтмый йөрдең!» — дип, өзгәләнеп елый.

Автобустан төшеп, таныш урамнардан атлаганда да, тротуар буйлап утыртылган тупылларның буй алып китүләренә сокланып барганда да Нәүфәл әнисе белән очрашу тәэсиреннән айный алмады. Тик шәһәрнең илленче елларда салынган ике катлы таш йортлары янына җиткәч кенә уйларыннан бүленде. Алар өенең подъезды каршында буй-сыны, төсйөзе таныш булган үсмер кызны күргәч, хәтта елмаеп та куйды.

— Исәнмесез-саумысыз!

— Исәнмесез, Нәүфәл абый! — диде кыз Нәүфәлне шаккаттырып.

Нәүфәл бер мизгелгә карашын кызның иңнәренә сибелеп төшкән чәчләрдә туктатты. Нәүфәл унынчыда укыганда бу кызны беренче класска үзе илткән иде.

— Исемең Нәҗибә бит синең?

— Нәҗибә.

— Гел җиткән кыз булгансың.

Шулай диде дә Нәүфәл, йөгерә-атлый, икенче катка менеп китте. Баскычларга баскан саен йөрәге ашкыныбрак тибә башлады... Әнисе аны аңлар, югалып йөргәне, хат язмаганы өчен кичерер. Нәүфәл аның күкрәгенә башын салыр да гафу үтенер, кичерүен сорар... Әнисе аның нечкә күңелле кеше, улын аңлар, хәленә керер. Ул аңа институтны тәмамламый торып туган якларга кайтырга теләмәве турында кат-кат аңлатыр. Барысы турында да сөйләр: бик интегеп укуы һәм институтта ук кандидатлык диссертациясен якларга тырышуы, әле булса шул хыя-

лын ташламавы — барысы-барысы турында да бәйнә-бәйнә сөйләп бирер һәм әнисе улының хәленә керер.

Менә аларның кыңгырау төймәсе, ишеккә кадакланган почта ящигы.

— Нәүфәл абый, Нәүфәл абый. Анда хәзер ике ел инде... бүтән кешеләр тора.

Әйтерсең башына ни беләндер китереп тондырдылар Нәүфәлнең — бер мәлгә зиһенен җыя алмый торды. Тамак төбенә төер килеп бөялде, күз төпләрен әчеттереп, бите буйлап кайнар яшь бөртекләре тәгәрәште. Башын почта ящигына төртте дә, бер тын сүзсез торды.

— Нәүфәл абый, әйдәгез безгә. Әти хәзер эштән кайтыр.

— Рәхмәт, Нәҗибә акыллым. Кергән чаклар да булыр әле.

Чемодан белән портфелен алды да түбән төшеп китте. Беренче катка җиткәч туктады, һични күрмәс күзләре белән бала чакта ишек-стеналарга ясалган сәнгать «җимешләренә» карап торды.

Нәүфәлне әнисе бик нужаланып үстерде. Бик авырлык белән, михнәт-хәсрәтләр күрә-күрә үстерде. Инде кул астына керә башлады, инде балигъ булды дигәндә генә эттән таланып, гарьлегеннән баш алып, кай тарафларгадыр китеп барды үсмер.

— Әйберләрегез Кадыйр абыйларыгызда, Нәүфәл абый, — диде артыннан ияреп төшкән Нәҗибә.

— Абыйлар һаман шул Таулы урамында торалармы?

— Әйе, җиденче өй. Кызлары Гөлүсә белән бер класста укыйбыз.

Нәүфәл, уйларыннан арынып, янә кызга күз төшереп алды. Һәм күрше кызы Нәҗибәне түгел, гүяки сеңелесе, әтисе белән бертуган абыйсының кызы — Гөлүсәне күрде. Нәүфәл унынчыда укыганда Гөлүсәгә нибары җиде-сигез яшь иде. Хәзер ул да танымаслыктыр инде...

Таныш беседкалар, коймалар, өйләр. Тротуар белән машина юлы арасына утыртылган юкә, тупыл агачлары. Кеше-мазар күренми. Хәер, Нәүфәл тирә-ягына карап барыр хәлдә түгел иде. Ул табутта ятучы лимондай сары йөзле әнисен күз алдына китерде. Әнисенең табуты янында аның белән бергә эшләгән хатын-кыз, ә баш очында Кадыйр абыйсы белән җиңгәчәсе Зөһрә. Бер читтәрәк, аз гына кәефләнеп алган, торак бүлегендә слесарь булып эшләүче күршеләре Мөхәммәтҗан. Ул аскы иренен бүлтәйтеп чыгарган да, борын астыннан гына мыгырдана:

— Улы кая соң, мать якасы?! Карагыз әле, туктагыз әле, Кадыйр Сөнгатович, улын нигә чакырмадыгыз? Ник хәбәр итмәдегез! Исәндер бит? Вәт агайне, нинди халык китте, улына да хәбәр итмәгәннәр...

Нәүфәлгә бу турыда уйлавы кыен иде. Үкенүләренә йөрәге кысылудан башын чайкап куйды. Моңа кадәр үз мәнфәгатен генә кайгыртып йөрүе, эт тешләгәннән соң гарьлегеннән кай тарафларгадыр чыгып китүе ким дигәндә ахмаклык булып тоелды.

Уйларын каршыга очраган бер карт бүлдерде.

— Һай, ни, туктале! Әттәгенәсе, Саҗидә малае түгелме соң? Билләһи, Саҗидә малае бит син! Шыл, шыл, билләһи-валлаһи, шыл. Исәнмимсең икән бит, дивана. Кайларда йөрдең?! Тәмам атаң сыңары икәнсең, туганкаем. Ул шулай өч-дүрт елга бер кайтып, күренеп китәр иде. Әйбәт кеше иде атаң. Эшли дә, яши дә белә. Мәрхүмдер инде, кайтмавына бишбылтыр. Катыны көн күрсәтмәде шыл, әчәсең, бар тапканыңны шул аракыга түгәсең дип күзен дә ачырмады. Азмы-күпме бергә эшләгән иек. Шәп кеше иде,— дип җупләп куйды карт. Шунда гына Нәүфәл картны таныды. Ярым кәмит, ярым дәрвиш бу кешене тануга, Нәүфәл тизрәк киту ягын карады.

— Күр әле моны, танымадыңмы әллә мине, — дип, карт аның җиңенә ябышты.— Чөгәдәй карт мин, бөтен шәһәрдә бердәнбер бүрекче.

Җиде дистәне тутырып та дөньяви хәлләрнең тәки асылына төшенә алмаган, үтә җор телле, шәһәрдәге һәр яңалыкны кимендә иман итеп кабул итәргә өйрәнгән Чөгәдәй карт Нәүфәлнең кайтуын иртәгә үк бөтен шәһәргә таратачак. Нәүфәл хәтта аның ничек сөйләп йөриячәгенә хәтле күз алдына китерде. «Ишеттеңме әле, Гөлнәзирә кодача дим, сиңа әйтәм, былтыр дөнья куйган чәч ыркучы Сәҗидә малае кайткан. Шәп инде, гаҗәеп шәп, муен кәкре, бар байлыгы бер чумадан»...

— Мин китим инде, бабакай.

— Карале, энекәш, рәтләп сораша да алмадым бит әле үзеңнән. Ниме, сине шул мәр кызы Халисәме әле эттән талаткан иде?.. Кияүгә чыкты инде ул кәнтәй. Һай, малайны харап иткән бит, әй!..

Нәүфәл карт яныннан ашыга-ашыга китеп барды. «Әллә соң абыйларга да кереп тормаскамы? Турыга, Пермьгә Петр янына китеп барыргамы? Сүнеп барган нефть ятмаларын цикллап эшкәртү мәсьәләсен аңлатып язгач, кил, уйлашырбыз, килешсәк сынап карарбыз, дип язган иде,— дип уйланды Нәүфәл, адымын кызулата барып.— Әни турында да сорашмыйчамы? Халисәне күрмичәме?! Юк, юк, мин аны күрергә тиеш. Ни дип өстерде микән этне?..»

Әле булса хәтерендә, больницадан чыгарга ике-өч көн калгач, палатага күршеләре Җәмилә килеп керде. Больницада няня булып эшләүче бу хатын аларга еш кына чәй эчәргә кергәли торган иде.

— Син аны судка бир, юләрем. Шаһитларың бар. Чөгәдәй карт белән карчыгы койма аша барысын да күреп торганнар. Хәйдәр кызы этне сине бугазлатыр өчен өстергән...

Нәүфәл шунда башын гына чайкады. Әмма күңеленә кереп калган көтү бик озак бәгыренә төшкән эремәс таш булып йөрде.

Әйе, кем әйтә ир-ат хатын-кызга үч тотмый дип! Кем моны ничек исбат итә ала?! Дөрес түгел! Кайчандыр адәм көлкесенә калдырган Халисәгә Нәүфәл әле булса ачулы иде. Күзгә-күз очрашкач, бәлкем ул аңа авыз ачып сүз дә әйтә алмас. Әмма барыбер күреп сорыйсы килә үзеннән: ни дип өстерде икән этне? Әлбәттә, яраткан егетен боторлап ташласын димәгәндер. Алай уйлыйсы килми иде Нәүфәлнең. Шулай ук яратмавы булды микәнни?..

...Каршы алу, күрешү хәлләре табигый булды. Кадыйр абыйсы ишегалдында нидер эшләп йөри иде, капкадан кереп килгән Нәүфәл энесен күрүгә, аңа каршы китте һәм исәнлек-саулык сорашуга өйгә ашыктырды. Нәүфәл кулыннан чемоданын алгач авырлыгын чамалап, селеккәләп торды.

— Ни бу чемоданда? Таш тутырмагансыңдыр бит? Һич күтәрмәле түгел.

— Китаплар. Бөтен байлыгым шунда.

Өйгә кергәч, Нәүфәлне күрүгә, җиңгәчәсе башта аптырабрак калды, соңыннан танып алдымы, алъяпкычына тиз-тиз сөрткән кулларын күрешергә сузды. Нәүфәл өс-башын салып, кулын юып чыккан арада табын хәзерләнгән, өстәл түрендә кукраеп бер шешә шәрап утыра иде инде. Баеп барган кояш нурында бәллүр рюмкалар җемелди. Табын янына утыруга, Кадыйр абыйсы хатынына ишетелердәй итеп тамак кырды.

— Хәзер, хәзер,— диде җиңгәчәсе кухня ягыннан.— җитешә торыгыз. Менә өчпочмакны гына карыйм да. Мактап йөрисең икән әле үзебезне, Нәүфәл.

Кадыйр абыйсы энесенең кәкре муенына янә текәлеп карап алды һәм нигәдер башын чайкап куйды.

— Әниең гүр иясе булды инде, Нәүфәл. Яшәгән җиреңне белмәгәч, хәбәр дә итә алмадык үзеңә.

— Гафу ит, абый. Яшьлекмедер... Инәй алдында гаебем зур, мәрхүмнең бәхиллеген дә ала алмадым. Гаебем зурлыгын бер үзем генә

белән. Кыен булгандыр мәрхүмкәйгә. Ни әтәй китеп югалды, ни мин дигәндәй.

Кадыйр аны тыңлады да, тыңламады да. Ул бертуган абыйсыннан калган малайның үзгәрүенә шаклар катып утырды. Әни дигән була, гаебем зур дигән була, ә соң шул гомергә бер хат яздыңмы хет әниенә? Юк. Хәер, Кадыйр малаеңны эзләтик дигәч, җиңгәчәсе үзе кирәкмәс дип каршы төшкән иде.

— Атасы сыңары, йөрер-йөрер дә әйләнеп кайтыр әле, — диде.

«Әйе, — дип уйлады Кадыйр каш астыннан гына һаман энесен күзәтеп. — Тәмам адәм хуры иткән эт бу егетне, кеше кыяфәте калдырмаган үзендә».

— Кайларда йөрдең инде, ниләр кырдың? Сер булмаса бәлкем сөйләп бирерсең?

— Булды инде хәлләр, абый, — Нәүфәл каршыга килеп утырган җиңгәчәсенә дикъкать белән карап алды. — Йөри торгач, Грозныйга барып чыктым. Нефть идарәсенә эшкә урнаштым. Күз күне институтка сынау бирдем. Укулары авыр иде, стипендиядән колак каккан айлар да булгалады. Сүнә башлаган нефть ятмаларыннан цикллап файдалану дигән темага институтта ук диссертация язарга керешкән идем, теория ягы тәмамланса да, сынап карап булмады. Мәйдан бирмәделәр. Кайтуымның төп сәбәбе, абый, шул идеяне биредә сынап булмас микән дип өмет итү иде.

Нәүфәл болай да кәкре муенын тагы да авыштыра төшеп, текәлебрәк абыйсының күзенә карагач, Кадыйр бер мәлгә ни әйтергә белми аптырап утырды. Килеш-килбәте котсыз булса да, фикер сөреше кызык иде, егет бер дә дөнья арбасыннан төшеп калганнарга охшамый.

— Нигә дәшмисез, абый? Көтмәгәндә кайтып төшүемә аптырап калдыгызмы?

— Нигә, бер дә аптырамаслыкмыни? Кайлардадыр югалып йөрде дә галимнәрнең генә башына килә торган нәрсәләр турында сөйләп утыра. Монда, кем әйтмешли, энең шул турыда хәбәр итмәсә дә, аптырамаслык түгел хәл. Ис итмәгәндә кайтып керүеңә гаҗәпләнмәдем, ә менә сүнеп барган нефть ятмаларын цикллап эшкәртү идеяң белән кызыксынуым хак. Без менә бүген Татарстанда шул хәлгә калдык. Ятма сүнә, скважиналар тулып су килә башлады. Үзеңне кем дип белик инде?

— Автоматчы. Инженер-автоматчы, ә эшләвен геолог булып эшләдем.

— Анысына гаҗәпләнмим. Диссертация темаң кызык күренә. Сер булмаса, бәлкем сөйләп, аңлатыбрак бирерсең.

Нәүфәл нигәдер бер тын дәшми торды, суынып барган чәен калак белән болгата башлады.

— Яшьлектәге бар хыял да тормышка ашса икән ул, абый. Тегендә дә башта бу идеягә бик дәртләнеп тотынучылар булды. Хакыйкать дибез, тик аны табулары гына ансат түгел. Нинди дә булса бер яңа идеяне, тәкъдим янсә алым-ысулны институт бирсә бик табигый яңгырый, ә инде шул ук идеяне, әйтик, минем кебек муены кәкре бирәү бирсә, китә тикшерү, шикләнү, икеләнү...

— Нык ук кимсетеләрмени?

— Кимсетеләр дип. Булды инде. Иң әүвәл таяныр кешем булмады. Исемем юк, дәрәҗәм юк. Шул идеяне фән докторы бирсә икән...

— Моны син абыең идарә начальнигы икәнен белеп әйттеңме?

— Идарә житәкчесенә күтәрелүегезне газетадан укып белдем. Күпләп бүләкләр алган чакларыгыз да булгалады. Куандым, шатландым сезнең өчен.

— Алгаладык бүләкләрне. Байрагы да булды. Ләкин, энекәш, үтте хәзер андый югарыдан-югарыга күтәрелүләр, үтте. Разведчиклар бил-

гелэгэн нефтьнең яртысын да бирмичә, ятмабыз сүнә башлады. Траур бездә бүген. Девон катламыннан нефть алу көннән-көн кими бара.

Нәүфәл авыз ачып нидер әйтергә дә өлгермәде, дымлы һава яртеп, Гөлүсә кайтып керде.

— Исәнмесез, Нәүфәл абый! — диде кыз һәм, түргә узып, зурларча күреште. — Миңа сезнең кайтуыгыз турында Нәҗибә әйтте. Мин аңа сөенчегә бер кап конфет ышандырдым.

— Ышандырсаң ышандыргансыңдыр, — диде Зөһрә, кызы янына килеп, — юкка чытлыкайланып торма әле. Бар әнә дәресеңне кара. Гел тыштан кайтып кермәс була башладың әле син, кызый.

Гөлүсә зурлар янынннан теләр-теләмәс кенә чыгып китте.

— Өйләнмәдеңме соң әле үзең, бик елмаеп утырасың? — дип сорады Кадыйр.

— Өлгермәдем, абый. Анысы качмас ла. Идеяненң кулдан ычкынуы бар. Еллар буена йөрткән хыял инде ул минем.

— Хыял дисең, — диде Кадыйр, ашап бетермәгән өчпочмагын табын уртасынарак этәреп. — Хыял ул, энекәш, барыбызда да бар хәзер, аллага шөкер кылыйк. Соңгы вакытта җирдән йөргән реалистлар азая башлады кебек тоела миңа. Ачуым килмәсә әйтмәс идем, барысы да һавада талпына, эзләнә, сыный, тәҗрибәләр үткәрә. Каяндыр сынаучы инженерлар килеп чыкты. Ә производство? Бүгенге проблемаларны хәл итү белән кем шөгыльләнергә тиеш? Дәүләт тарафыннан план алган предприятиеме?! Кем?! Ә ятма сүнә. Моңа кадәр тәүлегенә унөч мең тоннадан артык нефть биреп килә идек. Ә бүген шул чыганак сүнә. Хет разбой сал. Идарәне промысел итәргә ыжгырып торучылар бар. Ә хыялыйлар бер читтә, бу хәл аларга кагылмый. Тапсалар иде шул хыялыйлар бер әмәлен. Әйтик, ятмадан, һич югы, тагын берничә процент җир маен кысрыклап чыгару әмәлен. Ату хыял да хыял...

Кадыйр күлмәгенең өске сәдәфен ычкындырып җибәрде, бармакларын өстәлдә биетергә кереште.

— Чыгарылган нефтьнең барысын да эшкәртеп өлгерәсезме соң?

— Һай, кыю халык китте дә соң, билләһи! Менә замана нишләтә кешеләрне. Колачла, рөхсәт дисәң — җир шарын инләрләр иде. Соң, алла бәндәсе, республикада шундый берәр идарә бармы, юкмы диген ичмаса. Кая ишеткәнең бар булмастай могҗизаны! Яртысын, нибары яртысын чистартабыз. Калганы чирек бәягә озатыла. Һәм ай саен меңләгән сум штраф түлибез. Кондициягә җиткерелмәгән нефть тапшырган өчен... Установка дигәннәре җитсә, мин ул нефтьнең яртысын гына түгел, һәр тоннасын алтын итәр идем.

— Ә мин сезгә шул ук установкаларыгыз белән барлык чыгарган нефтегезне чистартып озатырдай ысул тәкъдим итсәм, нишләр идегез?..

Кадыйр бу юлы энесенә шикләнебрәк, хәтта ышанмыйча карады, янәсе, шизик-фәлән түгелме? Үз акылындамы егет? Эт талаганнан соң акыл-зиһенена ул-бу булмагандыр бит? Соң, шулай димичә. Бу турыда Кадыйрга техник фәннәр докторы Троянов әйтсә бер хәл иде әле, бераз ышанырга да булыр иде, чөнки Троянов шул өлкәдә эшли-эшли чәчен агарткан кеше. Әмма бу турыда аның да үзеп кенә бер сүз дә әйткәне юк. Һаман сыныйлар, һаман экспериментлар уздыралар. Аннары доктор кулында менә дигән институт, лабораторияләр, белгечләр, исәп-хисап машиналары. Ә бу кем? Йөргән кызы унҗиде яшендә эттән талаткан, еллар буе югалып йөргән байгыш. Идарәдә моның кебекләрдән мин болай да гарык. Баш инженер Идрисов үзе ни тора: идарәне промысел итмәкче, баш геолог Сибирцев катламны кислота белән кузгатмакчы. Әмма алар да әле синең кебек шапырынмыйлар, энекәш. Дөрес, Идрисов белән минем үземнең дә килешәсем килми. Иртәрәк әле безгә бирешергә. Нефть бар, бар әле нефть катламда. Һич югы, күмер катламына күчәргә була. Дөрес, күмер катламының нефть составында кү-

керт кислотасы күп, яңа корылмалар, яңа техника кирәк булачак. Шулай да, өметсез бер шайтан ди бу дөньяда, чаң сугарга иртәрәк әле, иртәрәк.

Өстәл янына Гөлүсә килеп басты.

— Ә мин, әтием, хыялга, хыялымның тормышка ашасына ышанам. Хыялсыз кеше — канатсыз кош ул.

— Ә син зурлар сөйләшкәндә кысылма, — дип, кухня ягыннан энисе килеп чыкты. — Бар әнә дәресләреңне кара. Әдәбияттан өчле алып кайткансың, адәм көлкесе. Әкият бит ул әдәбият. Бар, бар, юкка үпкәләп авыз турсайтып торма... Син дә, атасы, таптың сөйләр сүз. Ун ел күрмәгән энесе кайткан, ә син һаман ятма да ятма. Кемгә кирәк ул синең нефтең?

Кадыйр хатыны ягына хәтта борылып та карамады.

— Калу ниятең юктыр бит? — дип сорады ул Нәүфәлдән.

— Ә нигә, күңелгә ятыш эш булса...

— Калу ниятең булса, берочтан кайда яшәү мәсьәләсен дә хәл итәргә кирәк, — дип, йорт башы, ниһаять, хатынына күз салды. — Син ничек уйлыйсың, энисе?

— Әтием, абый бездә торачак, — дип, янә атылып килеп чыкты Гөлүсә. — Потому что мин так хочу.

— Рәхим генә итә күрсен. Бүлмә бар, — диде Кадыйр, ә үзе һаман хатыныннан күзен алмый торды. Соңгы сүзне нәкъ менә үзе әйтергә тиешлеген аңлап алган Зөһрә бераз көттерде.

— Бүлмәңдә рәтләп йоклаганың юк, торсын шунда, — диде ниһаять, җиңгәчәсе. — Әтисе белән бертуган абыйсы була торып, тулай торакларда ятмас бит инде.

— Комачауламасам, кысрыкламасам, — шул турыда сүз кузгалуга, Нәүфәл төп тотканың кемдә икәнен шундук аңлап алган иде инде, ул да җиңгәсенең тегермәненә су коярга кереште. — Бөтен комачаулык, җиңгәчәй, сезгә төшәчәк. Шулай булгач, иң әүвәл сезгә рәхмәт. Ләкин мин бит әле калу мәсьәләсен хәл итмәгән. Пермьдәге сабакташым янына китәргә исәп бар.

— Ниемә дәшми утырган буласың, атасы. Бер энеңә эш тапмассыңмы шул идарәңдә?!

— Эш булыр, — диде Кадыйр шулай ук көттеребрәк. — Миндә, Нәүфәл, синдәй хыялый инженерлар аллага шөкер. Тагын берәү генә өстәлгәннән әллә ни зыян күрмәмдер, шәт. Аннары уе-хыялы чын булса, ул миңа чыгарылган нефтьне чистартып бирергә ышандыра бит, — дип көлемсерәде абыйсы Зөһрәгә карап. — Шул эшкә алына икән, автоматчылар цехына инженер итеп урнаштырырмын.

Нәүфәл абыйсының кинаясен ишетмәгәнгә салышты.

— Калган хәлдә минем бер шартым бар, абый. Минем карамакка әнә шул хыялый дигән ике-өч инженер һәм бер автоматчылар бригадасы бирәсез. Шул бригада белән ике-өч ай эчендә ун-уналты скважинаны бер трапка бәйләргә рөхсәт итәсез. Бу — бер. Икенчедән, миңа бер тәэминатчы билгелисез. Техник материаллар табу өчен...

Әле «сез», әле «син» дип сөйләшеп утырган энесенә ышанырга да, ышанмаска да белмәде Кадыйр.

— Алдан ук әйтеп куйыйм, мин пәйгамбәр түгел, эш процессында ялгышып куюым да бар. Ләкин соңгы нәтиҗәнең уңай булуына иманым камил.

— Риза булмасам?

— Әйткәнемчә, Пермьгә китәм.

— Ашыгып куян куалар, энекәш.

— Кайбер хәлләр мәҗбүр итә.

— Кайбер хәлләр, — Кадыйр торып йөренеп килде, энесенең иңбашына кулын салды. — Хәл итәсе проблемалар бездә хәзер...

— Проблемалар беркайчан да ансат чишелмәде. Бу — хакыйкать. Проблема ул диалектик төшенчә, абый, аны бары тик үсештә генә хәл итәргә мөмкин. Ә хәл итмичә безгә үсү юк, прогресс юк. Тәвәккәллек җитми безгә. Ә ул һәр житәкче өчен бик тә, бик тә кирәк, сыйфат хәзер.

Кадыйр энесен битараф бер кыяфәттә тыңлады. Зөһрә дә, Гөлүсә дә үз эшләре белән чыгып киттеләр. Күркәм, таза гәүдәле, төз сынлы, башын чөебрәк йөргән бу кешегә кем дә илле яшь бирмәс, хәлбуки, аңа шул тирә иде. Менә ул креслога җәелеп утырды. Бер тын уйланып алды. Зиһене шулай үткенме энесенең, табигате белән акыллы булып туганмы? Ләкин акыллы фикер бирүчеләрне моңа кадәр дә күп күрде инде Кадыйр. Меңләгән сум чыгымнар тота-тота алар биргән тәкъдимнәрне производствога кертте, тик нәтиҗә һаман ул көткәннән ким булды. Идея, тәкъдим бирүчеләр аны тагын ышандырырга керештеләр. Нәрсәсендер үзгәртергә, нидер өстәргә кирәк дип кайнаштылар, әмма бер гайрәте чиккән Кадыйр күп вакытта аларны кире борып чыгарды, артык чыгымнар тотуга бармады. Бу да зурдан кизәнә, җитмәсә, үз энем, хәерле булсын, дип уйлады Кадыйр, үртәлгәндәй.

— Скважиналарны группалап бәйләүгә технологик схемаларың, расчетларың да бармы, әллә идея булып кына йөриме?

— Кызыксынсагыз, хәзер үк күрсәтә алам.

Нәүфәл чемоданын алып килде, ачып, бик озак актарынды да бер төргәк кәгазь сөйрәп чыгарды.

— Бар байлыгың шулмы,— диде абыйсы чемоданда китап-кәгазьдән башка берни дә күрмәгәч, — әллә тагын берәр контейнер-фәлән кайтасымы?

— Бөтен байлык та, контейнер да менә монда минем, абый.

— Алдан кычкырган күкенең башы ярылыр диләрме әле?

— Син миңа, абый, башта сораган эшне бир. Аннары таләп ит.

— Миңа калса, бездә иң мөһиме акыллы кешегә акыл сатмау, ә эшләп күрсәтү. Хак әйттемме? Килешәсең, димәк...

Балигъ булганнан бирле Кадыйр матди дөньяга реалистлар, рационалистлар күзлегеннән карап эш итте. Энесенең коры сүзләренә ул мөкиббән китмәде, китәргә уйламады. Шулай да энесе әйткәннәр аны нык кына кызыксындыра башлады. Иртәгә аның янына барлык материалларын алып, Сибирцев керергә тиеш иде. Баш геологка бу тәкъдимнәр ничегрәк тәэсир итәр микән дип уйланды. Пилмән хәленә кереп, катламнан нефтькә ияреп чыккан парафин һәм җир мае өлешендәге төрле-төрле сумалаларга төренгән су тамчысы — нефть чистартучыларның иң-иң яман дошманы. Идарәгә нефтьне судан һәм тозлардан арындыру миллионнарча сумнарга төшә, шуның өчен дисталәрчә махсус корылмалар төзелде. Ә бу катламнан чыгарылган нефтьне паркларга җиткәнче үк су һәм тозлардан арындырмакчы. Ничек инде шуннан соң моңа Хыялый Хәйрүш димәскә.

Кадыйр сызымнарны бик дикъкать белән, җентекләп карап чыкты, ниһаять, ул башын күтәрде, кулларын җәеп җибәрде.

— Дәлилләрең нык күренә, белгечләр белән киңәшеп, алар да риза булсалар, сынап карарга булыр...

## 4

Абыйсының бүлмәсенә кергәч, Нәүфәл тәрәзәгә таба узды. Ул шушында яшәргә тиеш иде. Тәрәзә төбенә терәлде дә күз йөртеп чыкты. Сул кулда — тумбочка-бар, уң кулда — журналлар өстәле, ишек ягында — диван-кровать. Бүлмәнең бердәнбер тәрәзәсе төньякка карый, ачык форточкадан дымлы һава исе керә. Күрше бүлмәдә Гөлүсә дәрес-

ләр карый. Ул, күрәсең, онытылып, вакыт-вакыт ярымтавышка көйләп җибәрә. Тышта яңгыр сибәләп узган булса кирәк, түбә кыегыннан тамчы тамгалый.

Кичке эңгергәчә вакыт ничектер тиз үтте, куе томан төшкәнгәме, бүлмә эче кинәт кенә караңгыланып калды. Гөлүсә дә ятты бугай, җырламый башлады. Ә Нәүфәл тәрәзә төбенә утырган килеш торды да торды. Хәтер дигәне абыйсының: «Өйләндеңме әле?» — дигән соравына эләгеп калды. Нәүфәлнең күз алдына Грозныйдагы Тәнзилә килеп басты. Яратышудан битәр ир назына тансыклаган, ике мәртәбә кияүдән кайткан утыз биш яшьлек Тәнзиләгә ул һич көтмәгәндә йортка кереп куйды. Һәр буйдакка хас булганча, вакыт тарлыгы кичерә иде Нәүфәл. Я ашханә ябылыр алдыннан гына килеп керә, я бөтенләй ябылгач ук. Әмма, аны, ни хикмәттер, һәр чак ишек ачып керттеләр, йомырка тәбәсе булса да ашатып чыгардылар. Чөнки монда Тәнзилә пешекче булып эшли һәм кәкре муенлы егеткә күптән күз атып йөри иде инде. Күп вакытта Тәнзилә аңа ишекне үзе ачты, земляк дигән булып, йомыркадан тәбә куырып китерде. Бер тапкыр хатын кәкре муенлы егет каршына килеп утырды да, землякны ачыктан-ачык күзәтә башлады.

— Карале, җегет, земляк тә, земляк диләр үзеңне, кайсы як татары соң үзең?

— Минзәлә дигән якларны ишеткәнең бармы?

— Бәй, Минзәлә типтәремени әле син, бахыр. Күрче берәүне, әйтми йөргән була тагын. Туган якларыңа кайтканың бармы соң? Юкмы?.. Минем дә кайткан юк. Ун ел яшим инде шушы Грозный шәһәрендә. Бик тә кайтып киләсем килгән чакларым була, әллә нигә кодрәтем житми шунда. Мин җыенам — акчасы булмый, туганнар чакыралар — башка бер-бер сәбәбе килеп чыга. Нюрка, Нюрка, — дип кычкырды Тәнзилә кухня ягына таба борылып.— Неси бутылку сухого, я впрямь земляка нашла... Упшежитиедә торасыңдыр әле? — Нәүфәл хатынга карап көлемсерәп алды. — Мескенем, керләреңне кем юа инде?.. Үзеңне тагын инженер булып эшлисең диләр... Күрче берәүне, күнектем дип утырган була тагын. Упшежитиегә күнегеп буламы? Анда сезнең ата — улны, ана — кызны белми, диләр бит. Кил күчеп үземә. Бер үзем өч бүлмә. Кызым ГПТУда укый, атна-ун көнгә бер генә кайта. Я инде, нинди яхшы түгел дигән сүз ди ул. Чит-ят милләтме әллә мин сиңа. Иң зур бүлмәмне бирермен үзеңә. Яшә рәхәтләнеп...

Бер шешә шәраб янында бик озак сөйләшеп утырдылар.

Танышулары шулай булды.

Тагын ике атнадан Нәүфәл бар булган әйберен күтәрде дә Тәнзиләгә күченеп килде. Дөресен әйтергә кирәк, тол хатын ни уйлагандыр, бүлмәгә кереп урнашкач та Нәүфәл: «Фатирга гына кермәдем, йортка кердем инде болай булгач», — дип уйлаган иде, хак булып чыкты, беренче төндә үк Тәнзилә: «Әллә нигә өшеп торам, җылыт әле, якташ»,— дип, эчке күлмәктән шыпырт кына Нәүфәл янына килеп ятты.

Билгеле, Нәүфәл баштан ук Тәнзиләнең аңа җайлашырга тырышуын күрде. Ләкин үзенең гариплеген яхшы белгәнгә моннан артыгына өмет тә тотмады. Хәтта, әйтик, шушы тормышка өйрәнеп, гадәтләнеп тә бара иде инде, уйламаганда Тәнзиләнең кызы кайтып төште. Әнисенең чираттагы кияве турында белгәч, кыз ачуланды. Хәл кычкырышуга ук барып җиткәч, Нәүфәл түзмәде, барып, түр бүлмәнең ишеген ачты.

— Инәкәй, нишләвең инде бу тагын. Синнән ун яшькә кече бит ул. Торыр дисеңме син аны үзең белән?

— Җап иләк авызыңны, юньсез кыз! Күкәй тавыкны өйрәтми. Тик тор! Сиңа гына калган тагын әниеңне тикшерергә. Оял бераз! Пешекче булып күпме алам дип беләсең? Нинди акчага киенәсең дә, ниемә ясанасың, бизәнәсең... Себердә сөрелеп йөргән атаңнан килгән ун сум алимент акчасынамы? Ә бу адәм миңа аны көрәп алып кайта. Шушы

яшемә житеп, ичмасам, бер шуба алып киярмен. Синең өстеңә дә юнәтербез, боерган итсә...

Нәүфәл Тәнзиләгә хәтта мал колы булуын да гафу иткән булыр иде, ул саран булса да яшь иренә авыр сүз әйтмәде, өс-башын чиста йөртте, вакытында ашатты, эчерде, дигәндәй. Ә бер тапкыр хәтта:

— Нәүфәл жаным, табып биримме үзеңә бер малай?! — дип, кычеп килгәч күңеле тынычланып калган ир-егетнең йөрәген ярсытып куйган иде. Тик әллә нигә яшәп китә алмадылар. Көннәрдән бер көнне Тәнзиләнең кызы янә кайтты, янә кыз белән ана арасында дәгъва-талаш китте.

— Әнием, бәгырькәем, ни барысы ун сум сорыйм бит, кызлар театрга, концертларга бара, ә мин...

— Сантый нәмәстә, аңламасаң аңламас икәнсең аңгыра, дивана баш, шубага акча жыям дим ич. Бер-ике ел киярмен дә үзеңә калыр,— ни өчендер Тәнзилә тавышын баса төште, ләкин Нәүфәл ишекне әз генә ачып куйды. — Ни пычагыма мин шушы имгәккә чыктым дип беләсең, тиле. Янына яту түгел, булмәсенә кермәс идем...

Бу сүз Нәүфәлнең йөрәген үткен пычак белән телгәндәй итте. Гафу итә, кичерә алмады Тәнзиләне, икенче көнне жыенды да тулай торакка күчеп китте.

5

Иртән эшкә килгәндә баш геолог Сибирцев аны көтеп тора иде инде. Күрештеләр, сүзсез генә Кадыйр бүлмәсенә уздылар. Утырыштылар. Сибирцев күтәреп кергән кәгазьләрне буй өстәлгә тезеп салды һәм, иягенә таянып, моңсуланып көтеп тора башлады. «Бу хәлдән соң мин генә түгел, бу бичара да дуадак каз кебек каңгырып калды бугай, — дип уйланды Кадыйр. — Тагын катламга күкерт кислотасы кудырыйк дияр микән? Теге вакытта сынап караган арада ике бозау, өч-дүрт оя каз кырылган иде. Түләп бетерә алмый интекте. Юк инде, күкерт кислотасы — кичәге көн. Мине бүген ятманы цикллап файдалану идеясе борчый. Әйтергәме моңа, юкмы икән?»

— Кадыйр Сөнгатович, Идрисов Берләшмәгә идарәне промысел итү турында рапорт биргән. Кичә генә ишеттем, Берләшмәнең геология бүлеге Кудрявцева рапортны кабул итмәгән. Шуннан Идрисов рапортны шефның үзенә кертеп биргән, диделәр.

— Болай булгач, эш министрлыкка ук барып житәчәк, Михалыч.

— Житәчәк. Без кул кушырып утырыйкмы? Күмер катламына күчәргә вакыт.

— Хәзерлә документларын. Бүген үк кул куям.

— Менә алар, — Сибирцев идарә начальнигы алдына берничә бит кәгазь китереп салды. — Ләкин аннан аласы нефть төпсез ыштанга ямау гына булачак.

— Иш янына куш, Михалыч, әлегә ул да ярап торыр. Утырыгыз әле. Киңәшәсе бар. Бер идея борчый мине. Катламнан цикллап файдалану дигән идея. Болай эшләнә: атна-ун көн буена катламга суны кудыртабыз, ә үзебез бер тонна да нефть суыртмыйбыз.

Идеянең асылына төшенергә теләпмедер, Сибирцев бик озак уйланып торды. Баш геологның зиһен «лампочкалары» аша бөтен бер ятма, девон катламы, анда барган процесс үтте бугай. Баш геолог акрын гына кузгалды, ишекле-түрле йөренеп килде, идарә эшкәрткән карта янында бер мәл басып торды. Ияген учлап тоткан килеш, як-якка башын чайкаштырды.

— Ул арада аласы нефтьне безгә кем бирер микән соң, Сөнгатович? — диде ул, ниһаять, Кадыйр ягына карамый гына.

— Без.

— Без? Без ук. Тәүлегенә күпме нефть алып ятуыбызны исегезгә төшеримме әллә? Юкмы?.. Идеясе кемнеке?..

— Кеше күрсә коты алынырлык энем бар минем. Автоматчы, геолог булып эшләгән. Күп еллар сөйрәп йөри икән инде.

— Кызык,— Сибирцев өстәл янына килеп утырды.— Беләсеңме, Кадыйр Сөнгатович, рөхсәт сорап Берләшмәгә хат языйк.

— Син алай падишах аучысы һөд-һөд кошын тоткан сыман куанмый тор әле, Михалыч. Эш синең белән мин уйлаганнан күп тапкыр катлаулырак.

— Анысы инде сезнең эш, Кадыйр Сөнгатович,— дип, баш геолог тиз генә «сезгә» күчте.— Приказ язып әләсез дә, вәссәлам. Сез идарә башлыгы, беренче сүз сездән. Хәл иттегез бит әле катламга күкерт кислотасы белән тәэсир итү мәсьәләсен. Дөрес, уңмадык, шуңа карамастан сынап карадык.

— Ә шәхси делога язып бирелгән шелтә, син колхозчыларга түләгән ике мең сум акча?

— Шелтә килә дә, китә дә торган нәрсә ул — акча кебек ук. Аның каравы, без яңа бер ысулны сынап карадык. Бу идея дә кызык күренә. Белмим, нинди фәнни нәтиҗәләргә таянып эш итәдер ул энегез, әмма идеясе мавыктыргыч. Бөтен курыккан нәрсәм, катлам кадәр катламны туктатып тору. Җитмәсә, ятма сүнеп барганда. Идрисов шундук Кудрявцевка хәбәр итәчәк.— Сибирцев нягенаышкыштырып утырды, уйланды.— Миңа калса, башта безгә ул идеянең документлары белән танышырга кирәк булыр. Чынлап та, кеше кебек ук, ятма да кайчандыр ялга чыгарга тиештер бит инде,— дип, Сибирцев көлемсерәп куйды.

— Бөтен хикмәт Берләшмәдә, Михалыч.

— Нигә Берләшмә, нигә безнең үзебезгә хәл итмәскә!?

— Алдан ук сизенәм, дошманнарсыз булмас.

— Мин сезне яклар идем, Сөнгатович.

— Их, Михалыч, Михалыч, синең белән мин генә җавап бирердәй нәрсә булса икән... Ярый, партком секретарен дә чакырып киңәшик әле башта.

Кадыйр Воронцовны чакырды.

Күп тә үтмәде, кабинетка партком секретаре Воронцов килеп керде. Чандыр гәүдәле, озын буйлы, шулай ук озынча ябык йөзле, эчкә баткан янаклы Воронцов гомер буена ашказаны авыруы белән интекте, диетада гына яшәде. Аның белән Кадыйр аягүрә басып күреште.

— Ни булды, ни бар, Кадыйр Сөнгатович?

— Синең киңәшкә мохтаҗбыз, Владимир Поликарпович. Бер идея туып килә. Мәгълүм булганча, бу катламда нефть бетте дигәндә дә, анда разведчиклар күрсәткән нефтьнең ярты запасы кала. Шуның һич югы биш-алты процентын алу максаты белән ятманы файдаланудан туктатып торсак дигән фикер бар. Биш-ун көн булырмы ул, артыгракмы, әлегә билгесез,— диде Кадыйр. Аның соңгы сүзләренә Воронцов көлемсерәп, башын чайкап алды.

— Ай-һай, кем генә рөхсәт бирер икән моңа.

— Сез,— диде Сибирцев.— Кадыйр Сөнгатович һәм сез, Владимир Поликарпович.

Әмма партком секретаре баш геологны ишетмәгәнгә салышты һәм өстәл янына узды, бу аның: «Әйдәгез, утырып киңәшик»,— диюе иде. Баш геолог та, Кадыйр да сүзсез генә буйсындылар, өстәл янына килеп урнаштылар.

— Эшчеләргә хезмәт хакын кем түләр?.. Нефте нефть инде, аңа да рөхсәт әллә бирәләр, әллә юк,— диде Воронцов икеләнүен яшермичә.— Хәлләр. Шулай да башта исәп-хисаплаулар, технологик схема белән танышасы иде.

— Эшчеләргә эш бар. Бүген-иртәгә күмер катламына күчәргә торабыз. Шушы буш вакыттан файдаланып, яшьләр сораган бассейнны корып куйсак та әйбәт булыр иде.

Воронцовның чандыр чыраенда үтә гаҗәпләнү галәмәтләре кабынып алды. Чөнки идарә начальнигының сүзләрендә нинди дер күләмдә хаклык бар иде барын. Тик шулай тиз генә хәл ителә торган нәрсәме ятма кадәр ятманы туктатып тору? Китәр дәгъва, китәр әләк. Эш өлкә комитетына чаклы барып җитәр. Һәм җитәчәк тә. Ә болар — Дон-Кихотча — тоталар да үзләре генә хәл итәләр. Канга тоз салучылар бик күп һәм бик тиз табылыр бу эшкә болай җиңел генә карасак, һич шикләнмә, министр хәтле министр үзе килеп төшәр...

— Миңа калса, нинди генә актуаль идея булмасын, иң әүвәл ул фәнни яктан төпле итеп нигезләнергә тиештер. Ул якларын да карарбыз. Саф интуитив хыялга корылган идеяләрне, гафу итегез, Кадыйр Сөнгатович, мин аңламадым, аңламамдыр да, мөгаен.

— Дөрес әйтәсез, Владимир Поликарпович, хыял һәр чак нарасый бала күңеледәй саф булырга тиеш. Иң кыйммәтле идеяләрне бу дөньяда нәкъ менә хыялый кешеләр, хыялга бай башлар биреп килде.

Воронцов утырган урынында борсаланып алды, аның шулай түземлеген җуеп нервлануын күрүгә, Сибирцев та:

— Әүвәл танышу кирәк булыр, — диде, ә үзе җиде кат җир астындагы ятманы күргәндәй сәер бер кыяфәттә уйланып утырды. Аны күзәтеп торган Воронцов үзалдына көлемсерәп куйды, кузгалды, кулларын җәеп: «Нишлим, идеягез болай гына барып җитмәде шул әле миңа, гафу итегез», — дигәндәй, торып басты.

— Танышырга һәм... галимнәр белән киңәшеп карарга кирәк булыр, — дип, баягы фикерен җөпләде Воронцов.

Кадыйрга партком секретаренең җилкә җыерып торуы ошамады, баш геолог кебек, моның да бер сүз белән ышануын көткән иде ул, әмма Сибирцев кебек фантазиягә бай кеше түгел иде шул партком секретаре Воронцов, киресенчә, бүгенге көн мәшәкате белән яшәргә өйрәнгән кеше иде, бөтен дәлилләрне ачып салып кына аны ышандырып була һәм шул чакта гына ул янып-көеп идеягә ябышучылардан иде. Шундый нәтиҗәгә килде Кадыйр, партком секретаре белән сүзне шунда туктатырга булды.

Воронцов ишеккә таба кузгалды.

— Һавадагы торнага өмет итеп, кулдагы чыпчыкны ычкындырмыйк, Кадыйр Сөнгатович.

— Ахмак идея белән мавыгасыз дип уйлавыгыз түгелдер бит, иптәш Воронцов?

— Юк, алай дип әйтәсем килми. Һәрхәлдә, нинди дер нәтиҗә ясауны ашыктырмаска дияр идем. Бер хакыйкать бар, — диде Воронцов кабинет уртасында туктап.— Һи отышлы идея дә ахырынача уйланылган, җитлеккән булырга тиеш.

— Ашыгырга, нәкъ менә ашыгырга, чаң сугарга кирәк безгә, Владимир Поликарпович. Ятма сүнә бит, сүнә! Шул ысул үзе тора-бара кулдагы чыпчык булып калмагае, киләчәк бәлки шуны күрсәтер. Кеше һәр чак өмет белән яшәргә, әнә шул һавадагы торнаны тоту турында уйларга тиеш, — диде Кадыйр. Идарәне промысел итәргә теш кысып җыенып йөрүчеләр бар. Кул кушырып шуны көтеп утырыйкмы?

— Танышып чыгыйк, активны җыеп фикер алышыйк, аннары күз күрер. Һәр ятма үзенә бер төрле. Аларның һәммәсенә бер үлчәм белән килеп булмый, Кадыйр Сөнгатович. Кулай идея икән, мине беләсез, бу эшкә тешем-тырнагым белән ябышачакмын.

... Өенә атлаганда Кадыйр нинди йөгәнсез хыял белән эш башлап җибәрүенә, ниһаять, төшенде. Ул өч кеше арасында булып алган сөй-

ләшүгә анализ ясарга тырышты, ләкин үзе үк күкрәк кага-кага яклаган идеянең ныклыгына һич кенә дә инана алмады. «Күрче, житмәсә бит Воронцовны ышандырырга керештем, — дип уйлады ул партком секретаренең кинаяле чыраен күз алдыннан жуя алмый аптырап. — Ул миңа, әлбәттә, ышанмады». Юл буена шул уйларыннан арына алмады, үтүче-сүтүчеләрне күрмәде, гүя ул тротуар жәйгән урамнан түгел, кыр юлыннан атлый иде. «Хәер, нигә соң Сибирцев идеяне ишетү белән кабул итте, киләчәгеннән ачык күзалладымы? — дип, уен дәвам итте Кадыйр. — Нинди аңламаслык сер бар бу ике кешедә»...

Әмиров үзалдына сөйләнә башлавын сизми дә калды, ул әле булса Воронцов белән бәхәсләшә иде:

«Бу идеяне тормышка ашыруга мин көчемне жәлләмәячәкмен».

«Ләкин барыбер ашыкмаска кирәк», — ди Воронцов.

«Мин сезне аңламыйм, — дип сүзгә кушыла Сибирцев. — Өллә соң сез башка бер идарәдә эшлисезме, Владимир Поликарпович. Бу ни дигән сүз инде! Ятма сүнә, үлә һәм ул үлемне кичектереп була, яман чирле авыруны операция өстәленә салырга жыенабыз, бу идея исә аңа — хирург, ятмага яңа сулыш, яңа тормыш бирүче. Ятма арыды, алжыды, аңа ял бирергә кирәк. Менә нәрсәгә төшендем мин кинәт кенә».

«Ятманың язмышын кеше гомере белән чагыштыруны мин аңламыйм һәм аңларга да теләмим. Һәр идея техник яктан дәлилләнгән булырга тиеш, шуны гына беләм мин».

«Мин инде монда унбиш ел баш геолог булып эшлим, бу ятма — минем тормышым, үзем ул, Владимир Поликарпович. Нинди генә прогрессив ысуллар белән эшкәртмик катламны, әмма разведка күрсәткән запасның илле процентыннан артыгы жирдә калып бара. Ә бу метод, бу ысул нинди дер күләмдә шушы калган нефтьне алырга ярдәм итәргә тиеш. Мәгълүм ки, катламда басым арткан саен андагы нефть калдыклары бер төбәккә жыела башлый һәм бу процесс бик акрын дәвам итә, аңа вакыт кирәк. Катламда ике төрле сыекча арасында мәңгелек көрәш бара. Аның берсе су, ул житезрәк, хәрәкәтчәнрәк — хәтта катламнан катламга күчә. Нәкъ менә шул чакта катламдагы салмак, акрын хәрәкәт итүче нефть «күлләре» томаланып кала. Ә без ятмадан нефтьне суыртабыз да суыртабыз һәм шуның белән жир маена бер төбәккә жыелырга мөмкинлек бирмибез. Иш-ишкә, төс-төскә омтыла диләр, Владимир Поликарпович».

Капканы ачып ишегалдына кергәндә ул һаман да үз кабинетындагыдай бәхәсләшә иде әле. Картлар сыман үзалдына сөйләнә-сөйләнә кайтып кергән ирен күрүгә, ишегалдында агач төпләрен йомшартып маташкан Зөһрә көрәгенә таянды да:

— Нишләвең бу, Чөгәдәй кебек мыгырдап кайтасың? — дип аптырап алды.

— Нәүфәл өйдәме? — дип сорады Кадыйр, әйтерсең ул хатынының кинәясен ишетмәде дә.

— Нидер язып утыра.

Кадыйр туктамыйча атлый бирде һәм энесе яшәгән бүлмәгә ашыга-кабалана узды.

## 6

Телефон аның өчен бүген илаһи бер көчкә ия кебек тоела башлады. Идрисов мондагы хәлләрне, һичшиксез, Кудрявцевка житкергәндер һәм Берләшмәнең нефть жыю бүлеге начальнигы Кадыйрга шалтыратырга чират житкәнне генә көтәдер. Әлбәттә, шулай. Кадыйр нишләргә тиеш соң бу очракта? Воронцов диссертацияне укып чыкты, технологик

схемалар белән танышты, әмма һаман кисеп кенә сүзен әйткәне юк. Дөрес, баш геолог Сибирцев рухын төшерми, җаны-тәне белән шул ысулны сынап карыйк дип кыстый, ләкин аннан гына ни файда, исеме бармы ул Сибирцевның Берләшмә тирәсендә, кешегә күрсәтерлек эше бармы? Белмиләр аны, белгәннәре дә булмады. Күкерт кислотасы белән җенләнеп йөрде, әле дә булса йөри бирә бирүен, әмма тәкъдимне кабул итәргә нигәдер ашыкмыйлар. Район тау-техник инспекциясе кире каккач Берләшмәдә утыручылар аңа вето салды. Ә хәзер әнә шул Сибирцевның Нәүфәл идеясе белән башы әйләнде, бүген приказ язып бирсәгез, Сөнгатович, иртәгә үк керешәбез бу эшкә дип котырта.

Тынып-сузып телефон шалтырады.

— Алло, тыңлыйм. Исәнме!

Телефонда Кудрявцев иде. Ул Кадыйрны элекке вакытлардагы кебек ашыктырмады: «Хәзер үк килеп җит!» — дип тә әйтмәде, «Килеп чык әле, Кадыйр, киңәшәсе нәрсәләр бар», — гына диде.

Кадыйр, трубкадан кулын алмыйча, бер тын уйланып торды, аннары җитез хәрәкәтләр белән ишеккә таба кузгалды, ләкин, нидер исенә төшеп, шкаф янына тукталды, плащын алып беләгенә салды һәм чыгарга юнәлде. Секретаре ягына чыккач, ул:

— Бүген булмамдыр, сорап килүчеләр көтмәсен,— диде.

— Бер приказга кул куеп китегезче, Кадыйр Сөнгатович. Вәгыйз Исламович кул куярга теләмәде. Ул кешеләрне начальник үзе алган, имзаны да үзе салсын ди.

Кадыйр өстәл янына борылды да приказны алып укып чыкты. Баш инженерга ул, скважиналарны группалап теркәү эшенә бригада оештыру турында приказ язарга, бригадага өлкән инженер итеп Әмиров Нәүфәлне билгеләргә дигән киңәш-боерык биргән иде. Идрисов аның алдында ук приказны язып утырган булды, әмма ул, машинкада басылып, өстәлгә яткач, баш инженер нигәдер кинәт икенче уйга килеп приказга кул куюдан баш тарткан.

— Алай икән, — дип куйды Кадыйр үзалдына. — Ярый, бир әле ручка. Бүген үк эләп куй. Копиясен автоматчылар цехына җибәр.

Гадәти кояшлы көн. Агачлар куе яшел яфракларын кояшка каршы куеп, шифалы нур җыялар. Кадыйр нигәдер ашыкты, исәбе барысын берьюлы хәл итәргә идеме, машинага утыруга шоферына:

— Әлмәткә, тизрәк тот, — диде.

Җете кара төстәге «Волга» олы юлга төште һәм тыгыз һаваны ерып, алга омтылды. Шул уңайга Кадыйрның гомер хәтирәләренә бәйле уй җебе янә ялганып китте.

Нигәдер язмыш аларны гел бергә йөртте. Кадыйр Виталийны күрәлмады, шул ук вакытта, сусыз яши алмаган балык шикелле, үзе үк аңа тартылды. Бәйдәге җәнлектәй, Кудрявцев кая барса, шунда булды. Каядыр читкә юл алырга рухи көче җитмәде, чөнки монда, Виталий янында, Наташа бар иде. Әйе, ул хатынны Кадыйр гомере буена яратты. Әмма аның яратканы башка берәү белән яши иде. Очрашкан чаклары да булды, булмады түгел, нәкъ менә шул минутлар аңа тиңсез бәхет китерде. Хатынның ягымлы карашы, аңа карата булган үзгәрәк мөлаем мөнәсәбәте болай да сөю-ятратуга көйләнгән ирнең күңелен айкап-уйнатып җибәргәләде. Шундый мәлләрдә ул үзен гаять дәрәҗәдә бәхетле итеп тойды, шундый очрашулардан соң Кадыйрга ул да бер аны гына яратадыр, аның өчен генә сагышланадыр кебек тоела иде. Килер бер вакыт, бер мәл, сөйгәне үзе үк аның күкрәгенә килеп капланыр һәм, бик ихтимал, яшьлек хаталары өчен гафу үтенер, ул гынамы, бергә булуларын теләр сыман тоела башлый иде. Хикмәтле хәл. Кадыйр һәр чак аны күрергә җай эзләде. Җай килгән чаклары да булды, әмма барыбер күзгә-күз карашып аңлашу бәхете Кадыйрга тимәде. Хак анысы, һәр очрашулары күңеленә үзе дә аң-

лап бетермәгән дәрт, якты өмет өстәде. Әмма соңгы чиктә Наташа аны барыбер яшьлек дусты итеп кенә кабул итте, Кадыйрның гитара кылыдай гел аны сөюгә көйләнгән күңелен хатын аңламады, аңлапмы якын җибәрмәде. Шуңа күрәме, Кадыйрда бу хатынга карата һәр чак ике тойгы яшәде: үткәннәргә үпкә һәм, ничәмә-ничә еллар узуга карамастан, йөрәгендәге шушы хатынга карата булган сүнмәс вә сүрелмәс хис ялкыны. Ләкин бер хакыйкатьне искә алмады ул: якты дөньяга килгән һәм үнҗиде яше тулып узган һәр кыз иртәме-соңгы, мәхәббәт ашамы, вакыт җитепме барыбер кияүгә чыга, бала таба һәм нәкъ менә шунда инде аның матди дөньяга карашы да үзгәрә. Инде аңа матур гына гаилә корырга да насыйп булган икән, Наташа да, мөгаен, яшьлек мәхәббәтен изге бер истәлек итеп кенә исенә төшерәдер. Ә бит теге вакытта, Кадыйр аны яратып йөргәндә, Губкин исемендәге нефть институты студенткасы Наташа Жукова, мөгаен, якты уй-хисләр белән генә яшәгәндер, аның өчен киләчәк тормыш гүзәл бер романтик моң булып күренгәндер.

Онытты микәнни? Очрашуларын, иңгә-иң куеп, сәгатьләр буена киләчәк турында сөйләшеп утыруларын онытты микәнни?

Ә Кадыйр аны һаман исә оныта алмый изалана.

Әле менә, Кудрявцев янына барырга чыккач та, ул тагын Наташаны исенә төшерде. Шул исем тел очына килүгә, Кадыйр һәр чак иң кадерле әйберен югалткан сыман, сыкрап куя, күңеле актарылып китәр дәрәҗәдә үкенү тоя. Ә бит ул хәлләрдән соң ничәмә-ничә еллар узды инде, күпме сулар акты инде. Ул арада Наташа иргә чыгып малай тапты. Кадыйр өйләнде — менә дигән чибәр кыз үстерәләр. Хәзер инде әнә шул балалар бер-берсен яратышып йөри... Ә Кадыйрның Наташага булган мәхәббәте сүрелми генә бит. Шуңа карамастан, Кадыйр моның турында Наташага ни дә булса әйтергә җөрьәт итмәде. Ул аңлый иде: алар икесе дә инде ул яшьләреннән узганнар — Наташаның улы Әлмәт нефтьчеләр институтының икенче курсында укый, Кадыйрның кызы быел унны тәмамлаячак.

Бу дөньяда бар кеше дә үлеп яраткан кешесе белән генә яшәми, язмыш, аерата яшь чакта, шаяручан, алдаучан, һәм, шул ук вакытта, алданучан була. Шуңа күрәме, нәкъ менә шул хакыйкатьне аңлагангамы, Кадыйр үз язмышына үкенмәде, ул чаклы сыкрап рәнҗемәде, күңелендә шушы язмышы белән һәр чак килешмәүчәнлек уе яшәсә дә, бу хис, бу уй беркайчан да аның җанын ниндидер кискен хәлләргә котыртмады, киресенчә, сабыр итәргә, ирешкәненә риза булырга өндәде.

Наташа турында бик күп уйлангангамы, аның исемен гелән-гелән тәкрарлагангамы, язмыш аның белән тагын бер шаярып алды. Бу хәл Кара диңгез буенда, Зөһрә белән ялга баргач булды.

Көннәрдән бер көнне алар тыныч кына ял итеп яткан йортка улы белән Наташа килеп төште.

Очрашу-күрешүләр гадәттәгечә булды, Кадыйр аны хатыны Зөһрә белән таныштырды һәм ике хатын бик тиз дуслашып киттеләр, торабара аларны аерып булмый башлады. Бу хәлгә Кадыйрның эче тырналса да, килеште тагын, чынлап та ир уртасы булудан узып барган һәм инде җитеп килгән кыз үстергән атага яшьлек мәхәббәте белән яну килешмәстәй бер хәл булып тоелды. Ләкин йөрәк дигәнең аклануга гына йөз тоткан бу дәлилләрне исәпкә алырга теләмәде, Наташа белән икәүдән-икәү генә калуларын теләде. Кадыйр тәмам йокыдан калды, төннәрен бер яктан икенче якка әйләнә-тулгалана ятты, Кара диңгез буена бер үзе генә килмәвенә үкенеп бетә алмады, җаны актарылып тиргәлде. Ә бит аның биредә Зөһрәсез ял иткән җәйләре дә булгалады, килеп төшмәде шул чакларда Наташа язгы кошлар кебек сагындырып...

Институтта уртача укыды Кадыйр, берәүләр кебек атылып алга чыкмады, шулай да дипломын яхшы билгесенә яклады. Дипломны аңа Наташа язышты. Икәүдән-икәү генә бер бүлмәдә утыралар, яза-яза арыгач, музыка тыңларлар, ул да түгел, шау-гөр килеп биергә тотынырлар иде. Янә бер нәрсәне беләләр иде курсташ студентлар: геология бүлеге студенткасы Наташа Жукова ике егетне күзеннән яздырмый, ләкин әле кемгә кияүгә чыгу мәсьәләсен тәгаен хәл иткәне юк, сер итеп йөртә. Кызның кемне сайлаячагын егетләр дә белмиләр иде: Виталийга да, Кадыйрга да соңгы көнгә кадәр өзеп кенә сүз әйтмәде Наташа. Бәлкем соңгы минутына кадәр икеләнеп йөргәндер?.. Бәлкем...

Кадыйрны уйлары Наташа белән яратышып йөргән чакларга алып китә һәм ул янә үзалдына: «Наташа, нигә соң әле без кавыша алмадык, кем комачаулады?» — дип куя. Әмма аңа кем җавап бирсен?! Соңгарып килгән бу сагышлы газап-үкенүләрнең ахыр чиктә бер рәхәте — Наташаны күрү, аның белән сөйләшү бәхете килгәч, йөрәгенең күкрәгенә сыймас дәрәҗәгә җитеп дулкынлануын тыя алмаудан тәмам гаҗиз калган иде ул.

Исендә, барысы да исендә, югыйсә...

Машина, җилне куып җитәргә теләгәндәй, Әлмәткә очты, ә Кадыйрның хәтер кәтүге сүтелә торды.

Практиканы алар Урал якларындагы бер авылда уздылар. Эшкә һәр көн тар гына инеш аша чыгып йөрелде. Беренче көннән үк егетләр кызларны инеш аша кулларына күтәреп чыгара торган булып киттеләр. Башта кем-кемнең янына туры килсә, кызны шул күтәреп алып чыга иде, соңга таба кызлар сайлана башладылар, хәтта: «Кадыйр, җитәр, гел Наташаны гына чыгарма, иртәгә мине чыгарырсың»,— дип чытлыкланучылар да булгалады. Ләкин Наташа баштан ук Кадыйрны сайлаган иде, егетне берәүгә дә бирмәде. Шул көннән инеш кичү бер уенга әверелеп китте. Башкаларга караганда җилкәлерәк, тазарак булган Кадыйр Наташаны инеш аша бик ансат чыгарды. Группа старостасы Кудрявцев яше белән дә, тормышның ыгы-зыгысын аңлавы белән дә тәҗрибәлерәк иде, бу хәлгә ирония белән карарга тырышты, әмма мондый дәвамлы уен аңа ошап җитмәде, күрәсең. Ул берничә тапкыр Кадыйрга аркылы төште, ләкин Наташа уенын-чынын бергә кушып: «Юк инде, Виталий, мин Кадыйрга ышанарак төшәм», — дип, бүселеп килгән егетне шып туктатты. Әй, ул инеш аша чыгулар! Кадыйр Наташаны кулына күтәреп алыр иде... китәр иде шунда чыр-чулар, чытлыкланулар, һаваланулар — студенткалар түгел, хан кызлары диярсең. Наташа Кадыйрның муеныннан кочаклап алыр иде дә:

— Ну, Кадыйр, поехали!—дип команда бирер иде, үзе йомшак коңгырт чәчләре белән егетнең битен кытыклап, аннары тагы да иләсләнә төшеп: — Ой, ой, егасың ич, егасың, Кадыйрчик! — дип кайнар сулышы белән егетнең муенын пешерер, шул чакта кызның чынаяктай ак бит очлары алсуланып, балкып китәр иде. Шул хис ялкынына эләгеп, кыюлана төшкән Кадыйр Наташаның битеннән үбәргә теләсә, кыз аңа пышылдап кына: «Кич белән, яме...» — дип, егетнең болай да ярсыган күңеленә әллә ниткән коткылар салыр иде.

Шул исерткеч пышылдаудан соң, бер тапкыр Кадыйр сабырын җуеп:

— Апкитимме үзеңне Казанга тикле шулай? — дигән иде.

Ә Наташа зәп-зәңгәр күзләрен кыса төште, әллә юри, әллә чынчынлап:

— Апкит, Кадыйр, апкит әле, — дия-дия канатланып көлергә тотынган иде.

Әйе, Виталий Кудрявцев Кадыйрны шунда ук яратмады, бәйрәм ашы кара-каршы дигәндәй, Кадыйр да аңа шундый ук «мәхәббәт» белән җавап кайтарды. Виталийга Кадыйрны яратырлык та түгел иде

шул. Кудрявцевның Наташа Жукова артыннан йөргән чагы, ә кыз аңа гел игътибар итми башлады, һәр вакыт Әмиров белән бергә... Бәлкем бу мавыгып алу кызның үзенә күрә бер хәйләсе булгандыр. Наташаның үзен яратуын белеп алгач, Виталий кәпрәя, эреләнә башламасын дип юри шулай кыланса гаҗәпмени. Үзенә күрә бер тактика. Шулай булуы бик ихтимал, чөнки соңыннан барыбер Кудрявцевны сайлады бит!..

Янә бер хәл бик ачык хәтерендә саклана: алар бер бүлмәдә, китапханәнең бер өстәле артында мыштым гына, иңне-иңгә терәп утырып, диплом өчен материал җыялар. Шул чакта башлары-башка орынып китә, ә алар моны сизмиләр дә. Утыра торгач, Наташа, башын артка чөеп, коңгырт чәчләрен селкеп җибәрер һәм алар күзгә-күз карашып алырлар иде. Кыз энҗедәй тезелеп киткән ак тешләрен күрсәтеп серле генә елмаер. Шул караштан, елмаюдан тәмам гаҗиз калган Кадыйр бу матди дөньяда үзләре генә булуын онытып, кызның бит очларын үбеп алыр иде. Наташа аңа үпкәләми, бармак яный һәм Кадыйрның чәчен туздырып ташлый иде.

Хәтерендә, барысы да хәтерендә. Теге чакта, инеш аша чыкканда, беренче тапкыр үбешүләре дә, кич белән янә очрашып татлы мәхәббәт дәрьясына чумулары да — барысы да хәтерендә... Иртәгәме, берсекөнгәме Виталийга кияүгә чыгам дигәндә, көтмәгәндә бүлмәсенә Наташаның килеп керүе дә, ул кергәч үзенең ни кылырга белми өтәләнеп алуы да хәтердә. Шунда ул янә бер ачык авызлык күрсәтте бугай. Килеп кергән җайга Наташа аның янына үзды, янәшәсенә утырды.

— Чакыр әле бер ресторанга, Кадыйр, һич югы, киногә дәш, — диде кыз нигәдер ачыргаланып. — Чакыр әле бер!

Кыю иде Мәскәү кызы, ләкин егетне барыбер аңлап бетермәгән икән. Каян килсен инде чит-ят җирләрдә таки-токы стипендиягә укып яткан студентка ресторанга кызлар чакырыр акчалар. Кадыйр шунда кызарынды, бүртенде, ләкин авызын ачып ләм-мим сүз әйтә алмады.

— Ярый, син мине яратасыңмы хет, Кадыйр? Яратсаң, үп, алайса, үп! Мин китәм хәзер, ишетәсеңме, Кадыйр, китәм!

— Әйдә ресторанга!

Бер тапкыр гына ресторанга кереп чыгарлык акчасы, әлбәттә, бар иде Кадыйрның, ул кызны чын күңеленнән чакырды, кыланып тормады.

— Кирәкмәс, — диде кыз бөтенләй кәефе кырылып. — Кирәкмәс, мин болай гына, уйнап кына әйттем. — Ул башын күтәрде, егетнең күзләренә карады. — Мин кияүгә чыгам, Кадыйр...

Беренче тапкыр язмыш аңа шунда аяк чалды.

Икенчесе Кара диңгез буенда булды. Билгеле, һәр хатынга хас көнләшү сыйфаты Зөһрәгә дә ят нәрсә түгел иде, ул иренең Наташага йотлыгып карап торуын күрә-күзәтә килде. Ләкин Кадыйрга комачауламады, киресенчә, иренең Наташага шулай каравын күргән саен үзалдына уфтанып кына куяр иде. Ире аны яратмаганнан түгел, Кадыйрның яшьлектә булган романтик мәхәббәтен әлегә кадәр сүрелдермичә саклавына уфтанган иде хатын. Ә бит ире аны да ярата. Ләкин башкачарак, үзгәчә... Үкенеп, үртәнеп куя Зөһрә кайчак. Яшьлегендә ул гомергә истә калырлык мәхәббәт кичермәде. Зөһрә өчен ул бер булды — Кадыйр. Шул ук вакытта ул, тәҗрибәле хатын-кыз буларак, Наташа өчен Кадыйрның шулай өзгәләнүен, дөресрәге, өтәләнүен чынга да ала алмады. Шуңа күрәме, бер тапкыр, Кадыйр шулай авызын ачып Наташага карап торганда, Зөһрә ирен суда йөзгән хатынга таба этеп җибәрде.

— Ниемә, авызың ачып, хәчтерүшләнеп басып торган буласың инде, бар бер йөзеп кил үзе белән...

Шомарып, төрле формага кергән эре-эре чуерташлар аякны пешерә, алар арасында диңгез суы күбекләнә, йөгереп, ашкынып килгән дул-

кын түбән тәгәрәүгә, төрле төстәге таш өсләре чуарлана, гаҗәеп матур мозаика хасил була. Кадыйр бер мәл сүзсез генә көлемсерәп басып торган Зөһрәгә әйләнеп карады, җылы диңгез суы рәхәт итеп аякларын кытыклый башлаган икенче мәлдә инде ул ярга таба ишелеп килгән дулкынга ташланды. Аннары алар бергәләп бик озак йөзеп йөрделәр. Наташа арый төшкәч, Кадыйр аны ярга таба этеп-этеп җибәрде. Түш тиңентен җиргә җиткәч, аяклар катыга басуга, Кадыйр Наташадан:

— Уралдагы кебек күтәреп чыгарыйммы үзеңне, Наташа?— дип шаяртты.

Шул чагында Наташаны төнбоек чәчкәсенә охшаткан иде ул, гүя судан аксыл-сары резин башлык киеп Наташа чыгып килми, ә тын күлдә төнбоек чәчкә атып утыра. Бу чагыштырудан Кадыйрның йөрәге леп итеп куйды, ни кылырга, ни әйтергә белмәүдән гаҗиз калып торды.

— Теге вакыттагыча кулыма күтәреп чыгарыйммы үзеңне, Наташа?

Наташа кыйгач кашларына эленеп калган диңгез суы тамчыларын сыпырып алды, каш астыннан гына назлап-үртәбрәк әйтеп куйды:

— Көньяк диңгезе барысын да гамәлдән сызып атар дип уйлавыңмы әллә, юләрем. Әнә Зөһрәң ашардай булып карап тора түгелме?!

— Бу якка таба карамый да әле ул. Әйдә инде, Наташа!— диде Кадыйр һәм ялыну-ялваруы шул хәтле чын килеп чыкты ки, Наташа бер мәлгә аңа онытылып карап торды.

— Күр син аны, һаман онытмадыңмы, әллә кылануың гынамы, Кадыйр?

— Онытмадым,— диде Кадыйр һәм үз сүзендә чынлык, хаклык күреп көлеп куйды.

Урал ягында практикада: «Наташа, Наташам!»— дип өзгәләнмәгән булса һәм әле тагын шул елларны хәтерләтеп үзе янәшәдә су эчендә басып тормаса, бәлкем Кадыйр алай дип әйтә алмаган да булыр иде. Наташа аны гомере буена зарыктырды, Кадыйр гомере буена шушы минутны көткән кебек яшәде. Тик Наташаның чын фигыленә, Урал ягындагы кебек үк, әле дә төшенә алмады ул. Кадыйр Наташаның күз карашында, ирен чите белән генә елмаюында сагаеп калу галәмәтен күрде һәм, шушы көтелмәгән очрашудан канәгатьсез калып, эчке бер сыкрану тойды. Ә бит мондый очрашуны ул зар-интизар булып көткән иде, ә ул әнә ничек килеп чыкты. Наташа кузгалып китте. Кадыйр аңа иярде. «Холык алышына, гадәт кала»,— дип уйланды ул, Наташага ияреп атлаганда. Кадыйр белә иде: Наташаның бераз кылланган чаклары да булгалый, кирәк икән, яшь кызлар кебек кыбырсый да ала ул. Егерме ел элек тә шундый иде, хәзер дә шул гадәтен ташламаган. Наташаның тәнендә су тамчылары энҗе бөртекләре кебек ялтырый, уйнаклап барган гәүдәсеннән гүзәллек сирпелә. Шул мәлдә Кадыйрга диңгез буендагы барлык кызынучылар, ял итүчеләр Наташага карап тора сыман тоела башлый.

— Яшь чагымда ничек яраткан булсам, әле дә шулай яратам. Ышанасыңмы шуңа?!

— Ай-һай?...— диде аңа таба борылып Наташа һәм нигәдер шаркылдап көлеп җибәрде — рәхәтләнеп, чын күңеленнән көлде. «Хатын түгел бу, иблистер,— дип уйлый Кадыйр.— Ни тамаша үрти, тәмам җанны актара».

Кадыйр Зөһрәсе ягына күз ташлый, ләкин хатында гүяки алар кайгысы юк иде. Зөһрә изрәп, күзен йомган килеш, кояш нурларында коена.

— Мин бу сүзләрне ихлас күңелдән әйттем, Наташа!..

Наташа томыраеп торган зуп-зур зәңгәр күзләре белән Кадыйрга сирпеп карады, иренең тәне чымырдап китте, тиле кеше шикелле, шул яшендә сагышланып йөрүенә үзе дә үкенеп куйды.

— Шуннан рәхәтлек аласың икән, ярата бир, Кадыйр. Тик рәнҗетмә мине, үтенеп сорыйм синнән, рәнҗетмә,— диде һәм шул тиклә ягымлы-ихлас вә чын күңелдән әйтте бу сүзләрен, бу юлы инде Кадыйр үз самимилегеннән үзе көлеп җибәрде.

Кудрявцев үзендә иде, сабакташы Кадыйр килеп керүгә ул аңа ябырылды.

— Нишләвең бу синең? Утыр әле якынрак. Ни куптарып ятасың син анда? Квартал планын тутыра алмый иза чигәсең, җитмәсә, ятманы файдаланудан туктатырга исәп тотып йөрисең икән. Квартал тәмамланырга өч-дүрт атна калып барганда... Бу бит, бу бит,— Кудрявцев, кирәк сүз таба алмый тотлыгып торды.— Бу бит бөтен Берләшмәгә аяк чалу, Кадыйр!

— Ятманы эшкәртүдә без яңа ысул таптык. Ләкин аңа керешкән юк бит әле, нигә ул тиклем бугаз киерергә. Нәрсә, мин нинди дә булса законнарга хыянәт иттемме, әллә булмаса нефть бирүне туктаттыммы?! Хәлемнән килсә, баштан ук ятманы цикллап эшкәртергә керешкән булыр идем.

— Эһ, сиңа гына бирәсе булган икән ятмаларны эшкәртүне.

— Ә нигә, вакытында бирелгән булса, бәлкем тагын да камилрәк ысулын тапкан булыр идек.

— Кыю сөйләшәсең, ләкин дуамал кыюсың. Ярый, бу фәлсәфәңне башка вакытка калдырып торыйк. Биреп җиткермәгән нефтьне ничек тутырырга исәбең? Нефть эшкәртү заводлары миннән чимал көтә һәм договорда күрсәтелгән күләмне, башыма таш яуса да, озатырга тиешмен. Минем хәлгә кер. Син бит боларның барысын да бик әйбәт беләсең.

— Әйт әле, Виталий, ятманы цикллап эшкәртү турында кем әйтеп өлгерде?

— Өлгерделәр менә,— дип кәефләнеп, елмаеп куйды Кудрявцев.— Ә син ул дә үрә тор, әмма квартал азагына чаклы бирәсе нефтеңне биреп бетер.— Ул кисәк кенә күтәрелде, үзе утырып торган урындык артына чыгып басты һәм урындык башын төя-төя:— Кара аны, квартал планың үтәлгән булсын. Аннары экспериментыңны үткәрерсең. Анда да бездән рөхсәт алгач кына әле.— Шуннан соң ул янә үз урынына утырды һәм якын дустына дәшкәндәй тыныч кына:— Чәй эчәргә керәсеңме? Кадыйр килеп чыкса, мине күрми китмәсен әле, дигән иде Наташа.

— Рәхмәт, вакытым тар. Иркенләбрәк килермен әле,— Кадыйр Кудрявцевның күзенә карамый гына өстәп куйды:— Нәрсә, авырыпнитеп китмәгәндер бит?

— Шулайрак шул әле, сырхаулабрак тора,— диде Кудрявцев.

Кадыйр кузгала башлады.

— Нефтьне биреп бетереп булмас. Хәтта контрольдәге скважиналардан да тоташ су килә башлады.

— Күмер катламына күч! — дип, янә тавышын күтәрә төште Кудрявцев.— Үсеп килгән даныңа үзең үк тап төшермә. Идарәң беренче квартал планын арттырып үтәде. Бу нинди бунт тагын? Башны кем катыра анда? Ниндидер туганың кайткан, диделәр. Аның идеясеме?.. Алай булгач, нигә соң Грозныйда сынап карамаган?! Синең ул энең хәйләкәр булырга охшый. Абыйсының кулы белән ут уйнатырга уйлый. Ә мин сине алдынгылар рәтенә чыгарып ятам, шул мөмкинлекне кулыңнан ычкындыру кем дигәндә юләрлек булыр иде. Күрсәт үзеңне тагын бер тапкыр. Аннары, бәлкем, яңа идарәгә дә күчерербез.

— Кайсы ягым белән күрсәтим? Ятма сүнә. Нефть алу көннән-

көн кими бара, ә син нефть даулыйсың. Ятманы яңа ысул белән эшкәртеп карарга исәп, синең фатихаң кирәк.

— Кара, ничек сөйләшә. Ятма кадәр ятманы туктатып тормакчы. Яңа ысул, имеш. Сим-сим, ишегеңне ач, сандыгыңдагы актык хәзинәңне алабыз димәкчеме? Белгәнемчә, дөньядагы иң прогрессив ысул — катламга су кудыру булды, бу өлкәдә башканы мин ишетергә дә, күрергә дә теләмим. Калдыкны кысрыклау өчен син миңа яңа матдәләр, яңа җисемнәр тап, җегәр көчен арттыр катламның. Ә бит синең баш инженерың акыллырак булып чыкты. Ул, заман кешесе, сүнеп барган ятма белән чирәшмәскә куша һәм мин аның белән килешәм. Идарәне промысел итеп калдыруга беренче булып ул рапорт китерде. Дөрес, мин аны әлегә тоткарлап торам һәм, әйтер идем моны, синең өчен эшлим. Моннан ары да шулай үҗәтләнеп маташасың икән, рапортны момент ходка җибәрәчәкмен. Ишетсен колагың!

— Рәхмәт, кайгыртуың өчен... Тик хикмәт андамыни, Виталий. Хикмәт бит ятма сүнүдә. Бу методны кулланып без шуннан миллионнарча тонна өстәмә нефть алачакбыз.

— Алачакбыз? Аны әллә бирәсең, әллә юк әле син. Кыскасы, квартал планы үтисең, калганы минем эш. Инде үтәмисең икән, идарәңне промысел итеп калдыруга министрлыкка рапортны үзем бирәм. Хәер, без аны үзебез дә хәл итә алабыз. Син алай тырпаерга гына торма әле, Кадыйр.

— Кошка да үз оясы газиз, мин бит — кеше, күпме чирәштем шул идарәдә, ничәмә ел гомерем сарыф иттем.

— Күзгә төтен җибәрмә, миңа нефть кирәк, нефть кирәк. План, план һәм тагын бер тапкыр план! Шуны гына уйларга тиешсең син!

— Аңлашылды. Мин китим инде.

— Зөһрәгә сәлам юлла. Эш эш белән дигәндәй...

Ләкин Әмиров аның соңгы сүзләрен ишетте дә, ишетмәде дә, аның күңеленә гүя кара болыт төште. Кадыйр ашыга-кабалана коридорга чыкты һәм башына эшләпәсен дә кияргә онытып, урамга атлады. Тышта кыеклап салкын яңгыр ява иде, аны да сизмәде. Машинага утыргач та ул бик озак тынычлана алмады, кайтканда машинасын тәмам акрынайткан шоферына төксе итеп:

— Куала бераз, туйдан кайтмыйбыз ич,— диде. Аннары үзалдына:— Тәмам кәефне бозды, тинтәк,— дип куйды.— План, план, имеш. Нәрсә ул минем бугазга баса, ни хакы бар!— дип һаман тынычлана алмый кайтты.

Машина ыжгырып үр менә башлады, кара-күгелҗем тасмадай сузылган асфальт машинаны үзе суыра шикелле, кайчак юл өстендә дулкыннар сикерешкән кебек күренә башлый. Үр менгәч йөз кырык километр белән элдерә башлаган шоферны тыя төшәргә теләп, Кадыйр тамак кырды. Бу аның: «Кара аны, чәпәлеп куюыбыз бар»,— дию иде.

## 7

Тәнзиләнең сүзләре Нәүфәл йөрәгенә агулы ук булып кадалды, ә агуы аның белән дуслашырга ният иткән башка хатыннарга да җитә иде — буйдак ир аларның һәр эшендә я мәкер, я хәйлә күрде. Тормышның кырыс чынбарлыгы аңа һаман-һаман каты орынып торудан аның күңеле кимсенде, кемгәдер ачуы чыкты. Тормыш беркайчан да аның башыннан сыйпамады, шуңамы, ул үз тирәсендә әвәрә килгән кешеләрнең кимчелекләрен җиңелрәк кичерде, ләкин Тәнзиләне кичерә алмады, аның белән исәбе башка иде.

Төшке аш вакытында автоматчылар бригадиры Нәүфәл Әмиров

урман буена урнашкан вагоннан чыкты да бөдрәләнеп утырган каеннарга таба китте. Егетләрнең бер ишесе вагон күләгәсендә тәмәке көйрәтә, кайберләре шахмат уйный яки домино суга, кайсыберсе, яшел чирәмгә ятып, китап укый. Уникe кешелек бригада менә айдан артык инде скважиналарны бергәләп файдалану җайланмасын корып ята. Ун-унбиш скважинаны бергә, бер трапка томалап бәйләргә рөхсәт алгач, Нәүфәл өйгә бөтенләй кайтмас булды. Шуны башлап җибәргәч, алар янына килеп йөргән баш инженер Идрисов бу эш белән техник фәннәр докторы Троянов шөгыльләнүе турында сүз кузгатты. Автоматчылар бригадасын оештыруны баштан ук хупламаган Идрисовның болай өтәләнеп йөрүе сәеррәк иде сәерен, ләкин Нәүфәл моңа игътибар итмәде. Ул яктан килгәндә, аның корылмасында да кайбер кимчелекләр булуы бар иде. Ә инде фәннәр докторы корылманы камилләштерүдә бергәләп эшлик дисә, Нәүфәл бу тәкъдимне бик рәхәтләнеп кабул итәчәк. Иллә баш инженер әйткән Троянов нигәдер алар янына килергә ашыкмый иде. Скважиналарны бер трапка бәйләп кору юнәлешендә эшләүчеләр бер алар гына түгел, күрәсең. Әкеннәр үтә, ике скважинаны гына бәйлисе калып бара, шушы арада килеп чыкса да, соң булмас кебек. Килеп, эшлекле тәкъдимнәр әйтсә, «Спутник» корылмасы моннан отар гына иде. «Әллә соң үземә барып кайтыргамы?— дип уйлады Нәүфәл.— Ерак ара түгел, аннары ул бит доктор, дәрәҗәле кеше».

Июнь кояшы рәхәт итеп арканы кыздыра, урман буендагы чирәмдә төрле төстәге күбәләкләр биешә, ул да түгел, колак яныннан гына төклетура гөжләп уза, кыяк-җилпәзәсен кояшка җәеп салган сары башлы кыр ромашкасында бал корты кайнаша. Нәүфәл урман эченә атлады. Биредә дымсурак, тыгыз һава күкрәкне киңәйтеп, үпкәгә тула, аяк астында — мәңге кысыр абага үләне, соңгы тапкыр дөнья күрергә чыккан зөбәрҗәт алкаларын тәлгәшләп тезгән хуш исле ландыш.

Нәүфәл ак каеннарның берсенә сөяләә һәм йөрәге дөп-дөп тибә башлавын тоя. Нигә ярсып китте әле бу йөрәк дигәнең? Нинди җир бу, алда нинди таныш алан? Шул бит, шул! Шул аланда алар кулга-кул тотынышып йөргәннәр, хәтфә үләндә зәңгәр күккә карап ятканнар иде. Нәүфәл шунда Халисәнең кулын йөрәк турына куйган иде — янәсе, тыңла әле, ничек тибә! Чынлап та, ярсып-ярсып, чабыштан килгән аргамакныкыдай дөпелди иде ул. Хәтерендә, моны сизгән Халисә терсәгенә таянып күтәрелә төште, елмая-көлә Нәүфәлнең күзләренә карады. Халисәнең күзләре куе-кара чәй кебек иде. Якты көндә, зәңгәр күк йөзенең аязлыгында, яшел аланның чагылышында бу күзләр салават күпере сыман нурланып киттеләр. Шунда Нәүфәл дә терсәгенә таянып күтәрелде, аннары торып ук басты, хуш исле үлән-чәчкә арасыннан кызга да торырга ярдәм итте. Шунда, нәкъ менә шунда күзләр кисеште, иреннәргә гүя ут капты. Беренче тапкыр алар шунда, шушы аланда үбештеләр. Ничек атадылар соң әле шуннан соң бу аланны? Кыңгыраулы алан. Әйе, әйе. Кыңгыраулы дип исем бирделәр. Алан тулып кыңгырау чәчәкләре үсә иде. Китәр алдыннан Нәүфәл чәчәкләр җыйды һәм Халисәгә бирде. Әле булса исендә: Халисә чәчәкләрне кочагына алды да, бал корты сыман, борынын чәчкә бәйләме эченә төртте, күзләрен йомды һәм, исереп китүен аңлатырга теләп, авып китә язды, Нәүфәл аны көчкә тотып өлгерде, аннары икесе дә көлешергә тотындылар. Гомумән, юк кына нәрсәдән дә көләргә сәбәп табалар иде алар.

Нәүфәл, каеннан аерылып, тураеп басты, чалт аяз күк йөзенә карады. Бөдрә каен очлары арасыннан аяк астына кояш нурлары үтеп керә һәм алар, көмеш тәңкәгә әверелеп, зыңлап китәләр кебек. Нәрсә бу, кинәт кенә хисләнеп китүдән шулаймы? Шушы таныш аланны

күргәчме әллә?.. Тукта, сабыр ит. Бер дә юктан гына түгел бу. Һаман аны шулай яратуданмы әллә? «Мин аны яратам, әле булса яратам. Тик ул кияүдә бит, күптән инде кияүдә. Кемдә? Яшьлек дустың Гайсәдә. Кайчандыр, мыек йоны тибеп чыга башлаган вакытта, тана хәтле эт янында ташлап калдырып китүче классташ Гайсәдә!..»

Нәүфәл янә аяк астына карый, һични күрмәс күзләре белән карый, тик бераз торгач кына күрә башлый. «Күрче, аяк янымда ук кыңгырау чәчәге». Иелде, әмма кагылмады. Зәңгәр чәчәкләр боегып башларын игәннәр, кагылдың исә, көмеш кыңгырау чыңнары чыгар шикелле. «Мин аны моңа кадәр нәфрәт хисе тәэсирендә генә күңел түрендә йөртәм дип уйлый идем. Мин аны яратам икән бит, әле дә булса өзелеп сөям икән бит! Димәк, мин аны күрергә тиешмен. Бүгенме, иртәгәме — шарт итеп куймыйм, әмма барыбер мин аны күрергә тиеш».

Кемдер аңа: «Кеше күңеле — хәзинә, андагы истәлекләрне әрәмшәрәм иттеңме, кадерен җибәрдеңме, бик тиз рухи бөлгенлеккә төшәчәксең»,— дип әйткән иде. Әллә соң?..

Нәүфәл янә ак каенга сөялде, хис тулы күз карашы кыңгырау чәчәкләрдә. Шунда ук Кыңгыраулы аланда йөрүче ак күлмәк кигән берәүне күрде. Йөрәге тагын күкрәгенә сыймас дәрәҗәгә җитеп тибәргә тотынды. Шушы истәлекле уйлар, кинәт кенә Кыңгыраулы аланда пәйда булган хатын-кыз аны гүя күккә күтәреп менеп китте; ул, татлы шәраб эчкәннән соң кисәк кенә исереп киткәндәй, Кыңгыраулы аланга таба берничә адым ясады, тик шунда ук тораташтай катып калды. Чәчәкләр җыеп йөргән ак күлмәкле хатын-кызда ул аның чалымнарын, йөреш-кыяфәтен күрде, хәтта күксел-кара чәчләре дә нәкъ аныкыча иңбашларына таралып төшкән иде. Икенче мәлдә аңа ул җир кызы булып түгел, күктән иңгән фәрештә булып тоелды. Юк, алай да түгел, кинәт кенә Кыңгыраулы аланда пәйда булган тылсымлы кыз — ак каеннарның берсе икән, гүя чәчләрен иңбашына сибеп утырган каеннарның берсе кузгалып киткән дә үзенә яңа иптәш эзли.

Нәүфәлнең бөтен тәне калтырый башлады, ул, аяк астын тоймас хәлгә җитеп, акрын гына җиргә шуышты. Ак каенның юка тузы аркасын сыдырды, ул аны сизмәде, тоймады: каеннар арасыннан җир өстенә коелган «көмеш тәңкәләр», аланда чәчәкләр җыеп йөргән ак күлмәкле кыз, башын түбән игән зәңгәр кыңгырау чәчәге, тирә-юньдәге һәммә нәрсә бер мизгелдә күз алдыннан юкка чыкты — ул җиргә утырды, башын тезләренә салды һәм, мәрткә киткән бер рәвештә, уйга чумды.

...Кайчан бер-берсенә тартылып куйдылар алар? Кайчан аңа карата Нәүфәл күңелендә үсмерләргә хас ярсу гыйшык уты кабынды? Фехтованиегә йөри башлагачмы? Тәгаен шунда. Әле булса хәтерендә, Нәүфәлнең рапира тота белмәвеннән Халисәнең башта тәмам гайрәте чикте. Нәүфәл еш ялгышты, нервланды, каушады, аның җайсыз һәм килбәтсез хәрәкәтләреннән Халисә соңынтын эче катып көлде. Рапирачылар ярышында берничә тапкырлар катнашкан кыз гаять оста алыша, Нәүфәлнең рапирасын читкә атып кына тора иде.

— Әй син аны кысып тотма, әүвәл гәүдәңне сакла, җитезрәк тайпыл, җитезрәк,— дип хәленә кергән булды кыз. Нәүфәл аңа тагын, тагын ташланды, әмма җитез мушкетер кызны бер тапкыр да кадый алмады. Шул вакыт алар янына тренер килде. Ул аларның көрәшләренә карап торды-торды да:

— Халисә, ишетәсеңме Ишкова, уен-көлкесез генә өйрәт әле син аны. Үзеңнең беренче көнеңне онытмадыңмыни. Әй синдә,— дип тренер Нәүфәл янына килде,— җитезлек бар, егетем. Шуңа осталык та өстәлсә... Әй осталыкка ирешеп була, теләк кенә кирәк. Әмиров бит әле син?

— Әйе.

— Бик әйбәт. Тренировкалар бездә кичке сәгать алтыда башлана, шефың менә дигән, республика чемпионы,— тренер Халисә ягына күрсәтеп, күз кысып алды.— Уңышлар сиңа.

Шулай диде дә тренер китеп тә барды.

Тренировкалардан соң кайтып китер алдыннан ул аңа мушкетерлар турында китап китереп бирде.

— Укып чык. Ярдәме тими калмас.

Шул көннән алып, Нәүфәл тормышында яңа бер дөнья башланды. Тренировкаларга бару вакытын көтеп ала алмый иза чикте. Чөнки анда Халисә бар иде. Тутсылрак йөзле, кара кашлы, җете кара күзле, тал чыбыгыдай нечкә, зифа, сылу гәүдәле. Әлбәттә, кыз аңа башта һич игътибар итмәде. Ул бит республика чемпионы, ә Нәүфәл ни барысы өйрәнчек. Ләкин ул өйрәнчекләр арасыннан бик тиз аерылып чыкты. Егетнең өлгерлеген күреп алган кыз аңа карата игътибарлырак була башлады. Алышырга еш кына аның тасмасына басты. Һәм: «Молодец! Шулай, көтмә дошманны, һөҗүм ит, кыюрак, кыюрак»,— дип дәрт бирep торды.

Әй, ул көннәрне искә төшерсәң!.. Кайда гына бармасын, Нәүфәл таяк тоткан булыр, ул аны кулыннан да төшермәде. Иртән торса да шул, кич тә. Егет хәтта ябыкты, күз төпләренә күксел сызыклар төште. Дөрес, күзләре эчкә батуда, йокысыз ятуда башка бер сәбәп тә бар иде — егет кызга гашыйк булды. Ул аңа яратуы турында әйтмәде, аллам сакласын, икесе дә унынчыда укып йөрсәләр дә, ни әйтсәң дә, кыз чемпион иде бит. Нәүфәлнең моңсуланып калуын, үзгәрүен чемпион да сизде, ни сәбәпледер егеткә мәгънәлерәк итеп карый башлады. Нәкъ менә шул көннән алар арасында күзгә күренмәгән кызыл җеп тартылып куйды. Кичке якта, тренировкадан соң, Нәүфәл аңа ияреп чыкты, озата китте. Халисә моңа кадәр үзен һичкемнән озаттырганы юк иде.

— Мин үзем дә юлны бик яхшы беләм!— дип, кырт кисеп, озатырга бәйләнгән егетләрне суынырга мәҗбүр итә иде. Бүген исә ул да аяк астына караган да әкрен генә атлый.

— Беләсең килсә, Нәүфәл,— дип башлады кыз, — минем егетем бар. Гайсә исемле. Сезнең мәктәптә укый.

Нәүфәл Гайсәне белә иде. Ничек кенә әле! Ә теге эт вакыйгасыннан соң Нәүфәл аның белән ике айга якын сөйләшмәде. Өченче айга киткәч, Гайсәнең әтисе икенче районнан яңа квартира алды һәм алар күчеп киттеләр. Шуннан бирле күрешкәннәре юк. Чынын гына әйткәндә, күрәсе дә килми иде Нәүфәлнең ул тәкәббер дустын.

— Бергә, бер параллель класста укыдык без аның белән, беләм мин аны.

— Ә син егетем бар дигәнгә үпкәләмәдеңме? — Нәүфәл башын түбән иде, бер тын дәшми барды.— Их син, мушкетерҗан! Үпкәләдең бит!

— Беләсеңме, Халисә... Бер сүз әйтимме үзеңә.

— Әйт!

— Миңа калса, бу төр спорт кызларга бер дә килешми. Гүзәл затларга гүзәл уеннар гына хас булырга тиеш.

— Фехтование, Нәүфәл, житезләр, кыюлар спорты.

— Ялгышасың, Халисә. Мин сине башка урында күрергә теләр идем. Гимнастка итеп, мәсәлән.

— Ә миңа фехтование ошый.

— Миңа да ошый. Тик мин бит...

— Ошый.— Кыз ул арада ике таяк табып китерде.— Тот әле, мушкетерҗан, алышабыз. Кем беренче итеп кадый, шул хаклы.

Мушкетер кыз таягын чожлатып кояш ясап алды.

— Кирәкми, Халисә.
— Бас тасмага, куркак җан.
Нәүфәлнең көрәшкә нияте юк иде, шулай да кызның боерыгына карусыз буйсынды.
— Саклан, мушкетерҗан, саклан!
Егет шунда ук ике укол алды һәм таягын читкә ташлады.
— Бирелэм. Син хаклы. Сез.
— Ярар, — диде кыз. — Син булгач, син булсын.
Халисә таягы белән тагын кояш ясап алды.
— Өегезгә дә җиткәнбез икән.
— Сөйләшмә. Син минем әсирем. Ишеттеңме, әсирем. Хәзер тыңла: иртәгә иртәнге сәгать унда мине чишмә буенда көтәсең.
— Мин иртәнге якта укыйм, дәресләрем бар.
— Молчать! Әсирме син, түгелме! Әсир икәнсең тыңла. Иртәгә сәгать унда мине чишмә буенда көтәсең!
— Аңлашылды.
— Аңлашылдымы? Хәзер әйдә безнең ишегалдына, — кыз аңа якын ук килде. — Урта Азиядән алма посылкасы килде. Мин аны куак астына яшереп куйдым. Әйдә.
Халисә егетне кулыннан алды да ишегалдына әйдәде, кече капкадан сак кына керделәр.
— Әтиең кайда эшли соң синең?
— Тс-с, шаулама, утыр менә монда.
Кыз эскәмиягә бер әрҗә алма күтәреп куйды. Шул мәл Нәүфәл күрше куак төбендә дәү эт күрде. Эт ырылдап алды.
— Джек, бар ояңа кереп ят! — дип боерды аңа кыз.
— Нигә этегезгә кеше исеме куштыгыз?
— Әти кушты. Әти карый аны. Мин аның белән уйныйм гына. Кайчак кич белән урамга ияртеп чыгам, Джекны күрәләр дә хулиганнар якын да килми. Акыллы ул, гел кеше кебек.
— Кеше акылы булса, аңа эт димәсләр иде... Теләсәң ни әйт, мин сезнең этне кайдадыр күргәнем бар.
— Аша инде, — Нәүфәл тәмләп алма ашый башлады. — Тәмлеме? — дип сорады аңардан Халисә һәм үзе капкан алманы егеткә каптырды. — Серең сөйләрсең.
— Минем синнән яшерер серем юк.
— Булмасын да, Чөнки син миңа ошыйсың. Давай дуслашабыз?
— Әйдә.
— Кап әле менә шул алманы.
Нәүфәл башламаган алманы тешләп алды, Халисә аның янәшәсенә килеп утырды һәм алманың икенче ягыннан капты. Кызның чәчләре кагылып, егетнең битен рәхәт итеп кытыклады.
— Тешлә!
— И-и, — диде кыз көлемсерәп. — Бигрәк зур авызлы икәнсең, бер кабуда ярты алманы юк иттең.
Кемдер өйдән чыкты, болдырга басып, тыңлап торды.
— Кем анда, Халисә синме!
Дәшүче Халисәнең әнисе иде.
— Әйе, мин, әнием! — диде.
— Кер инде, соң бит.
— Хәзер, әнием. Менә Джекны гына ашатам да.
— Мин аны ашаттым инде, бозма этне.
— Хәзер керәм.
Әнисе кереп киткәч, Халисә алмаларны Нәүфәлнең кесәләренә тутыра башлады.
— Иртәгә чишмә буена алып килерсең. Ә менә болары әниеңә. Пока.

...Нәүфәл төне буена рәтләп йоклый алмады. Әллә ни булды егеткә, тәмам сихерләде үзен мушкетер кыз. Чишмә буена ул бик иртә җыена башлады. Әнисе моңа шикләнә калды.

— Нишләп мәктәбеңә бик иртә җыенасың. Тагын металлолом җыясызмы әллә?

— Әйе, металлолом җыябыз,— дип күзен дә йоммый алдады әнисен Нәүфәл һәм колак очларына чаклы кызарынды.

— Атаңнан хат бар, җавап язар идең, ичмасам. Үтен, ялвар үзеннән, кайтсын иде инде. Китүенә биш ел булды бит... Мине санга сукмый инде ул, балигъ булган улын тыңлар иде, ичмасам.

— Ярый, язармын.

...Тау битендәге чишмә янында һичкем юк. Чылтыр-чылтыр чишмә ага. Нәүфәл чишмә тирәли хәтфәдәй җәелгән куе яшел үләнгә кырын төште. Чәберчек очынып йөри, коерыгын селкеп сары түш таш өстендә кемнедер чакыра. Шәһәр яклап, чишмәгә таба килүче берәү күренде. Чәчләре иңнәренә сибелеп төшкән. Нәүфәл аягүрә басты. Бу — ул, Халисә иде. Егет кызга каршы йөгерде. Кыз да йөгерә башлады. Йөгерешеп килделәр дә, сулышларына кысылып, күзгә-күз карап туктап калдылар. Икесе берьюлы көлеп җибәрде. Егет кызның кулларыннан алды, аны чишмәгә таба әйдәде. Чишмә янына җиткәч, егет кызны җилтерәтеп әйләндерә башлады. Халисә куркынган булып кыланды, әмма үзе бик рәхәтләнеп көлде, уйнады. Аннары туктап, янә күзгә-күз карашып тордылар. Тирә-юньдәге тереклек алар өчен кинәт юкка чыкты, дөньяда алар гүя икәүдән-икәү генә калдылар. Башта Халисә исенә килде, кайнарланып киткән йөзен сүрелдерер өчен салкын чишмә суы белән битен юды. Шуннан соң икесе бер ташка утырдылар да еллар, гасырлар үтеп, чуер ташка әверелеп беткән шома ташларга бәрелә-сугыла чылтыр-чылтыр аккан чишмәгә карап тын калдылар. Бер-берсенең ни турында уйланып утыруларын белгәндәй, икесе берьюлы тирән итеп сулап куйды. Әллә соң шушындый минутларда туамы ул мәхәббәт дигәнең?! Нәүфәл күңеле тулышудан гаҗиз калып кызның судагы сурәтенә карый, ә чишмә суындагы сурәт, бозык телевизор экранындагы кебек, әле бозыла, әле рәтләнә.

— Күр әле, Нәүфәл, күрче нишләтә берәүне бу чишмә! Абау, битйөзең шулай җәелеп китә күрмәсен!

Кызның алсу иреннәрендә чишмә суының тамчылары елтырый, күзләрендә бетмәс-төкәнмәс шатлык нуры балкый. Мәңге калдырасы иде хатын-кыз иреннәрендә энҗедәй саф, чиста су тамчыларын, мәңге калдырасы иде беренче гыйшык кабынган минутларда балкып киткән шатлык нурын, мәңге, мәңге!

Шул мәлдә Нәүфәл күңелендә тулышкан шатлыктан сикереп торды да, ат башы хәтле алтын тапкан берәүдәй, үрле-кырлы сикерергә тотынды, ул да түгел, Тарзан рәвешенә кереп, кычкырып алды, аннары таштан-ташка сикерә-сикерә чишмә типкән төбәккә кереп китте. Егылып китә язды. Кыз: «Аh!» итте. Нәүфәлгә шул гына кирәк иде дә, ул суга сикереп төште, тез тиңентен су ерып кыз янына чыкты.

— Юләрем,— диде кыз аның яңагыннан сөеп.— Нишләвең бу?

— Минем дөньяны иңлисем килә, Халисә.

— Сихерле урынмы әллә ул. Мин дә керәм.

Шулай диде дә кыз таштан-ташка сикерә-сикерә эчкә кереп китте һәм шундый ук җитезлек белән әйләнеп тә чыкты. Нәүфәл аңа кул бирде, үзенәрәк тартып алды. Кыз башта егеткә елыша төште, ахырда әллә инде оялып:

— Нәүфәл, җибәр. Җибәр инде,— дип йомшак кына ялваргандай итте.

Егетнең кызны җибәрүе булды, шуны гына көткән кебек, Халисә чыр-чу килә-килә үргә таба йөгерде. Нәүфәл аны куа китте.

— Куып җит!

Җитез иде кыз, шундук каеннар арасына кереп югалды. Нәүфәл аны көч-хәл белән куып җитте. Юк, җитә алмады, Халисә үзе адымын баса төште. Ул да түгел, зур аланлыкка килеп чыктылар. Халисә түгәрәк аланлыкны кисеп узды да бер каен артына посты. Нәүфәл аны күрмәмешкә салышты, юри югалткан булып кыланды, эзләгән итте. Һәм бер җай китереп Халисә яшеренгән каен ягыннан узганда кинәт шул якка ташланды, әмма кыз урынына каенны кочып алды.

— Менә ул мин эзләгән сылу,— диде егет сер бирмәскә тырышып.

— Шул микән,— дип көлде Халисә эчен тота-тота.

— Ә менә икенчесе, нәкъ мин эзләгәне,— диде егет, кыз көлгән арада аны кочагына алып.— Халисә, мин...

Кайтканда кыз, хәзер барысы да мин дигәнчә генә булачак дигән сыман:

— Төштән соң, сәгать дүрткә киногa барабыз. Билетлар алып куй. Килермен,— диде.

Нәүфәл өчен бу кимендә боерык булды. Һәм ул аны ничек бар, шулай карусыз кабул итте.

Билетларны ул кайтышлый ук кереп алды.

...Кинотеатр ерак түгел иде, ун минут кала барырга чыкты. Ләкин юлда эштән кайтып килүче әнисен очратты.

— Син кая болай, Нәүфәл? Дәресләреңне кайчан карарсың?

— Бүген өйгә эш бирмәделәр.

— Киногамы әллә?

— Әйе.

— Акчаң бармы соң? Булмаса, мә.— Әнисе бер сум көмеш тоттырды.— Юк-барга әрәм-шәрәм итмә... Ә атаңа хат яздыңмы?

— Кайткач язармын инде. Хәзер генә мәктәптән кайттым,— дип, бер көндә икенче тапкыр ялганлады Нәүфәл һәм, әнисеннән уңайсызлана калып, күзләрен читкә алды.

— Аны-моны эшләп ташламагансың бит, ник алай күзгә туры карарга уңайсызланасың?

— Юк. Болай гына. Ярый, мин киттем.

Әнисе Нәүфәлнең биш минутын юк итте. Кинотеатрга янә биш минутлык юл калган иде. Әнисе чатка күмелүгә, Нәүфәл җан-фәрманга йөгерә башлады. Чаттан борылуга Халисәнең кызыл күлмәге күренде. Чишмә буенда да шул күлмәктән иде кыз. Ул арты белән баскан иде, Нәүфәлне күрмәде. Ләкин икенче бер күренеш егетне баскан җирендә шым булып калырга мәҗбүр итте: кыз янында, әле чишмә буенда гына үбешкән Халисә янәшәсендә Гайсә басып тора һәм кызып-кызып нидер сөйли иде. Халисә, тирә-ягына карангаласа да, аны дикъкать белән тыңлый. Ул да түгел, икесе берьюлы көлешергә тотындылар. Нәүфәлнең битләре ут булып янды, йөрәге күкрәгенә сыймас булып тибәргә тотынды. Ул теләр-теләмәс кенә почмакка чигенде. Гайсә итагатьле итеп кызны култыклап алды һәм алар кинога кереп киттеләр.

Нәүфәл янак итеп чәйнәде, җен ачулары чыкты. Башта аның фойега кереп Халисәне оялтасы, битенә төкерәсе килде. Әмма алай итмәде. Билетларын ертып ташлады да китеп барды.

Ярсулы ачуыннан ул хыял белән кинозалга үтеп керде, Гайсә белән Халисә утырган урыннарны тапты да, тегеләрнең икесен тиң тышка сөйрәп чыгарды, егетне кеше танымаслык итеп кыйнады... Шулай тилереп, уйлана-хыяллана урам-тыкрыкларда тулганып йөри торгач, кич җитүен, кояш байый башлавын сизми дә калды. Иң сәере

шул буйды: бу вакытта ул Халисәләр капкасы янында басып тора. Кыз исә мыскыллы көлемсерәп ишегалдында аңа карап тора иде.

— Хыянәтче, алдакчы,— диде кыз аңа ачулы итеп.— Ник киногa килмәдең?

— Үзең, үзең... кем белән басып тора идең. Миннән билет алдырдың, аның белән киногa кереп киттең. Син үзең хыянәтче.

Нәүфәл ишегалдына керде, ачудан аның борын яфраклары агарынган иде.

— Мин алдакчыларны яратмыйм,— диде кыз баскан урыныннан кузгалмыйча.— Ә син алдакчыларның алдакчысы.

— Минме алдакчыларның алдакчысы?!

— Син, син!— кыз ни әйтергә белми ярсынды.— Син! Куркак, йоны коелган койрыксыз күркә!

— Әй, ни хакың бар синең мине мыскыл итәргә?

— Чыгып кит йорттан. Калай этәч!

— Китмәсәм нишләрсең?

— Нишләрменме?!— диде кыз, артына каерылып карап.— Джек! Шунда гына Нәүфәл куак янында торган этне күрде. Әйе, бу эт аңа таныш иде. Егет шунда ук коймага сөяп куелган көрәккә таба омтылды.

— Джек, өс!— дип өлгерде кыз.

Нәүфәл ике адым ясарга өлгермәде, аның өстенә, авыр капчык булып, эт килеп бәрелде һәм аның муенына әйтерсең лә кинәт утлы күмер кисәве тиеп китте. Икенче мәлдә инде ул аңын җуйды. Соңгы секундта аның колак очына Халисәнең чырыйлап кычкырып җибәрүе ишетелеп калды...

Истәлекләрдән арынып, Нәүфәл торып басты, әкрен генә будкага таба китте.

...Гайсә белән ике ара ничек иде соң әле? Әйе, алар арасында беркайчан да чын дуслык булмады. Ә бер хәлдән соң Нәүфәл аның белән бөтенләй сөйләшмәс булды. Ял көне иде, ике класс бергә урманга чыгарга җыена. Гайсә аңа иртән иртүк килеп керде.

— Якты күлгә барабыз,— диде ул.— Минем сылуның әтисе шунда дача корган, теләсәң кереп чыгарбыз.

— Исеме ничек сылуыңның.

— Исемендәмени хикмәт. Хан кызы, гүзәлләрнең гүзәле. Сирәк исемле кыз.

— Сирәктер,— диде Нәүфәл, капчыкка ипи, тоз, йомырка, колбаса кисәге сала-сала.

— Ашарга алма. Берни дә кирәкми. Әйтәм бит, минем сылуларга кереп чыгарбыз. Анда җаның ни тели, шул булачак.

...Якты күл буенда халык гадәттәгедән күп иде. Укытучы апалары егетләрнең гитара алмауларына үпкәсен белдерде. Күл буендагы наратлар төбенә утырыштылар.

— Кирәк булса гитара таба алам мин,— диде шунда Гайсә.

— Тап әле, тап,— диеште кызлар.

— Ярты сәгатьтән гитара биредә булыр. Үземә бер кешене ияртергә рөхсәт итәсезме?

— Теләсәң хет икене иярт, Гайсә, алып кына килә күр!

— Әйдә, Нәүфәл. Шул җиткән миңа,— диде Гайсә.

Наратлар арасыннан елан сыман сузылган сукмаклардан атлый торгач, бизәкләп салынган, төрле төсләргә буялган дача йорты каршына килеп чыктылар.

— Күрәмсең җәннәтне,— дип, терсәге белән кагылып алды Гайсә артыннан шәүлә кебек килгән Нәүфәлгә.

— Да, күңелле биредә, хәйран,— диде Нәүфәл соклануын яшермичә.

— Этләренә игътибар итмә,— диде Гайсә кече капканы ачып эчкә кергәндә.— Мине белә ул.

Дача өеннән ун метрлар гына читтә утырып торган эт аларга колагын тырпайтып карап алды да, Гайсәне танып, дәү башын аякларына салып, сузылып ятты.

— Әйттем бит мине таный дип. Әйдә,— дип, Гайсә кыюланып ишек янына таба китте. Нәүфәл аңа иярде. Гайсә болдыр баскычы астындагы иске чүәк эченнән өй ачкычын табып алды. Ишекне ачты. Эчкә үттеләр.

— Ашап-эчеп тормыйбыз,— диде Нәүфәл.

— Әлбәттә.— Гайсә ашыгып икенче катка менеп китте, ул да түгел, кулына гитара тотып килеп тә чыкты.— Әйдә.

Чыктылар, ишекне бикләгәндә Гайсә гитараны Нәүфәлгә бирде. Капкага таба юнәлделәр, ләкин ни хикмәтер, кергәндә бер читтә ятып торган эт, егетләр чыкканда кече капка янына күчеп утырган иде. Бу хәлне күреп, эт мине таный дигән Гайсә дә шүрли калды. Шулай да эткә таба бер-ике адым ясады.

— Джек, ишетәсеңме, кит юл өстеннән!

Эт аны тыңламады гына түгел, иреннәрен калтыратып, үткен тешләрен күрсәтеп ырлап куйды.

— Нишлибез?— диде Нәүфәл.

— Миңа тимәс ул, мин чыгам, ә син гитараны койма аша ташларсың.

— Ә ничек чыгармын?

— Чыккач мин аны бер як читкә чакырып алырмын.

Гайсә сак һәм вак кына атлый-атлый эткә таба якынлашты.

— Джек. Юләрләнмә син алай. Дуслар бит без синең белән, менә дигән дуслар. Джек...

Чынлап та, эт, Гайсәне танып, әлбәттә, сукмак өстеннән бер яккарак тайпылды, баягыча, башын тәпиләренә салып, иренчәк кенә күзәтә башлады.

Гайсә чыгып китте, әмма аның артыннан Нәүфәл кузгала башлауга, эт алгы аякларына күтәрелде, тешен ыржайтты.

— Ташла гитараны койма аша,— диде урам якка чыгып баскан Гайсә.

Нәүфәл гитараны урам якка атты, эт гитара артыннан карап калды, әмма артык хәрәкәт ясамады.

— Чык әйдә үзең. Хәзер тими ул.

Тик эш Гайсә әйткәнчә булмады, Нәүфәлнең капкага бер адым ясавы булды, эт янә тешләрен ыржайтып, ырылдый ук башлады.

— Нәүфәл, ул сине хуҗалары кайтканчы барыбер җибәрмәс. Мин киттем. Кызлар көтәләр. Егет сүзе бер булырга тиеш.

Нәүфәл дәшмәде, Гайсә китеп баргач, ул җиргә утырды, текәлеп эткә карады. Эт тә башын кире аяклары өстенә салды һәм күзләрен йомар-йоммас Нәүфәлне күзәтә башлады.

Шунда Нәүфәл сукмак читенә тезгән бер кирпечне суырып чыгарды да ишек ягына ташлады. Эт сикереп торды һәм кирпеч артыннан омтылды, ул арада Нәүфәл капкага ташланды, әмма эт егет артыннан килеп, инде капкадан чыгып барганда гына аның чалбар балагыннан кабып өлгерде. Балак шытырдап ертылып китте һәм тез башында гына җилфердәп калды. Шулай да Нәүфәл, бер ычкынып киткәч, йөз метрлар чамасы чабып барды. Шуннан соң гына туктап, чалбарына игътибар итте. Эт чалбарның кеше күзенә күренерлеген калдырмаган иде...

Шул вакыйгадан соң Гайсә белән бер тапкыр да исәнләшмәде Нәүфәл. Шулай да аны күңел түреннән кинәт кенә алып та ташлый алмады. Гүя Гайсә аның күләгәсенә әйләнде. Теге чакта ул Нәүфәлнең беренче мәхәббәтен тартып алды. Бер карашка бик күптән үткән хәл иде бу, тик күңел дигәнең әллә нигә онгыттырмады шул Гайсәне, әледән-әле хәтерләтеп, искә төшереп торды. Ул читкә чыгып киткәч, Гайсәнең нәкъ менә Халисә барасы институтка укырга баруы, Халисәгә өйләнүе, туган шәһәрләренә кайтып, бергәләп бер больницада эшли башлаулары Нәүфәлгә кеше ышанмаслык хәл булып тоелды. Кайчак та хәтта аңа ике дошманы бергә берләшкәннәр дигән уй килгәли. Ләкин уйлана торгач, ул аларның икесен дә аклый, аерата Халисәне акларга тырыша иде. «Этне ул болай булыр дип өстермәгәндер», — дип, теге коточкыч хәлне онытырга тырыша иде.

Әйе, күпме генә үчле булырга теләмәсен, Гайсәдән битәр, иң әүвәл Халисәне күрәсе килде аның. Кайтуы гел аның өчен генә булмаса да, аны күрергә дә кайткан иде ул.

## 8

Идрисовның тәкъдимен беренче булып Кудрявцев күтәреп ала. Кадыйр белә иде: баш инженерның дәлилләре нык, ятма чынлап та сүнүгә таба бара, Идрисов тәкъдимен инкарь итү өчен Кадыйрга корычтай дәлилләр табарга кирәк булачак, ул гынамы, күтәреп чыккан идеяңне исбат итәргә туры киләчәк. Һәм кайда да булса түгел, Берләшмәдә, аның бөтен белгечләре алдында, бәлкем әле министрлыкта да булуы бар. Чөнки ятма кадәр ятманы ун көнгә туктатып тору уен эш түгел, Берләшмә ул арада меңнәрчә тонна нефть югалтачак. Җитмәсә министрлыкта Кудрявцевның дәрәҗәле исеме бар, әлбәттә, Берләшмәдә дә, министрлыкта да иң әүвәл аның сүзенә колак салачаклар. Юкка гына күтәреп чыкмады микән ул Нәүфәлнең идеясен? Бу тәгаен ходайдан каргалган эш булды. Ятманы файдаланудан туктатып тору мәсьәләсендә Идрисовка өмет тотмый иде Кадыйр, алай да, соңыннан сүзе булмасын өчен дипме, баш инженерны чакырып тагын бер тапкыр сөйләшергә булды.

— Хәлләр бик шәптән түгел бит әле, Вәгыйз Исламович.

— Алай дип әйтергә мин бер дә нигез күрмим, киресенчә, дәүләт күләм күзлектән чыгып эш иткәндә министрлык безгә бу чарага бик вакытлы керештегез дияр кебек.

— Нинди чарага?

— Идарәне промысел итеп калдыруга.

Кадыйр янә Идрисовтан өметен өзде, бу кеше аның хәленә керергә теләмәде генә түгел, Нәүфәл идеясен бөтенләй санга сукмыйча, ул Кадыйрга аяк чалырга ук җыена иде. Тик шуны гына аңламады Кадыйр: чынлап та, дәүләт күләмендә шушындый югары кайгыртучанлык күрсәтергә теләвеме бу кешенең, әллә булмаса Кадыйрдан үч алуы гынамы? Әгәр дә мәгәр кайгыртучанлык нияте белән эш итә икән, Кадыйр хәтта аның хәленә дә керергә әзер иде. Тик бүген түгел. Бүген аңа үз фикерен үткәрергә, идарәне идарә итеп калдырырга һәм, иң мөһиме, моңа хәтле чыгарган нефтьнең күләмен бер генә тоннага да киметмәскә кирәк иде. Әмма бу изге максатка нинди чаралар, нинди юллар белән ирешергә? Бәлкем ятманы ял иттерә-иттерә файдалану нәкъ менә шул чараларның берседер?

— Мин сезнең ниятегезне аңламыйм, Вәгыйз Исламович.

Идрисовның маңгаена җыерчыклар өелде, ул, башын күтәрми генә, Кадыйрга күз төшереп алды, ирен чите белән елмайды һәм башын чайкап куйды.

— Ният изге минем, Кадыйр Сөнгатович. Идарә аппараты елдан-ел күперә. Ничек шуны аңламыйсыз. Мангышлакка, Төмәнгә белгечләр кирәк, ә бездә һәр бүлектә унышар кеше утыра һәм, әйтер идем, күбесе төпле эш белән шөгыльләнми.

— Моны сез производство киңәшмәсендә кузгатыгыз, Вәгыйз Исламович. Бүлектәге һәр белгеч җитди эш башкара, һәммәсе ниндидер бер участок өчен җавап бирә бит. Әйтик, менә сезнең кул астындагы механика бүлеген генә алыйк...

— Рөхсәт итсәгез, мин бүлектә нибары ике кеше калдырыр идем.

— Вакыты җиткәч, бәлкем чынлап та ике генә кеше калдырылыр, ләкин бүген һич тә мөмкин хәл түгел бу, иптәш Идрисов.

— Сүз дәүләт акчасын туздырып ятучылар турында бара.

Кадыйр үзалдына уйланып алды. Нигә ул Идрисов белән дусларча гына сөйләшә алмый, ә бит уртак тел табарга тырышу аның тарафыннан булмады түгел. Әмма ул һәр вакыт ниндидер күзгә күренми торган диварга барып төртелде. Идрисов аны аңларга теләмәде, әллә инде тамаша дошман күрүе иде?

— Бүген сүз ул турыда түгел, иптәш Идрисов, ә ятмада яшеренеп калган нефтьнең, һич югы, сигез-ун процентын алу турында бара.

— Ятма сүнә, Кадыйр Сөнгатович. Бу турыда нинди сүз булырга тиеш ди. Бердәнбер чара: идарәне промысел итеп калдыру.

Элек Кадыйр үзе дә, ятмада нефть запасы бетүгә таба барганда, яңа районнарга таба кузгалырга кирәк булыр дигән уй белән яшәде. Һәм, чынлап та, телиме моны Әмиров, юкмы, бу язмыш аның идарәсенә дә киләчәк иде. Ләкин менә Нәүфәл кайтып, яңа идея биргән булып күңелне котыртты. Ләкин Идрисов үз фикерендә калды: идарәне промысел итү — чор таләбе дип барды.

Дөнья яратылганнан бирле өзлексез туып, бер-берсе белән гел чәкешеп торган төрле идеяләр, теорияләрнең бары тик меңнән берсе аксиома була алган һәм ниндидер законга нигез салган, шул ук вакытта, шушы алдынгы фикернең, идеянең, теориянең берсе дә көрәшсез, хәтта сугышсыз, фаҗигасез тормышка ашмаган. Идеяләр көрәше дәвам итә, бәлкем аларның колачы, алымы, күләме үзгәрә торадыр, әмма мең еллар элек башланган көрәш бүген дә дәвам итә һәм яңа бик күп еллар итәр. Гомумән, кешеләр яшәгән мохитта идеяләр көрәше бетмәс ул.

Кадыйр инде Нәүфәл идеясен тормышка ашырырга ашкынып йөри. Моның өчен аңа кемнәр беләндер конфликтка керергә, хакыйкатьне эзләргә туры киләчәк. Аңларлармы аны? Кирәк дип табарлармы Нәүфәл идеясен? Идрисов исә әнә тыңларга да теләми, аңа азрак мәшәкать, күбрәк дан булсын, андыйлар гадәттә катлаулы проблемаларны хәл итүдән куркалар, тизрәк читләтеп үтү ягын карыйлар. Берләшмә, министрлык әһелләре ни әйтерләр?..

— Девон катламында нефть бетсә, күмер катламына күчәрбез. Алгарак күз салсак, битум запасына керешергә вакыт җитеп бара кебек. Кая болай ашыгасыз, Вәгыйз Исламович? Ярый, бөтен булган байлыкны пыран-заран китердек ди, киләчәк буынга ни калдырырга исәп тотасыз?

— Моңа безне реаль хәлләр мәҗбүр итә. Акны — ак, караны — кара дип әйтергә, ниһаять, сезгә дә ярыйдыр, Кадыйр Сөнгатович. Торып-торып шаккатам мин сезгә, соңгы вакытта чиле-пешле шул идеядән башка һичнәрсә күрмәс булдыгыз.

— Сез мине беркайчан да аңламадыгыз, иптәш Идрисов. Гаҗәп хәл, тискәрелек галәмәтеме бу, әллә идеяне кабул итмәү теләгеме? Нинди тәкъдим күтәреп чыксалар да, сездә шуңа негатив караш була. Бу ни бу? Моннан ары безгә бергә эшләү кыен булачак.

— Күпкә түзгәнне азга түзәрсез, шәт. Мактала-мактала алыштыр-

мас шәхескә әйләнеп китә күрмәгез, Кадыйр Сөнгатович. Соңга калыбрак булса да сезгә киңәш итәр идем: китегез Виталий Семенович тәкъдим иткән җиргә. Чын күңелдән әйтәм, сезнең өчен бик кулай урын ул.

Кадыйр, ике кулына таянып, урыныннан кузгала башлады. Аның битенә гүя ут капты, муен тамырлары бүртенеп чыкты.

— Эш өчен җан атып йөргән буласыз. Бактың исә гади интриган икәнсез бит! Коточкыч кеше!..

Идрисов белән сөйләшү барып чыкмады, хәер, чыкмаячагы Кадыйрга күптән билгеле иде инде.

## 9

— Карыйм- карыйм да аптырап китәм, бер дә кәефегез юк кебек, Халисә Хәйдәровна. Гайсә Ильясовичка ул-бу булмагандыр бит?.. Юкмы? Әйе, сезнең арадан җил дә үтмәстер. Тату яшисез, көнләшеп куярлык. Ә мин менә үземнекенә һаман ачкыч таба алмый йөдим.

Халисә авырулар тарихын язып утырган җиреннән башын күтәрми генә Валентина Петровнага сирпелеп алды. Ап-ак чырайлы, саргылт чәчле врач-хирург Меженкова белән алар күп вакытта бер-беренә эч серләрен ачалар — ике хатын арасында уртага салып сөйләшер сүзләр еш була торган иде.

— Минем Меженков курортка китәргә җыена, — дип сүзен дәвам итте Валентина Петровна. — Тәмам канатланып кайткан. Китеп бер ун көн торгач артыннан барып күрмәгәнен күрсәтермен әле үзенә. Ниндидер бер оператор кыз артыннан чаба, диләр. Анысы да шул якка тайган. Халык усал бит хәзер, юри котырталар дип йөргән идем.

— Минем Гайсә дә берүзе баргалады, — диде Халисә, язуын дәвам итә-итә. — Миңа да әллә ниләр сөйли торганнар иде. Кеше сүзе кеше үтерә диләр бит.

Валентина Петровна көрсенеп куйды.

— Синең Гайсәң алтын ул, Халисә. Ичмасам, үтереп төчеләнә белә. Күп нәрсә кирәкмени хатын-кыз күңеленә, ир-ат берничә җылы сүз әйттеме, күңел дигәнең эри дә китә. Сине бит ул «сөеклем», «тәтием» дип кенә йөри. Ишетерсең минем Меженковтан андый сүзләр. «Валя» да «Валька» менә минем җанкисәкнең бар сүзе. Гайсә Ильясович фәрештә ул, Халисә. Ә минем Меженковта ул сыйфатлар булмады. Характеры авыр да соң үзенең. Кирәк бит шундый шайтан булырга, хатыны белгән көенчә кәнтәе артыннан китәргә йөри.

Меженковның аумакайлыгы Халисә өчен дә ачыш түгел иде, әмма Валентинаның кинаяләпме, чынын кушыпмы Гайсәне мактавы Халисәне аптырашка калдырды. Бу сүзләрне тыңлавы аңа җиңел түгел иде, никтер күңел ашкынып-алгысынып китте. Алай да Халисә дәшмәде. «Нишләмәк кирәк, өлешеңә тигән көмешең», — дип уйлады ул. Хирургия бүлегендә иңгә-иң торып эшләгән ике хирург арасында соңгы елда конфликтлар ешая төшүен дә Халисә белә-күрә йөрде. Кичә булып алган әйтешүләре турында да аңа түкми-чәчми җиткергәннәр иде. Әмма ул кичәге хәлне белмәгәнгә сабышты.

— Гайсә белән тагын ни бүлешәлмәдегез, Валя?

— Анысы вак мәсьәлә, — дип кул селтәде Меженкова. — Мин дежурда идем. Кичен аппендицит белән бер кызны китерделәр. Операциягә алдык. Ул арада Гайсә Ильясович та килеп җитте һәм кулларын юа башлады. Нигә башта ук миңа хәбәр итмәдегез, ди. Сер бик тиз ачылды: Әмиров кызын китергәннәр икән. Операционныйдан чыгуыма кызның әнисе: «Гафу итегез инде, Валентина Петровна, бердәнбер кызыбыз, Гайсә Ильясовичка хәбәр итәргә булдык», — ди.

— Гайсә урынында булсаң, Валя, син дә каршы килә алмас идең, бәлкем аңа үзенә дә җиңел булмагандыр...

— Үткән эшкә салават, Халисә. Аның үз намусында калсын.

Һәр вакыт тыныч һәм кыю холыклы хирург хатынны тагын нидер борчый иде, Халисә моны күңеле белән сизде. Валентина аның кабинетына шул хәбәрне генә әйтергә кермәгән иде булса кирәк. Халисә язуыннан туктады. Ләкин Валентина Петровна урыныннан торып дәшми-тынмый гына ишеккә юнәлде.

— Валя! — Валентина Петровна туктады, ләкин башын күтәрмәде. Халисә аның янына килде, беләгенә тотынды. — Ни булды сиңа, Валя?

— Үземне-үзем кая куярга белмим, Халисә. Меженков китә...

— Китсә соң? Отпускасы бетүгә әйләнер дә кайтыр.

Валентина Петровнаның зәңгәр күзләре яшь белән мөлдерәп тулды, әмма ул бөтен ихтыярын җыеп, тыелып калды, көч-хәл белән булса да елмаерга тырышты.

— Бөтен бәла дә шунда шул, Халисәкәй, ул бөтенләйгә китә... Менә запискасы. Шул оператор кыз беләндер инде. Төмәнгәме, Мангышлаккамы, кай тарафкадыр. Башта курортка гына барам диде.

— Ул бит идарәнең план бүлеге начальнигы. Әмиров җибәрмәс аны, шундый житәкчене ничек ычкындырмак кирәк?

— Китәргә теләгән белгечләрнең берсен дә тотмый Әмиров. Юк, Халисә, бармыйм мин анда. Ирексезләп калдырыргамы?..

Халисә Валентинаның иңбашына кулын салды.

— Сабыр ит. Үтәр. Сабыр ит, Валя, кайтыр ул.

Меженкова аскы иренен тешләде, башын чайкады.

— Ярар, китим, Халисә Хәйдәровна. Гафу ит, эчем бушамасмы дип кенә кергән идем.

Кабинетка Гайсә килеп керде, ишек ачылуга, Валентина Петровна чыгып китте. Гайсә аның артыннан сәерсенеп карап калды.

— Ни булган моңа?

Халисә түргә узды, халатына төренә төште. Ачык форточкадан кергән салкынча һавамы, Валентина хәбәреме аны өшетеп җибәргән иде.

— Авырыбрак тора, шуңа кәефе юк.

— Ә мин башка бер нәрсә ишеткән идем, — диде Гайсә көлемсерәп. — Меженков Әмировка китәм дип гариза биргән. Бер...

Халисә иренә шундый иттереп карады, хатыныннан моны көтмәгән Гайсә бер мәл ачкан авызын ябалмый торды.

— Һәм син шуңа ышандыңмы?

— Бу ни дигән сүз тагын! Ярый, күрәм, синең дә кәефең юк. Мин операциягә хәзерләнәм. — Гайсә ишекле-түрле йөренеп килде, Халисә янында туктады. — Куй, борчылма юкка. Меженков аның белән барыбер тормас иде. Күреп йөрдек ич, икесенең берсе дә баш бирмәде: икесе дә үтә горурлар, тәкәбберләр... Мине көтәрсеңме?

— Юк, кайта торам. Тиз булмас әле ул синең операция...

Гайсә ишеккә җитте, кулын тоткага салуга нидер исенә төшеп, тукталып калды.

— Ишеттеңме әле, Халисә, — диде ул артка каерылып. — Нәүфәл кайткан икән бит.

Йөзе кинәт агарынып киткән Халисә, иренә бернәрсә дә сиздермәс өчен өстәл янына узды, калтыраган куллары белән авырулар тарихын җыештыра башлады.

— Кайтса соң. Шуннан ни!..

— Болай гына, — диде Гайсә. Ул сизелер-сизелмәс кенә елмаеп куйды, кашларын сикертеп, гаҗәпләнгәндәй итте. — Болай гына, — дип кабатлады ул чыга-чыгышлый.

Үзе генә калгач, Халисә кинәт күңеле болгануын, башы әйләнеп китүен тойды, егылмас өчен ике куллап өстәл читенә ябышты. «Ни

булды миңа? Әллә соң?.. — дигән уй башын айкап узды, йөрәге леп итеп сулкылдап алды. — Шулай ук?.. — Шунда ук ул үз-үзен тынычландырырга кереште. — Булмас. Булса соң? Вакыт бит инде, күпме бергә торабыз. Ичмасам, тынычланыбрак яшәрмен».

Шулай үз-үзен тынычландыруга карамастан, үз-үзенә ясаган бу ачыш аңа баш өстендә чаң суккандай тәэсир итте. Дөресен генә әйткәндә, ул моңа рухи яктан да әзер түгел иде әле. Ә ул әнә, агач ябалдашларына төнлә яуган йомшак кар кебек, иңбашына ишелде дә төште. Халисәнең бөтен тәнен киеренкелек биләп алды, бу хәлнең кайчан да булса бер киләсен белә иде ул, әмма әле түгел, бүген түгел!.. Нигә бүген түгел? Аның кайту хәбәрен ишеткәнгәме? Ник соң әле ул бу тикле куркуга калды, ник болай куркына ул?!.

Халисә бөтен тәнендә җиңелчә генә калтырау тоя. «Я раббы! Бу ни инде тагын? Чү, врач ич син. Узсам соң!.. Табармын...»

Кабинетка Зөһрә ханым килеп керде. Аның өстендә җем-җем итеп торган укалы күлмәк, әйтерсең ул больницага түгел, театрга җыенган, әмма йөзе борчулы, йокысыз үткәргән төннән соң тартылып, сулып киткән.

— Гафу итегез, Халисә Хәйдәровна. Кичә театрга барырга чыккан гына идек, Гөлүсәбезнең эче авырта башлады. Нәрсә ашадың дип тә карыйм, сүзен дә әйтә алмый, балакай. Ярдәм чакырырга булдым. Рәхмәт инде, Гайсә Ильясович үзе ясарга алынды. Аппендицит сабыйда. Барысы да әйбәт булыр, диде. Шундый тыныч, итагатьле, алтын куллы кеше инде иретез, Халисә Хәйдәровна, ходай гомерен генә бирә күрсен. Бергә-бергә бәхетләрегез белән генә яши күрегез...

— Барысы да әйбәт булыр, борчылмагыз. Операцияне җиңел кичергән, озакламый терелер.

— Җиңел диләр дә, ана бит, һаман күңел борчыла. Кичә әйтәм, театр кайгысы да калмады. Җитмәсә, бүген атасын Әлмәткә, Берләшмәгә дәшкәннәр иде. Ир кешенең шул инде, үз кайгысы кайгы. Ятмадан яртылаш су чыга, аны чистартырга установкалары җитми.

— Ә сез утырыгыз, Зөһрә ханым.

— Кая инде ул утырып торулар, — диде Зөһрә. Ә үзе түргә узып креслога урнашты. — Кирәк бит, Халисә Хәйдәровна, бәхетле генә яшәгәндә. Әле йөргән егете Сережасына хәбәр итмәдем, Кадыйр әйтмәгән булса инде. Ул ишетсә нишләр, балакай. Үлепләр ярата бит ул аны. Өйләнешәбез дип йөриләр. Бигрәк тә яшь шул әле, Кадыйрның ул турыда ишетәсе дә килми. Нишләмәк кирәк, яшьләр бездән сорап торалармы? Егете дә бик әйбәт шул. Әлмәт нефть белгечләре хәзерләү институтының кичке бүлегендә укый, икенче курста. Гөлүсә дә шунда керәм дип тора. Документларын да илтеп кайтты инде. Мин сезне тоткарламыйммы, Халисә Хәйдәровна? Эч пошканнан гына керүем иде. Бая Гайсә Ильясовичка да сөйләп тордым әле. Нәүфәлебез кайтты бит. Абыйсы үзен автоматика цехына урнаштырды. Шаклар катарсың инде үзенә, каядыр китеп югалган иде, Грозныйга барып чыккан, шунда институт тәмамлаган, хәзер нинди дер «спутниклар» көйләп җенләнә. Гарип булса да башлы тагын үзе, бичаракаем...

«Гарип булса да?.. Бичара?» Бу сүзләр Халисәнең бәгырен үткен пычак белән телгәләде, аның сулышы кысылды, йөрәге күкрәгенә сыешмыйча тибә башлады. «Ул гарип, минем аркада бит.» Аның кычкырып җибәрәсе, кабинеттан чыгып китәсе килде. Тик кая? Кемгә генә сөйли ала ул ярсыган йөрәк серләрен? Һичкемгә. Нишләргә соң, нишләргә? Горурлыгын җуеп беренче булып аның каршына барыргамы, үткәннәр өчен гафу үтенергәме?.. «Мин горурлык турында уйлыйм, ә ул минем аркада гарип калган», — дип үз-үзен битәрләде Халисә.

— Гафу итегез, Зөһрә ханым, минем ашыгыч эшем бар иде.

Халисә коридорга чыкты да көрсенеп, тирән итеп сулыш алып куй-

ды. Күтәрсә күтәрә икән хатын-кыз иңбашлары берсе артыннан берсе ишелеп торган хәбәрләрне дә...
Ул акрын гына баскычтан төште. Авырулар аның белән саубуллашалар, ак юл теләп калалар. Тик ул аларны күрде дә, күрмәде дә. Нәүфәлнең кайтуы, биредә инженер булып эшләве, аның аркасында гарип калуы — барысы да бер йомгакка уралды, буталды, чуалды, уйзиһене үткән хатирәләр, истәлекләр белән тулды.

Иртән уянып китүгә, ул үз-үзенә ике ачыш ясады. Беренчедән, кичәге күңел болгануның эзе дә калмаган иде, димәк, авырга узмаган, икенчедән, көн шундый матур булып туып килә, иртәнге кояш нурлары караватка чаклы җиткән иде — бер көне бер гомер булыр сыман.
Халисә Гайсәгә үрелде, юрган почмагын күтәрде.
— Ку-ку! Гайсә, уян! Операцияң ничек узды? Уян инде!
Гайсә, баш астына кулларын салып, түшәмгә текәлде.
— Мин кайтканда йоклый идең, шуннан бирле уянмадыңмы?
— Мин синнән операция ничек узды дип сорадым түгелме? Башта миңа җавап бир.
Халисә, кыштыр-кыштыр килеп, Гайсә янынарак күчте.
— Әйбәт үтте операция, нормально. Ә син ник көтмәдең?
Халисә иренең суса кебек борынына бармагы белән бәргәләп алды.
— Даң-даң, даң-доң чаң кагалар, торып чәй куярга кушалар.
— Миңамы?
— Сиңа шул.
— Меженков турында ишеттеңме әле?
— Меженков маена чыдамый башлаган, Гайсә. Валя кебек хатынны табасы бар әле аңа. Бер киткәч Валя аны кабат кертмәячәк, мин әйтте диярсең, характерлы хатын ул, тикмәгә генә хирург булып эшләми.
— Чәй куярга дисең инде... — Гайсә, кулларын алга сузып, терсәгенә таянмый гына торып утырды, аякларына чүәк киде, урындык башында эленеп торган буйлы пижамын үрелеп алып җилкәсенә салды, чүәген лаштыр-лоштыр өстерәп, кухняга кереп китте.
— Аякларыңны күтәребрәк бас, берсен атлаганчы икенчесен эт ашар төсле.
— Янымда син булганда бернинди эттән дә курыкмыйм мин, белеп тор шуны, — Гайсәнең соңгы сүзләрен Халисә ишетмәде, аны йокы басты.
Гайсә «Дөнья матур, дөнья киң» дип көйли-көйли чәйниккә су агызып кайнатырга куйды, аннары хатыны янына килде дә, звонок төймәсенә баскандай, аның борын очына җиңелчә генә басып: «Дзи-и-и-нь, минем тәтиемә дә торырга вакыт, диган хәбәр килде! Бүген ял да, бәйрәм дә түгел», — диде. Аннары ул ваннада фыр-фыр килә-килә, тамак төбе белән көхелди-көхелди коена башлады. Халисә хәтта көнләшеп куйды — шул хәтле рәхәт юына иде ир.
Халисә бер мәлгә иртәнге сафлык тойгысына бирелеп кузгалмый ятты, икенче мәлдә инде ул сикереп торып күнегүләр ясады, тиз генә юынып алды да, кухняга кереп, иртәнге аш хәстәрли башлады, өстәлгә май, вареньe китереп куйды, ипи кисте, чәй пешерде. Душ коенып чыккан Гайсә хатынының артыннан килеп кочып алды.
— Эһ-һе, эләктеңме?
— Җибәр, Гайсә, юешсең ич!
Халисә аңа каерылып, ачулы итеп карап алды.
— Ник болай тимәс борын тибешергә торасың әле син?
— Әллә нигә кәефем китеп тора. Игътибар итмә, әйдә, утырышыйк.

Шунда Халисә, беренче тапкыр күргәндәй, Гайсәгә карады. «Нигә кинәт кенә ул миңа шулай ят тоелды?» — дип куркынып уйлады ул.

Гайсәне эшкә озаткач, Халисә көзге алдында утырып чәчен тарады, битенә иннек якты. Күңелдә нидер уянып, җанланып киткән кебек. Нигә булыр икән?

Урамга чыккач, чишмә ягына күз ташлап алды. Башын иеп, үзалдына елмаеп куйды. Көн аяз, күк йөзе зәп-зәңгәр, агарып, уңып калган ай да, балкып торган кояш та бер үк күк гөмбәзенә сыйганнар.

Больницага ике юл белән барып була иде. Беренчесе туры булмаса да, ике квартал аша уратып, такыр тротуардан узасың, икенчесе — урман аша. Урман аша салынган сукмактан Халисә бик сирәк йөри, ләкин аның күңелен бүген шундагы каеннар тартты. Кемдер аңа урманда чәчәкләр бик күп дип әйткән иде. Агачлар арасыннан асфальт сукмак җәйгәннәр, Халисә шунда таба атлады. Беренче кыңгырау чәчәге аны үзенә дәште, урманга чакырды. Сәгатенә күз төшереп алды — вакыт бар иде әле. Больницага житәрәк сулга борылды. Дымсурак һава, гаҗәеп тынлык аның күңелен тартты, ул агачлар арасында сузылып яткан сукмактан атлап китте. Каядыр бик еракта күке тавышы ишетелеп куйгалый. Ак каеннар арасына килеп керүгә, Халисәнең ихтыяры җуелды, гүя хатынны урман иясе җитәкләп алып китте, ул адымын кызулата төште. Бара торгач, Кыңгыраулы аланга килеп чыкты. Биредә кояш патшалык итә. Балтырган сабагына кунып чәберчек сайрый, анда-санда үрмәләч йөгереп уза, төсен-йөзен тагын да купшылатырга өлгергән песнәк ботактан-ботакка кунып пыр-пыр очына. Саф һавадан, табигатьнең мөлдерәп тулган манзарасыннан Халисәнең күңеле күтәрелеп китте: кояшка, җиһанга ашарга теләгәндәй, кулларын күккә күтәрде. Агач башларында иренеп кенә җил уйный. Җиргә бакты: тукранбаш үләне, сәгать теле кебек, әле уңга, әле сулга чайкалып куя. Шунда гына эшкә барырга чыгуы исенә төште.

Халисә больницага килеп кергәндә иртәнге биш минутлык киңәшмәдән врачлар таралыша иде инде. Кайберәүләре аның белән исәнләшеп, шелтә белдергәндәй, шаяртып уздылар: «Озак йоклыйсыз да соң, Халисә Хәйдәровна. Гайсә Ильясович шундый көтте үзегезне... ишектән күзен дә алмады. Югалткан берәү күгәрченкәен дип утырдык».

Баш врач кабинетыннан терапия бүлеге мөдире Асия Хәмитовна чыкты, Халисәне күрүгә, ул аның янына ашыкты һәм, килә-килүгә, яшь врачны култыклап алды, янәшә атлап китте.

— Җаным-түгәрәгем, Халисә Хәйдәровна, ул-бу булмагандыр бит? Плотников агаң бүген бик тә борчулы иде. Гайсә Ильясовтан күзен дә алмады. Котым алынып утырдым. Врачларыгыз кая дип сораса? Таптыра башласа, мин әйтәм, ниләр дип әйтермен.

— Гафу итегез, Асия Хәмитовна, әллә берәр нәрсә булдымы? Авыруларым... Мин бүтән соңга калмаска тырышырмын. Урман аша килгән идем, таныш аланыма барып чыктым да гел дөньямны онытып җибәргәнмен, — диде Халисә, шактый төксе генә һәм кырт борылып, өлкән сестра бүлмәсенә юнәлде.

Ләкин аны Асия Хәмитовна култыклап ук алды.

— Бүген обходны бергәләп уздырырбыз диган идем. Кәефегез юк шикелле. Мин кичә сезнең авыруларыгызга дарулар бирүгә үзгәрешләр керттем. Күрдегезме әле?

— Мин ул үзгәрешләрне кабул итмәдем, Асия Хәмитовна. Үз авыруларымны үзем дәваларга телим. Даруларның да бик хаҗәтләрен генә бирәм, кайчан нинди укол салырга кирәклеген дә әйбәт беләм. — Халисәнең бит очлары алсуланып китте, шул сүзләрне әйтеп туктап калуга, күксел-кара күзләренә әйтерсең лә нәфрәт уты төште. — Асия

Хәмитовна, без бу турыда бер тапкыр сөйләшкән идек бит инде: бер-беребезнең эшенә кысылмаска. Бу хәл тагын бер кабатланса, мин баш врачка керәчәкмен. Мин болай эшли алмыйм. Авыруларымны сәламәтләндерү өчен башта мин үзем тыныч булырга тиешмен.

Халисәнең ачулануына бүлек мөдиренең бик үк исе китмәде, гүя ул аның соңгы сүзләрен ишетмәде дә, һични булмаган кебек, үз сүзен дәвам итте:

— Җаныем, Халисә Хәйдәровна, зинһар юк-барга кәефегезне кырмагызчы. Мин биредә һичкемнән дә курыкмыйм. Баш врач димәгәе, министрның үзенә барсагыз да үземнекен итәчәкмен. Мөдир буларак сездән эш таләп итәргә хакым бармы? Бар. — Асия Хәмитовна тыныч сөйләргә нихәтле тырышса да булдыра алмады, бит-муеннарына тимгел-тимгел кызыл таплар тибеп чыкты, юка иреннәрен тагы да кыса төште. — Әгәр дә шуңардан авыруларыгыз алдында абруегыз төшәр дип куркасыз икән, китегез биредән. Әйе, авыруларыгыз сезне яраталар, әмма дәвалаучы врач өчен бу аз әле дияр идем мин. Врачка тәҗрибә еллар буе эшли-эшли генә килә. Ә мин ярты гасыр гомеремне врач булып эшлим.

— Мине ялгыш аңлый күрмәгез тагын, Асия Хәмитовна, сүз сезнең тәҗрибәгез турында бармый. Сүз авыруның гомере турында бара. Мин, гади ординатор буларак, үземнең авыруларыма якынрак торам, мин һәрчак алар өчен борчылам, билгеләгән процедураларым, даруларым турында кат-кат уйлыйм. Сездән исә ни бары бер нәрсәне үтенәм: минем сырхауларыма теге я бу даруны үзгәртеп бирергә исәп тотасыз икән, киңәшеп эш итик, бергәләп уйлашыйк, соңгы мәлдә барыбер бөтен авырлык чирле кеше башына төшәчәк ич.

— Инде миннән дә канәгать булмасагыз, Халисә Хәйдәровна... Беләсегез килсә, мин сезне үз баламдай якын күреп йөрим. — Асия Хәмитовна, үпкәләвен сиздереп, күзләрен читкә алды. — Әнә Нәүфәлнең кайтуы турында ишеткәч тә әллә нишләп киттем. Менә язмышлар нишли, мин әйтәм, бәндә балалары белән.

— Асия апа, бу ни дигән сүз инде тагын, ни сөйлисез сез? — Халисә, кырт борылып, китеп барды. Бүлек мөдире аны туктатмады, ул ни әйтергә белмәүдән гаҗиз булып калды, яшь хатынның бу кыланышыннан үзенә бер нәтиҗә ясарга маташып карады, әмма зиһененә һичнинди рәтле уй килмәде. «Их-хи-хи, акыллым, — диде ул, ниһаять, үзалдына. — Дөнья бу. Күзләрең үк әйтеп тора, онытмагансың син аны. Януларың-көюләрең алда әле, алда...»

Бүлек мөдире белән бу рәвештә сөйләшү Халисәнең тәмам кәефен кырды, ул үзендә эчке бер калтырау тойды, аннары үртәлү хисе килде. Нигә әле очраган берсе аның турында сөйли? Ниемә кирәк? Бераздан аңа бөтен кеше: «Нәүфәл кайткан бит, күрдеңме әле?» — дип сорар кебек тоела башлады. Халисәнең үзалдына битләре кызышты, ни кылырга белми, бүлмәсенә килеп керүгә, ишекле-түрле йөренергә тотынды. Нигә шулай тинтерәтәләр аны! Ул болай да газаплана ич, алар әйтмәсә дә бик тә, бик тә кыен ич аңа. Адәмгә иске җәрәхәтләрне яңартулары җиңел түгел ич.

Обход узуга, Халисә врачлар бүлмәсенә кереп, көндәгечә авыру тарихларын язарга кереште. Һәрбер тарих — үзе бер язмыш, үзе бер кеше гомере. Кешеләрнең күпләре ул авыруларны үзләре теләп алганнар кебек тоела башлый Халисәгә. Менә дүртенче палатада ятучы агайның авыру тарихы. Язва белән авырый, тәмәке тарта, шактый эчкәләгән дә, җитмәсә, кырда эшли, хезмәте авыр, вакытлы-вакытсыз ашый. «Килер бер көн, — дип уйлый Халисә, — һәр кеше врачы кушкан эштә генә эшләр. Шунда инде чирләүчеләр дә азаер, безгә җиңеләер». Коридорда аяк тавышы ишетелде, Халисә сагая калды. Аңа хә-

зер берәрсе килеп керер дә тагын шул Нәүфәл турында әйтер шикелле иде. Бүлмәгә Валентина Петровна керде.

— Саумы!

— Әйдә, Валя.

— Башымны кая куярга белмим. Гафу ит. Бүтән киңәшер кешем юкка гына керүем иде.

— Син нәрсә, Валя, без бит гел шулай эчләребез бушаганчы сөйләшә торган идек. Уз менә моннан. Аннары кайгырма әле бик алай.

— Их, Халисә җаным, ир бирмәк — җан бирмәк диләр бит. Бүген иртән Вадик торды да: «Әнием, эти кайда, нигә ул озак кайтмый?» — ди. Беләсеңме, баланың шул сүзенә үз-үземә урын таба алмый башладым. Бергә торганда гына ир кадерләрен белмибез икән бит, Халисәкәй! Шушы минутта Карлның алдына барып тезләнер хәлгә җиттем.

— Ул синең шушы түбәнсенүләреңне аңлар дип уйлыйсыңмы? Куй син аны, нык бул. Киттеме соң әле үзе?

— Бүген китә бугай. Расчет алып йөри.

— Ичмасам, парткомга барыр идең. Сиздерер идең үзенә азрак. Воронцовны бик яхшы кеше диләр бит.

Валентина Петровна ишек яңагына сөялгән көе тора бирде, Халисәнең үгетенә башын гына чайкады.

— Юк инде, Халисә, бакмаганны — яратып, ятмаганны йоклатып булмый. Мин аның алдына һичкайчан баш иеп барасы кеше түгел. Ярый.

Халисә Валентина Петровнага ияреп коридорга чыкты, инде тол калган ахирәтен култыклап алды.

— Сабыр ит, Валя, сабыр итә күр, җаным. Мин юләр дә шулай бер тапкыр кайгырып караган идем. Суларга ташлана яздым. Соңыннан үтте, узды тагын.

Халисә аны юатырга тырышты һәм шунда бер нәрсәгә төшенеп алды: кеше өчен кайгырту җиңелрәк икән. Алай дисәң бу хатын хәсрәте янында синең кайгың кысыр хәсрәт кенә ич, нәүмиз җан! Нигә ул сиңа Нәүфәл? Ярый, яшь чакта, тиле чакта, үлеп яраттың ди. Менә хәзер нигә ул сиңа? Ирең бар, менә дигән эшең...

Алар каршына Гөлүсә чыкты, Валя кызның кыеклабрак атлавын күрде дә:

— Кыюрак, кыюрак, Гөлүсә, тураебрак бас, — диде.

— Авырта шул, Валентина Петровна. Чак кына тураебрак атласам да...

Гөлүсә йөзен чытты, Халисәгә текәлебрәк карап алды.

«Бу бала да Нәүфәл турында сүз катса, чыгып качасы гына кала миңа бу больницадан», — дип уйлап алды Халисә ни әйтергә белмичә. Ләкин кыз Валентина Петровнага мөрәҗәгать итте.

— Валентина Петровна, минем яныма...

Шул вакыт ишек янында торучы кортка телгә килде.

— Валентина Петровна, нишлим инде бу кыз белән, ишек яныннан да китми. Егете килгән, — һәм врачлар алдында тагы да усалрак булырга теләп булса кирәк, ишек янында торучы егеткә янә әче сүзләр тезә башлады. — Ярамый дигәч ярамый инде, грамотныйсыңдыр бит. Укып бак: авырулар янына уналты сәгатьтән алып унсигез сәгатькә чаклы гына килергә мөмкин, диеп язылган.

Валентина Петровна ишек янына узды, үрелеп, теге яктагы егеткә күз төшерде.

— Исәнмесез, Валентина Петровна! — диде аңа ишек артында әле булса керергә ният итеп торучы ак чәчле егет.

— Исәнме! Гөлүсә янынамы?

— Иртәгә Казанга китәм...

— Няня, — дип карчыкка боерды Валентина Петровна. — Кертегез егетне!

Һәм борылды да китеп барды. Меженкованы озаткач, Халисә жиденче палатага узды, авыр хәлдә ятучы чирле янына килеп утырды. Больницада куна ук ятмаса да, көн-төн хатыны янында булган ир тәрәзә каршында басып тора икән, Халисә керүгә тамак кырды. Ләкин Халисә аның ягына әйләнеп тә карамады. Заманында авыру Мәхтүмә апаның ире хатынын юкка җәберләве, дөньясын онытып, атналар буе эчеп йөрүе һәм менә яман чир алып хатыны больницага яткач, аның алдында акланырга теләгәндәй, шифаханәдә куна ятуы, күңелдә сәер бер тәэсир калдыра иде.

— Хәлегез ничек, Мәхтүмә апа? Тормагыз, тормагыз. Ятып кына сөйләшегез.

— Һәй акыллым, сорама ходайдан каргалган кешедән ару хәлләр. Менә Йосыф абыеңны орышып торадыр ием әле. Көн димәде, төн димәде, баш күтәрми эчте, инде хәзер бер терелеп кайтсаң, авызыма да алмас идем шул агуны дигән була. Әнә үзе балан суы кайнатып китергән, шуны эчкәч күңелләрем күтәрелеп киткән сыман булды. Тик менә хәлкәйләрем генә юк, акыллым, буыннарыма чаклы үземнеке түгел шикелле, кулыма стакан алырга куркам, — шулай дип авыру хатын тилмерүле күзләре белән врачка текәлде — йомшак сүзләр белән юатуын көтте, ахрысы.

«Нинди түземле, сабыр хатын син, Мәхтүмә апакаем, — дип уйлады Халисә авыру хатынның нуры сүнә башлаган күзләренә карап. — Дүрт күзләп минем керүемне көтәсең. Ә мин әле сиңа һични әйтә алмыйм. Хәлең бер дә алга бармый шул, җаным».

— Болай булгач, Мәхтүмә апа, алга таба киттек инде. Бүген менә тагын плазма салырлар, — Халисә авыруның коры сөяккә калган кулларын алды. — Үз гаебен үзе таныгач, ирең начар кеше түгелдер, Мәхтүмә апа, — дип пышылдады. — Юкка рәнҗетмәгез, миңа калса ул болай да бик үкенә...

— Рәхмәт, балакаем, яхшы сүзләрең өчен рәхмәтләр яусын үзеңә. Бәхетең-тәүфигың белән яшә. Ирең дә беркөнне кереп чыкты. Йомшак табигатьле, әйбәт кеше күренә. Тигез яшәгез, арагыздан җил үтмәсен, бер-берегездән күңелегез сүрелә күрмәсен. Минем әнә күңелем бер сүрелде дә һаман җәфаланам. Ир-канатым булса да, кан-яшь түктергән кешеңне күңелкәйләр җиңел генә кичерми икән, балакай.

— Я, Мәхтүмә апа, борчылмагыз, барысы да әйбәт булыр. Бер-ике атнадан таштай-тукмактай йөри башларсыз әле.

— Шулай гына була күрсен инде, балакаем. Ичмасам, кече кызымны кияүгә бирсәм...

— Бирерсез, менә дигән туй итәрсез әле, апа җаным.

— Амин, балакаем. Синең белән сөйләшкәч җаннарым тынычланып китә.

«Бүгеннән преднизолон дозасын арттырырга булыр,» — дип уйлады Халисә. Урыныннан кузгалганда тәрәзә каршында басып торучы ир-атның очлы җилкәләренә игътибар итте. — Чандыр агай. Ә чандырлар сирәгрәк чирлиләр. Ә синдә, Мәхтүмә апакаем, кимендә туксан кило булгандыр. Ә менә хәзер...» — Халисә үзалдына башын чайкап куйды.

Вестибюльдәге роза гөле янында басып торучы Гөлүсә белән ак чәчле егетне күрүгә, Халисәнең йөрәге тагын әллә нишләп китте. Егете шактый буйчан, җете күзле иде. Гөлүсә, авырткан якка бөгелә төшеп, операция урынын кысып тоткан.

— Сережа, җаным, бәгырем, көлдермә әле, миңа көләргә ярамый, — дип үтенә.

— Тагын тегәрләр, — дип шаярта егет. — Көл көләсең килгәндә.

Алар турына җиткәч, Халисә юри адымын акрынайта төште һәм

күз кырые белән карап алды. Гөлүсә, башын кырын сала төшеп, азрак кына кыланчыкланып, вак-вак итеп башын чайкый, иреннәре ирексездән елмаеп җәелә, егет артындагы Халисәне күрми, Гөлүсәне үбеп ала.

«Я, я инде, ни булды әле сиңа кинәт! Ниемә тагын тилереп кеше бәхетенә көнли башладың! Үзеңнеке үзеңә җитмәгәнме? — дип уйлады Халисә адымын тизләтә төшеп. — Нишләдем мин? Нидер телим һәм шул теләгемне үз-үземнән яшерәм түгелме? Мин аны күрергә тиеш. Ул миңа ачу сакламыйдыр, сакламаска тиеш».

Халисә төштән соң поликлиникага авырулар кабул итәргә китте. Ишектән чыккач та күзе иртән йөргән каенлыкка төште. Офык чите белән кушылган урман өстендә күзне рәхәтләндерердәй сыек рәшә ага иде.

Нишләде соң әле ул? Нигә болай үз-үзенә урын таба алмый? Соңгы көннәрдә тагын күңеле җилкенә башлады. Тәмам йөрәгенә сеңдеме әллә бу Нәүфәл — әле онытылып торган кебек, әле бөтенләй күз алдында тора. Килә, күңелне айкый, актара да тагын югала да янә килеп чыга. Ул килгән саен күңел күгендәге истәлек-хатирәләр кабынып китә, үткән өчен үкенү, рәнҗү, әрнешү уяна. «Мин һаман саен гажизләнә барам. Бу бер дә юньлегә түгел. Җәза бу минем өчен, җәза! Нигә генә кайттың соң әле син, Нәүфәл! Нинди хәерсез тылсымнарга ия кеше син! Синең аркада торган саен ихтыяр көчем югалта барам».

Халисә үз кыланышыннан үзе кимсенде, гарьләнде. Я ходаем, онытылмаса онытылмас кеше булыр икән! Яратмыйм бит мин аны, яратмыйм. Януларым, көюләрем, асыл ташка кызыккан бала кебек, үткәнгә кызыгуым гына ич. Күрәсем дә килми хәтта... Килмиме? Нишләвем инде бу тагын, ниемә тиктомалга ябырылдым әле бер гаепсез кешегә. Иң мөһиме ул мине гафу итте. Тилекәй. Хәзер бит инде син үнҗиде яшьлек Халисә түгел, ир хатыны. Матур гына тормыш итеп ятабыз. Ә Нәүфәл?! Юк, юк, мин аны бары тик кызганам гына, кызгануымнан гына шулай көяләнәм.

Поликлиникага җитеп килгәндә аңа кемдер дәште.

— Халисә Хәйдәровна, Халисә Хәйдәровна, бер генә минутка туктагызчы!

Уң кулына гладиолус букеты тоткан Зөһрә ашыга-кабалана аны куып килә иде. Килеп җитүгә, хатын аңа карап торды.

— Исәнмесез, Халисә Хәйдәровна, саумысез!

— Исәнмесез, Зөһрә апа.

— Менә шул чәчәкләрне Гайсә Ильясовичка бирегезче. Үпкәли күрмәгез тагын. Гөлүсәбез йөри дә башлады. Серёжасы килгән. Гөрләшәләр, гел пар күгәрченнәр инде менә. Бичарамның канатлары гына кыскарды, очып кына китәрләр иде. Ә үзе, әнием, әчем бер тамчы да авыртмый дигән була тагын, балакай. Авыртмый буламы, мин белмимме әллә?

— Ярый, рәхмәт сезгә, бирермен.

Артык сөйләшеп торырга вакыты да тар, теләге дә юк иде, Халисә чәчәкләрне алды да поликлиникага юнәлде.

Коридор буйлап авырулар тезелешеп утырган, кайберәүләре түземсезләнеп кабул итү бүлмәсенең ишеге янына ук килеп стенага сөялеп көтәләр. Халисәне күрүгә, үзара сөйләшүдән туктап, аның белән исәнләштеләр. Артыннан ук, чакыруын да көтмичә, кабинетка бер карчык килеп керде.

— И-и, балакаем, көтәргә бер дә хәлем калмады, рәнҗемә инде.

Халисә сестрага чәчкәләрне вазага утыртырга кушты, үзе тиз генә ак халатын киеп алды, өстәл янына узды.

— Минә шушы җирем генә чәнчә, берәр яхшырак дару язып җибәрмәс идең микән дип кенә килүем иде.

— Чишенә торыгыз,— диде карчыкка Халисә, авыруның карточкасын актаргалап карады.

— Кызым, таныш брач та икәнсең, тишендереп торма инде карчык кешене. Әллә нәрсәгә тәнем ояла. Бер дә тән күрсәтергә күнекмәгән шул без, балакаем... Нием авырта диеп, минә тушыннан тиктомалга чәнчә дә тора энәтерәк. Ходайның хикмәте, тозлы әйберне гел дә капмалы булмый башлады. Тишениммени инде?..

Халисә карчыкның эчен баскалап карады, ике бармагы белән уң як кабырга астына төртүе булды, әбинең бөтен тәне куырылып, бөрешеп куйды.

— Киенегез. Сезнең үт куыгыгыз авырта, әбекәй. Башта анализлар бирерсез, ике көннән шул анализлар белән тагын керерсез.

— Рәхмәт яусын инде, балакаем, кулларың сызлаусыз булсын. Дару гына язып бир дә мин китим.

— Әлегә мин микстура язам, аптекадан алып эчә торырсыз, калганын анализлар әзер булгач эшләрбез, әбекәй.

— Әнәлиз, әнәлиз,— дип сукранды карчык чыгып барганда.— Тәүгесе бер дә сорамый ие әле. Иң яхшы граничный дарулар язып бирә торган ие. Бусына әнәлиз кирәк...

Карчыктан соң, дәү гәүдәле ир-ат килеп керде.

— Минем билгеле инде — язва, — диде ул Халисә аның чире турында сораштыра башлагач. — Ит капсаң да китереп кыса, сөт капсаң да, дигәндәй. Нә катынга, нә балаларга йокы юк, төнозын йөреп чыктым. Әз генә җибәргән кебек итә дә тагын бөтерә дә ала, бөтерә дә ала монавыннан.

— Күптән авырыйсызмы?

— Ике еллап булыр. Эчмәгән дару, капмаган нәрсә калмады инде, кайсы каргагандыр, рәтләнеп кенә китеп булмый. Кеше сүзенә карап спиртка хәтле эчтем, килешмәгәч килешми икән ходайның хикмәте. Күрше Кашафетдин әнә Ижауга барып шифалы су эчеп кайтты да гамьсез йөри. Юкса, миннән дә яман җәфалана иде.

— Аракы да эчкәлисезме?

— Кем эчми аны хәзер. Кунак, дус-иш килә. Без түгел, пәйгамбәрләр дә эчкән бит, булгалый шыл, сеңелкәй, булгалый. Ул шайтан суын эчкәч, ни хикмәттер, басылып тора тагын үзе.

— Димәк, чирне үзегез үк акчага сатып аласыз? Сөйләвегезгә караганда, шулай булып чыга түгелме соң? Телегезне күрсәтегез әле.

Халисә, авыруны кушеткага яткырып, җентекләп карады. Чәчләре чаларган бу кешенең яңагы — яңакка, эче—эчкә ябышкан дип әйтсәң дә зур ялгышлык булмас иде. Ике ел авырып йөреп, ничек моңарчы бер дә килеп күренмәгән икән, шунысы сәер тоелды Халисәгә.

— Сөйләсәң сүз инде... Мин, сеңел, бәхет сынап карыйм дип Түбән якларына чыгып киткән идем. Шунда чир таптым, кан косып больниска эләктем, ике айны шунда черетеп чыктым. Картайган көнемдә үз өемдә генә утырасым иде дә бит, юк, күңелне кытыклап, тик шайтан котыртып тора. Иярдем дә киттем бит яшь кенә егетләргә. Тегеләр әле булса шында эшләп яталар, чурт та булмый үзләренә. Картаела шыл, шайтан алгыры, картаела. Яшь чакларны сагынып сөйләргә генә калды. Чыгып киткән идек бер мәлне мәрхүм Садрый белән Себер якларына. Дүрт ел шында эшләп кайттым. Галәмәт гайрәтле чаклар! Узды заманалар, узды, сеңелкәш. — Авыру бер тын башын чайкап сүзсез утырды. — Алай да бәхетсезләр рәтенә куймыйм үземне. Исән кеше бер кайтмаса бер кайта. Әнә, мәрхүм Садрыйның зимагур малае кайткан диләр. Атасы гына чит-ят җирләрдә ятып калды.

Янә Халисәнең тәне эсселе-суыклы булып китте. «Бусы да шул

Нәүфәл турында сүз кузгатса, аның кайтуы турында радиодан хәбәр иткәннәр дип кенә әйтәсе кала»,— дип, үзалдына уйланды Халисә.

— Сезгә больницага кереп, дәваланып чыгарга кирәк булыр, абый.

— Нишләмәк кирәк, чыдар хәлләрем калмады шул. Яткыргач, ятмак итәрбез.

... Кабул итү сәгате беткәч, Халисә больницага китте. Сукмак буендагы бакча эчендә авырулар утыра, ял итәргә килгән кешеләр кебек салмак кына сөйләшәләр. Болары бүген-иртәгә сәламәтләнеп чыгып китәсе кешеләр. Гөлүсә китеп барган егетенә тәрәзәдән кул изи.

Коридорга кергәч, Гөлүсә янынннан үткәндә, Халисә кызга текәлебрәк карап узды һәм аңарда ниндидер бер мизгелдә: «Нәүфәл абыең кайчан кайтты?» — дип сорау теләге туды, ләкин бу теләк ничек туган булса, шулай тиз генә юкка да чыкты. Гөлүсәнең йөзеннән сөенеч, егете килеп киткәннән соң туган куаныч нурлары сүнмәгән иде әле.

— Халисә апа, мине тиз чыгарырлармы икән?

— Бер атнадан, — Халисә кызның янә күзләренә карады. — Бик тә яратасыңмы? — дип, егет китеп барган якка ым какты. Гөлүсә күзләрен йомды, өзелеп яратуын сиздерде.

Халисә кызның чыраендагы һәр сызыкны күздән кичерде. Ак чырайлы, түгәрәк йөзле, әнисе кебек гаҗәеп мөлаем, самими карашлы күк күзләре нур чәчә, буяу әсәре тимәгән коңгырт-кара чәч бөдрәләре алкаланып маңгаена төшкән, алсу иреннәрендә шатлыклы елмаю, бит очындагы бармак йөзе хәтле генә уйдымнары тагын да тирәнәйгән, дугаланып килгән кашлар уйнаклап тора.

— Халисә апа, кичке якта минем янга Нәүфәл абый килмәкче. Ишектә торучы няня болдырга гына чыгарга рөхсәт итсә иде.

— Сиңа рөхсәтне Валентина Петровна бирә бит, үскәнем.

Халисәнең кисәк сулышы кысылды. Хәзер ул чынлап та үз-үзенә урын таба алмый башлады. «Нәрсә инде бу, аның больницага килүен ишетеп шулай дулкынланаммы? Я, килде ди. Шуннан ни? Ул килер, ә мин инде өйдә булырмын. Ник алай борчылам, хафаланам соң әле. Иң башта ул да мине рәнҗетте, ул да мине елатты, йөрәккәемне әрнүләргә салды!» — дип уйлады Халисә кабинетына таба атлаганда.

Кабинетта да үз-үзен кая куярга белмәгәч, ул тизрәк палатага, авырулар янына ашыкты, шунда кеше арасында бераз онытылып алды, кайгылары таралгандай булды.

Өенә ул хәтта бераз иртәрәк тә китте бугай. Янә йөрәге ашкынды, җинаятен фаш итүдән курыккан кешедәй, урамга йөгерә-атлый чыкты. Сукмак буйлап тезелеп киткән тупыллардан биялэй-биялэй мамык оча, кин ябалдашлары шау чәчәкләрдә утырган юкәләрдән тирә-юньгә татлы бал исе тарала. Саф һавада күңел бераз утыра, тынычлана төште. Халисә адымын тыеп кына барды. Бер-ике тапкыр туктап, тирән итеп сулыш алды — көрсенеп куйды. Шуннан үз-үзенә: «Тилекәй, җан атма, Гайсәң көтәдер», — дип өенә ашыкты.

... Гайсә, чынлап та, өйдә иде инде. Ул аш куйган, биленә Халисәнең алъяпкычын бәйләп алган да, кухня ягында нидер кыздырып маташа.

— Беләсеңме, — диде ул Халисәне каршылап. — Әллә нигә күңел өчпочмак теләп куйды. Ничек уйлыйсың, булдырып булырмы?

Халисә иренең яңагыннан сөеп, битеннән үбеп алды, өс киемен салып, ваннага кереп китте, кулын юып чыкты.

— Ә миңа ни эш кушасың, атказанган пешекче?

— Әйдә, мин ит турыйм, ә син бәрәңге әрче. Әллә камыр басасыңмы? Ярый, әүвәл камыр бас, — диде ул, резин перчаткасын тартыбрак киеп куйды, үзе бәрәңге әрчергә кереште.

Халисә халат киде дә, сәдәфләрен каптыра-каптыра, әйләнеп кухняга керде. Камырны ул бик тиз басты һәм җәйде. Икәүләп, сүзсез ге-

нә бәрәңге турадылар. Халисә өчпочмаклар ясаганчы Гайсә духовканы кабызды, кайнар калайларны майлап әзерләп куйды.

— Иллә кулларың оста да, хатын, — дип, Гайсә Халисәнең аркасыннан сөйде. — Беләсеңме мин бүген кемне күрдем? — диде ул хатыны өчпочмакларны духовкага тыккан арада. Кем дип уйлыйсың?

Халисә җилкәсен җыерып куйды, имеш, миңа барыбер, әйтсәң әйт, әйтмәсәң кирәге юк.

— Нәүфәлне.

Халисә шап итеп духовка капкачын япты. Гайсә сискәнеп китте.

— Болай үзе үзгәрмәгән дә кебек. Тик, әллә муены кәкере булганга, Квазимодагамы охшап калган шунда, теге кинодагы...

Халисә иренә шундый иттереп карады, Гайсә ачкан авызын ни әйтергә белми яба алмый торды.

— Беләсеңме кем аркасында гарип калган кеше ул, Гайсә! — Халисәнең тәмам йөрәге кабарды, ничә көн буена талкынган күңеле ташып китте. — Ишетәсеңме, Гайсә, тимә аңа. Тимә аңа, алла бәндәсе, мине бик аз гына булса да хөрмәт итсәң, тимә!..

— Нишләвең бу синең, ниемә дип тиктомалга ярсынасың?!

«Хатының күңел түрендә ни көйрәгәнен белсәң икән син, Гайсә. Белмисең шул. Ә мин куркам аңардан, очрашудан куркам, күзләренә туры караудан. Юк, син берни дә белмисең, аңламыйсың хатының хәлен. Аңларгамы теләмисең...»

— Кайгырма ул хәтле. Син уйлаганча ук мескен түгел ул. Үз дәрәҗәсен үзе бик яхшы белә.

Халисә җавап бирмәде, кулындагы сәгатен чишеп өстәлгә куйды да түр бүлмәгә кереп китте. Хатынының бу хәленә ачуы чыгарга өлгергән Гайсә телевизорны кабызды, тавышын күтәреп җибәрде.

— Әйдә хоккей карыйбыз. Безнекеләр Канада белән уйный.

Халисә килеп ярым ачык калган ишекне шап итеп япты да, креслога аягын җыеп утырды.

Хәтер күгендә барысы да калган, барысы да сакланган, һәммәсе истә. Ә шулай да, нигә Халисә аның белән очрашырга курка?

Куркамы?

Юк, юк, курыкмый!

Халисә өшеп китте, иңбашына салган шәленә төренебрәк утырды. Күз алдына янә Нәүфәл килеп басты, бик күптән булып узган вакыйгалар хәтерендә яңабаштан яңарып киттеләр. Соңгы тапкыр ул аны койма буенда кан эчендә яткан килеш күрде. Аннары әтисе кайтып керде. Җирдә өнсез яткан Нәүфәлне, гаебен сизеп, койрыгын бот арасына кыстырып оясына кереп барган этне күрде дә, фронтовикларга хас җитезлек белән егеткә ташланды, аны күтәреп машинасына алып чыгып китте. Әтисе Халисә ягына күз ташлады. Шул күз карашы Халисәнең бөтен тәнен гүя ут белән көйдереп алды. Ул шунда гына минут эчендә нинди фаҗига булганына ачык төшенде. Төшенде һәм җан-фәрманга больницага йөгерде. Нәүфәл янына Халисәне кертмәү генә түгел, якын да җибәрмәделәр. Әйе, аны һичкем аңларга теләмәде, хәтта әтисе дә. Больницадан чыгып килгәндә, ул аңа карамый гына:

— Синең эшеңме? — дип сорады.

Ләкин җавап көтмәстән машинасына таба китте, утырды, кабызды һәм Халисәгә янә бер кәлимә сүз катмый китеп барды.

Әйе, ул көннәрдә Халисә күңеле белән гафу үтенергә мең тапкыр диярлек килде, ялынды, ялварды.

Ә бит ул аны шул тикле бирелеп яраткан иде. Егет аның күңелен тәмам әсир итте. Сиздe, тойды бит Халисә, егет тә аны яраткан иде... Беренче тапкыр үбешүләре... Чылтырап аккан чишмә буе, сулышларына каба-каба куышулары... Баш алып кай тарафларгадыр китеп

бармаса, ихтимал, Халисә аңа, кәкре муенлы булуына карамастан, кияүгә чыгып куйган да булыр иде әле...

Әле булса хәтерендә, Халисә больницага килде. Шунда аңа: «Аның сине күрәсе килми», — дип чыгып әйттеләр. Халисә гарьлегеннән нишләргә, кая барып сугылырга белмәде. Шунда Гайсә килде, ул аның хәлен аңлады, юатты, тынычландырды. Һәм шул көннән ул аның якын дусты булып китте. Калганын язмыш үзе хәл итте. Гадәтләнү, бер кешегә өйрәнү була. Шул килде Халисәгә. Яраттымы ул Гайсәне, яндымы, көйдеме ялкынлы мәхәббәт утында? Юктыр, юк. Шуңа карамастан, аңа кияүгә чыкты.

## 10

Эш сәгате башлануга, бүлмәсенә Меженков килеп кергәч, Кадыйр аның белән коры гына исәнләште.

— Әйдә, уз, сөйләп җибәр.

Меженков бер тын өстәл янында таптанып торды.

— Син нәрсә гашыйк егет кебек кызарынасың. Уз. Ни булды?

— Мин китәргә булдым, Кадыйр Сөнгатович, менә гариза... Шуңа рөхсәт кенә бирсәгез иде.

Кадыйр гаризаны укып тормады, өстәлгә җәеп салды да йомры кулын кәгазь битенә куйды.

— Бәлкем, сәбәбен дә әйтерсең?

Ниһаять, Меженков түргә узды, утырды, кулларын әле өстәл астына алды, әле өстәлгә куйды.

— Ни булды сиңа, чынлап торып әйтче?

— Китәм. Бөтенләйгә, Кадыйр Сөнгатович.

— Димәк, дөресен сөйлиләр? Хатын белән аерылышасың?

Меженков дәшмәде, башын түбән ия төште.

— Хәлләр...— диде Кадыйр.— Ай-һай, кеше язмышы белән уйнау гына түгелме бу синең кыланышың? — Каш астыннан Меженковның йөз-кыяфәтен күзәтеп торды, тегесе утырган урынында борсаланып куйды, күзләрен яшерде. — Владимир Поликарпович ни ди?

— Аңа кермәдем әле.

— Хатының ризамы соң?..

— Без аның белән килештек...

— Ярый, китсәң китәрсең. Тик ишет: кайтам дип кире әйләнәсе булма, басу капкасыннан ары җибәрмәячәкмен. Тоже миңа, Дон Жуан, — дип өстәп куйды Кадыйр.

Меженков чыгып китүгә, ишектә секретарь кыз күренде.

— Кадыйр Сөнгатович, бер ханым керергә рөхсәт сорый. Бик житди мәсьәлә белән килдем, ди.

— Керсен.

Кадыйр аны түргә узганчы көтеп алды, килеп житәрәк кенә, урыныннан кузгалып, каршы торып басты.

— Рәхим итегез, Халисә Хәйдәровна, рәхим итегез. Нинди йомышлар төшеп, без бахырларны бәхетле иттегез?.. Бик житди йомыш дисез? Узыгыз, рәхим итегез. Тыңлыйм сезне, Халисә Хәйдәровна.

Дөресен әйтергә кирәк, Кадыйр шәһәрдә ихтирамга лаек булган бу врач хатыннан Меженковка кагылган сөйләшүне көтмәгән иде. Меженковның китүен ишетеп тә өлгергән үзе. «Ә мин аның гаризасына хәзер генә кул куеп чыгардым», — дип ачыктан-ачык әйтеп салды Кадыйр һәм, сөйләшүне тагын да житдиләтү өченме, әңгәмәгә телефоннан партком секретаре Воронцовны чакырды.

— Миңа кадәр бу урында утырган агай әйткән иде, безнең эштә иң читен, иң четерекле мәсьәләләрнең берсе — гаилә хикмәтләре бу-

лыр дип, һәм шул сүзләр дөрескә чыга кебек. Бәлкем безгә, хөрмәтлем Халисә Хәйдәровна, бу эшкә бөтенләй катнашмаска кирәктер? — бүлмәгә Воронцов керде, врач ханым ияк кагып кына исәнләште дә якындагы урындыкларның берсенә чүмәште. — Миңа калса, хөрмәтлем Халисә Хәйдәровна, Меженков барыбер китәр иде, кем әйтмешли, көчләп яраттырып булмый. Аннары ирексезләү, мәҗбүр итү, көчләү кеше күңелендә һәрчак каршылык хисе уятучан. Җиткермик бу хәлгә. Әгәр дә, сез әйткәнчә үк, Меженков адымы аның ялгышуы, юләрләнүе генә булса, үгет-нәсихәт белән генә акылга утыртып булмас кебек аны. Ялкынлы мәхәббәтләр үтүчән була диләр. Җете кызыл тиз уңа, шулаймы, Владимир Поликарпович? — Воронцов сүзгә кушыларга ашыкмады, башта Халисәгә, аннан Кадыйрга бер-бер артлы сынаулы караш ташлады, үзалдына көрсенеп куйды. — Шулай булгач, — дип дәвам итте Кадыйр, — кызыл мәхәббәт кенә булса, мин әйтте диярсез, акылына тиз утыра ул, күп тә үтмәс, әйләнеп кайтыр.

Халисә дәшмәде, Әмировның фикере белән тиз килеште кебек. Әмировның кешене тиз ышандыра алуына Воронцов та күптән инанган иде инде, телдән төшмәстәй матур сүзләр дә әйтмәде кебек, ә врачлардан вәкил булып килгән хатынны ышандырды бит тәмам. Шуннан соң тегесе гел дәшмәс булды, әмма йөзендә аптырау чалымнары көчәйде, бит очлары никтер алсуланып китте, борын яфраклары калтыранды.

Воронцов Меженковны бик яхшы белә иде, бу турыда ике арада шактый кызу сөйләшүләр булып алды һәм бу мәсьәләдә яңадан сүз куертуны артыкка санады. Андыйларга мең тапкыр үгет сүзен ишетүгә караганда, бер тапкыр үзе кичерү нәтиҗәлерәк булучан, шуңа күрә китә икән, әйдә, китә бирсен.

— Бәлкем сез, Халисә Хәйдәровна, минем белән килешмисездер? — диде Кадыйр, хатынның нindidер эчке дулкынануын сизеп.

— Мин коллектив исеменнән килдем, Кадыйр Сөнгатович. Гафу итегез, сездән мин бу сөйләшүне көтмәгән идем, — диде, ниһаять, Халисә. — Һәм гаилә мәсьәләсе, үзегез әйткәнчә, артык четерекле булгангамы, күренеп тора, сез аны гомумиләштерергә тырышасыз. — Хатын бу сүзләрне әйтүгә, идарә начальнигы көлемсерәп куйды, берни аңламастан, гаҗәпсенеп, җилкәсен җыерды. Халисәнең нәзек кара кашлары кош канатыдай талпынып куйдылар. — Гаилә язмышын хәл иткәндә нindidер мода турында сөйләнүне мин, ким дигәндә, хәлнең асылын белергә теләмәвегез белән аңлатыр идем, — диде Халисә ике ир-атка да хәтере калуын сиздереп.

— Гафу итегез, Халисә Хәйдәровна, ләкин бу бит хакыйкать. Нәрсә исәбенә аларны бергә яшәтеп булыр икән соң? Ярый, без аны эшеннән җибәрмәдек, ди, каты шелтә бирдек, ди, моннан ни үзгәрер?

— Семья ул — җәмгыятьнең нигезе, Кадыйр Сөнгатович. Бу эштән коллектив читтә кала алмый.

Халисә үз-үзенә исе китеп утырды. Ул сөйлиме бу сүзләрне? Башка берәү түгелме? Каян килде аңа бу кирелек, әллә соң начальникның шулай мәкерле елмаюы күңелне ярсыттымы? «Нинди тузга язмаган сүзләр сөйләп утырам. Алар мине тәрбияле, күркәм, нечкә хисле хатын дип кабул иткәннәр кебек иде, хәзер әнә Әмировның да йөзенә күләгә кунды, Воронцов та башын игән дә аяк очына карап утыра, ул да минем өчен ояла сыман. Ни сөйлим мин, нигә килдем, нигә биредә утырам, нигә торып чыгып китмим?..»

Халисә гаҗиз бер кыяфәттә торып басты.

— Утырыгыз, утыр, Халисә Хәйдәровна. Сез бик дөрес әйтәсез, гаилә — җәмгыятьнең төп ячейкасы. Тик семья дигән җирдә мәхәббәт тә булырга тиештер инде ул, — диде, ниһаять, Воронцов. Минемчә, бу мәсьәләдә башта Валентина Петровнаның үзе белән сөйләшеп карарга кирәктер? Бәлкем ул үзе үк аның китүен телидер?

Әмиров Халисәгә тагын да текәлебрәк карады, аның күзләрендә Халисә үзен кызгану хисе күрде кебек: бит алмалары тагын да кызарыбрак китте, уч төпләренә хәтле кызыша башлады.

— Төпченүем өчен гафу итегез, Халисә Хәйдәровна. Ләкин сөйләшү юнәлешебез шул якка таба кузгалгач, әйтми дә булдыра алмыйм. Мондый хурлыкка калганчы, мин үзем дә баш алып таюны артыграк санар идем...

Халисә инде Әмировны тыңламады, ул үзе өчен үзе хурланды, әмма кинәт кенә торып чыгып китәргә дә яхшысынмады.

— Белгеч буларак, барыбер бу хәл аны бизәми. Кешелек сыйфаты турында сөйләп тә торасы юк... Хушыгыз.

Ирләр икесе дә торып бастылар, икесе бергә Халисәне секретарь ягына чаклы озата чыктылар.

Халисә үлеп гарьләнде, үзе өчен үзе гарьләнде.

— Моны фәкать вакыт хәл итәчәк. Кайтыр ул, Халисә Хәйдәровна, — диде Воронцов.

— Әйе, вакыт кына исбат итә ала безнең хаклыкны, — дип куәтләде начальник партком секретаренең сүзен.

Халисә Воронцовка карап алды, куе бөдрә чәчле, ялкынсынган авыру чырайлы бу кеше аңа ошамады, ә менә Әмировның үз-үзен тотышын килештерде. Шактый һавалы, эре кыяфәт белән куллар бирешеп аерылышсалар да, Халисә бу йорттан күңелен тутырып авыр хис төяп чыкты. Хәзер ул сестра-няняларның сүзләренә карап бире килүенә үкенеп бетә алмады. Нигә болай йөри соң әле ул? Валя белсә ни әйтер? Нәрсә ул, сазаган кызмы әллә? Баласы, менә дигән хезмәте, алтын куллары бар. Теләсә үз тиңен табар әле. Бала? Бала аңа өчен иңенә ишелеп килгән бәхет кенә ич ул!

Изге әйберен җуйган берәүдәй, ул бик озак шәһәр урамнарында йөрде. Шуннан соң гына кинәт Валяларга таба китте. Хәзер инде ул аңа ни әйтерен белә иде.

Ләкин барып керүгә Валяның күзендә сагыш, иңендә күтәрә алмаслык авыр хәсрәт ятканын сизде-күрде дә, үзе дә елап җибәрде.

## 11

Кичтән эштән кайтып табын янына җыелгач, Кадыйр ашап утырган энесенә карамый гына әйтә салды:

— Ике «Жигули» кайткан иде, берсен алырга булдым. Син, Нәүфәл, ничек уйлыйсын?

— Машина? — Нәүфәл кашыгын йөртүдән туктады. — Нигә ул сезгә, болай да машинадан төшкәнегез юк.

— Чират житте дә алыйм инде дидем. Әлегә син йөреп торырсын, доверенность бирермен дә... Я,я, ярар инде дип тыйнакланып утырма. Сиңа бик кирәк чагы аның.

Сүзгә Зөһрә җиңгәчәсе кушылды.

— Егет кешегә ярап торыр ул. Син безгә чит-ят кешемени, туганыбыз ич! Бер дә яхшысынмый торасы түгел. Праваң бар дисен үзең.

— Я ходаем, мин бик шат, җиңгәчәй. Ичмасам, эштән кайчан телим шунда кайтырмын.

— Ә болай бик еш кайтасың инде,— диде Кадыйр.— Кайчан тәгәллисең? Теге вакытта бер атнадан дигән идең...

— Тиздән, абый. Күпкә түзгәнне, азга түзегез инде. Дозатор белән чиләнәбез.

— Бик сузмасагыз икән... Күреп торасың, эш мөшкел безнең.

— Тырышабыз, үзең күрәсең, ничә атна ялсыз эшлиләр егетләр.— Нәүфәл, аш өчен рәхмәт әйтеп, үз бүлмәсенә чыкты. Таң билгеләре беленә башлагач кына аның тәрәзәсендә ут сүнде.

*

* *

Әйткән сүз — аткан ук дигәндәй, менә икенче көн инде ул эшкә куе яшел төстәге өр-яңа «Жигули» белән килә. Нәүфәлнең бригадасында ике инженер, ике слесарь, бер автогенчы эшли. Йомакыйрак кеше буларак, Нәүфәл һичкайчан алар белән ачылып сөйләшеп утырмады. Ул аз сүзле кешеләргә хас үҗәтлек белән эшләп йөрде, кирәк икән, автогенчы да булды, слесарь эшләрен башкарудан да баш тартмады. Аңа беркетелгән инженерлар да эшкә хирыс булдылар, кирәк чакта уникешәр сәгать эшләделәр, вакыт белән исәпләшмәделәр. Гомумән алганда, Нәүфәл алардан канәгать иде. Автогенчы Симушкин гына мутрак булып чыкты. Нәүфәл машина белән йөри башлауга, ул тамак төбен кыргалады, ә бер тапкыр килеп туктагач:

— Мастер, эшләр харап бит, — диде.

— Ул-бу булдымы әллә, Володя?

— Юк ла. Менә машина алдыгыз, ә юу турында ләм-мим. Бер дә егетлек түгел бу, Нәүфәл Садриевич.

— Башта эшне тәгәллибез, аннары төяләбез дә — ресторанга. Килештекме?

— Юмаган әйбер, юмаган инде ул. Һич югы, бер әйләнеп килим, бирегез әле ачкычыгызны, Нәүфәл Садриевич. Армиядә хезмәт иткәндә бер полковникны йөрттем. Права кесәдә. Менә...

— Я, я, ышанам. Бар, әйләнә.

Симушкин дозатор янында торган Батыр Нигъмәтуллинга кул изәде.

— Әйдә, Батыр, бер уратып китерәм үзеңне!

— Куркам мин сиңа утырырга. Олага күр.

Симушкин бияләйләрен салып ташлады да, учына төкереп, кулынкулга ышкып алды.

— Бир ачкычыңны, мастер, — ачкычны алуга, ул аны чылтыратып һавага сикертеп алды. — Киттем, алайса!

— Әнә теге ферманы гына әйләнеп киләм.— Симушкин, машинага утыруга, борынын тартып, яңа буяу исен иснәде. — Шик, братцы!

Симушкин, үз-үзенә команда биреп, стартерга басты.

— Әйдә, Буранов, — диде ул машина кабынгач Нәүфәл янында басып торган инженер Халит Булановка.

— Юк инде, үзең генә әйләнә, — диде Буранов, аннары Нәүфәлгә: — Юкка бирәсең бу җилкуарга, әллә йөртә белә, әллә юк. Әйләнеп капланыр, шул булыр, — диде.

Машина китеп баргач кына әйтелгән бу сүздән Нәүфәл күңелендә дә шик туды.

— Кая китте дип беләсез сез аны? Кызы янына. Әнә күрәсезме колхоз фермасын. Шундагы бер сыер савучы янына килеп сара мут җан.

— Нияте изге икән, йөри бирсен, — диде Нәүфәл.

— Кая инде изге ният ул эт ялаган нәмәстәдә. Җиде җирдә җиде кызы бар. Эчеп кайтмаса, бик хуш дигез.

Нәүфәл янә машинасын Симушкинга бирүенә үкенү тойды. «Кеше машинасы, — дип уйлады ул.— Берәр кая барып чәпәлмәсә инде».

Дозатор яныннан китмәсә дә, Нәүфәл юк-юк та, Симушкин кайтмыймы дип, күзләре белән Бөгелмә юлыннан яшел «Жигули»ны эзләде. Ләкин тегесе, аның җанын көйдереп, күренми дә күренми иде, җитмәсә, Нигъмәтуллин янган учакка керосин бөрки торды:

— Бер дә бүтән түгел, Бөгелмәгә китте бу, Нәүфәл Садриевич. Мут җан бит ул, кызлар күрсә күзе тона. Утырткандыр җанкисәген дә гөмбәгә тайгандыр.

— Ә-ә, йөри бирсен, чәпәлә генә күрмәсен, — дигән булды Нәүфәл.

...Володя Симушкин әбәт алдыннан гына кайтып җитте. Машинага төсен танымаслык дәрәҗәдә пычрак чәчрәгән, аны исән-төзек күргә, Нәүфәл шунда ук тынычланды.

— Мә, мастер ачкычыңны, — диде автогенчы каршысына килүче Нәүфәлгә. — Рәхмәт яусын. Туйганчы йөрдем, ичмасам.

Һәм йөгереп барып уң яктагы ишекне ачты. Машинадан егетләр бер күрүдә гашыйк булырдай, гитара сыманрак гәүдәле бер кыз чыкты.

— Бусы әле анасы, хәзер булыр баласы, — диде Симушкин, арткы ишекне ачып, янә бер кызны чыгарды.— Менә бусы сезгә — хан кызы, менә бусысы минеке — царевна, юк, Василиса Прекрасная.

Машинадан беренче булып төшкән кыз Симушкинның кепкасын маңгаена төшереп куйды.

— Маша, нишләвең бу! Менә эшлә син боларга изгелек.

Симушкин кепкасын салды да, биш бармагы белән чәчен тарап баш киемен култык астына кыстырды.

— Таныш булыгыз, мастер. Райондагы иң алдынгы колхозның иң алдынгы сыер савучылары, орденга куалар.

— М-м, тел бистәсе, — диде Маша дигәне. — Әйдә, телеңә тилчә чыкканчы сайра инде.

— Исәнмесез!

— Мария, Маша, Машенька, — диде Симушкин кыз өчен. — Ә бусы Халисә исемле.

Нәүфәлнең йөрәге дерт итеп китте. Очраклы рәвештә әйтелгән бу исем аның күңелен айкап алды. Секундлар эчендә күз алдыннан чишмә буе, каенлык, бакча, теге чактагы эт сурәтләре чалынып узды.

Халисә атлы кыз озын чандыр буйлы, какча гәүдәле, тирән утырган җете кара күзле, ап-ак йөзле иде.

— Әйдәгез чәй эчәргә, кызлар. Мактап йөрисез икән, — диде Нәүфәл.

Кызлар күргәч, будкада чәй эчеп утыручы егетләрнең барысы да тышкы якка ябырылдылар..

— Берәмләп чиратка басып танышыгыз, катык борыннар. Кыюрак, Маша, Халисә! — Симушкин авыз эченнән туш уйнап алды.— Таныштыгызмы? Әйдәгез чәй эчәргә, кызлар! — Кечкенә будкага егетләр керә башлады. Баскыч өстенә менеп өлгергән Симушкин: — Э-э, егетләр, әдәп саклау кирәк, берәмләп. Башта кунаклар узсын. Мастер, әйдәгез.

Маша, аның артыннан ояла-тартына Халисә кергәч, Нәүфәл дә будкага күтәрелде. Симушкин өстәлгә төрле шоколад конфетлары чыгарып сипте.

— Гафу ит, мастер, чибәркәйләрне сыйлау өчен Бөгелмәне урап килергә туры килде.

Маша белән Володя күзгә-күз карашып алдылар. Халисә, учы белән авызын каплап, пырхылдап көлеп җибәрде.

— Кулдагы бармакның иң көчлесе, иң матуры, иң хаҗәте кайсысы? Имән бармак инде. Менә мин кем, мастер. — Володя түшен киерде. — Маша, күр!

Маша шап итеп аның күкрәгенә сугып алды.

— Калай әтәчләнмә әле бик, Володька. Чәй көйлә әнә.

Чәйне бик тәмләп эчеп утырганда, Маша Нәүфәлгә карап сорау бирде.

— Әйтегез әле, мастер, ни корасыз биредә айлар буена?

— Менә Володя аңлатсын,— диде Нәүфәл, үзе Халисә ягына күз ташлады. — Барысын да ул коручы.

Шуны гына көткәндәй, Симушкин «Спутник» һәм дозатор турында дәртләнеп сөйли башлады. Маша аны тыңлап торды-торды да:

— Ә сез безгә дә шундыйрак бер автомат корып бирә алыр идегезме? — дип сорады.

Симушкинның күзләре зурайды, ул әле Нәүфәлгә, әле кызларга күз төшереп алды да, кулын күтәреп:

— Бирәлабыз, ник бирмәскә, — диде. — Тик, Машенька, без бит инде җиде кат җир астыннан нефть суыртабыз, ә сез дүрт имчәкле сыер-малкайларны савасыз.

— Шаяртмале, Володя. Безгә сыерларга азык өләшергә автомат кирәк.

— Азык өләшергә иң камил, иң әйбәт автомат, бишенче гасыр коралы — дүрт япьле сәнәк.

Халисә янә авызын каплап көлеп җибәрде. Маша калагы белән Володяның маңгаена менеп төште. Симушкин, күз агын әйләндереп, аннары кылыйландырып, бер тын иңке-миңке булып торгандай кыланды.

— Сөйләмә тузга язмаганны. Сездә әнә автомат та автомат, ә бездә — сәнәк. Сез нефть бирәсез, ә без — сөт. Кайсы сиңа кирәгрәк, әйт әле, Симушкин! Иртән ни эчәсең, иблис токымы?!

— Пас! — Симушкин ике кулын күтәрде.— Пас, пас. Мастер,— диде ул Нәүфәлгә.— Эшлик үзләренә бер изгелек, ясап бирик бер автомат.

— Башлаган эшне төгәллик әле, Володя, аннары күз күрер.

— Сез керешсәгезме, Нәүфәл Садриевич! — дип, канатланып китте Володя һәм өстәп куйды. — Нәүфәл Садриевич алынамы, Машенька, җиренә җиткермичә туктамый да туктамый инде.

— Бу егыз чын булса, әүвәл барып карарга булыр.

Маша Нәүфәлгә шикләнеп карап торды. Мастерның кыяфәте ана ошамадымы, кызның куе зәңгәр күзләрендә серле һәм кинаяле бер елмаю чагылып алды.

— Чынлап килерсезме?

— Менә бу «Спутникны» ходка җибәргәч, сез дигәндә — без идәндә, — диде Володя Нәүфәл өчен.

— Килербез! — диде Симушкин сүзләрен куәтләп Нәүфәл дә. Ул моны шундый нык һәм ышандырырлык итеп әйтте, Маша белән Халисә, сөйләшеп куйгандай, икесе тиң авыр итеп көрсенеп алдылар.

— Мастер, инде кызларны илтергә рөхсәт итегезче.

— Юк, Володя, кызларны Буранов илтә һәм бер җайдан фермаларын да күреп кайтыр.

Кызлар бер-берсенә карашып елмаеп куйдылар, чәй өчен рәхмәт әйтеп, кузгала башладылар.

Симушкин аларны машинага чаклы озата килде, утырышырга булышты, шул арада җанкисәген үбәргә өлгерде, аннары шапылдатып ишек япты һәм кул изи-изи кызларны озатып калды.

— Эх мастер, кызларның иң асылын, күргәзмәгә китергәндәй, каршыгызга тездем. Булса була икән дөньяда шундый кеше, хет бер күз сирпеп сокланып карар идегез үзләренә! — дип аптыратты Симушкин.

— Буш мәсьәлә бу, Симушкин, юкка баш ватма, бар, эшеңә кереш, — дип, егеттән арыну ягын карады Нәүфәл. Ә үзенең әллә нигә күңеле тетрәнеп китте. Халисә исемен ишетүгә — әллә нишләде бит. Онытылмаса онытылмас икән яшьлектәге изге хисләр.

## 12

Ятмадан цикллап файдалану мәсьәләсе буенча район комитеты белән киңәшеп алган Воронцов иртән иртүк Кадыйр янына керде.

— Беренче секретарь да, икенчесе дә башта идарә белгечләре, актив белән җыелып сөйләшергә киңәш бирәләр. Нишлибез, Кадыйр Сөнгатович? Чынлап та, шулай эшләргә кирәк булыр. Мин аларның фикерен хуплыйм.

Кадыйр галстугын бушата төште, ахыр килеп, түзмәде, торып ишекле-түрле йөренергә кереште.

— Сүз дә юк, зур эшкә зуррак хәзерлек кирәк. Мин риза, киңәшик. Ләкин бер идея тирәсендә бик озак әвәрә килә башласак, аны башка берәүләрнең тормышка ашырып куюлары бар. Сабыр төбе сары алтын булса да, теге я бу чараны тормышка ашыруда нинди дер тәвәккәллеккә бармыйча булмый, Василий Поликарпович. Баш геолог Сибирцевның да бу хакта нигездә фикере бар, башкалар нинди киңәш бирүгә карамастан, сез дә бу идеяне тизрәк тормышка ашыруда миңа ярдәм итсәгез иде дигән идем.

Воронцов әллә ризалашып, әллә идарә начальнигының тәвәккәллегенә гаҗәпләнә калып, баш кага-кага чыгып киткәч, Кадыйр өстәл янына узды. «Ярый, — дип сыкрады ул эчтән генә, — әйдә, ул дигәнчә булсын, җыелып киңәшик. Әмма моннан ни үзгәрер? Һични! Доклад ясауны Сибирцевка бирергә булыр. Нәүфәлне дә чакырырга. Әйдә, тыңласын, күрсен әле нинди кыенлыкларга дучар итте абыйсын туар-тумас идеясе белән».

Киңәшмә алдыннан Кадыйр «Нефть ятмаларыннан цикллап файдалану ысулы яңамы?» исемле мәкалә белән өлкә газетасында чыкты. Мәкалә район белгечләрен генә түгел, Берләшмәдәгеләрен дә кызыксындырган, күрәсең, икенче көнне үк аңа Кудрявцев шалтыратты.

— Тагын ни майтарып ятасың анда? Сүнеп барган ятманнан ни алмакчысың? Булмаганны. Ташла. Юк белән башың катырма. Шул сиңа дусларча киңәш.

Кудрявцев белән сөйләшүдән исенә килеп җитмәде, Кадыйрга район партия комитетының промышленность бүлеге мөдире шалтыратты.

— Ашыга төшәсез түгелме, Кадыйр Сөнгатович? Беләсезме ашыгып ни куалар?.. Әйе, куян, — диде күкрәк тавышы белән бүлек мөдире. — Әүвәл галимнәр белән киңәшеп карарга иде. Элмәккә баш тыгарга өлгерер идегез әле...

Кайдыр телефон трубкасының кайнарлана башлавын тойды кебек. «Менә башланды да», — дип уйлады ул кәефе кырыла баруын сизеп. Һәм, трубканы куйган булса да, бүлек мөдире белән сөйләшкәндәй әйтеп салды: «Ярый, сезнеңчә булсын, киңәшик, галимнәрне дә дәшәрбез, килсәләр», — дип өстәде.

Менә ничә көн инде киңәшмә мәсьәләсе Кадыйрның йөрәгендә таш булып ята. Киңәшмә көнен ул түземсезлек белән көтте. Шунда сөйләшү, ниһаять, йөрәктә яткан ташны да эретер сыман иде. Сибирцевның докладын тыңлаганнан соң кәефе кырылды. Баш геолог ысулның файдалы икәнен җиренә җиткереп дәлилли алмаган кебек тоелды аңа, бу хисне ул Нәүфәл энесен тыңлаганда да кичергән иде, шуңа карамастан, шушы идеягә теше-тырнагы белән ябышты түгелме?

...Кабинетка керүгә, Кадыйр өстен салмый-нитми түр якка узды, тәрәзә каршына барып басты. Шул тәрәзәдән ана уйсулыклар, Кыяр тавы, тау итәгендәге утыз өченче скважина күренә. Скважинадан карашын көнчыгышка күчерде. Кояш чыгып килә, шул тарафтан жил исә һәм тротуар буйлап утыртылган агачларның башын ия, яфракларын шаулата, кичәге яңгырдан жыелып калган күлдәвекләр өсте шадраланып кала, шул күлдәвекләрнең берсенә төшкән кәгазь кисәге, канаты сынган кош сыман, искән жилгә леперддәп, очып китәргә теләп талпынып куя.

«Ятманы туктатып торганнан соң аннан күпме нефть алыныр? Алган хәлдә, күпме күләмдә саф нефть чыгар? Алу тагын күпмегә барыр? Айлар буе Кадыйрның — аның гынамы, баш геологның һәм тагын әллә кемнәрнең — башын катырган мәсьәләләр шул иде. Секретаре ягында аяк тавышлары ишетелгәч, Кадыйр, плащын салып, өстәл янына килеп утырды. Нәүфәл ашыкмаска куша, барлык мәгълүматларны жыеп ЭВМга бирик ди, ятма сүнгәч эшкә керешүдә ни файда. Аның уенча, ЭВМ һәр скважина турында тулы мәгълүмат бирәчәк һәм, шуңа карап, кайсы скважинаны туктатып торырга, кайсысыннан файдаланырга мөмкин дигән төгәл нәтиҗә ясалачак. Ә ул хикмәтле ысулны сынап өлгермәсәк?..

Ул арада кабинетка белгечләр керә башлады. Киңәшмәгә килүчеләрнең кайсысы ияк кагып кына, кайсы кул биреп үк Кадыйр белән күрештеләр дә утырыша башладылар. Баш инженер Идрисов та керде һәм ул да Кадыйр белән ияк кагып кына исәнләште дә түр тәрәзә каршына узды. «Кудрявцевны көтә»,— дип уйлады Кадыйр, бу кешегә карата көннән-көн күңеле сүрелә баруын тоеп. Кичә аңа Воронцов район комитетыннан да кеше була дигән иде. «Аннан кем киләр икән?» — дип утырды Кадыйр тәүге уйларыннан арына алмыйча.

Кудрявцев килеп житүгә, Идрисов ашыгып ишеккә юнәлде. Кадыйрга хәтта аның баскычтан йөгереп төшкән аяк тавышлары ишетелгән кебек булды. Идрисовның болай кылануын кабинетка жыелган белгечләр дә ошатмады, күрәсең, бер-икесе тәрәзәгә капланды, баш инженерның Кудрявцевны каршы алуын күреп мәгънәле рәвештә баш чайкап куйдылар. Кадыйр да тышта барган хәлне күзаллап утырды. Менә Кудрявцев машинасы килеп туктады, Идрисов йөгереп чыкты, менә алар бер-берсенә баш ия-ия күрештеләр, менә баш инженер Берләшмә вәкилен култыклап алды, менә алар бергәләп ишеккә юнәлделәр...

Кабинетка керүгә, Кудрявцев һәммәсе белән дә кул биреп күрешеп чыкты, Кадыйрга житкәч, туктады, мәгънәле генә елмаеп:

— Котлыйм, дускай. Я, исәнлекме! Соңга калмадыммы? — диде.

— Юк-юк, бик вакытлы килдегез, Виталий Семенович,— диде Кадыйрдан алда вәкил янәшәсендә басып торган Идрисов.— Халык яңа гына жыела башлады. Район комитетыннан да кеше килеп житмәде әле.

— Иптәш Воронцов кайда соң? — дип, тирә-ягына карангалап алды Кудрявцев, ни сәбәпледер Берләшмә вәкиле янә Кадыйрга дәште, Идрисовка бөтенләй игътибар да итмәде.

— Биредә ул, райком вәкилен көтәдер,— диде Кадыйр.

— Нигәдер институттан да кешеләр күренми?

— Без аларны чакырмадык,— Кадыйр аягүрә басты.— Башта үзебез төшеник, уртак бер фикергә килик дигән идек...

— Һы, бәлкем дөрес тә эшләгәнсез,— диде Кудрявцев. Аннары, Кадыйрның колагына иелә төшеп, өстәде: — Наташа килә алмады, авырып тора, синнән персонально гафу үтенде,— диде. Кадыйрның йөзенә кызыллык йөгерде, аның шулай кызарынып китүенә игътибар

итмәскә тырышып, Кудрявцев: — Моннан да зуррак йомыш белән килергә исәбебез бар иде. Я, ярый, ул турыда соңыннан. — Берләшмә вәкиле Кадыйр янәшәсендәге буш урындыкка утырды, кабинеттагыларга күз йөртеп чыкты. — Күрәм-карыйм да, Кадыйр, нигәдер бер дә кәефең юк шикелле, — диде күршесенә карамый гына, чит берәүгә сөйләгән кебек. — Әллә, мәйтәм, хыялый уйларың бермәлгә калдырып торырга булдыңмы? Алдан ук кисәтеп куям: ятманы туктатып торырга Берләшмә риза булмаячак.

Ул да түгел, кабинетка соңга калуларына гафу утенә-утенә, Воронцов белән район комитеты вәкиле килеп керделәр. Ике метр ук булмаса да шул чаманы куып, буе белән түшәмгә тияр дәрәҗәгә җиткән партком секретаре артыннан атлаган райком вәкиле:

— Гафу итегез, иптәшләр, сезне бераз тоткарладык бугай — дип акланып алды. Стенага төрле диаграммалар, белешмәләр элеп йөргән Сибирцевка: — Башла булмаса, Михалыч, —диде.

Кадыйр күршесе Кудрявцевның терсәген тоя, ул Берләшмә вәкиленең төп уй-фикерен белми, шуңа, ахрысы, борчыла, нервлана иде. Берләшмә вәкиле буларак, Кудрявцев шефтан нинди дә булса төгәл күрсәтмә алып килгән булыр һәм биредә ниләр генә сөйләмәсеннәр, ул аны барыбер тормышка ашырыр. Башка берәү булса Кадыйр бәлкем әле шулай дип катгый төстә уйларга да икеләнер иде, әмма Кудрявцевның кем булуын артыгы белән белгәнгә, ул бүтәнчә уйлый алмады.

— Кыюрак, Михалыч. Иптәшләр белә: ысул яңа, һичкая сыналмаган, бәлкем әле барысы да исәпләнеп тә җитмәгәндер, шуның өчен җаваплылык иң әүвәл идеяне бирүче кеше өстенә төшәчәк, калганын ул өстәр, ул тулыландырыр, — диде Кадыйр һәм почмакта утыручы Нәүфәлгә күз төшереп алды.

Һәммәсе дә шул якка карадылар.

Баш геолог Сибирцевны тын алмый диярлек тыңладылар. Сүнеп барган ятмадан кимендә ун-унбиш процент өстәмә нефть алу — бөтен дөнья нефть суыртучыларының хыялы. Бу юнәлештә безнең илдә генә ничәмә-ничә фәнни-тикшеренү институтлары эшли, ә монда бер егет, әйтик, рядовой инженер шушы юнәлештә нидер үзгәртмәкче, нидер кырмакчы. Гаҗәпләнмәслек тә түгел иде шул.

Сибирцевтан соң Нәүфәл чыкты, ул берсе артыннан берсе коелып кына торган сорауларга нигезле җавап бирергә, төпле дәлилләр китерергә тырышты. Башта Нәүфәл шактый каушады, имгәнгән муен сеңере тартышкалап алды, тотлыкты, әмма тора-бара ул эчке тәэсиргә бирелгән бер кыяфәттә, онытылып киткәндәй булды, шомырт кара күзләре уттай уйнады, теле дә шомарды, указка тоткан килеш, ул бер сызымнан икенчесенә күчте, күрсәтте, аңлатты. Урынына утыргач кына Нәүфәл җиңел сулап куйды, тир бәреп чыккан маңгаен кулъяулык белән сөртә-сөртә, үзара сөйләшеп утырган белгечләргә күз йөртеп чыкты.

Аннары сүз ала башладылар. Баш инженер ашыга төште бугай, аның шулай атылып чыгуын күрүгә, фикердәшенең бу адымын килештермәвен сиздереп, Кудрявцев чыраен сытты, ияген чөя төште. Берләшмә вәкиленең канәгатьсезлеген күрепме, Идрисов кинәт кенә сүз башлый алмый, гипнозга дучар булган кешедәй, авызын ачкан килеш Кудрявцевка карап торды.

— Иптәшләр, ниндидер хыялларны калдырып, безгә тиз арада күмер катламына күчәргә кирәк, — дип сүзен башлады Идрисов. Ул Кудрявцевтан күзен ала алмый җәфаланды. — Шулай иткән хәлдә дә идарә бүген чыгарган күләм нефтьне суырта алмаячак. Иң дөресе, тиз арада идарәне промысел итү. Мин бу турыда элек тә әйтә килдем һәм янә кабатлыйсым килә...

— Аннары барыбызга да Төмәнгә күчеп китәргәме? — дип кыстырды кемдер урыныннан кузгалмыйча гына. Кудрявцев шул якка карап башын чайкап куйды, ә Идрисов гүя бу репликаны ишетмәде дә.

Сүзне Кудрявцев алгач, ул нигәдер сорауны Сибирцевка да, идеяне бирүче Нәүфәлгә дә бирмәде, ә Кадыйрга карап бирде.

— Әйтегез әле, Кадыйр Сөнгатович, ятманы озакка туктатып торыргамы исәбегез? Бирелә берничә сан әйтелде. Төгәл генә килгәндә, әйтик, тәүлегенә җиде-сигез, ул гына түгел, ун-унике мең тонна нефть биреп яткан ятманы күпмегә туктатып торырга мөмкин?

— Бүген ун мең тонна бирсә, иртәгә аның бөтенләй сүнеп куюы бар, Виталий Семенович, — диде Сибирцев. Кудрявцев: «Мин сорауны сезгә бирмәдем бугай», — дип гаҗәпләнгәндәй итте, сөзеп, баш геолог ягына карап алды.

— Бер атна, ә бәлкем ун көн, — диде Нәүфәл.

— Ун көн, — дип кабатлады Кудрявцев. — Арифметиканы белгән кешегә бераз гына мәгълүм булса кирәк, Берләшмә шушы ун көн эчендә меңнәрчә тонна нефть югалтачак.

— Билгеле, бу — риск, — диде Кадыйр. — Ләкин бит һәр сынау — үзе тәвәккәллек. Шунысы да мәгълүм булса кирәк сезгә, Виталий Семенович, илебездә йөзләгән ятма табылды, табыла тора, аларның беришесе инде сүнеп бара, иң хәтәре шул: геологлар күрсәткән нефть запасының яртысыннан күбесе сүнеп барган катлам куенында кала. Идарә һәм Берләшмә күзлегеннән генә эш йөрткәндә, беренче мәлдә, бәлкем, бу ысул кайбер югалтуларга да алып барыр. Кабат әйтәм, тик беренче мәлдә генә. Гомумән алганда, без ил өчен гаять перспективалы ысул тәкъдим итәбез. Шушы ысул белән җир куенында калган нефтьнең, әйтик, ике-өч процентын гына алганда да...

— Хыял, фантазия, — диде Кудрявцев Кадыйрны бүлдереп. — Идарәне саклап калдыру өчен мин сезгә башка юл сайларга киңәш бирер идем: баш инженерны тыңлап, тиз арада күмер катламын эшкәртүгә күчәргә һәм никадәр тизрәк күчсәгез, шул кадәр әйбәтрәк булыр. Чөнки баш геологның һәм бу идеяне биргән инженерның дәлилләре коры интуициягә генә корылган. Миңа хәзергә бер нәрсә ачык: ятма сүнә, дәүләт интереслары белән эш иткән кешегә аңлашылса кирәк, безнең өчен идарәне промысел итү бердәнбер чара булып кала. Бирелә сүз әнә шул турыда гына барырга мөмкин.

— Хакыгыз юк, — дип урыныннан күтәрелде автоматика цехы начальнигы Покровский. — Хакыгыз юк идарәне промысел итәргә, иптәш Кудрявцев. Бүгенге көндә идарә дәүләткә тәүлегенә ун мең тоннадан артык нефть озатып ята. Мин Әзербәйҗанда тәүлегенә нибарысы ике мең тонна нефть биргән идарәдә эшләдем. Ә тәүлегенә ун мең тонна биргәнне промысел итәргә хакыгыз юк!

— Сез, иптәш Покровский, әүвәл чор турында уйлап карагыз. Ул сугыштан соңгы еллар иде. Дәүләткүләм күзлектән чыгып эш иткәндә, хакыбыз бар, бик бар, — диде Кудрявцев.

Кадыйр цех начальнигы Покровскийга тынычланырга кушты. Кудрявцев әйтәсе сүзен әйтеп бетергәч тә, Покровский ягына карап алгалады.

— Ятманың һәм шул ятмада калган меңнәрчә тонна нефтьнең язмышы гына хәл ителми бүген, иптәш Покровский, — диде Кудрявцев куш йодрыгын өстәлгә салып. — Монда дөньяда хәл ителмәгән проблема куела. Һәм аны бүген кай якка булса да хәл итәргә кирәк. Сезнең бурыч — нефть бирү, иң әүвәл шул турыда онытмасагыз иде. Скважиналарны группалап корыга керештегез. Анысы әйбәт чара. Ә инде катламда калган нефтьне алырга тырышуыгыз коры хыял гына ул. Ни бәрабәренә төшәчәк Берләшмәгә бу ысул белән алган бер тонна җир мае? Ятманы ун көнгә файдаланудан туктатып тору һич тә

башка сыя торган чара түгел, иптәшләр. Бүген идарә биргән нефтьне кем бирер?

— Бирегез батырма насослар, бирегез яңа техника, нефтьне бирербез аны, — дип, тагын чәчрәп чыкты Покровский.

...Киңәшмә кичке сәгатьләрдә генә тәмамланды. Киңәшмәдән соң кабинетта икәүдән-икәү генә калгач, Кудрявцев ишекле-түрле йөренде-йөренде дә, өстәл артында утыручы Кадыйр янына туктады.

— Идея сыек, уйлап җиткермәгәнсез. Промыселлар идарәсе фәнни-тикшеренү институты түгел, экспериментлар уздырырга кем дә рөхсәт бирмәячәк. Юк белән баш ватма. Ризалаш. Иртәме, соңмы идарәне барыбер промысел итәрләр, яисә РИТС булыр. Үзең турында уйла. Җитмәсә, араларыбыз тагы да якынлашырга тора, — Кудрявцев кулын Кадыйрның җилкәсенә салды. — Нигә ашкынасың син алай. Миңа калса барысы да без дигәнчә бара түгелме. Синең төп вазифаң нефть бирү ич. Чиле-пешле идея белән мавыгып, үз-үзеңә аяк чалма әле. Мин дусларча әйтәм, үпкәләштән булмасын.

Кудрявцевның авыр кулыннан арынырга теләпме, үзенең ризасыз лыгын белдерүе идеме, Кадыйр урыныннан кузгалды. Җилкәсендә яткан кул шап итеп өстәлгә төште. Әйе, каты иде сабакташының кулы.

— Кем ул синең Покровскиең? Нигә ул ни теләсә шуны кычкырып утыра?

— Покровский әйбәт кеше, эш өчен җаны фида. Менә мин Идрисовны, баш инженерымны аңламыйм, кая таба тәгәри ул?! Синең җырыңны гына җырламыйдыр бит! — дип ачыктан-ачык әйтеп салды Кадыйр.

— Куй. Идрисов бик белеп эш итә. Ул, гафу ит, синең кебек юкбар идеяләр белән баш катырмый. — Кудрявцев Кадыйрның ай-һай дип башын чайкавына игътибар бирмичә, үз сүзен дәвам итте. — Идрисов үсәргә тели. Һәм мин аңа булдыра алган кадәр ярдәм итәчәкмен. Сиңа да....

— Куй. Боргалама. Син, сабый бала сыман, гел үпкәләргә генә торасың. Идрисов ул Идрисов инде, минем өчен ул беркайчан да сер булмады. Менә сине аңламый йөдим мин. Нинди урынга тәкъдим итәм үзеңне, ә синең үз туксаның туксан. Имеш, катламда калган илле процент хәзинәне ала. Бөтен дөнья галимнәре шул юнәлештә баш вата, әле булса нинди дер нәтиҗәгә ирешкәннәре юк. Ә монда берәү таш ярып су чыгармакчы...

— Идея ул — хыял, уй. Дөрес әйтәсең. Ләкин шул идея тормышка ашырылдымы — ул инде тормыш үзе. Бу идеяне тормышка ашыру, нефть чыгаруда революция үк булмаса да, шуңа таба зур адым булачак. Теләсәң нишлә, Виталий, мин үз фикеремдә калам.

Кудрявцев кулын гына селтәде.

— Каян эзләп таптың син аны? Чынлап та энеңме, әллә булмаса фамилиядәш кенәме ул сиңа?

— Анысы вак мәсьәлә. Иң мөһиме — идеяләр дөньясында яшәүче бер хыялый адәм ул.

— Троянов картка бир дә котыл үзеннән. Ул җыя шундый хыялыйларны. Институтка ул күбрәк файда китерер кебек. «Һәм синең башыңны катырып йөрмәс иде», — дип өстәргә иткән иде Кудрявцев, әмма Кадыйрның кырысланып китүен күрепме, дәшмәс булды.

Кадыйр өстәлдә яткан кәгазьләрен җыештыра башлады, сүзне тәмамларга вакыт дигәндәй кабаланды.

— Бармас ул анда.

— Син аңа башта тәкъдим итеп кара. Ә үзеңә менә дигән эш бар. Калдыр шул сүнеп яткан идарәне, күч, әйдә, мин әйткән урынга.

— Ятмадан ун процент калган запасны алганда да без...

— Герой булырга исәбеңме әллә? — Ярый, калдырып торыйк бу

бәхәсне. Күрәм, кәефсез чагың. Я, чәйгә дәшәргә ниятең бармы, юкмы синең? Кодалар булырга торабыз бугай, — дип, Кудрявцев коридорга чыгуга Кадыйрның җилкәсенә кулын салды, күзләренә карады.— Һ-э-э, брат, син бит әле һаман кызларча кызарына беләсең, бер дә тикмәгә түгел бу, гашыйк булдыңмы әллә?

— Ялгышмыйсың, Виталий. Мин, чынлап та, гашыйк...

— Зөһрә ханым ни ди соң?

— Бөтен бәла дә шунда шул, — Кадыйр кисәк сүзсез калды, тел очына килгән сүзне кире йотты. — Ашыкмыйлар микән бу яшьләр дип шикләнәм?

— Зөһрә ханым янына барыйк әле. Башта аны күрәсем килә.

— Зөһрә ул — хатын-кыз, логикасы да хатын-кызныкы. Минемчә, Виталий, яшьләр бераз ашыга төшәләр. Һич югы, институтны тәмамласыннар иде. Әле бит аларга һәммә нәрсә дә кызыл төстә күренә.

— Үзләре килешкәннәр икән, безгә ни, ризалашыйк, карышып маташма, Зөһрә ханымның да кәефен бозма. Ишетүем хак булса, ул күптән риза инде.

Урамга чыккач, Кудрявцев машинага утырудан баш тартты.

— Җәяү генә атлыйк. Бу идеяң белән тәмам башым катты.

Тротуарга төшеп, янәшә атлап киттеләр.

— Их, яңгырлар яумый, җир кибә, агачлар уңа башлады.

— Колхоз председателе генә буласы калган да бит үзеңә.

— Ә нигә? Куйган булсалар, ул эштә дә эшләгән булыр идек. Анда да әллә кемнәр эшләми. Бит иң мөһиме кешегә «мин үз урынымда» дигән хакыйкатьне аңлау.

— Килгән мәлне беренче секретарь сине колхозга вәкил итеп җибәрә язган икән дип ишеткән идем, хакмы шул?

— Шуңа охшаш бер хәл булып алган иде. Ләкин без бер-беребезне бик тиз аңлаштык.

— Күрәселәрең алда әле, туганкай.

— Бик ихтимал. Ләкин иманым бер нәрсәгә камил: син ашамасаң, минем башны ул ашамаячак.

— Ташласана. Куй дим. Мин сиңа бүген беләсеңме кем булып барам — башкода булып. Шулай булгач...

Зөһрә аларны ишегалдына чыгып каршы алды, кояштай балкып каршына атлаган хатынны күрүгә, кунак тәмам авызын җыялмас булды, рус халкына хас ачыклык белән булачак кодачасын ике бит алмасыннан чут-чут үбеп алды, шул ук вакытта: «Кадыйр көнләшмәс, шәт», — дип шаяртып алды, хәтта ирләргә хас итагатьлелек белән ниндидер юмарт комплимент та әйтергә өлгерде. Зөһрәнең болай да алсу битләренә гүя ут капты. Өйгә кереп, табын янына җыелгач та Кудрявцев булачак кодачасына комплиментлар әйтүдән туктамады. Шушындый төчеләнүләргә гадәтләнмәгән Зөһрә башта ни әйтергә, ни кылырга белми кухня белән ике арада йөрде-йөрде дә, чәе сыегая төшкәч, Кадыйр янәшәсенә килеп утырды. Өчпочмакны Виталий аерата яратып ашады, тамак колы булмаса да, өстәлдәге ризык-нигъмәтләрне хәзерләгән Зөһрәгә мактау сүзләре яудырып кына торды. Ниһаять, ул бераз тынып, алдындагы чәен көмеш калак белән болгатып утыра башлады. Ахыр килеп, тамак кырып алды. Сүз соравы иде.

— Зөһрә Ибраһимовна, мин сезгә бик тә, бик тә зур йомыш белән килдем бит әле. Сезгә мәгълүм булса кирәк, без Кадыйр белән бер институтта укыдык... — Ул янә тамак кырды. — Бер группада. Һәм иң гаҗәбе шул булды: язмыш безне бүгенге көнгә кадәр аермады, бер сукмактан, бер эздән йөртте. Шул гомер эчендә ул да үзенә тиңне тапкан. Икебезнең сөекләребез дә, сөйләшкәндәй, берсе малай, берсе кыз тапты, алар инде әнә балигъ булып үсеп җиттеләр, хәзер шул балалар чәчләрен чәчкә бәйләмәкчеләр. Заманалар алышынды, Зөһрә

ханым, хәзерге балалар ата-анадан кем беләндер кавышырга рөхсәт-фәлән сорап тормыйлар, табышалар да кавышалар да куялар. Яшьләр, минемчә, үзара килешкәннәр инде, безгә, кем әйтмешли, ризалашырга гына каладыр. Мәхәббәттән өстен булып булмый. Күпме карышсак та, саф мәхәббәт барыбер җиңәр.

— Хөрмәтлем Виталий Семенович, очар казда артык кауры́й булмаган кебек, ата-анадан да бала артмый диләр. Кызыбыз бик тә яшь бит әле, Виталий Семенович. Яшьлектәге сөю-сөелүләр тиз үтүчән була ул,— дип көяләнебрәк тезеп китте ана кеше. Хатыны инде күз яшенә тыгылыбрак сөйләгәнгә, ата кеше гаҗәпләнә калды. Сөйләшү рәсми төс ала башлагач, ана кеше монда да ана булып калды, кызын югалтуга эчке сыкрау тойдымы, кинәт нягe белән түшенә төртелде һәм елап җибәрде.— Укысыннар иде баш-шта, Виталий Семенович. Өлгерерләр иде әле ганлә йөгенә җигелергә, исән кешегә качасы нәрсәме...

— Менә инде анысына яшьләр үзләре гаепле, сөеклем Зөһрә Ибраһимовна. Мәхәббәт кемгә дә ишек шакып килеп керми бит, сизми дә каласың гашыйк булуыңны...

Кадыйр бу ике кешегә ачуланмады, тын гына тыңлады, чәй эчте, уйланды. Алар аның өчен сәхнәдә уйнаучы артистлар сыман иде. Ул кызы турында да, аның йөргән егете Сережа турында да уйламады, ике кеше аның барлыгын онытып яшьләр язмышы турында сөйләшкән арада Наташа турында уйланып утырды Кадыйр. Ничек кабул итәр ул балаларның кавышуын? Хуплармы? Әллә соң тыштан хуплап та, эченнән минем кебек йөрәге әрнеп утырырмы?.. Ни сөйли бу хатын тагын? Ире турында гайбәт сата башлады түгелме? Узынды тәгаен... Уйлары бүленде, хатынының сүзләренә колак салды.

— ...бераү булса бер көн дә тормас иде үзе белән. Күрче син аны ниндәен эштән баш тарта икән бит әле. Күрче, сүнеп барган ятма кадерле аңа. Ишетәсенме, Кадыйр дим, синең турында сөйлибез түгелме. Ни дип әле син Кама ягына китүдән баш тартып йөрисең? Әйе, синеке генә — синеке, үзенекен үзе итмәсә капканы — калҗа, ашаганы — ризык түгел. Китмисең икән, кал шул ятмаңа ябышып, ә мин тотам да китәм. Табып бирер әле Виталий Семенович үземә бер фатир. Ишетәсенме, Кадыйр, сиңа әйтәм түгелме?

Кадыйр көлемсерәп алды, чебен кугандай, кул селкеп куйды, янәсе, юк белән башны катырма әле, бик китәсең килә икән, китә бир, мондый иргә хатын бетмәс. Аның шулай усал кигәвеннән котылырга теләгәндәй селтәнүен күреп Зөһрә белән Виталий көлешергә тотындылар. Кадыйр кунакның рюмкасына коньяк койды. Ләкин Кудрявцев үрелеп тә карамады, киресенчә, ризык-нигъмәтләрне мактады, ашап кына утырды, Кадыйр исә кыстатып тормады: салды да эчте, салды да эчте, шуңамы бераз йомшара төште. Шуннан соң табындагылар аңа бөтенләй игътибар итми башладылар.

— Ай-һай, тәмле дә соң вак бәлешегез, — дип һаман мактавын белде аз-маз капкалап утырган Кудрявцев. — Телеңне йотмалы. Мондайны капмавыма бер гомер булгандыр. Әни, мәрхүмә, шулай сезнең кебек, Зөһрә ханым, тәмле итеп пешерә торган иде ризыкны.

— Әй, оялтмасана, Виталий Семенович.

— Юк-юк, чыны шул. Кызыгыз да шулай аш-суга оста булса, яшәсе икән минем Сережага бал да май эчендә.

— Куегызчы, Виталий Семенович. Наташагызның да кулыннан килмәгәне юк. Бер тапкыр балык пирогы пешереп ашатты. Кадыйр өчме, дүртме кисәк ашады шунда, мактап бетерә алмады хатынгызны.

«Юләр хатын, — дип уйланып утырды Кадыйр. — Наташаның күнеле булсын өчен генә ашадым ич мин ул пирогларны. Бу да синең күңелең булсын өчен генә мактаганны белмисеңмени! Нигъмәт-ризык күрмәгән кешеме Виталий. Әнисе пешекче булып эшләгән аның, Зөһ-

рәкәй. Ә син аңа ышанасың, авызың колагыңа житкән. Дөнья ул, дөнья диләр аны картлар. Белмисең шул әле син иреннең шул Наташа исемле хатынны әле булса яратканын, белсәң ниләр кылыр идең микән, нинди көйләргә җырлый башлар идең?»

— Һич югы, башта институтка керсен иде кызыбыз, Виталий Семенович.

— Анысы вак мәсьәлә, Зөһрә Ибраһимовна, быел булмаса, киләсе елга керер, — Кудрявцев шунда гына Кадыйрга игътибар итте. — Ә син нигә дәшми-тынмый гына утырасың әле? Ата буларак син дә әйт сүзеңне!

— Әллә нигә кәеф китеп тора. Кыз бирүләрне җиңел дип беләсеңме? Менә син аны башта үстереп кара, Витюк.

Зөһрә чәй кайнатырга дип, кухня ягына кереп китте.

— Һаман идарәң турында уйлыйсыңмы, Кадыйрҗан! Ташла әле! Күч әйдә Кама буена, яңа ятма, яңа идарә, яңа коллектив.

Кадыйр дәшмәде, акрын гына як-якка башын чайкады.

Кудрявцевны озатканнан соң Кадыйр үз-үзенә урын таба алмый йөрде. Кухня ягында Зөһрә шалтыр-шолтыр савыт-саба юа, бүлмә эченә әкрен генә караңгылык иңә бара, шушы караңгылык Кадыйрның да күңеленә тула кебек. Ул бер рюмка коньяк салып эчте, ләкин ярсыган йөрәге моның белән генә басылмады, шуннан күтәрелде дә ишегалдына чыкты, бакча түренә таба атлады. Монда саф һава, монда савыт-саба шалтырамый, алмагач астындагы эскәмиядә рәхәтләнеп, уйланып утырырга була иде.

*
* *

Иокыдан уянып житмәс борын ук ул урам якта тавышлар ишетте, маңгаен нидер рәхимсез кыздыра иде, әйләнеп ятарга итте, әмма кузгала алмады, кымшанасы да килмәде. Кичә кич соңгарыбрак кайткан Гөлүсә уянган, әкрен-сак кына йөренә, менә ул ваннага керде, краны ачты, озаклап юынды, аннары кухня ягына чыгып чәй куйды. Кадыйр боларның барысын да ишетеп ятты, ләкин анда да әле кузгаласы килмәде. Ныклап уянуы булды, кичәге киңәшмә күз алдына килеп басты, Кудрявцевның Гөлүсәгә баш кода булып килүе исенә төште. Одеалын бер читкә сыдырып, торып утырды, ялан аякларын бер-берсенә ышкыштырып алды. Кояш инде күптән чыккан, күтәрелеп килә, аның зәһәрләнә башлаган нурлары ачык тәрәзәдән ятакка төшкән, Зөһрәнең маңгаен, ярты битен, төз борынын, киңчәрәк ияген кыздыра, ләкин хатыны шул тикле тәмле итеп йоклый, боларның берсен дә сизми дә, тоймый да. Кадыйр үзенең куе-каты төк баскан сакалын ышкыштырып алгач янә хатынына күз ташлады. Зөһрә чәчләрен мендәргә таратып, изрәп йоклап ята, соңгы елларда тәнгә тагы да түгәрәкләнеп, тулыланып киткән хатынның киң күкрәгендә, иңбашларында кояш нурлары уйный. «Ни ашап шул хәтле симерә бу»,— дип ирен чите белән генә елмаеп алды ир һәм күз алдына сылулыгын әле булса җуймаган, нәфис гүзәллеген югалтмаган Наташа килеп басты.

Кадыйр хатирәгә бирелеп, күзләрен йома, шундук инеш аша кулында Наташаны күтәреп чыгаруын күрә, кылган кебек йомшак чәчләре битләрен кытыклый, кайнар иреннәре белән Кадыйрның битенә кагылып алгандай итә һәм: «Апкит, апкит шул Казаныңа», — дип үртиирkәләнә сыман. Кадыйр эчке бер сыкрану белән торып баса һәм хатынына акрын гына дәшә:

— Торасы иде бит, Зөһрә. Болай йокы симертсәң тазармый кая барырсың...

Зөһрә әллә йокламый иде, әллә шулай сизгер йоклавы булды, тәмле итеп киерелеп-сузылып алды, күзләрен ачты.

— Иртәрәк түгелме соң, Кадыйрҗан? Кил әле, бераз гына янымда ятып торчы.

Хатыны тагын бер тәмле итеп киерелеп-сузылып алды да янә күзләрен йомды. Кадыйр яңадан дәшмәде, нинди дер кимсенү хисе тоеп, ваннага юнәлде. Анда ул бик озак фр-фр килеп юынды, күкрәгенә шап-шап суга-суга салкынчарак су белән коенды, аннары киндер сөлге алды да тәннәре буй-буй кызарганчы сөртенде, өстенә пижама элеп кухняга чыкты, Гөлүсә ашый-эчә китап укый иде, әтисен күргә, күтәрелеп карады.

— Хәерле иртә, әтием!

— Минем иртә хәерле, үзеңнең хәлең ничек, эчең бик авыртмыймы?

— Минә мыскал да авыртмый, әтием.

— Ашыкма. Хәзерләнәсең?

— Тыңла әле, әтием, сиңа бер сүзем бар. Минем турыда сүз чыкса, Сережаның әтисенә әйт, институтка керергә миңа ярдәм итәм дип йөрмәсен. Миңа ярдәм кирәкми, мин алардан зависимый булырга теләмим.

Кадыйр кызының башына кулын салды.

— Ә син молодец!

— Әти, Наталья Николаевнага әллә ниләр сөйләп бетергән әни. Имеш, безгә кооператив квартира алалар, әни дә мактанган, ярдәм итәрбез дип таулар вәгъдә иткән. Сорадымы соң әле ул миннән, бәлкем минем кияүгә чыгасым килмидер...

Кадыйр кызының башыннан кочты, чәченнән сыйпаштырды.

— Ә син бит мин уйлаганча ук юләр түгел икәнсең, кызым. Бер киңәшем бар: үзең ничек телисең, шулай ит.

Гөлүсә дәшмәде, китапка текәлде.

— Мин аны яратам, әтием. Тик әнием генә ул хәтле төчеләнмәсен иде...

— Яратасың икән — барысы да әйбәт булыр, юкка хафаланма. Сөйләштекме? Әйбәт булыр.

Кояш мөлдерәп тулып чыккан көйгә һаман югарыга, күк йөзенең үзәк ноктасына юл тота. Урман буенда сыек томан тулгана, кояш югарыга күтәрелгән саен ул да сарыая, төссезләнә бара, зәңгәр һавага сеңеп юкка чыга.

Шоферы куып житкәч, Кадыйр аның белән баш кагып кына исәнләште дә кабинага кереп утырды.

— Сынау урынына.

Шофер уналты скважинаны бер трапка бәйли торган жирне белә иде, машинасын шунда элдереп алып китте. Сынала торган жирдә яңгын машиналарын күргәч тә Кадыйр: «Троянов белән мине көтәләр»,— дип уйлап алды. Ләкин техник фәннәр докторының килүе икеле иде, кичә кич белән хәбәр иткәч, ул: «Вакыт тапсам килермен», — дип кенә жибәргән. Кадыйр килеп житкәндә насосларны жибәрергә хәзерләп йөрүче Нәүфәл кулын селти-селти кемгәдер, нидер аңлата иде. Алар янында ук Идрисов. Кадыйр машинадан төште дә барысы белән дә кул биреп күрешеп чыкты.

— Троянов килмәде, башлыйбызмы, Кадыйр Сөнгатович? — дип сорады баш инженер. — Монда бар нәрсә төгәл, әйбәт, мин тикшердем.

— Ярый, башларбыз,— Кадыйр нинди дер борчылу тоеп, Бөгелмә юлына күз төшереп алды. — Барысы да әзерме соң? — дип сорады ул Нәүфәлдән.

— Әзер.

— Биш минуттан башлыйбыз.

— Әнә бабай килә! — диде берәү.

Барысы да янә Бөгелмә юлына карады һәм сынау төбәгенә таба кара «Волга»ның килүен күреп, беравыздан диярлек: «Килә!» — диделәр.

Чөнки һәммәсе белә иде, Трояновның сынау вакытында биредә булуы күп кенә бәхәсне хәл итәчәк, ник дисәң, фәннәр докторы нефтьне катламнан кысрыклап чыгару һәм аны чистарту юнәлешендәге проблемалар белән шөгыльләнүче алдынгы галимнәрнең берсе иде, аның сүзе, әлбәттә, бар җирдә дә үтәчәк, моны һәркем белә, хәтта Идрисов та бик әйбәт белә бу турыда, шуңамы, ул да түземсезлек белән көтә иде галимнең килүен. Кадыйр гына, Идрисов ягына күз төшергәч, нигәдер уйлап куйды: «Бер-бер этлек эшләргә маташамы әллә бу кеше?» Ләкин бүген аның алай уйлыйсы килмәде, гомумән алганда ни югалта иде баш инженер «Спутник» дип аталган уналты скважинаны бер трапка бәйләү чарасын үткәрүдән? Һични! Җитмәсә, Нәүфәл ятмадан чыккан нефтьне паркка житкәнче үк ят тозлардан һәм иярә чыккан сулардан арындырмакчы. Бу чараның уңай килеп чыгасына бик ышанып җитми җитүен, ләкин Нәүфәл эшкә керешәм дигәч, риза булды, фатихасын бирде. Кадыйр өчен бу гаять тә зур тәвәккәллек иде. «Бу эшләр белән я болытларга баскыч куям, я җәһәннәмгә мәтәллим», — дип уйлады ул һаман да Бөгелмә юлыннан күзен алмыйча.

Троянов килеп машинадан төшүгә, аның каршысына Идрисов ашыкты.

— Сезне көтәбез, хөрмәтле Иннокентий Герасимович!

— Ул гаепле, мин түгел, юлда баллоны бушады, — дип шоферы ягына күрсәтте галим. Аннары Нәүфәлгә бармагы белән ымлап: — Сездәме исәп-хисаплар? — дип сорады.

— Менә монда, — Нәүфәл, доктор шаярта дип белепме, мангаена кулын тидереп алды.

— «Спутник»ның эшләү принцибы безгә дә мәгълүм.

— Һәр скважинаның үз режимы булачак.

— Яхшы. Ә дозатор дигәнегез?

— Скважина «чыршысына» махсус корылма — дозатор урнаштырыла, аңа десолван[1] салына һәм дозатор аны кирәк күләмдә биреп торачак.

— Ярый. Нәтиҗә?

— Паркка барып җиткәндә катламнан хәзер генә чыккан нефть глобуллардан[2] һәм тозлардан арындырылган булыр.

— Гафу итегез, иптәшләр, мин уйлап табучыдан сынау алам кебек. Биредә теория дә, практика да бар һәм менә бу яшь егет безне бу өлкәдә шаккатырмакчы. Әйдәгез, карыйк. «Спутник» безне ул хәтле кызыксындырмый, аны башкортлар да көйләп яталар, кайсыбызныкы камилрәк булыр, нәтиҗәне сынау күрсәтер. Ә менә дозатор, — Троянов кинәт кенә Кадыйрга таба борылды. — Кадыйр Сөнгатович, ә сез зур уңышлар ясыйсыз, — һәм игътибарны тагын Нәүфәлгә күчерде.

Нәүфәл сөйләгәндә егетнең имгәнүле муенына хәзер генә игътибар иткәндәй карап торган Троянов үзе дә башын кырын салыбрак тыңлады. Техник мәсьәләләрне белгечнең ярты сүзеннән аңларга өйрәнгән Троянов барган көйгә Нәүфәлнең иңенә кулын сузды.

— Белемегез?

— Инженер-автоматчы, геолог булып та эшләдем.

Троянов житез, тере, гаять җор телле кеше, яше шактый булуына карамастан, җил-җил йөрде.

— Кайда укыдыгыз? — дип сорады ул үзеннән калышмый янәшәсендә атлап барган Нәүфәлдән.

[1] Десолван — нефтьне судан аеру өчен кислоталар кушымтасы.
[2] Глобуллар — парафинга төренгән су тамчылары.

— Грозныйда.

— Геологиядән Звягинцев укыттымы?

— Әйе. Сез аны beлә идегезме? — дип сорады үз чиратында Нәүфәл.

— Туганымнан да якын кеше иде ул миңа, егетем.

Нәүфәл дәшмәде, көлемсерәп кенә куйды.

Сынау башланды. Сынау барганда Троянов һичкем белән сөйләшмәде, бик җентекләп корылмаларны карап йөрде. Соңыннан ул Кадыйр янына килде, сакалын учлап тоткан килеш:

— Аңлашыла. Әйдәгез хәзер паркка. Әгәр нефть анда җиткәнче чын мәгънәсендә саф «кара алтын» хәленә керсә, бу егетне мин сездә калдырмыйм, Кадыйр Сөнгатович, — Троянов баш инженерны дәшеп китерде. — Иптәш Идрисов, сезнең идарәдә җир астына күмелгән ничә километр торба бар?

— Өч мең километр тирәсе.

— Ишеттегезме, Кадыйр Сөнгатович, сезнең яңадан өч мең «кубометр» чаныгыз бар дигән сүз бу. Миңа калса, бу ысулның бәясе исәпләнмәгән әле. Димәк, торбаларда нефтьне транспортлау белән бергә беренчел чистарту процессы да уздырыла. Ә экономия! Электроэнергиягә, металлга, насосларга, аннары җир, күпме җир колхозларга кире кайтарылыр.

— Ә яңа ачылачак нефть районнарында, — дип сүзгә кушылды Кадыйр.

— Әйе, әйе, — дип эләктереп алып китте Троянов. — Яңа ачылган нефть районнарында гаять кыйммәтле булган чистарту установкалары корылмас, корылган хәлдә дә бик аз кирәк булыр.

Машиналар эскорты зур-зур дүрт-биш чан торган якка юнәлгәч, янгын сүндерүчеләр китәргә җыена башладылар. Алар да сынауның болай тиз үтүенә ышанмыйчарак торалар иде. Троянов һаман сөйләнде.

— Ә егетегез миңа ошады, акыллы күренә. Менә ул, Кадыйр Сөнгатович, бөек галимнең җимешләре. Их, Звягинцев, хөрмәтле профессор, үзен күрсәңче шуларны, — диде Троянов алга караган килеш, үзалдына сөйләнгәндәй. — Ә сез кемнең лекцияләрен тыңладыгыз, Кадыйр Сөнгатович?

— Чибисовны. Владимир Дмитриевич Чибисов.

— Мәрхүмне рәнҗетәсем килми, ләкин бушрак, коры теория белән яшәүчерәк иде ул.

Паркта күчмә лаборатория пробаларны алган иде инде. Троянов үзе үк лабораториягә керде, анализларны тикшерде, шуннан соң гына канәгать калды, лаборатория баскычына чыгып баскач, бер тын зәңгәр һавага карап торды.

— Юк, иптәшләр, бу гади җиңү генә түгел. Катламнан ияреп чыккан нефть составындагы глобуллар бөтенләе белән таралган. Һәм безгә шушы продукцияне турыдан-туры нефть эшкәртү заводларына кудырырга мөмкин. Бөтен мәгълүматларны җыегыз да, Кадыйр Сөнгатович, атна-ун көннән институтка килегез, эш башкарган егетегезне дә калдырмагыз. Аның да фамилиясе Әмиров диделәр, бертуган түгелсездер бит?

— Энем ул минем, Иннокентий Герасимович.

— Энегез, — диде Троянов гаҗәпләнә калып. — Соң энегез булгач, бигрәк тә әйбәт, калдыра күрмәгез!

## 13

«Ул кайтмаган булса?» — дип уйлады Халисә, урамга чыккач. Кичтән яуган яңгырдан соң дымга туйган җирдән сызылып кына бу күтә-

реләә. Асфальт юлдагы күлдәвектә чыр-чу килеп чыпчыклар коена. Юл буендагы тупыллар, юкә агачлары мунчадан яңа чыккандай яшәреп, матурланып киткәннәр. Асфальт өсте көзге сыман ялтырап тора. Көннең матурлыгына, кояшның муллыгына куанышкан чыпчыклар аяк астына керер дәрәҗәгә җитеп чыркылдашалар. Уң як тротуардан да, сул яктан да машина юлы аша кешеләр узып тора — каядыр ашыгалар. Һәркемнең үз хәсрәте, үз мәшәкате, үз дөньясы.

Халисәнең дә бит үз дөньясы бар. Семьясы да... Шул турыда уйлый башлауга, аның күңел түрендә ниндидер ризасызлык туды, үзе дә аңлап җиткерелмәгән канәгатьсезлек хисе иде бу һәм ул, уйларыннан арынырга теләп, ашыга-ашыга урамның икенче ягына чыкты, кызу атлавын дәвам итеп, бала арбасы тәгәрәтеп баручы яшь ананы куып җитте. Балага ап-ак ползунок кидергәннәр, нәни чалкан төшкән дә аяклары белән уйный һәм тырышып-тырышып, яңакларына чокырлар ясый-ясый резин имезлек суыра иде.

Бала арбасы янына җиткәч, Халисә адымын акрынайта төште, яшь ана белән беррәттән атлап китте, ананың килеш-килбәтенә, йөреш-кыяфәтенә игътибар итте һәм ул яшь хатынның йөз-чыраенда сүз белән әйтеп бетермәслек шатлык нурлары балкуын күрде. Аның нәфислеге хәтта тирә-юньне бизи сыман иде. Их, аласы иде дә шушы изге җанның нарасыен, шытырдатып кысасы иде хис тулы күкрәгеңә. Аңлап җиткерә микән хет бу хатын үз бәхетен...

Биш минутлык киңәшмәгә ул иң соңгы кеше булып килеп керде. Ул кергәндә төнлә дежурда булган Гайсә сөйли иде инде, Халисә аңа күз ташлап алды да, ишек янындагы урындыкка утырды. Терапия бүлеге мөдирәсе Асия Хәмитовна Халисәгә текәлеп карап, башын чайкап куйды.

— Авырулар, аерата терапия авырулары, — дип дәвам итте Гайсә, — вакытында ятмыйлар, төне буе йөренәләр, йокы сәгатьләрендә бакчага чыгып китүчеләр дә бар. Шул хәлләрне күргәннән соң минә алар арасында тап-таза кешеләр дә бардыр кебек тоела башлады. Тугызынчы палатада ятучы Фазылҗанов, өченче палатадан Кудесников таң белән торалар, кычкырып сөйләшәләр. Алтынчы палатада ятучы Җәмилов янына ниндидер кызлар килә, хи-хи-хи да ха-ха-ха. Әйтерсең больница түгел, ниндидер ял йорты. Мин бу авыруларның чирләре белән кызыксындым, — дип, Гайсә Асия Хәмитовнага текәлде. — Берсендә гастрит, икенчесендә радикулит. Кудесниковның йөрү-кыяфәтенә караганда аңарда бер дә радикулит димәссең. Күптән чыгарырга кирәк иде ул кешеләрне, хөрмәтле Асия Хәмитовна.

Киңәшмәдән соң өлкән терапевт Халисәне үз кабинетына чакырып алды.

— Җаным-бәгърем, Гайсә Ильясович безнең бүлеккә тагын замечание ясады бит. Синең авыруларың турында сүз барды. Бүген үк чыгарып җибәр үзләрен, нигә шулар өчен сүз ишетергә, Халисә акыллым, — диде.

Халисә: «Ярый, мин карармын!» — дип чыгып китсә дә, Фазылҗановны да, Кудесниковны да калдырырга булды. Обход ясап бетергәннән соң Халисә икесенең дә авыру тарихлары белән янә бер танышып чыкты, анализларын кат-кат чагыштырып карады. Фазылҗановның эч авыртуы басылса да, кан составы рәтләнеп җитмәгән, канын кабат тикшереп ачыклыйсы бар иде. Ул гына да түгел, үнсигез ел рәттән бораулау мастеры булып эшләгән бу авыруны, больницадан чыгуга, санаторийга җибәрергә кирәк дигән нәтиҗәгә килде Халисә һәм көндәлек дәфтәренә шул турыда язып та куйды. Ә Кудесников? Больница коридорыннан төз йөрүенә карап кына, терелде дип, авыр йөк машинасында эшләгән шоферны эшкә чыгарып буламы, ул чирләнә невро-

патолог күзәтә. Кудесниковны да белгеч фикерен ишеткәннән соң гына чыгарачак Халисә.

Бу хәлне белеп алган Асия Хәмитовна, эштән китәр алдыннан, янә Халисә янына керде.

— Халисә, алтыным, Гайсә Ильясович тагын бәйләнер инде. Сез теге авыруларны чыгармагансыз икән бит!

— Сез иң әүвәл аларның авыру тарихлары белән танышып чыгыгыз, Асия Хәмитовна, палатага кереп үзләре белән сөйләшегез. Ихтимал, шуннан соң сезнең дә үз фикерегез туар. Ә мин дежур врач фикере белән килешә алмыйм, теләсәгез нишләгез.

— Сез аның үзенә дә шулай дип әйтегез инде, сөеклем.

— Асия Хәмитовна, сез бит бу бүлекнең өлкән врачы, нигә сез үзегезне шулай түбәнсетәсез.

— Кирәкми, җаным, мин карт инде, пенсиягә китәргә торам. Гайсә Ильясович акыллы кеше. Моңа кадәр юкка-барга бәйләнгәне булмады.

— Ярый, борчылмагыз, үзем мин аңа әйтермен.

Асия Хәмитовна чыгып киткәч, Халисә бик озак үзалдына уйланып утырды. Ул еш кына очракта, принципиальлеге җитмәү сәбәпле, күп эшләрне гадел хәл итә алмаган Асия Хәмитовнаның хәленә керергә тырыша иде. Кеше фәрештә түгел, бөтеннәргә хас кимчелек Асия Хәмитовнада да бар иде, әлбәттә. Ләкин аларны Халисә еш кына гафу итә килде — аның төче теле, йомшаклыгы өчен гафу итте. Нәкъ менә шул үтә йомшаклыгы аркасында шәхси тормышында да күп кенә бәхетсезлекләргә дучар булган ул хатын. Кайчандыр үзеннән шактый кече яшьтәге кешегә кияүгә чыгуы, аның белән замандаш булырга теләп, паспортына хәтле яшен ким күрсәтүе, бергәләп озак еллар гомер иткәч, теге җилкуарның үзенә тиң бер хатын белән читкә китеп баруы, яшен ким күрсәтү сәбәпле инде картайган көнендә дә эшләп йөрүе — барысы да Халисә өчен кызганыч хәл иде. Әйе, үзебез сайлаган язмыш. Нинди хәсрәтләр генә төшермисең син газиз адәм башкайларына.

«Мин аны кызганып утырам. Ә мине кем кызганыр икән? Мин соң үзем дә шулай ук кызганыч хәлдә түгелме? Икебез бергә яшибез, бер эштә эшлибез, ләкин ул үз дөньясына кереп чумган, минем үз кайгым үземә бик җиткән. Күз бәйләшле уйныйбыз түгелме? Чөнки шулай икебезгә дә кулайрак, бер-беребезне җәберләмибез, рәнҗетмибез...»

## 14

Якшәмбе көн Нәүфәл өйгә кайтты. Өйдә җиңгәчәсе генә иде. Әйтерсең Нәүфәлнең кайтасын белеп өчпочмак пешергән. Өй тулы тәмле аш исе... Нәүфәлне күрде дә Зөһрә, канатланып ук китте.

— Менә ходай миңа кемне бирде. Тилмерәм бит бер ялгызым, читлеккә эләккән кош диярсең. Кадыйрын Бөгелмәгә чакырып алдылар, дөнья беткәндәй, өчпочмак пешкәнне дә көтмичә китеп барды, Гөлүсәсе документларын бирергә китеп Әлмәттән кайтмый ята. Пешергән өчпочмагым ашар кешем булды, ичмасам. Уз-уз. Чишен дә юынып ал. Хәзер ваннага су җибәрәм.

Зөһрә эре парча төшкән атлас япон халатын кигән, болай да «нечкә» биленә кульяулыктан аз гына зуррак алъяпкыч бәйләгән.

— Ванна булса бик ярап куяр иде, җиңгәчәй.

— Су җибәрдем. Кереп чишенә башла. Хәзер киемнәр карап бирәм. Үзеңнекеләр күренми, абыеңныкын киярсең. Аның өелеп ята. Менә боларны... үзенә алган идем, кечкенә булды.

Җиңгәчәсе Нәүфәлнең кулына ниндидер диңгез-океан аръякларындагы илләрдә эшләнгән затлы эчке күлмәк-ыштан тоттырды. Ярата да

соң Зөһрә чит ил әйберләрен, аңа барысы да импортный булсын. Биргән киемнәрне култык астына кыстырып, Нәүфәл ваннага керде. Су талгын, рәхәт иде, хәтта бераз эссерәк тә кебек. Тәнгә рәхәт, ул ниндидер ою тоя. Кухня ягында духовка капкачын ачып-япкан тавыш ишетелеп куя. Нәүфәл үз гомерендә беренче тапкыр абыйсыннан көнләшеп куйды. Егерменче гасыр кешеләренең тормышын болай ук итеп күз алдына китерү кыен иде. Абыйсы, әлбәттә, хатыннан уңган. Чибәр, чая, ир дигәндә кирәк икән утка, кирәк икән суга керергә әзер. Өй эче һәр вакыт чиста һәм пөхтә итеп җыештырылган, табында җан теләгән ризык-нигъмәт, кирәк икән шәрабе дә бар. Шул хәлләрне күз алдына китерүгә, моңа кадәр үзе өчен уңайлы тормыш шартлары эзләмәгән һәм беркайчан да шуңа омтылмаган Нәүфәлнең дә күңеле кузгалып китте. Семья бәхете нидән гыйбарәт? Бәлкем, шулай арып-талып эштән кайтып кергәндә хатының, бердәнбереӊ, күгәрчендәй гөрли-гөрли, кояштай балкып каршы алудандыр, син кайтып керүгә, бөтен мәшәкатен онытып, синең турыңда гына кайгыртудандыр. Бер мизгелгә генә Нәүфәл үзен шушы өйнең хуҗасы итеп тойды. Хатыны, имеш, өчпочмаклар пешерә, тәмле аш исеннән авыз сулары килә, менә ул юынып чыга, өстәл инде хәзерләнгән, янында өстенә йомшак халат киеп алган хатыны бөтерелә. Юк, тулы гәүдәле, түгәрәк йөзле Зөһрә җиңгәчәсе түгел, нечкә билле, озынча йөзле, күксел-кара чәчле Халисә йөрәнә.

Шушындый татлы уй-хыяллардан Нәүфәл хәтта күзләрен йомды, әмма бик тиз исенә килде: реаль тормышка кайтты. Кем аңа кияүгә чыксын? Кәкре муенлы, Квазимодога охшаган гарип кемгә кирәк?

Нәүфәл, күңеле кабул итә алмаган ят исем тел очына килүгә, шундый гарьләнү тойды, хәтта тешен шытырдатып, үзалдына сыкрап куйды, йөрәге кысылды. Нишләп алай, нишләп?.. Кем аның язмышына аяк чалды? Кемне гаепләргә тиеш ул? Анымы? Үзенме?..

Күз алдына афәт булган көн килә дә аның йөрәге тагын да авыртыбрак кысылып куя. Их, барысын да яңабаштан башласаң икән? Уналты-унҗиде яшьтән. Чишмә башыннан...

— Чыгасыңмы инде?.. Өчпочмак әзер...

Нәүфәл күпереп торган сөлге белән сөртенде, хуш исләр килеп торган күлмәк-ыштан киде. Җиңгәчәсе аңа абыйсының ваннадан соң кия торган халатын да ишекне кысып кына сузды.

— Ки шуны. Барыбер абыеңа ярамый.

Тәндәге сүлпәнлекнең эзе дә калмаган, ваннадан соң җиңеләеп киткән гәүдә-сын хәрәкәткә омтылып тора. Нәүфәл, халатны киеп, билбавы белән билен бәйләде, аягына чүәк элеп ваннадан чыкты.

Булса була икән нигъмәтләр — өстәл тулы ризык, уртада шампан шешәсе кукыраеп утыра, тастымал белән капланган коштабактан тәмле исләр тарала.

— Утыр әйдә менә моннан.

Нәүфәлнең яңа тарап җибәргән чәче дулкынланып тора, бите парланган, алсуланган.

— Ә син чибәрләнеп киткәнсең. Якынрак утыр! — диде җиңгәчәсе. Ул алъяпкычын салып ташлаган, халатның билбавын кысыбрак бәйләгән, шуңамы, болай да калку янбашлары тагы да кабарыбрак киткән кебек.

Нәүфәл шампан шешәсен ике тез арасына кыстырды да бөке бәйләгән чыбыкны җай гына сүтте, шешәне кырынайта төшеп, имән бармагы белән иплән кенә капрон бөкегә кагылды. Шартлап очкан бөке түшәмгә бәрелде дә бусага янына барып төште.

— Я, Нәүфәл, — җиңгәчә ак тешләрен күрсәтеп елмайды. — Ни хакына эчәбез? Синең белән абыең уңышынамы?

— Әйдә, шуның өчен булсын.

Бокалларда чемердэп торган шампанны аз-аз гына йотып куйдылар.

Зөһрә коштабак өстендәге тастымалны алды да Нәүфәл алдындагы тәлинкәгә бер өчпочмак куйды.

— Өчпочмактан житеш әйдә, аша. Тартынып утырма. Күрәм түгәрәкләнеп киткәнсең, килешкән үзеңә кыр әпәе.

Нәүфәл ышанмагандай бит-яңакларын капшаштырды. Кем әйтә эчкәч зиһен тарала дип? Юк сүз. Бер бокал шампаннан соң, Нәүфәл үзен бик яхшы хис итте, хәтта кыюланыбрак та китте.

— Әйтегез әле, жиңгәчәй, сез бәхетлеме?

— Мена сиңа иске авыздан яңа сүз. Бәхетнең бизмәне бармыни? Биргәненә шөкер итеп яши бирәм. Син үзеңне бәхетсезләр рәтенә куярга телисеңме әллә? Бәхет синдә дә ташып тора ул, Нәүфәл, кадерен генә белмисең.

Нәүфәл чәнчә бармагы белән муенын кашыштырып алды.

— Ир кешегә гариплек — бәхеткә, хатын-кызга — тәхеткә ди торган иде минем әни. Тукта әле, тукта, — диде Зөһрә мавыгып китеп. — Кемгә күрсәткәнең бар син муеныңны? Менә чәй эчәбез дә, башта әйбәтләп үзем карыйм. Жиңгәчәң кайчандыр хирургия медсестрасы булып эшләгән кеше, бер дә аптырап карама алай. Сиңа, Нәүфәлжан, тәжрибәле хирургка күренеп карарга кирәк. Сөйләмәсәнә юкны, нинди курку ди ул. Менә дигән хирурглар бар. Күрен әнә Гайсә Ильясовичка. Курыксаң, үзем сөйләшәм. Юкны сөйләп тормасана. Бергә үскәнсез... Яшьлектә ни булмас. Тәвәккәллә, Нәүфәлжан. Куйчы, нинди тартыну ди ул, иске дуслар искерәме! Алынсамы Гайсә Ильясович, ясый да ясый инде. Ни, беркөнне Халисәсен күрдем, теге, яшь чакта, икәүләп яратканыгызны. Күзе-башы тонган, кадала-каплана идарәгә кереп бара. Нәфис инде, нәфис, хан кызы диярсең, ул киенүе дисеңме, ул йөрешләреме. Ыспай, бик ыспай хатын. Син дә онытмагансың әле үзен? Тиле, онытыламы соң яшьлектә булганнар. Мин дә яшь чакта шулай берәүне өзелеп яраткан идем. Ду килеп йөрдек — Хәлил белән Галиябану диярсең. Бер көн күрмәсәм, күземә йокы керми торган иде. Соныннан ул да онытты, мин дә... Институт тәмамлап кайткач, бер тапкыр күрдем тегене: урам себереп йөри беренче мәхәббәтем, эчкән дә унбиш тәүлеккә эләккән, мескенкәй. Житмәсә, безнең турыны себерә. Күрдем дә, малакаем, жир тишекләренә кереп китәрдәй булдым. Шул хәтле гарьләндем, шул хәтле гарьләндем... Бит мин аның өчен тилерер дәрәжәләргә житкән идем. Тәмам күземне ачты моның шулай йөрүе. Эчкән егетләрдән котым алына башлады. Шуннан абыеңны очраттым. Һ-и-и, тегенең белән чагыштырып карамалымы. Ул дәрәжә, ул гәүдәсын, ул игътибарлылык... Ә теге, беренче мәхәббәтем, әле булса йөк ташучы булып йөри. Һ-и-и, беренче мәхәббәт ул, язгы ажаган кебек, ялтырый да уза. Хан кызы кебеге үзеңә чыгам дип торыр әле менә, жиңгәчәй әйтте диярсең.

Көлештеләр. Көлә-көлә жиңгәчәсенең халат изүләре ачылып, аннан күкрәкчәсе, алсу төстәге капрон эчке күлмәге күренеп китте. Чәй көйли-көйли, ул халат сәдәфен тиз генә элэктереп куйды.

— Әйдә, әнә теге урындыкка күчеп утыр әле. Хәзер балалар бакчасы мөдире булсам, кайчандыр жиңгәчәң атаклы хирург Познанскийның беренче ярдәмчесе иде. Мин килмичә операциягә керми торган иде, мәрхүм.

Йомшак бармаклар рәхәт итеп муенны капшаштыра, бәхете ташып торган хатыннан затлы француз хушбуй исләре килә. Шул хуш истән Нәүфәл күзен йомды. Бармаклар һәр тамырга, һәр сеңергә иплэп кенә, жайлап кына кагыла, күңелгә әллә ниткән якты хыяллар тула.

— Авыртамы?

— Юк, авыртканы булмады, авыртмый.

— Күрен, Нәүфәл, күрен Гайсә Ильясовичка, күңелем белән тоям, алыныр ул операциягә.

— Операциягә соңрактыр шул, җиңгәчәй, кирәкмәс.

— Бер дә соң түгел. Тәвәккәлләә. Яхшысынмасаң, үзем әйтәм, — диде җиңгәчәсе һәм текәлеп каенесенә карап алды. — Бер дә соң түгел.

Өстәл янына күчтеләр, җиңгәчәсе, чытлыкыйлана төшеп, чәй көйләде, савыт-сабаларны кузгаткалады.

— Җитеш әле теге чия вареньесеннән дә. Әллә нигә быел куерак булды. Мин үзем әчкелтемрәкне яратам... Абыең турында кирәкмәгәнне дә сөйләп ташладым бугай инде сиңа, Нәүфәл. Чит кеше түгелсең әле, кешегә җиткермәссең.

— Җиңгәчәй, ни сөйлисез сез. Миңа калса, абый бик зур эшләр майтарып йөри, әйтер идем, үз эшен бик яхшы башкара ул. Үз урынында, һичшиксез, үз постында.

— Шулаен шулайдыр да... Алай да сүләгәннәр икебез арасында гына калсын. Абыеңны Түбән Камага күчерәләр. Язган булса, сине дә үз янына алыр, — җиңгәчә бокалларга янә шампан койды. — Әйдә әле, Нәүфәлҗан, синең исәнлегеңә күтәреп куйыйк шуны. Боерган булса, операцияң дә уңышлы булыр... Аннары үзеңне өйләндерәм. Юк-юк, авызыңны да ачма, өйләндерәм дигәч өйләндерәм. Менә дигән бер тәрбиячем бар. Сылу, яшь. Аннары чүпрәк ярата, андыйлар акчалы ир кадерен белүчән булалар.

«Синең кебек инде алай булгач», — дип уйланды Нәүфәл күңелсезләнә барып. Җиңгәчәсе Нәүфәлнең кулына йомшак бармаклары белән кагылып алды.

— Өйлән, туганым. Ир бәхете — семьяда. Менә бер бәләкәчне дә табып куйсын әле шул Нурия үзеңә. Нурия исемле ул. Исеме дә җисеменә туры килә, нурга ия, чибәр, — Зөһрә кинәт җитдиләнеп китте, үткен күз карашы Нәүфәлгә кадалды. — Һ-и-и-и, яшь чагым булса, беркемгә дә бирмәс идем үзеңне, валлаһи!

— Куегыз инде, җиңгәчәй, булмаганны. Нинди өйләнү ди ул!

— Куйма, куйма! Сәламәт тәнгә сәламәт кан кирәк. Машина майлауны, хатыннар иркәләүне ярата. Абыеңа ошасаң, син дә кимен куймассың әле менә.

— Абый үзенә, мин үземә. Без ике төрле кеше.

— Икегез ике булсагыз, нәселегез, каныгыз бер. Дөрес, син бик юашсың. Ул хәтле булма. Юаш бүрене бәрән ялар, юаш ирне хатын талар диләр.

...Бүлмәсенә кергәч, Нәүфәл бик озак уйланып ятты. Күзгә йокы керми, башта мең төрле уй бөтерелә. Әллә соң, чынлап та, җиңгәчәсе әйтмешли, өйләнеп куяргамы? Дүрт бүлмәле квартира, чибәр хатын... Ләкин шулмы соң аның хыялы? Юк. Их, Халисә, Халисә. Нишләп соң әле мин генә шул бер мәхәббәткә табынып яшим? Нишләп соң әле син минем хыялым? Әллә соң барысына да кул селтәп Пермьгә Петр янына китеп барыргамы? Ләкин ничек китсен, ярата бит ул аны, кайчак дөньясын онытып ярата. Әйе, ул әүвәл Халисәне күрергә тиеш. Туган ягына бит ул шуның өчен дип тә кайтты. Сынар өчен, инаныр өчен. Саклана микән яшьлектәге чишмә суыдай саф мәхәббәт, әллә дөнья мәшәкатенә кереп чумуга, тузганактай җилгә очамы? «Әйе, мин үземне аны сөюдән мәхрүм итә алмыйм, бу минем көчемнән килә торган хәл түгел, — дип уйланып ятты Нәүфәл. Ул әле бер ягына, әле икенче ягына әйләнде, алай да булмагач, торып, бүлмә буйлап йөренергә керешә. — Шул ук вакытта җил кай тарафларга иссә, шул якка китеп барырга мин көзге яфрак та түгел ич. Юк-юк, мин аны күрергә тиеш,

һич югы, бер сүз әйтергә». Ә бит аның шушы яшьлек мәхәббәтеннән башка беркеме дә юк. Яшьлек мәхәббәте — аның тормышы: хәзергесе, үткәне, киләчәге, хыялы, туган һәм туасы идеяләре. Кемдер аңа: «Газаплар арасындагы газапларның иң күркәме, иң ачысы — мәхәббәт газабы», — дигән иде. Кайчандыр ул мәхәббәтенә үзе үк аяк чалды һәм шуннан бирле башын газапка салды бугай.

Ачык форточкадан саф һава бөркелә, бүлмәгә төнге чәчәкләрнең хуш исе тула, һавада йолдызлар җемелди, кемдер тып-тып баса-баса тротуардан узып бара.

...Тәвәккәлләде. Иртән торды да больницага юнәлде. Поликлиникага кереп чиратка язылды, регистратурадан талон алды, озын коридор буйлап хирургия кабинетына таба китте. Берничә авыру кабул итүне көтеп утыра иде инде. Нәүфәл җайлап кына йомшак креслога урнашты, култык астына кыстырып алып килгән газета-журналларны ачып караштырырга керешге. Шул арада чират көтеп утыручыларга да күз төшереп алгалады, үтеп-сүтеп йөрүче медикларны күзәткәләде. Аңа менә-менә яныннан Халисә узып китәр сыман тоела башлады. Танымас ул аны, туктамас та, адымын да акрынайтмас, әмма күңел барыбер аның килеп чыгуын теләде. Икенче каттан төшеп килүче ак халатлы хатын-кызны күргә, Нәүфәлнең сулышы кысылды, йөрәге күкрәгенә сыймас булды. Врач хатын аскы катка төшеп китүгә Нәүфәл тынычлана төште һәм, җиңгәсенең сүзен тыңлап, поликлиникага шулай җинел генә килеп керүенә үкенеп куйды. Әмма ул белә иде: бирегә килүе дә һаман Халисәне күрергә теләвеннән генә булды, аның өчен генә килде, хирургка күренү шуңа сәбәп кенә иде.

Кабинетка килеп кергәч, хатын-кыз врач аңа хәтта күтәрелеп тә карамады, ул нәрсәдер яза иде, гадәтенчә ишек төбендә таптанып торган авыруга:

— Утырыгыз, — дип кенә әйтте.

Бераздан ул язуын язып бетерде, ручкасын бер читкәрәк куйды, күтәрелеп Нәүфәлгә карады. Гариплекне күргән, күп кешедә була торган гаҗәпсенү, аптырабрак калу хикмәте күрмәде бу хатында Нәүфәл. Ул аңа тыныч кына, игътибар белән карап торды, гүя аңа егетнең кыяфәте күптән таныш иде.

Нәүфәл врач янындагы урындыкка утырды, талонын бирде. Ак кәстрүлгә охшаган башлык кигән хирург, бик озак димәсәң дә, шактый көттереп аның исем-фамилиясе, тору һәм эш урынын сораштырды, шуннан соң гына:

— Килүегез беренче тапкыр икән, авыру тарихы битләре буш. Нәрсә китерде безгә, ни борчый? — дип сорады.

— Менә шул инде, муен...

Нәүфәл муенындагы яра җөенә кагылып алды һәм янә җиңгәчәсенең коткысына бирелеп бирегә килүенә үкенеп куйды, хәтта нииндидер бер мизгелдә аның бирсдән күтәрелеп чыгып китәсе килде.

— Менә мондарак күчеп утырыгызчы.

Врач шулай дигәч кенә Нәүфәл аңа игътибар итте. Юантыграк гәүдәле, ак чырайлы, түенкерәк борынлы, бер-берсеннән качып китәргә җыенган, бер дугага беркетелгән кыңгыраудай, кыйгачланып утырган ачык зәңгәр күзле иде врач хатын.

— Күптән булдымы бу хәл?

— Ун еллап булыр.

Врач йомшак бармаклары белән муендагы җөйләрне шактый озак капшаштырды.

— Турайтырга исәп муенны, шулаймы. Матураерга, ә?

Ханым елмаеп, иелебрәк авыруның күзенә карады шикелле, ләкин бу Нәүфәлгә генә шулай тоелды, врач һәр сеңерне, һәр тамырны, җөйләрне капшап тикшерә иде.

— Минемчә, сезнең муеныгызны турайтып булыр кебек. Безгә килеп дөрес эшләгәнсез. Мин сезне больницага салам. Киңәшик, ихтимал тәвәккәлләрбез дә.

Нәүфәл врачка карусыз буйсынды.

... Күңел ялкынсынып, ярсыбрак тора, больница исе сулышны кыса. Нәүфәл тәрәзәнең бер канатын ачты, авызын күркә сыман сузып, күкрәк тутырып, тирән сулап торганда ишек катындагы авыру ыңгырашып алды, Нәүфәл тәрәзәнең канатын кыса төште дә, үзе белән бер палатада ятучы авыруга карамый гына, караватына килеп утырды. Карт иде инде күршесе, аңа кичәгенәк операция ясап бер бөерен алганнар, диделәр. Нәүфәл аның хәлен сорашырга дип дәшеп тә карады, тик агай ләм-мим бер сүз әйтмәде, кымшанырга да куркып, ыңгыраштыргалап ята бирде.

Нәүфәл караватына сузылып ятты. Тәрәзә аша аңа карт каен күренә — юан-юан ботаклы, киң ябалдашлы агач. Ул да түгел, бер ботакка саескан килеп куна, ябалдашлар янә бер селкенеп, җанланып китәләр. Саескан сиртмә койрыгын селкетә-селкетә нидер шыкырдый-шыкырдый очып китә. Күп тә үтми, ботакка ала карга килеп куна, бу озын гомерле кош гаять сабыр кылана, тирә-юньне бик озак күзәтә, бик озак тыңлый, шуннан соң гына, көттереп кенә бер тапкыр: «Кар-р-р!» — дип куя, кемгәдер дәшә һәм шулай ук бик озак, сабыр гына җавап көтә, ә җавап юк та юк, ала карга тагын дәшеп маташмый, канатларын лыпыр-лыпыр китереп очып китә. Ябалдашлар, аңа кул изәгәндәй, бик озак селкенеп торалар.

Нәүфәл җиңгәчәсенең Гайсәгә шалтыратуын белә. Хирургия бүлегенең иркен һәм якты палатасына кереп урнашкач та, ул яшьлек дустын түземсезлек белән көтә башлады. Менә-менә килеп керер кебек иде. Мондагылар аның үткән маҗарасын беләләр булса кирәк, һәрхәлдә, аңа шулай тоела, палатага сестра килеп керсә дә, няня күз ташласа да: «Шулмыный инде теге эт талаган гашыйк дивана», — дигән сыман карап торалар кебек иде. Ләкин менә икенче көн инде больница караватында ауный, Гайсәнең килеп кергәне юк, ә бит Гайсә генә түгел, «ул» да биредә эшли...

Әйе, Нәүфәл Халисәне зарыгып көтте, палата янынннан узучының һәр аяк тавышына: «Ул!» — дип колак салды, ишек янында хатынкыз сөйләшүен ишетсә, йөрәге ешрак тибә башлады. Әмма көн үтте, төн килде, тагын бер көн узып бара... Ә бит икесе дә шушында эшлиләр, сәгать саен булмаса да, көненә ике-өч тапкыр ул яткан палата яныннан узалар...

... Шул көнне обходка кергән Валентина Петровна аның бу хәләтен сизепме:

— Юк, юк, болай ярамый, сез гаять борчулы. Һавага чыгып әйләнеп керегез, — врач ым кагып ишек янында ятучы авыруны күрсәтте. Ә бу агай чукрак. Сөйләшерлек кеше дә туры килмәгән, ичмасам, үзегезгә. Әллә моңсуракмы? — дип сорады.

— Шулайрак шул, Валентина Петровна.

Врач аның кулын алды, пульсын капшап карады.

— Ай-һай, чаптыралар бертөрле атларны. Тынычланыгыз. Анализлар, снимокларыгыз әзер, бүген-иртәгә консилиум булыр һәм... ә хәзергә — һавага!

Нәүфәл селкенмәде дә, кулын баш астына куйган килеш ята бирде. Аңа Валентина Петровнаның вак кына сипкел тәңкәләре тибеп-тибеп чыккан уң як бите, энҗе бөртеге хәтле генә алтын алкасы, халат астыннан чыгып торган якасыз күлмәк чите күренә. Башлык астына җыйса да, маңгай тирәләренә сибелеп төшкән коңгырт чәч бөртекләре калган.

— Бар да әйбәт булыр, туган, борчылмагыз, Гайсә Ильясович кон-

силнум үткәрергә риза булды. Тиздән-тиздән... Ә хәзергә... Сөйләштекме, ашау белән ишегалдына чыгасыз. Ерак китмәгез, ял итегез, тынычланыгыз...

Нәүфәл үзен шактый түземле кеше дип йөри иде, ә бу больницада тәмам түземе җуелды, гасабиланды, иртәнге ашны ашады да, иңбашына больница халатын салып, коридорга чыкты. Бакса, каршысында Гөлүсә басып тора.

— Абый җаным, ни булды?

Ул Нәүфәлнең күкрәгенә килеп капланды, куркынып күзләренә карады.

— Берни дә булмады, минә муенны турайтмакчылар, — диде ул көлеп, кызның аркасыннан кага-кага.

— Ә син курыкмыйсыңмы?

Гөлүсәнең борчылуы чыраена ук чыккан иде.

— Юк дим ич! Мин дә курыккач. Сиңа ясадылар бит әле, үтте, терелдең, сау-сәламәт йөрисең, кияүгә димләп йөриләр икән дип тә ишеттем.

Гөлүсә елмая, аның бит уентылары тирәнәя һәм болай да нурлы йөзе тагы да нурланып китә. Менә ул көлеп җибәрде, кыяфәте тәмам үзгәрде, бит алмаларына алсулык йөгерде. Ике-өч атна гына элек бөкрәя төшеп, әчен тотып йөргән кызның дөньясы гел тигезләнде.

— Абый, мин тәвәккәлләдем, документларымны институтка тапшырып кайттым, — диде ул Нәүфәлнең соңгы сүзләрен ишетмәмешкә сабышып.

— Бик әйбәт булган. Әйдә тышка, мин һавада йөрергә чыга идем.

Гөлүсә шат, сумкасын җил-җил селкә-селкә янәшәдә атлый, я булмаса килеп сырпаланып ала, акылга утырып җитмәгән кызларга хас хәрәкәтләр ясый. Нәүфәл аның башыннан сыйпап, аңа карап ирексездән көлә-елмая һәм:

— Менә чикерткә дисәң дә чикерткә инде син, Гөлүсә, — дип куя.

— Э-э, мин чикерткә түгел. Мин күбәләгем-түгәрәгем, абыем.

— Егетең шулай диме?

— Э-э, юк, ул түгел...

Ак каеннар арасыннан атлап киттеләр дә нәни бер аланга килеп чыктылар. Мондагы чәчкәләр исеннән баш әйләнмәле иде. Һәм гаҗәеп күренеш: алан башында өч пошн басып тора. Боларны күрүгә, мөгезләре төрле якка таралган эти пошиның колаклары торды, күмер кебек кара күзләре белән ул кешеләрнең һәр хәрәкәтен сагая төшеп күзәтә башлады. Куркырга һичнинди сәбәп булмаса да, пошкыргалап алды. Аның артындарак әни поши яфраклар ашый. Бозаулары әле яшь, саклана белми, баскан җирдә сикергәләнә, кешеләрне күргәч алан уртасына ук чыгып басты. Бу хәлгә әтисе тагы да катырак пошкырып куйды. Ул да түгел, алар өчесе дә агачлар арасына кереп югалдылар.

Бу күренешкә таң калып, ике куллап абыйсының җиңенә ябышкан килеш басып торган Гөлүсә:

— Нинди матурлар! Бозавын, бозавын гына күрче! — диде. — Кулга нияләштерсәң икән шуларны...

Бераздан пошилар кереп югалган яктан тонык кына мөгрәү ишетелде һәм тирә-юнь тагын тынып калды.

— Мин сиңа, Нәүфәл абый, сок алып килдем. Менә: бер, ике, өч банка. Эч һәм тизрәк сәламәтлән... Күреп торам, синең кәефең юк. Ни өчен юклыгын да беләм, — дип өстәп куйды Гөлүсә, абыйсына серле караш ташлап. — Әйтмәсәң дә беләм. Син әле аны күрмәдең, э-э? Шуңа кәефең дә юк, шулаймы?

Нәүфәл дәшмәде, каен очларына тиеп торган зәңгәр күккә карады. Көньяктан төньякка таба куксел-кара болытлар агыла, болытлар куерып килгәнгәме, күк читендәге зәңгәрлек тагы да куера төшкән. Алан

читеннән үк башланган каеннар ак күлмәк кигән мәктәп кызларын хәтерләтәләр, шул елларны искә төшерәләр, әйтерсең алар көлә-көлә егетләрдән качалар, шул ук мәлдә котырып бөтергәләнеп алалар, үзләренә генә билгеле булган серле бер хәрәкәт белән егетләрне чакыралар сыман.

— Утырыйк әле шунда, Гөлүсә.

Кояш эссесен җыеп өлгергән үлән уч төбен җылыта, ләкин кул җиргә житүгә, дымсу талгынлык бөтен тәнгә йөгерә. Гөлүсә аякларын артка бөкләп утырды да сумкасыннан банкалар чыгара башлады, аларны бер рәткә тезеп куйды, шуннан соң үрелеп кенә янындагы ромашка чәчәкләрен өзеп банкалар өстенә салды. Ул бит очларын уймакландырып елмая, күзләрендә нурлар биешә, күзенә төшкән чәч бөжраларын өф дип өреп җибәрә дә янә елмая.

— Ә син аны бик тә, бик тә яраттыңмыни, абый?..

Нәүфәл сеңлесенең күзләренә карый, елмая, башын чайкап куя, үлән өзеп авызына каба, терсәгенә таянып кырын төшә.

— Бик күп белергә телисең,— ди ул һәм кулларын баш астына куеп чалкан ята, болытлар каплый башлаган күк гөмбәзенә карый. — Бу дөньяда барысы да үтүчән, Гөлүсә. Хәтта иң саф мәхәббәт хисе дә. Вакыт узгач ул да башка мәгънә ала, эчтәлеге белән үзгәрә димме.

— Ләкин мәхәббәт барыбер үлемсез, абыем!

— Мәхәббәт кешенең иң саф, иң изге, иң гүзәл, иң кадерле хисләренең берсе. Менә сиңа унҗиде яшь. Синең нәфис, эчкерсез бәгъреңә мәхәббәт яңа үрелә башлагандыр әле, сеңелкәш. Хис ташкынына иярел, акылыңны җуйма. Соңыннан минем кебек үкенергә, әрнешергә, мине нахакка рәнҗеттеләр дип, сөйгән кешеңә ачу сакларга язмасын. Бик яраткан кешеңнең күңеле син көткәндәй үтә саф, үтә гадел һәм изге дә булмаска мөмкин. Башта син аны сынап кара, тәмам ансыз яши алмавыңа инангач кына тәүге адымыңны яса... Ашыкма...

— Абый, син бөтенләй тәкъва кеше булып киткәнсең ич! Син, син... Юк, әйтмим...

— Нигә? Әйтеп бир.

Нәүфәл йөзтүбән әйләнеп ятты, үлән башына үрмәләүче бер камкәрияне тотып сыртына җибәрде. Бөҗәк, нидер сизенеп, канатларын җәйде дә очып китте.

Гөлүсә дәшмәде, кулындагы ромашканың таҗ яфракларын берәмберәм йолка башлады.

— Хәер, сиңа ни. Әтиең урындагы кеше, Сережаның әтисе түрәләрнең түрәсе, өйләнешүегезгә кооператив квартира булыр, институт тәмамларсың, анда да җылы урын әзерләнгән булыр. Теплица чәчкәсе булырга теләмәсәң, үзеңчә яшәргә, үз тормышыңны үзең корырга тырыш, сеңелкәш. Әзергә-мәзер алынган тормышның кадере булмый,— диеп уенны чынга борып җибәрде Нәүфәл. — Иң мөһиме, үз фикереңдә нык бул. Әтиең синең, Гөлүсә, теге яки бу эшне хәл иткәндә бик күп уйлана, икеләнә, үзе яңалык өчен көрәшкә чыкса да, тәвәккәлли алмый изалана. Минем идеяләрне әле булса тормышка ашырганы юк. Ә мин аңа ышанып биредә калган идем. Болай булса, моннан китәргә генә кала.

— Сәер кеше син, абый, — Гөлүсә никтер оялып китте, бит очлары алсуланды, уңайсызлануын абыйсыннан яшерергә тырышып, үзалдына көлеп куйды.

— Ярар, куйыйк бу сөйләшүне. Җиңгәчәй ни хәлдә? Абый кайтмадымы әле?

— Яшиләр бер көйгә. Мин кайтыйм инде, абый.

Гөлүсә китте. «Үпкәләде», — дип уйлады Нәүфәл. Ул да кузгалды, ашыкмый гына төз каеннар арасына кереп китте.

*Ахыры киләсе санда*

Габдрахман Минский

# ЯШӘҮ

хикәя



Хөрмәтевне больницага кичкырын гына китереп салдылар.

Кабул итүче врачның «Нәрсәдән зарланасыз?» дип соравына ул җавап таба алмыйчарак торды.

Су бирделәр. Бер-ике йотым йоткач җиңел булып китте.

— Болай... атап әйтерлеге дә юк кебек тә бит...

— Әйтегез... Әйт, ни булды?

— Бер күңелсез хәл инде шунда...

— Нинди күңелсез хәл?

— Булды инде...

— Ягъни?!

— Рәнҗеттеләр...

— Рәнҗеттеләр?! Ничек?

— Сүз белән... Начар мөнәсәбәт белән...

Хөрмәтев сүзен бүлде дә инәлеп врачка карады:

— Гафу итегез, доктор... Мөмкин булса... бу сөйләшүне соңгарак...

Врач, тынычландырырга теләгән сыман, кулын аның иңбашына куйды:

— Ярар. Алайса, соңыннан.

Авыруның кан басымын үлчәп, пульсын санагач, укол кададылар. Кан басымы авыруны минутында койкага салыр дәрәҗәдә югары иде.

— Сезне хәзер уналтынчы палатага, бик әйбәт кеше янына урнаштырырлар, — диде врач. — Ул үзе дә берәр күрше булса икән дип тилмерә. Сезгә дә кулай булыр, аңа да. Сезгә хәзер үзегез әйткән күңелсез хәлдән мөмкин кадәр ераклашырга, булдыра алсагыз, бөтенләй онытырга кирәк. Шәфкать туташы дарулар кертер. Калганы иртәгә ачыкланыр.

Уналтынчы палатадагы ике караватның берсендә Сабирҗан Зарипов фамилияле авыру ята иде. Больница пижамасыннан килеп кергән яңа кешене Зарипов яткан җиреннән күтәрелә төшеп каршылады.

— Бу кичне дә ялгыз чыгам дип кайгырып ята идем. Яшибез, болай булгач!

Хөрмәтев, үзен бу килеш каршылауны бигүк ошатмавын сиздергәндәй, каш астыннан гына тегеңә карап куйды.

— Яшисең инде аны... Башыңа төшкәч...

Ниндидер бер төшенкелек белән әйтте моны Хөрмәтев. Зарипов уңайсызлана калды. Бәлки болай каршылау кирәкмәгәндер? Кеше хәлен белмәссең! Зарипов бераз сагаеп, әмма тегеңә сиздермәскә тырышып, берни булмагандай сүзен дәвам итте:

— Сүзләрем өчен гафу итегез... Но, минемчә, мондый очракта, бигрәк тә мондый урында, кунак каршылагандагы кебек: «Хуш киләсез!», «Рәхим итегез» һәм башка шуның ише сәламләүләр яңгырамыйлар...

— Килешәм, — диде Хөрмәтев кыска гына итеп.

— Минә килештек тә! Болай булгач, әлеге дә баягы шул бер сүзгә кайтабыз: «Яшибез!»

Хөрмәтев йөзендә чак кына елмаю чагылды. Бу тикле оптимист авыруга юлыгудан туа башлаган елмаю иде бу.

Зарипов хәлне тиз шәйләп алды:

— Әйдә, алайса, танышу йоласын башлап җибәрик. Без фәкыйрегез врачлар телендә «ходящий больной» санала. Рас шулай икән, хәзер, йөгереп кенә барып, чәй китерәм, ә башкасы тумбочка тулы, сыймаганы, әнә, тәрәзә төбендә, — диде Зарипов, компот банкаларына, алма һәм тагы берничә тартмалы ризыкка күрсәтеп.

— Чәйләп алыйк дисезмени? — Хөрмәтевнең тавышы бу юлы көррәк яңгырады. — Кунакчыл кеше икәнсез, туган! Врач та әйткән иде шул.

— Нәрсә әйтте? Күп сөйләргә ярата, дигәндер...

— Юк, алай түгел. Әйбәт кеше диде. Ә, нигә?! Мин үзем дә, мәсәлән, сөйләшергә килгәндә, кем әйтмешли, сүз эзләп кесә капшаучылардан түгел.

— Минә уртак тел дә табылды, ә теле табылгач — сүзе чишмә инде аның, — диде Зарипов һәм термосын алып чәйгә китте. Хөрмәтев исә аның турында уйлап торды... Ничектер күңеленә якын иде ул. Врач, рәхмәт төшкере, дөрес әйткән икән. Дәваланыйк әле башта. Әйе, яшибез болай булгач.

Зарипов кайтып керде.

— Минә чәй дә булды. Титанның, паровоз күк пар бөркеп, кайнаган чагы икән. Беләсеңме, туган, нинди чәй бу?! Әмири чәй! Миңа сугыш елларында Кавказ оборонасында катнашырга туры килде. Ул як халыкларында чәй дәмләү, безнеңчә әйтсәк, пешерүнең күп төрле ысуллары бар. Иң әйбәт дәмләнгән чәйне «әмири чәй!» диләр. Ягъни гали затлар, әмирләр эчә торган чәй. Ә без кемнән ким! Әйдә, теге бер җырдагыча, самаварны... термосны екканчы, тастымалны сыкканчы эчиек әле. Тирләп чәй эчүнең тәнгә дә сихәтләре санап бетергесез диләр бит әле! Нәрсә белән эчәсез? Вареньe беләнә? Ике төрле, минә монысы карлыганныкы, ә монысы кара миләш — кан басымын төшерә. Әллә тел очына шикәр кабып кынамы? Рәхим ит! Онытa язганмын бит, әй! Бал! Юкә балы да бар әле безнең! Ну шәп нәрсә! «Искра» председателе Фәйзи дә балдан терелеп чыгып китте. Югары катта астмалы бер шагыйрь ята, аңа да кертәсе бар...

— Балны бик борынгы дәва дип әйтәләр...

— Дөрес әйтәләр! Җитмеш җиде төрле авыруга ярый ул...

— Миндә җитмеш сигезенчесе шул.

Хөрмәтев баягы төшенкелегенә кайтып әйтте моны. Каш-кабагы тагы йомылды.

— Берәр модный чирме әллә! Стресс, ишимиш, аллергия...

— Шуларның берседер инде. Врачның «нәрсәдән зарланасың?» дигән соравына җавап таба алмый тордым...

Хөрмәтев, сөйләүдән ни файда дигән сыман хәрәкәт ясап, алдындагы суына башлаган чәйгә сузылды. Палатаны җайсыз тынлык басты. Стакан чыңлап куйды. Хөрмәтевнең кулы калтырый иде. Нервысы уйный, дип уйлады күршесе. Нидер әйтергә, хискә бик бирелеп китмәсен өчен нинди дә булса уңай сүз катарга кирәк иде. Әмма Хөрмәтев үзе сүз башлады:

— Я, ярый, борчылуларны куеп торыйк әле бер читкә. Чәй эчәргә булдык түгелме соң?

Зарипов бердән купкан эчке шатлыгын яшерә алмыйча, аның сүзләрен эләктереп алды:

— Мин дә шулай дим ич!

Сабирҗан Зарипов — күпне күргән, күпне кичергән, Ватан сугышының утын-суын кичкән отставкадагы полковник. Җәмәгатьчелек тәртибендә башкарган эше буенча аңа күп төрле профессия кешеләре белән очрашып, әле акыллы киңәше, әле ихлас теләктәшлеге белән берсенең кайгысын, икенчесенең шатлыгын уртаклашырга туры килә. Болар аңа кеше күңеленә ачкыч табу юлларын өйрәтте. Гадел, ягымлы сүзнең хикмәтле көчен һәм, киресенчә, алама тел ярасының күпме хәвеф китергәнен, шуңа дучар булучының аянычлы хәлгә калу, хәтта сафтан чыгу фактлары турында ишетсә дә, Хөрмәтев кебек больница койкасына килеп ауган тере оригиналын беренче очратуы иде. Үзе чәй ясый, үзе Хөрмәтев күңеленә юллар эзли иде ул.

— Әйе, чәй эчиек әле башта.

— Кайчан дару китерерләр икән? Звонок төймәләре юкмыни басарга?

— Даруны китерерләр аны. Звоноксыз да китерерләр... дару качмас...

— Нервы талый...

— Чәй инде аның даруы, туган, чәй! Беләсеңме чәйнең нәрсәдән яралуын?

Хөрмәтев теләр-теләмәс кенә сораган итте:

— Нәрсәдән соң? Үләннән, канешно.

— Сократ Хәким керфегеннән! Вот! — диде Зарипов. — Әйе, әйе! Бер дә гаҗәпләнмә. Тыңла, алайса. Тәүлектә бирелгән вакыт җитми бу галимгә. Көнен дә утырып эшли бу, төнен дә... Йокларга да кирәк бит. Ни әйтсәң дә адәм баласы! Кош-кортлар да вакыты җиткәч йокыга тала. Йоклар иде — вакыт жәл моның. Хәле шул дәрәҗәгә килеп җитә ки, йокысызлыктан талган күз кабаклары керфекләрен дә күтәрә алмаслык булып авыраялар. Галим нишли диген? Кайчы ала да керфекләрне кыркып ташлый. Чәй үсеп чыга.

— Әй-бә-ә-т! — диде мондый риваятьтән кәефе күтәрелгән Хөрмәтев. — Бар шул, хәйран да хикмәте бар бу чәйнең. Безнең әбекәй мәрхүмә гел: «Чәй эчмәсәм башым авырта, эчсәм көч-хәл кереп китә», — ди торган иде. Туксан дүрткә җитеп үлде.

— Менә бит, үзең әйтеп торасың! Грузия, Әзербәйҗан якларында йөздән узган колхоз картларының җимерттереп эшләп йөрүләре нәрсәдән дисең? Чәйдән!

— Әзербәйҗан дигәч тә, бер вакыйганы искә төшердең,— дип ялгап алып китте сүзне Хөрмәтев.— Сугыш елларында булган хәл...

— Яле, яле. Узганга кайту — яшьлеккә кайту, ди торган иде безнең бабай. Тыңлыйм.

— ...Кырык икенченең яз башы. Үзең беләсең, сугышның хәтсез авыр чагы. Кырым фронты. Безнең батальон Керчь каласыннан көньяктарак бер киңлектә оборона тота. Бу җирләрдән моңарчы бер бәреп чыгарылган дошман яңа атакага әзерләнә. Сугышлар, әлегә, разведка тәртибендә, күктә, баш очыбызда бара. Кыскасы, «воздух!» командасы бер дә көттереп тормый. Шундый киеренке көннәрнең берсендә отделение командирыбыз, әзербәйҗан егете Мәммәд Әли барыбызга да юынырга, кырынырга, таба алганнар ак яка тегәргә, итекләребезне чистартырга кушып команда бирде... Шук табигатьле украин егете Чумак шунда сорап куйды:

— Операга җыенмыйбыздыр бит?..

— Операга сугыш беткәч! — диде сержант. — Безгә килерсең, Бакуга! Үзем алып барырмын. «Ләйлә вә Мәҗнүн». Менә дигән опера! Мәхәббәт турында!

Ярый. Юындык-киендек, су күп. Урнашкан җиребезнең исеме дә «Җиде кое» дип атала. Шул арада бер-ике «воздух!» та уздырып җибәрдек. Болыт арасыннан безнекеләр килеп чыгуга, чәчелә-сибелә сыпырткан фашистларга таба Мәммәд Әли бармак яный: «Папайдешь, слуши, мы от тебя, стервятника, шашлык сделаем!» Ярый. Чумак әйтмешли, операга әзерләнгән кебек купшыландык. Арадан берәүнең чәни бармак хәтле генә шешәдә «Красная Москва» дигән ислемае да килеп чыкты. Тамчылап кына сөрттек. Көтәбез хәзер сержантны. Көтәбез. «Стройся!», «Шагом арш!» командасын...

Менә үзе дә. Өстендә әле генә өтеләнгән, ялтыр төймәле китель, түшендә медальләр һәм тагы берничә значок. Аякта хром итек. Башта кызыл йолдызлы яңа пилотка. Тантаналы парадка басарлык! Шулай уйларга да өлгермәдек, сержантыбыз, барыбызны да таң калдырып, тыныч замандагы кунак каршылаучы хуҗа кебек кулларын җәеп, такта өстәлгә күрсәтә:

— Кадерле дуслар, хөрмәтле полкташлар! Бүген сез минем иң якын кунакларым. Рәхим итеп утырышыгыз.

Мондый «команда»ны берьюлы гына аңлый алмыйча басып торабыз.

— Садись!

Монысын аңладык. Барыбыз да өстәл әйләнәсенә сыешып утырабыз.

— Дусларым, — дип дәвам итте сержант. — Бүген минем көн — 20 яшь тулган көн. Армиягә озатканда колхозыбыз председателе Әли дан[1] менә шушы бизәкле матур тартманы бүләк итте дә әйтте: Мәммәд Әли, диде, бу Ленкорань колхозчылары үстергән «Әзербәйҗан чәе». Бу чәй, диде, кешегә көч бирә, дәрт-кәеф өсти, туган туфрагыңа, аның кара күзле, кыйгач кашлы кызларына мәхәббәт арттыра. Мин сезне, дусларым, бүген шундый чәй белән сыйлыйм.

Шинель белән томалап куелган флягалардан һәркайсыбызга чәй ясалды. Билгеле инде туган көн «теге нәрсәсез» уза алмый. Табынның уртасына «анысы» да чыгып кунаклады. Старшина фронтовой паек хисабыннан ике «шкальник» бүләк иткән. Борын башына иллешәр грамм. Граммындамыни эш, тостында! Тостында!!

Дистәләрчә еллар артында калган ул тостны мин әле бүген дә, мәҗлесләрдә, аеруча Җиңү көне табыннарында кабатламыйча калмыйм. Әйтергә кирәк, бертавыштан хуплап, кул чабып каршы алалар.

— Әллә тагын бер кабатлыйсыңмы шундый озын гомерле тостны?!

[1] Дан (әзер.) — абый.

— Була ул, була! — дип эләктереп алды Хөрмәтев.— Тыңла, алайса.

Хөрмәтев, тост әйтергә җыенгандай, стаканын кулына алды, торып басты һәм әзербәйҗан акценты беләнрәк әлеге тостка керешге:

— Ата-бабаларымыздан гәлән гөзәль адәт диянчә, әлләремездәе балаҗа бокал, йөрәхләремездәге чох бөек хис илә күтәрих, дослар[1], за советский народ, который дал Гитлеру от ворот поворот!

— Бүген дә яңгырый бу тост. Тапкан бит, ә!

— Сугышта табыла ул, Сабирҗан дус! Ватан сугышында безнең солдат үзенең батырлыгы белән дә, зирәклеге белән дә алдырды. Теркин үзе ни тора! Матросов, Газинур...

— Зирәклек дигәннән, укыгансыздыр. «Кече җир» китабында да дулкынландыргыч бер «туган көн» китерелә...

— Укымыйча! Егерме өч яшь тулган десантчыга туган көнен котлап бирерлек кыйммәтле бүләк эзлиләр. Дусты аңа үз автоматы дискесеннән егерме өч патрон бүләк итә. Яшь десантчы өчен иң кыйммәтле бүләк бу, чөнки патроннар җитми, ә алда дошман өстенә атака әзерләнә.

Ике авыру, истәлекле вакыйгалар тәэсиренә бирелүдәнме, әллә инде әңгәмәнең бик көйләнеп китүе комарыннанмы, берьюлы ничектер бушанып, тынып калдылар. Бу тынлыкта алар, үз уйлары агымында бер истәлектән икенчесенә күчә барып, үзләрен иске танышлар белән очрашкан төсле сизделәр. Әгәр дә ишек ачылып шәфкать туташы килеп кермәсә, уйлар агымыннан тиз генә аерыла алмаган да булырлар иде.

— Хәерле кич! — ягымлы тавыш икесен дә уятып җибәрде.

— Хәерле кич, Верочка! — диде Зарипов һәм бу юлы да комплимент әйтми кала алмады: — Бу кич, Верочка, сез бик тә мөлаем күренәсез...

— Сез әйтерсез инде, Зарипов абый! — диде Верочка, тагын да яктырып. Күренеп тора, тыгыз тәнле, сылу буйлы, ачык йөзле кыз мондый комплиментка бик шат, бик риза... Ул Зариповка термометр бирде дә Хөрмәтев янына килде.

— Хәлегез ничек... Тынычланабызмы?

— Рәхмәт...

— Менә бу даруларны ятар алдыннан эчәрсез, — диде Вера һәм тумбочкага кайсы сәдәп, кайсы борчак кебек берничә дару куйды.

— Нәрсәдән соң болар? — дип кызыксынды Хөрмәтев.

— Монысы менә — тынычландыру өчен, ә монысы — йоклаткыч, монысы — кан басымын төшерә.

Аннары Верочка янадан Зарипов янына кайтып, термометрын алып карады.

— Ничә?

— Шул бер үк хәл: утыз биш.

— Нишләп күтәрелми бу, ә?!

Вера, тыныч йокы теләп, чыгып китте.

Хөрмәтев, шуны гына көткән шикелле, ишек ябылуга Зариповка дәште:

— Сабирҗан дус...

Зарипов җавап бирмәде.

— Әллә ишетмәде инде? — Хөрмәтев үзалдына гына әйтеп куйды.

— Ә?! Нәрсә? Миңа әйтәсеңме? — диде Зарипов, үзе генә кичергән уйларыннан котылып.— Шәфкать туташы нәрсә диде соң?

---

[1] Ата-бабаларыбыздан килгән гүзәл гадәт кушканча, кулларыбыздагы кечкенә бокалны йөрәкләребездәге олы хис белән күтәрик, дуслар...

— Дөнья дару калдырды. Йотмасам ничек булыр икән, ә?!
— Куркасыңмы?
— Кирәге юк кебек... Мин үзем, гомумән, даруга каршы кеше.
— Бая үзең дару дигән идең.
— Бая бер хәл иде, хәзер хәл башкара бара төсле...
— Менә бит, — диде Зарипов чын-чыннан шатланып һәм өстәп әйтеп куйды: — Шулай була гына күрсен!
— Була да була! — диде Хөрмәтев. — Мин үзем, Сабирҗан дус, медицинаның бер өлкәсенә фанатикларча бирелгән кеше...
— Мәсәлән?
— Психотерапия! Яхшы сүз белән, яхшы мөнәсәбәт, кешеләрчә игътибарлылык...
— Аның бит, туганкай, авыруның хирург пычагы гына дәвалый торганы да бар.
— Сукыр эчәк...
Зарипов саран гына елмайды һәм көрсенеп әйтте:
— Сукыр эчәк пустяк... дияр идем, аңардан да аяк сузучылар була.
— Бу очракта да игътибарсызлык! Монысында инде үз-үзеңә игътибар итмәү.
— Килешәм.
— Кеше ул минемчә, Сабирҗан дус, авырумы, сәламәтме, барыннан элек кешеләрчә мөнәсәбәткә мохтаҗ. Кешене аның аламасы белән рәнҗетә алган кебек, яхшы мөнәсәбәт белән дәвалап та була. Бердәнбер хикмәтле дару — игътибарлылык! Моның рухи дөньябызны баеткан, яшәвебезне бизәгән күп кенә гүзәл үрнәкләрен күреп тә, укып та беләбез без. Шул ук вакытта, кызганычка каршы дияргә кирәк, әлбәттә, юк-юк дигәндә үзен бер күрсәтеп алган алама күренешләр белән дә очрашып торабыз... Я, ярый, яңадан күңелсез темага кайтмыйк әле. Врач та кушмый. Арымаган булсак, яхшы кешеләр, аларның яхшы эшләре турында сөйләшә-сөйләшә йокыга китиек әле... Шуннан да файдалысы булмас.
Зарипов арыган иде, тик үз хәлен сиздермәскә булды, аннары ялгызлыкта интеккән палатага ямь өстәп килеп кергән бу кешене ул үзе көтеп алды бит әле.

Төнге караңгылыкка чумган палатада дуслашып өлгергән бу ике авыру әңгәмә куертырга тотындылар. Әле берсе, әле икенчесе, бер-берсен бүлә-бүлә, яисә берсе икенчесенә өсти-өсти яхшы күңелле кешеләрнең яхшы эшләре турында сөйләделәр алар. Күбрәк мавыгып киткән Хөрмәтев сөйләде. Зарипов аның дәртләнә баруын кызыгып күзәтә һәм бер үк вакытта тавышында арганлык та ишеткәндәй була. Әмма Хөрмәтев үзендә бернинди арганлык та сизми. Әгәр дә, сөйли торгач, кинәт Зариповның гырылдап сулыш ала башлавын ишетеп ярты сүздә бүленеп калмаса, ул әле әңгәмәне озак дәвам иткән булыр иде.

Хөрмәтев тумбочка өстендә яткан кул сәгатенә күз салды. И, күпме бар әле таң атарга!.. Һәм шунда көтмәгәндә-уйламаганда колак төбендә яңадан оныгының үксеп елаган тавышы зыңлагандай булды... Маңгаена салкын тир тамчылары бәреп чыкты... Башына уйлар ябырыла башлады. Ул аларны куарга теләп, тизрәк йокыга чумар өчен күзләрен дә йомып ятты, әле бер ягына, әле икенче ягына да әйләнгәләде, әмма йокы килмәде. Уйлар... уйлар... уйлар, тынгысыз да, кара да, бозлдай куырып алган салкын да уйлар.

...Барысы да әлеге яшь каеннан, балалар бакчасы нәниләре, шул җөмләдән оныгы Рафаэль кулы белән дә утыртылып һәм «Гүзәл» исеме бирелгән яшь каеннан башланды.

Һәр иртәдә онытын балалар бакчасына озата барган Хөрмәтев, Гүзәлнең ничек көннән-көн матурая баруын, ап-ак күлмәген бизәгәннән бизәп яшел яфрак яруын күреп туя алмый иде. Бөек рәссам — табигать кодрәте белән тудырылган бу матурлык Хөрмәтевкә җан рәхәте бирә иде. Ул инде хыялында аларның — Гүзәл белән Рафаэльнең — берзаман үсеп ныгуларын күз алдына китерә, оныгы белән каен кызының җирдәге якты киләчәге турында уйлану аның гадәтенә әверелеп бара иде...

Һәм менә көтмәгәндә кояшлы иртәдә фаҗига килеп чыкмасынмы!

Хөрмәтевнең оныгы Рафаэльне балалар бакчасына озата барган чагы иде. Зур тизлектә очып килүче «Победа» юл уртасындагы язгы кар суына пычранырга теләмичә кырт борылып юлдан чыкты да Гүзәлне изеп китте.

Моны күргән Хөрмәтев, акылын җуйган кешедәй, бер мәл ихтыярсыз торды. Аны оныгы Рафаэльнең өзгәләнеп елаган тавышы гына уятып, айнытып җибәрде кебек.

Ярсыган бала күңелен көч-хәл белән бераз тынычландырып бакча капкасыннан керткәч, Хөрмәтев җинаятьче машина эзеннән китте.

Машина комбинат директоры урынбасарыныкы икән. Урынбасар белән сөйләшү Хөрмәтевне рәнҗетте генә. «Сез, хөрмәтле гражданин, — диде аңа урынбасар урындык-фәлән тәкъдим итеп мәшәкатьләнмичә генә, — аңларга тиеш идегез: комбинат каен-маеннар белән шөгыльләнми, ә зур, дәүләткүләм бурычлар белән яши. Рас шулай икән, сез эш кешеләренең кыйммәтле вакытын юк-бар белән әрәм-шәрәм итеп йөрергә ярамавын да аңларга тиеш идегез».

«Түгел! Юк-бар түгел бу!» — дип, Хөрмәтев директор урынбасарының ялгыш фикердә булуын аңлатып бирмәкче булды. Шул вакыт телефон аппаратларының берсе шалтырый башлады. Директор урынбасары Хөрмәтевкә ым белән генә: «Ярый! Аңлаштык! Китә аласыз»ны аңлаткач, телефон трубкасын алды...

Хөрмәтев урынбасар кабинетыннан чыкканда колагына тегенең: «... бер демагог шунда, килгән миңа акыл сатарга», — дигән һичшиксез аның адресына әйтелгән сүзләрен ишетте.

Секретарь-машинистка бүлмәсенә чыгуга, Хөрмәтевнең күзенә беренче күренгәне өстәлдәге графин тулы су иде. Стаканга салып берике йоткач, Хөрмәтев урамга чыкты... Әмма ул барасы җиренә барып җитә алмады. Башы әйләнгәндәй, аяк буыннары бушагандай сизде ул үзен. Бирешмәскә тырышып та караган иде, ләкин тыңлаусыз аяклар бөтенләй бушагач, Хөрмәтев җиргә чүгеп утырды.

Узып баручылар аның хәлен тиз абайладылар.

— Сезгә кыенмы әллә?!

— Әйе... Бик кыен... Бик!

Аны узып барган машинаны туктатып алып киттеләр...

Зарипов та, төнлә уянып, таң алдында гына кабат йокыга китә алды. Ул да төн буе, гадәтенчә, үз уйларында йөзде — гел эзләнде... Гел яңа чара, яңа әмәл табарга тырышып уйланды... Сырхаудан арынасы, әле яшисе, гомер юлын сузасы — озынайтасы килә иде аның...

Хөрмәтевне больницада озак тотмадылар. Атна-ун көн дигәндә, анализларның барысы да эшләнеп һәм ачыкланып беткәч, ул өенә кайтып китте.

— Ярый хуш, Сабирҗан дус! Мин биредән баеп — тагы бер әйбәт дуска баеп кайтам инде болай булгач. Рәхмәт сиңа, дус кеше. Сиңа да

тизрәк терелеп чыгарга язсын. Менә минем адрес, менә монысы — телефон... Чыгуыңа шалтырат.

— Сиңа да рәхмәт! Нәрсә телием соң үзеңә?!

— Килеп кергәндәгене...

Зарипов бераз гына абайламый торды. Хөрмәтев исенә төшерде: «Яшибез болай булгач!» Зарипов җәелеп торып елмайды:

— Яшибез!

Бусагада озатып калган Верочканың ачулангандай юри генә кашкабагын җыерып: «Артык бирегә аяк басасы булмагыз!» диюеннән икесе дә берьюлы шаркылдагач, Хөрмәтев тагы рәхмәтләрен әйтеп чыгып китте.

Больницадан чыгып берничә көн узгач, Хөрмәтевне командировкага җибәрделәр. Аннан ул ун көннән соң гына кайтты. «Юк, бер кеше шалтыратмады да, кермәде дә»,— диде аңа хатыны. Иртәгесен ул үзе Зарипов янына кереп чыгарга булды. Карчыгыннан анысын-монысын әзерләтте, Верочкага дип кесәсенә бер шоколад та салды. Әмма бүген дежурда башка кеше иде.

— Зариповны гына чакырып чыгыгыз әле, зинһар! — диде ул сестрага.

— Зариповны?! Кайсы Зариповны?!

— Кайсы дип... Шул бер Зарипов инде. Уналтынчы палатадан. «Ходячий» ул.

Шәфкать туташы хәтерләргә теләгән сыман бераз уйланып торды:

— Уналтынчы палатада Зарипов юк бит, абый!

— Әллә кайтып та киткән?

— Шулайдыр...

— Алайса, болай сөйләшик, акыллым, — диде Хөрмәтев. — Менә бу шоколад сиңа, ә менә күчтәнәч төргәген, 18 нче палатада Салихов фамилияле бер карт ята, шуңа бирерсең, яме?! Сорап та кил үзеннән — берәр йомышы юкмы икән. Мин көтә торырмын.

Сестра, Хөрмәтев йомышларын бик тиз үтәп, әйләнеп тә килде:

— Карт рәхмәт әйтте...

— Ярый, үзеңә дә рәхмәт! — диде Хөрмәтев һәм ишеккә таба китте.

— Абый!..

Сестра аны куып җитте:

— Абый... Ни бит... Зарипов юк... киткән...

— Кайтып киткәнме?

— Түгел... Бөтенләйгә...

— Ничек бөтенләйгә?!

— Әйе шул... бөтенләйгә... Кайтмаска киткән... бүген өченче көн икән...

Хөрмәтев бу тикле көтелмәгән хәбәрдән тетрәнеп калса да, ышанырга теләмичә, врач бүлмәсенә таба атлады.

Алар озак сөйләштеләр. Бу сөйләшүдә шунысы мәгълүм булды. Зарипов өметсез диярлек хәвефле авыру була. Врачлар гына түгел, үз хәлен ул үзе дә яхшы белә, әмма тиз генә килешергә-бирешергә теләми, киресенчә, яшәү теләге белән хәвефне җиңәргә, бөтенләй җиңмәсә дә, беразга сузу ышанычы белән яши.

— Әйтергә кирәк, ул шуңа ирешә дә. Югыйсә, медицина практикасы күрсәткәнчә, аның берничә ел алданрак китеп бару ихтималы да булган, — дип төгәлләде врач үзенең сүзен.

Ноябрь, 1978.

# ҖАН ИЯСЕ

хикәя

Кайгы баскан баш иелеп төшкән. Аскы ирен бүлтәеп салынган. Моң-зар тулы күзләрдән тәгәрәгән ялгыз яшь бөртеге бит уртасында боз борчагыдай катып калган...

«Мондый көнне күрермен дип уйлаган идемме-ни мин?! Бу хәтле кимсетелү!.. Гаделсезлек!.. Мин дә җан иясе ләбаса! Нәсел-нәсептән килгән даныбыз — батырлыгыбыз бар. Бабайның бабасы легендар Буденный гаскәрендә утны-суны кичкән. Уллары, оныклары Чапай тачанкасы белән җырга кергән... Инде көн буе җил-буранда чарасыздан бичара калып көтеп тор менә. Кайчан чыгар әле?! Уф, көтеп алудан да авыр нәрсә бар микән бу дөньяда! Көтә-көтә көтек булып бетәсең, әнә килә, менә килә дип өметләнәсең, ә ул... Авызына бер эләктеме — бетте. Дуңгыз булганчы лакый, сәрхүш баш! Исереп кенә калса иде, ичмасам... Ава-түнә чыгар да, бәбәкләрен котырган үгезнекедәй акайтыр һәм тотынып акырырга-бакырырга, әйтмәгән сүз калмас: син ялкау, син әрәм тамак, син үләксә, син фәлән дә син төгән... Китәр тезеп, китәр тезеп, түзеп кенә тор: анаң да калмас, бабаң да... Кайчак шундый кан кыза... тибеп очырырдай буласың. Әрләп-хурлап кына да калмый бит, кулына ни эләксә шуның белән тондыра. Башың дип тә тормый, күзең дип тә... Карт көнеңдә, төгең коелган шәрә тәндә камчы ярасы тиз бетми ул...»

Тимеркүк, уйларыннан бүленеп, башын калкытты. Тәрәзә пыяласына сыра бокалы төшерелгән павильон ягына күз ташлады. Хуҗа чыга дисә, җил тавышы гына икән.

Кайгы-хәсрәт тулы баш яңадан иелде, бахбай тагы күңелсез уйларына чумды...

«...Элегрәк заманда, гужтранспортта йөк ташыганда, олаучылар әбәткә туктасалар, сине дә онытмыйлар, яртылаш булса да туарып, авызлыгыңны ычкындырып, муеныңа солы торбасы тагып, алдыңа печәнен салып китә торганнар иде. Алар да тук, син дә. Карыныңа азык кергәч күңел күтәрелә, дөнья мәшәкате җиңеләйгәндәй була...»

Чү! Тимеркүк, башын күтәреп, колакларын тырпайтты. Әллә ялгыш ишетәме? Юк, юк, ялгыш түгел. Аның аяк тавышы!.. Аның исе!.. Әйе, әйе, ул! Ул!

Ат ялгышмады: иске танышы Турыбия иде бу. Тимеркүк үзенең яшьлек дустын шундук исеннән танып алды. Баядан бирле тынгы бирмичә борчыган уйлары бераз таралгандай, бөтенләй таралмаса да, җиңеләйгәндәй булды. Иске дус шул, иске дус — яшьлек дусты! Вакытында, күптән инде, яшь чакта, урак өсте иртәләренең берсендә бал исе аңкыган чәчәкле болында, алар арасында мәхәббәт тантанасы да булып алган иде бер.

Турыбия исә Тимеркүкне берьюлы гына таный алмады, башта ялгышмыйммы дип тамак төбе белән кешнәп куйды, янәсе, синме бу?!

Ә Тимеркүк булдыра алганча гәүдәне турайтып, башны тагы да күтәрә төшеп, колакларны торгызды, койрыкны әле бер сыртка, әле икенчесенә аткалап, дустының кешнәвенә каршы җавап бирде:

— Һе-һе-һе... Мин бу, мин! Якынрак кил.

Турыбиянең хуҗасы — совхоз ат караучысы Сәмигулла — дилбегә очын үрәчәгә бәйләп, атның нуктасын бушаткач, авызлыгын ычкындырып башына торба элде дә, «сусынны басып килим әле, малкай!»-ны әйтеп, ялын сыпырды һәм павильонга таба китте.

Шуны гына көткән Турыбия чанасы-ние белән Тимеркүк янына тартылды. Иске танышлар, ирен очларын тиештереп, койрык селеккәләп, колак кагышып назландылар, шуның тәэсиренә бирелгән Тимеркүк тагы бер кешнәде: «Һе-һе-һе! Сине дә күрәсе көн бар икән». Турыбия, муенын дустының җилкәсенә куеп, кызганган сыман бераз дәшми торгач, түзмәде, әйтте: «Нишләп бу тикле бетерештең». Тимеркүк, күзләрен йомып, башын иде: «Әйтмә дә инде. Аяклар бетте менә. Тоякларны күр син! Кыргычлап, дагалап тормагач, ярылып эштән чыктылар. Көч-хәлгә атлап йөрим». «Кайда эшлисең?» Мондый сорауны Тимеркүк өнәмәде, хәтта җавапсыз ук калдырырга теләп башын янтыкка бормакчы иде, әйтмичә түзеп кала алмады: «Эшлисең, имеш... Эш димәсәң хәтере калыр. Буш шешәләр, ящиклар ташыйм. Нинди көнгә калдык диген син, ә?!» Турыбия, мондый зар белән килешмичә, башын чайкап пошкырды: «Әйтмәс идем! Мин үз эшемнән бик разый. Совхозда эшлим. Азык ташыйм: комбикорма, салам. Ашаганым да ярма да ипи...» «Күренеп тора», «Сиңа эләгәме?» «Эләгә... сырт буена». «Һе-һе-һе». «Көлмә син». Тимеркүк ачулы карап куйды. «Хәер, сез, бия җенесе, гамьсез җан бит». «Ачуың киләмени?» Килмичә! Мин, дускай, тир түгеп тапканны ашарга яратам. Оныттыңмени гужтранспортта эшләгән көннәрне? Хәзер барысы да автотранспортка әйләнде шул. Бервакыт Бакалтайда утында эшлибез. Идел ярындагы салларның бүрәнәләрен тарттырып әрдәнәләргә өябез. Казан белән Үстия арасында әллә нигә бер узган трамвайдан башка машина әсәре юк. Утынын да, пароходлар бушаткан йөген ташу да безнең өстә. Теләсәң таң яктысыннан төн караңгысына тикле эшлә. Тир түгеп хезмәт итү үзе ни тора! И шул чакта тамакка бара да иде! Алдыңа ни салганны ялмап кына торасың... Хуш исле сусыл печән дисеңме! Көрпәгә болгаткан арыш саламымы! Хәзер бит алар бик тансык азык — делекатис диләрме әле? Син дә бит, әнә ат башың белән, кешеләр азыгын ашыйсың түгелме? Нәрсә авызыңда? Ипиме?

Турыбия, чәйнәвеннән туктап, тынып калды.

Тимеркүк ачуланып пошкырды:

— Синнән сорыйлар бит?

— Батон... — диде Турыбия кыска гына итеп.

— Ә?! Һе-һе-һе...

Бу мыскыллы һыһылдау бияне ярыйсы ук гарьләндерде.

— Кибеттә арыш ипие булмаганга мин гаеплемени? Алып бетерләннәр. Бездән алда бер шофер машинасына өч капчык ипи төяп алып китте. Батон дигәч тә, алты тиенлеге инде... диетчиклар ашый торганы.

Тимеркүк тагы кешнәп көлде:

— Һе-һе-һе-һе...— Рәтең калмаган икән, алайса, койрык очларың да пычранган, әллә эчең йомшадымы?

— Булды азрак, узган атнада хуҗам улын өйләндерде. Туй ясадылар. Ни көттем ялларыма аллы-гөлле тасмалар үреп, дуга бөҗрасына, тәртә очларына кыңгыраулар асып, чуклар тагып, тоякларыма постау чорнап җигәрләр дип, ни көттем. Очыртып апкайта идем бит аларга кияү белән кәләшне! Юк, искечә була, имеш. Таксилар яллап, куыклар тагып дөнья акча түктеләр. Икенче көн иртәсендә, туй узгач, ашъяулыкларны калдык-постыкларны белән утлыгыма селектеләр. Ни генә юк! Ипи кисәкләреннән алып бавырсак, өчпочмак, чәк-чәк калдыклары, гөбәдия кырыйлары, селедка башлары, чуртан койрыклары, колбаса кабыклары, тозлы кыяр, шоколадлы конфет... Әйтәм

ич, үз-үземне белештермичә ачкүзләнеп тыгынганмын. Шул эчне бозган, күрәсең...

Бу юлы инде Тимеркүк сары тешләрен ыржайтып хахылдады. Турыбиянең моңа бик кәефе китте. Колакларын шомартты, тегеңәр берне орып та алмакчы иде, тәртә комачау итте.

— Күпне күрә башлагансың...

— Ә мин сине күптән күргән, — диде Тимеркүк бәхәстә өстенлек алуына шатланып, — әллә оныттың дамы? — Монысы инде кинаяле төртке иде.

Турыбия гарьләнеп борын җыерды:

— Онытырлык булмады инде! Артымнан калмыйча теңкәгә тиеп бетә идең. Әле ялымны ялап иркәләгән була, әле җилкәмне кашып сөя... Шундый ачуым килә иде...

— Ялганлама! Бер дә ачуың килми иде әле. Киресенчә, башыңны түбән салган шәпкә тик тора идең. Ачуланган бия хәтәр ул: арт аяклар белән бәрә.

— Ул тиклесен белеп җиткермәгәнмен. Яшь идем, тәҗрибә җитмәгән...

Тимеркүк бердән юашланып, йомшарып китте, иркәләп-назлап дустының күз тирәләрен, колак очларын иснәде.

— Яшь идең шул. Яман да сылу идең. Күз кызарлык матур идең...

Алар, зәңгәр урманнар, яшел болыннар артында калган яшьлекләрен сагыну тәэсиреннән арына алмыйча, беркадәр вакыт тынып тордылар. Бу тынлыкта Тимеркүк Турыбиянең ничек итеп колынлавын, аннары колынны ялый-ялый юындыруын, аякка басарга, ими табарга өйрәтүен аталар горурлыгы белән күзәткәнен искә төшерде.

— Колынчак әйбәт кенә үстеме соң? Исән-саумы үзе?

— Ба-ар! Бик матур булып үсте. Сиңа охшаган. Тимгелле. Маңгаенда — кашка. Анысы миннәндер инде. Өч яшькә җитеп тәртә арасына кертәсе дигәндә, үзең беләсең, дөньяны машина басты. Грузовигы дисеңме, тракторы, автобусы, троллейбусы, бихисап такси... Безнең ат затына рәтле эш тә калмады. Сабан сөрәсе дә, сука сукалыйсы да, тирес чыгарасы да, су китерәсе дә — барысы, барысы юкка чыкты, бөтенесен машина башкара. Кыскасы, колынчакны мәктәпкә алдылар...

— Мәктәпкә?! Ни сөйлисең син? Нинди мәктәп?

— Сөйләп бетергәнне көт, бүлдермә, үзебезнең атлар мәктәбенә дим бит мин.

— Нишлиләр соң алар анда? Эшләмичә ашарга өйрәнәләрме?

— Нишләп алай булсын... Осталыкка өйрәнәләр!

— Шуннан?

— Шуннан соң циркка алганнар...

— Анысы ни була тагы?

— Әйбәт урын дип сөйлиләр. Ашатып-туендырып, юып-коендырып, сылап-сыйпап кына торалар, ди.

Тимеркүк шундый итеп пошкырып башын чайкады, Турыбия үзе дә аптырап калды.

— Муенга камыт киеп эшкә җигелмәгәч, ниткән әйбәт урын булсын ул? Колынчак яшеннән эшләмичә күшәп ятарга гадәтләнсә, кемгә ярый аннары?!

— Алай димә! Бик яратканнар. Үз эшен оста башкара икән, һөнәре бар, ди.

— Күшәп яту да һөнәр була димени?

— Юкка пошкырасың син...

— Ачуың кузгалса, пошкыру түгел, әллә ни кылырсың. Ярый, теге нишли соң, нинди һөнәр күрсәтә?

— Чаба, сикерә, бии, ди, кеше әйткәнне аңлый, ди, кушканны эшләп күрсәтә, ди.

Тимеркүк бераз уйланып торды. Югыйсә, аның үзенең дә, кеше телен аңлаган, биергә, сикерергә оста атлар турында ишеткәне бар иде.

Турыбия, дусты уйга калган арада, аны башыннан тоягына кадәр күздән кичерде. Шул чагында арка буйларында уелып кутырлаган эзләр күрде. Җаны әрнеп китте биянең:

— Хуҗаң нindирәк кеше?

— Кешелеге корысын! — диде Тимеркүк, яшьле күзләрен мелт-мелт йомгалап. — Алкашның берсе! Кайчандыр шофер булып машина йөрткән. Авария ясагач правасын алганнар... Тик менә безнең ише җан иясен рәнҗетү правасы калган. Югыйсә, бу тикле ерткыч булмас иде. Синең дә шуларның берседер әле.

Үз хуҗасына карата мондый фикер белән килешмичә, Турыбия бар гәүдәсе белән дигәндәй кагынып пошкырды:

— Хуҗам белән без бик дуслар. Исеме мактау тактасыннан төшми. Бу тирәгә дә әллә нидә бер сугыла. Үзе әйтмешли, «сусын басарга». Эчү-исерү дигәнне белми. Авыр сүз дә әйтмәс. Миңа «малкай» дип кенә дәшә.

Шыгырдап ишек ачылган тавыш ишетелде.

— Әнә үзе дә!

Турыбия тиз генә үз урынына авышты. Сәмигулла, килә-килешкә үк: «Озак көттермәдемме, малкай!» диде, биянең ялын сыйпады һәм «мәле, өлешеңне кабып җибәр» дип биягә учын сузды. «Тәки пирожки ашарга өйрәтә бит бу мине» дигән сыман, Турыбия ирен очлары белән генә учтагы сумсаны эләктереп алды һәм ике ялмап бер йотты.

Шуны көткән Сәмигулла, салам тутырган капчык өстенә җайлашып, дилбегәне биянең янтыгына тиертер-тиертмәс каккандай иткәч, «но-о, малкай» диде, сызгырып җибәрде.

Турыбия саубуллашкан сыман башын күтәрде, күзләрен тутырып Тимеркүккә карады, аннары, хуҗа әмерен тыңлау кирәклеген дә абайлап, юыртып китеп тә барды...

Турыбиянең соңгы карашында: «Хуш! Хәсрәткә бик бирелмә. Кайгырма, дускай! Дөньяда безне якын күргән дуслар барын да онытма!» дигән сыман мәгънә бар иде...

## Госман Садә

### Бүләккә әтәч

Күпме тамаша
Сабан туенда.
Корылган барсы
Мәзәк уенга.

Без дә бәхетне
Сыныйкчы, яшьтәш.
Колга очында —
Бүләккә әтәч.

Колга-багана
Боз кебек шома.
Кем анда менә —
Әтәч тә шуңа.

Мен дә ал аны —
Әйтүе ансат.
Әтәчне алу —
Бүгенге максат.

Асыл егетләр
Менеп карыйлар,
Әмма максатка
Җитә алмыйлар.

Уен һаман да
Кызганнан-кыза.
Кем кемне ота,
Кем кемне уза?

Колга очында —
Бүләккә әтәч.
Без дә бәхетне
Сыныйкчы, яшьтәш.

Кечкенә малай
(Килгәндер кайдан)
Менде дә китте,
Ах! итте мәйдан.

Корылган чынга
Уен да монда.
Бүләккә әтәч —
Малай кулында!

Гомер юлы да
Нәкъ шулай, яшьтәш.
Колга очында —
Бүләккә әтәч.
Бүләккә әтәч.

### Авылым киче

Әкрен генә көн сүрелеп, сүнә бара.
Кояш төшеп антеннага кунаклаган.
Куләгәләр чиксез үсеп, озынаеп,
Ерак кунак — марсианга охшап калган.

Кич якынлый. Анда-санда этләр өрә.
Авылыма тыныч гаскәр — көтү керә.
Тагын бер көн китеп бара үз кичәнә.
Авыл исә чумган җылы сөт исенә.

Картлар чыгып утырган да өй алдына
Гәпләшәләр. Телләрендә — дөнья хәле.
Яннарында уйнап йөри оныклары.
Әй, бу кичнең җанга якын тыныч мәле!

Йомгак ясап, көндез кылган үз эшенә,
Тагын бер көн китеп бара үз киченә.
Килә аңа алмаш булып яңа бер төн.
Иң мөһиме — күге зәңгәр, ае бөтен.

●

Төшләремә җылы яңгыр керә,
Бәхеткәме аны юрыйсы?
Агыйделдә калдың яңгыр белән,
Кулларымда — кулың җылысы.

Яңгырлар да ул чак җылы иде,
Яңа сауган парлы сөт сыман.
Бозлы яңгырларны җылытырлык
Кул җылыңны синең юксынам.

Кайвакытта назлы, җылы бер сүз
Ишетәсе килгән чак була.
Шундый мәлдә җылы яңгыр булып
Явып узсаң иде чак кына.

Төшләремә җылы яңгыр керә,
Бәхеткәме аны юрыйсы.
Агыйделдә калдың яңгыр белән,
Кулларымда — кулың җылысы.

## Ике парча

●

Кавышмагач та
Бу фани дөнья
Ни пычагыма!
... Ташланды күлгә.
Суда чагылган
Үз кочагына.

●

Керде санга ахир дуслар көче белән,
Чумды данга маһир дуслар көче белән.
Бу уенда искитәрлек бер ни дә юк:
Янды соңын шул ук дуслар көче белән.

## Булат Сөләйманов

### Казаннан китәр алдыннан

... Үпкәләрсең дип уйламыйм,
Йөрәгеңә барсы сыяр.
Идел, Кабан буйларында
Төннәремнең яктысы бар.

Сүз кирәкми, бар да калсын
Үткән көннәр файдасына.
Китәм сабый җаным алып
Ялгызлыкның тайгасына.

Казандагы топольләргә
Себер җиле хәбәр иткән:
Мин утырткан каенкаем
Мине сагынып җырлый икән.

Бәлки әле сүнмәгәндер
Ягып киткән учагым да,
Атлар кешни төшләремдә,
Төнге болын кочагында.

Рәшә түгел, мираж түгел,
Әллә минем Сопра микән?
Иртеш ага күзләремдә,
Тел төбемдә суы кипкән.

Ак нурлары юлларымда,
Анда мине көтә таңнар...
Саубуллашмый китәм, Казан,
Җырларымның киләсе бар.

### Самотлорда туй

Түгәрәк күл тирәли юл,
Тимер бетон җилкәсе.
Оператор кызга бүген
Балдак биргән иркәсе.

Була ул һәрбер сөюнең
Уңышы, алкышлары.
Самотлорда кунак түгел
Яшьлекнең аккошлары.

Киләчәккә кемнең барыр
Юллары, оныклары?! —
Себере булган халыкның
Киң, иркен офыклары.

Әкиятләрнең чынбарлыгын
Сөйли заман, сөйләсен!

Самотлорны әйләнәләр —
Хет кем кенә өйләнсен.

Чаптар атлар кебек җилгер
«Жигули» дә «Волга»лар.
Ялларында төрле тасма
Һәм антенна-колгалар.

Заманача, чорга тиңдәш
Яшьлек бизи юлларын.
Самотлорны түгел, гүя
Әйләнәләр җир шарын...

Түгәрәк күл тирәли юл,
Тимер бетон җилкәсе.
Әйтерсең лә Самотлорга
Балдак биргән иркәсе.

Мәгъсүм Насыйбуллин

# ЧАКЫРЫЛГАН КУНАК

СУД ОЧЕРКЫ [1]



Андрей Солнцев утырган зәңгәр «Москвич» район прокуратурасы урнашкан йорт янына килеп туктады. Ул битен-кулын юып, кабинетына керергә генә өлгерде — ишек шакыдылар.

— Рәхим итегез!

Бусага төбендә олы яшьләрдәге бер хатын күренде. Ачык ишек катында тукталып калды.

— Прокурор сез буласызмы? — Хатынның тавышы шактый коры һәм дорфа иде. Әле генә кабинетына үтәргә тартынып торган димәссең үзен.

— Әйе, прокурор мин булам,—диде Андрей Солнцев. — Утырыгыз!

Унбиш ел буе прокуратурада эшләгән кеше ул — бик яхшы белә: бирегә берәү дә шатлык уртаклашырга, сөенечен белдерергә килми. Аның ишеген шакыйлар икән инде — димәк, кемнеңдер хафасы, кайгысы, күңел ярасы бар. Кайдадыр закон бозылган, кайсындыр урынсыз рәнҗеткәннәр — шундый чакларда кешеләр прокурорга килә.

— Димәк, дөрес кергәнмен...— Хатын тирән сулап көрсенде дә Солнцев күрсәткән урынга утырды. — Улыма нәрсә булыр икән инде, иптәш прокурор? — дип, аңа төбәлде. Карашы хәсрәтле.

— Улыгыз кем соң?

— И, зиһеннәрем таралган инде!.. — Апа чал кергән чигә чәчләрен сыпырып алды да аңлатыбрак сөйләргә кереште:

— Анатолий Бусаревны соравым, иптәш прокурор. Аның әнисе мин. Нинди язмыш көтә икән Толигымны?

— Алдан әйтеп булмый, — диде прокурор йомшак кына итеп. — Улыгызның җинаять эше судта каралыр, хөкем карарын да суд чыгарыр.

— Толигымның җинаятьтә катнашуына ышанмыйм мин, иптәш прокурор!

— Андрей аның уй-хисләрен бик яхшы аңлый. Кайсы ана үз баласын җинаятьче итеп күрергә риза булыр икән?! Бусарева да прокурорга улының тормышын сөйли, үзләренең ничек яшәүләрен аңлата. Ана-

[1] Искәрмә. Кайбер исемнәр үзгәртелде.

толийның янәсе бер кара гамәле дә юк, булмаган ди. И ана күңеленең садәлеге! Ә Андрей Солнцев җинаять эше кәгазьләрен укып белә: Анатолийның кара эзләре шактый тирән уелган. Аларны ана күз яше белән генә юып булмаячак. Шулай да прокурор аның сүзен бүлдерми.

Анатолий Бусарев Казанда туып-үскән, җиденче классны тәмамлаган, һөнәр училищесында да укып йөргән. Бер автохуҗалыкта машиналар ремонтлаучы слесарь булып та эшләгән. Әнисе ул көннәрне сагынгандай искә төшерә.

Шулай да Бусаревлар капкасын милиция шакырга мәҗбүр була. Каян килеп диген әле — Куйбышев районыннан. Өйдә тентү үткәрәләр. Монысы инде өйдәгеләрнең башы өстендә аяз күктә ялтыраган яшен төсле тәэсир итә.

— Шунда гына күзләрем ачылды, иптәш прокурор. Сукыр булып яшәгәнмен икән, дөм сукыр булып!.. Уйлыйм-уйлыйм да аптырап калам: безнең улларыбызны кем юлдан яздыра шулай?.. Нигә эндәшмисез, иптәш прокурор?..

Тикшерү эше тәгәлләнмәгән. Ачыкланасы нәрсәләр байтак.

— Нәрсә ачыклап торасың инде аны! Кемдер аздырган аны, начар юлга этәргән.

— Ярый, сезнеңчә дә булсын, ди. Анатолийны кайсыдыр аздырган дип фараз кылыйк, — диде прокурор. — Тик ул үзе моңа ничек караган? Әйтегез әле, тентү вакытында өегездә нәрсәләр табылды, хәтерлисезме?

Солнцев тентү нәтиҗәләрен бик яхшы белсә дә, җавапны җинаятьченең әнисеннән ишетәсе килде. «Минем балам гаепсез», дип килгән бит ул.

Ханым беравык тынып торды — нидер исенә төшерде, ахрысы.

— Хәтерлим, иптәш прокурор, хәтерлим. Ике чалбар таптылар, затлы ике свитер. Аларны милициягә Толя үзе алып бирде.

— Бу әйберләрне кем алып кайтты соң?

— Толя.

— Кайдан, нинди акчага? Монысы сезгә билгелеме?

Хатын дәшми торды.

— Минем улым — әйбәт, башкаларныкы — начар. Сезнеңчә, шулай килеп чыга түгелме?

— Кешедә эшем юк, — диде хатын.

Бусарева урындыктан торды да ишеккә таба китте. Бусагада тукталып, янә сораулы карашын прокурорга төбәде:

— Толяның язмышы ничек хәл ителер?

— Соңгы сүзне һәр вакыт суд әйтә. Анда сезне дә чакырырлар.

Ханым чыгып китте.

Берничә көннән суд булды.

*
* *

Июль — җәйнең иң матур чагы. Бу вакытта Куйбышев районы якларына килүчеләр арта. Идел буе, нарат урманнары, матур табигать кешеләрне магниттай тарта сыман. Шимбә-якшәмбе көннәрендә пристань тирәләре шау-гөр килеп тора.

Шундый иртәләрнең берсендә районның Бурак авылына ике кеше килеп төште. Аларның берсе Сергей Шапкин — шушы авылда туып-үскән егет. Егерме өч яшьлек әзмәвердәй бу кеше Казанда яши, моторлар төзү заводында эшли. Авыл халкы аны бик яхшы белә. Ел саен диярлек бер үк вакытта ялга кайта Сергей. Аның әтисе — совхозда тракторчы, әйбәт исәптә. Әнисе дә эшчән, уңган хатын. Сергей — дүрт баланың өлкәне.

Шапкиннар капкасын ачып кергән кешеләрнең икенчесе авылда берәүгә дә таныш түгел иде. Кулында сумка, аркасына ялтырап торган гитара аскан. Сергейлар өенә ул шулай килеп керде.

Егерме көн тора бу кунак. Шул арада Шапкиннар гаиләсендә үз кеше булып җитә. Гаҗәп тә түгел. Монда аңа беркем сынап карамый, син кем дип төпченми. Сергей чакырып китергән икән—димәк, өлкән Шапкиннар кунакны сыйлаячак. Тәртибе шул инде, кунак төшә — ит пешә, дигәннәр бит борынгылар. Гаилә башы картларның бү сүзенә үзеннән дә өсти: кунак төшәме — куй өстәлеңә тулы шешәне! Хуҗа агайның үз түре башына утырткан кунагының кулларында кытай карасы белән энә чәнчеп яздырган сүзләргә дә исе китмәде. Малае да, дөресен әйткәндә, үзе чакырып китергән кунакны рәтләп белми икән. Аның хакында белгәннәрне яза калгач, нибары берничә юлга сыйган. Прокурор алдында яткан папкада ул кәгазь.

«Май башлары иде. Үзем яши торган йорт подъездында мин Ковалев фамилияле бер егет белән таныштым. Исемен, әтисенең исемен сорамадым, үзе әйтмәде. Безнең арада алай олыдан кубып «фәлән фәләнич» дип сөйләшү юк инде. Аны белгән малайлар барысы да «Соры» дип кенә йөртәләр. Мин дә шулай эндәштем. Ул күптән түгел генә әллә кай яктан кайткан диделәр. Кызыксынып тормадым. Безнең йортта апасы, җизнәсе, әнисе яши. Үзе бер урында да эшләмәде. Аерылмас дуслар булмасак та, вакыт-вакыт очрашкаладык. Кайчагында ул мине кибеткә аракы эчәргә чакыра иде, ләкин аның белән шешәдәш булмадым. Мин отпускага җыенгач, Ковалев та иярде. Гитарасын аркасына асты да юлга чыкты...»

Хәзер инде аның үзе турында башкалар язган бер кәгазьгә — ул эшли торган цех начальнигы, партбюро секретаре, профком председателе имзалары белән расланган характеристикага күз салыйк: «Сергей Шапкин — тәҗрибәле электромонтер, үзен яхшы яктан гына күрсәткән эшче. Хезмәтенә намус белән карый, дисциплина бозу очраклары юк. Йөкләмәләрне вакытында һәм төгәл үти. Белемен күтәрергә тырыша, үзлегеннән укый. Иптәшләре арасында абруйлы».

Прокурор шушы ике язманы янәшә куеп беравык уйланып утырды. Сәер хәл: Шапкин белән Соры — бер-беренә һич тә охшамаган кешеләр. Берсе — эшче, икенчесе — җилкуар. Сергей — гаилә башлыгы, куен кесәсендә комсомол билеты йөрткән. Сорының кесәсендә — пычак та аракы шешәсе. Бер-береннән аерылып торган шундый кешеләрнең очрашмый калуы мөмкин идеме? Әлбәттә. Сергей Шапкин уяурак булса, аның ата-анасы кунак егеткә таләпчәнрәк карасалар, хәл икенче төс алыр иде.

Степан Ковалев — яше белән түгел, күргәннәре ягыннан карт чыпчык, аны кибәккә алданыр димә. Шуны раслый торган бер документын янә күздән кичерде прокурор. Монысы Әлки районы халык судының хөкем карары. Аны тыңлаган чакта гаепләнүче Степан Ковалевка нибары унбиш яшь булган.

Самолет Базарлы Матак аэродромына төшә. Казаннан килгән Степан Ковалев самолеттан чыга да, җәяүләп кенә Биктимер авылына таба юнәлә. Юлда аңа бер кеше очрый. Якын-тирәдә бүтән адәм заты күренмәгәч, җинаятьченең күзләре ялт-йолт килә башлый. Ул, җәһәт кенә борылып, юлчы каршысына баса да:

— Акча бир! — дип боера.

— Булмаса каян алыйм? — ди юлчы, куркып калмый. Ковалев янынннан узып китә. Степан аның аркасына пычак белән кадап берничә җәрәхәт ясарга өлгерә.

Яралы Габделбәревны больницага озаталар.

Җинаятьчене шактый вакыт эзләгәннән соң кулга алалар. Суд аны өч елга хезмәт белән төзәтү урынына җибәрергә карар итә. Балигъ

булмавы аркасында гына котылып кала Ковалев. Өч еллык сынау шарты белән иректә калдыралар. Бер ел да узмый, ул янә хөкем ителә. Суд карарында аның яңа җинаяте болай аңлатыла: «Ике ай буе эшсез йөргән Степан Ковалев, исерек килеш, ачкыч ятратып, «Казаньхимстрой» тресты гаражын ача һәм шуннан М-21 маркалы автомашинага утырып чыга. Казан буйлап төрле урыннарда җилдергәннән соң, автомобильне Ленинград урамында ташлап калдыра...

РСФСР җинаять кодексының 212 статьясы нигезендә, Ковалевны бер елга, Әлки халык суды тарафыннан билгеләнгән җәзаның да өлешен кушып, барлыгы ике елга иректән мәхрүм итәргә».

Бер язучы әйтмешли, бушлай калач ашата торган урында да булып кайта егет. Анда аңа «Соры» кушаматы тагып җибәрәләр. «Эшкә көтәбез, рәхим итегез!», «Заводка төрле белгечләр кирәк», «Яшьләрне һөнәргә өйрәтәбез» дигән игъланнарга күз дә салмый йөри.

*
* *

Сергей Шапкинның ата-анасына кунакка менә шундый шомарган адәм килә. Яңа сауган сөт тә эчә, авыл каймагы да ашый, Актай елгасында коена, көннәр буе кызынып комда ауный. Ял гаҗәеп күңелле уза. Семьядагы төпчек малай — Генаны әйткән дә юк инде — кунак яныннан китми. Кушкан бер йомышын үтәп тора. Казандагы һөнәр училищеларының берсендә укучы бу малай нигәдер Ковалевка ярарга тырыша, хәтта ялагайлана да. Сәбәбен сорасаң, мөгаен, Гена үзенчә аңлатып та бирер иде. Соры — көчле, таза, тәвәккәл егет. Гитара уйнауларын тыңлап утыру —үзе бер рәхәт. Беркайда ишетелмәгән угры җыруларын да әйттерә башласа, авызыңны ачасың да карап торасың инде. Бу яктан артистлык бар Ковалевта. Аннары тагын беренче көнне үк авылның иң усал егетләре белән дуслашты бит ул. Илдус Газиев, Әнвәр Баһаветдинов аның тирәсендә биеп кенә йөриләр. Менә нинди көчле кеше ул Соры...

Сергейның ял вакыты тәгәлләнеп килә. Әнисе хушлашу мәҗлесе үткәрергә уйлый, шуның хәстәренә керешә. Аракы сатып алалар, ашсу әзерлиләр.

Табын уза. Кунакның рәхмәт әйтер көне җитә. Ковалев бу рәхмәтне үзенчә белдерә.

*
* *

Августның унҗидесе. Бурак авылы клубында кино куела. Картинадан соң — бию кичәсе. Соры да шунда, клуб тирәсендә кайнаша. Яшьләр төн уртасында гына таралалар. Инде кайтырга чыкканда, Соры гитарасын аркасына аса да Гена Шапкинга пышылдый:

— Илдус белән Әнвәргә әйт, минем янга килсеннәр!

Гена тегеләрне чакырып китерә.

— Бер эшкә киттек, егетләр,— ди Ковалев, сүз озайтып тормыйча. Егетләрне кибет янына алып килә. Аның артына чыгып, каяндыр тимер табып ала да амбар йозагын каерырга тотына.

Ыңгырашкан шикелле шыгырдап тимер йозак ачыла. Эчкә үтеп, Соры әмер бирә:

— Ну, Гена, әйдә, чум!

Илдус белән Әнвәр урамда күз-колак булырга кала. Соры аларның һәркайсына аракы өләшә. Гена үзе ала — ун шешә әлэктерә, Илдускә — өч, Әнвәргә биш шешә тоттыралар. Чалбар кесәләренә ике шешә тыгып, Соры шундук Валя Авдеева янына йөгерә. Атаманнарыннан

аерылган өч карак, урланган аракыларны алып, Шапкиннарның печәнлегенә менеп ята. Егетләр Сорының кайтканын көтә, ә ул юк та юк. Офыкта таң беленә башлаганда, Илдус белән Әнвәр дә авылларына — Көеккә кайтып китә, ә Гена Сорыны каршыларга бара. Алар урамда очрашалар.

— Әйдә, мәктәпкә киттек!

— Мәктәпкә?!. Ни калган анда безгә?

— Соры әйткәч, калган, димәк. Әйдә!..

Алар мәктәпкә юнәлә. Ковалев тикмәгә генә йөрмәгән икән бу тирәләрдә. Кайсы йозакның ничек ачылганын, кайсы тәрәзәдән нинди бүлмәгә керергә мөмкин булуын — барын да чамалаган. Генага әмер биреп кенә тора. Тегесе үзен сигез ел укыткан, кулына белем таныклыгы тоттырып чыгарган мәктәпне талый. Соры куша, Гена үти. Мәктәп магнитофоны, тагын нииндидер әйберләр Шапкиннар печәнлегенә күчә.

Көннәрен Соры кунак булып, ял итеп кенә уздырмаган икән — кайда ни ятканын караштыргалаган, үз тирәсендә чуалган малай-шалай, егет-җилкенчәкнең йомшак якларын да өйрәнгән. Гена Шапкин— аның өчен борын асты кипмәгән бер малай гына. Генаның кесәсендә өр-яңа паспорт булуын да, комсомол билеты барлыгын да белә Соры. Һөнәр училищесында фрезерчы профессиясе үзләштерүе дә аңа мәгълүм. Кавырсыны ныгып җитмәгән малайны үз ягына аудару өчен, бер стакан «зәмзәм суы» җитә.

Илдус белән Әнвәрне исә Ковалев аракы белән түгел, гитара, җыр ярдәмендә тозакка каптыра. Прокурор бу егетләргә бирелгән характеристикаларны укыган чагында, Соры үз колагына үзе ышанмыйча утырды. «Газиев Илдус, 1957 елда туган, техникумда дүртенче курста укый. ВЛКСМ члены. Техникумга А. Алиш исемендәге совхоз дирекциясе, партия оешмасы рекомендациясе белән килде. Өч курсны яхшы тәмамлады, үрнәк тәртипле булды. Тыйнак, үз-үзен тотышы әйбәт. Җәмәгать эшләрендә катнаша — ике ел рәттән стенгазета редколлегиясенә сайланды. Спорт белән даими һәм актив шөгыльләнә. Казан шәһәре боксчылары ярышында икенче урынны яулады. Укый башлаганнан бирле техникумның тулай торагында яши. Тәртип бозганы юк. Беркайчан да шелтәгә тартылмады. Газиев җинаятьтә катнашты дигән хәбәр барыбызны да бик гаҗәпләндерә...» «Баһаветдинов Әнвәр, 1957 елда туган, милләте татар, ВЛКСМ члены. Техникумда тулаем алганда «3» ле, «4» ле билгеләренә укый, дүртенче курска күчте. Белем алырга зур кызыксыну күрсәтмәсә дә, тәртипле укучы. Сәбәпсез дәрес калдырганы юк. Җәмгыять эшләрендә актив түгел, ләкин кушылганны вакытында үти. Оялчан, аз сүзле, кешеләр белән күп аралашмый, әмма танышлары арасында бигүк тартынучан түгел. Мотоциклчылар түгәрәгендә укыды. Спорт белән шөгыльләнми. Тәртип бозганы өчен, тулай тораktан чыгарылды».

Гена Шапкин гомерләрен намуслы хезмәт белән кичергән ата-анасының исеменә тап төшерүдән чирканмый — кибет басуда катнаша.

Илдус Газиев разрядлы боксчы булуын бөтенләй оныта. Сорының кундәм хезмәтчесенә әверелә. Ә бит аның бер хәрәкәте, бер сүзе җитә иде.

Әнвәр Баһаветдинов та — типсә тимер өзәрдәй егет — яңгырга эләккән көзге чебештәй, каушап кала.

*

* *

Августның унсигезе.

Мәктәп директоры Казакова иртүк магнитофон урлануын белеп ала һәм, акт язып, милициягә бара.

Кибетче Надежда Никитина, кибетнең ачык булуын күргәч, башта үз-үзен шелтәли. «И-и, хәтер диген инде, тавык мие ашаган нәрсә, биклəргə онытканмын лабаса», дип сөйләнә-сөйләнә йозакка үрелә. Аның бите каерылган, тимер өстендә «тырналган» эзләр ялтырап ята. Кибетче шикләнә кала. Амбарда бер әрҗә аракыны тапмагач, тиз генә авыл Советына йөгерә...

Унтугызынчы август таңында «дуслар» шул ук печәнлектә хушлаша. Ә кунак алардан соң да калып, йокысын туйдыра. Төштән соң гына кайту юлына чыга.

Шапкин Сергей: «Сәгать дүртләр тирәсендә эти трактор белән кайтты. Безне утыртып, олы юлга чыгарды. Соры өстендә этинең фуфайкасы иде. Шуны салып биргәндә, кесәләреннән җиде шешә аракы чыкты. Соры берсен ачып эчте, икесен кесәсенә, берсен минем сумкага тыкты. Өч шешәне этигә сузды.

— Кирәкмәс, Соры, — диде эти.

— Кучтәнәч! — диде Соры. Шулай дигәч, эти шешәләрне алды.

Казанга Соры белән бергә кайттык. Гитарасын, гадәтенчә, аркасына аскан иде. Магнитофонны кечкенә генә сумкада алып кайтты...»

Надежда Никитина: «Миңа паромда аракы эчкәннәрен җиткерделәр. Эчүчеләрнең берсе Сергей Шапкин булган. Шуны ишеткәч тә, Сергейның этисе белән сөйләштем. Кибеттән урланган бер әрҗә аракы турында әйттем.

— Шулар кулы уйнамадымы икән? — дип, шигемне дә белдердем. Ул бераз уйланып торды да:

— Сергей ике көннән кайта, сөйләшербез, мин сезгә хәбәр итәрмен, — диде.

Ике көн генә түгел, атналар үтте — Сергей Шапкин кайтмады, этисе күренмәде.»

Кунакны озатканнан соң атна-ун көн үткәч, Казаннан Гена кайта. Никитинага уллары белән сөйләшеп карарга сүз биргән Анатолий Шапкин урланган аракы турында читләтеп тә сорашып карамый. Гена да «разведкага» гына кайткан булса кирәк. Авылда аны ай күрә, кояш ала. Шундук Казанга китә һәм Соры янына йөгерә. Күрәсең, анда «барысы да тыныч» дип хәбәр иткәннәр. Теге «юмартлана» — юанычлы сүз китергән малайга үзе үк мәктәптән урлаган магнитофонны бүләк итә.

Ни өчен Анатолий Шапкин сүзендә тормаган? Соры калдырган кунак күчтәнәче аның да телен бәйләп куйган, күрәсең. Хәвефле хәбәрнең очына чыгарга теләп, кыл да кыймылдатмый ата кеше. Коточкыч ваемсызлык!

Ваемсызлык — бик хәтәр күренеш.

Шапкин кебек ваемсыз-гамьсезләр күләгәсендә караклык та, гаделсезлек тә, алдашу да яши ала. Явызлыкка, кара эшләргә кочакны киң ача ваемсызлык. Зирәк акыллардан берәү әйткән ди бит әнә: «Дошманыңнан курыкма, иң яман чиктә ул сине үтерә генә ала, дустыңнан да курыкма, иң әшәке чиктә аның сиңа хыянәт итүе генә мөмкин; ваемсызлыктан курык — ул үтерми дә, хыянәт тә итми, әмма ваемсызларның сүзсез ризалыгы белән җир йөзендәге бик күп кара эшләр—явызлык, хыянәт, үтерүләр яшәп килә».

Әйе, ваемсызлык — кеше җанының кара сазлыгы ул. Анда гайбәт бакасы да, агулы елан да — кыскасы, төрле хәшәрәтләр үрчергә урын табыла.

Күргәнебезчә, Шапкин ваемсызлыгы, пәрдә сыман урап, каракны саклап тора. Ә шул пәрдә артында Соры яңа җинаятькә әзерләнә.

* * *

Кулларын кесәсенә тыккан килеш ишегалдына сызгырынып йөргән Соры август кичләренең берсендә якыннан гына узып баручы бер танышын күреп ала. Соры аның каршысына килеп баса да, җилкәсенә кулын салып, хәл-әхвәл сораша башлый. Әлеге кеше Казандагы автохуҗалыкларның берсендә слесарь булып эшләүче Бусарев икән — Куйбышев районы прокуроры Андрей Солнцевка киңәшкә килгән хатынның улы. Эштән кайтып кына килеше икән, шулай да кайдадыр бераз «төшереп» өлгергән инде. Ковалев аңа кайсы яктан суктырырга кирәген бик тиз төшенә:

— Хәлең бигүк шәптән түгел, ахрысы, Толя, әйдә безгә кереп чыгыйк,— ди ул.— Минем запас та бар.— Соры, гадәтенчә, күз кыса. Анатолийны җитәкләп диярлек кухняга алып керә. Зур стакан тутырып аракы сала.

— Бер тында эчеп бетерә алсаң, егет син!

Сынатмаска тырыша Анатолий, стаканны әйләндереп каплый. Бераздан, икесе дә кызып җиткәч, күршеләрнең инде телләре телгә йокмый.

— Авылда булганың бармы, Толя? — дип сорый Ковалев.

— Эх, кая инде ул безгә! — ди теле көрмәкләнгән Анатолий. — Син ышанасыңмы, Соры, авылны күрмәгәнемә җиде ел инде.

Ковалев сызгырып куя:

— Фью-ют!.. Син андагы рәхәтлекне күрсәң парин.

— Син йөреп кайттың, ахрысы.

— Шуңа сөйлим дә инде, Толик. Авылда булып кайтырга исәбе юкмы икән бу егетнең дә дим.

— Мин эштә бит, Соры, кем җибәрсен?

— Бер-ике көнгә сорап кит!

Казанда башланган бу сөйләшү, ике көн узгач, Куйбышев районының Көек авылында, Таһир Шәйхаттаров өендә дәвам итә:

Авылга көндез үк килеп төшкән Соры иске дусларыннан Әнвәрне дә, Илдусны да таба алмый. Урам буйлап ачуыннан сүгенә-сүгенә барганда, язмыш аның юлына тагын бер корбанны — Таһирны чыгара. Мәләкәстә эшләүче бу егет тә ялга кайткан икән, теге чакта клубта очрашып та өлгергәннәр. Ковалев «иске танышны» ычкындыра торганнардан түгел инде.

Өйдә Таһир аларны өстәл янына утыртып, самавар китереп куя. Ковалев исә кесәләреннән берничә шешә чыгара.

— Безнең самавар шушы булыр, энекәш. Утсыз кайный, сусыз пешерә торганы.

Шулай итеп, чәйгә чакырылган кунаклар «мәй» чөмерергә керешә. Таһирның әти-әнисе уракта, боларга — аулак өй. Көн буе кәеф-сафа коралар. Кичкә таба Әнвәр белән Илдус та кайтып керә. Мәҗлес караңгы төшкәнче дәвам итә.

Сәрхүшләр төркеме, Таһирлардан чыгып, Илдусларга табан барганда, Ковалев урамның каршы ягында торган, кирпечтән салынган зур кибеткә ишарәли:

— Бу кәнүшнине бераз чистартырга кирәк булыр, егетләр! — ди. — Мин аның эчендә кайда ни ятканын теге чакта ук мыекка урагач идем...

Көек егетләре кибетне талауда катнашудан баш тарталар. Ләкин, кунакның хәтерен саклап, аның бу «эшен» беркемгә дә әйтмәячәкләренә ант итәләр. Антлары да йөзәр грамм белән ныгытыла.

— Без урам аша карап торырбыз, — ди егетләрнең берсе. — Илдуслар коймасы буеннан...

Көек егетләренең намусы уянмый. Авылларын талыйлар бит, югыйсә. Ә боларның ник мыек төге селкенсен. Бөтенесен икешәр стакан аракыга саталар. Авыр-авыр чемоданнар, кабарынкы портфельләр тоткан Соры белән Толя сакта торган дуслары янына киләләр. Ковалев маңгай тирләрен сөртә:

— Кәҗә маем чыга язды, билләһи... Бөтенесе тәртиптә,— дип Илдуска борыла. — Аякка кияргә берәр нәрсә алып чык әле, малай. Минекеләр тәмам туздылар. — Ул босоножкаларын салып койма буена ыргыта.

Газиев өйләреннән бер пар туфли алып чыга.

— Я машина, я матай кирәк, малайлар, — ди Соры. — Ягез, миләрегезне кыймылдатып карагыз әле: кайсы өйдә транспорт бар? Тизрәк уйлагыз!..

— Ат кына алыгыз, — ди Илдус.

Илдус Газиев аңлатмасыннан: «Бишәүләп совхозның ат абзарына юнәлдек. Урамда Соры миңа үз кулындагы портфельне тоттырды. Шәйхаттаров белән Баһаветдинов та берәр чемодан күтәреп бардылар. Бикле капканы ватып, ат абзарына үттек. Бусарев дирбия алды. Таһир ат чыгарды. Бергәләп җиктек тә дилбегәне Толяга тоттырдык. Арбага менеп утыргач, Соры бер чемоданны ачты. Ул коньяк, төрле шәраблар, кыйммәтле консервалар, папирос, сигарет пачкалары белән тулы иде. Бер шешәне алып, Соры безне коньяк белән сыйлый башлады».

Тагын ике-өч сәгатьтән тирә-як авылларында хәбәр тарала:

— Көек кибетен басканнар!..

Райподан килеп җиткән ревизорлар кибеттә 2.332 сумлык товар җитмәвен исәпләп чыгара. Абдулла Алиш исемендәге совхоз, прокуратурага мөрәҗәгать итеп, югалган арба, ат өчен дәгъва кузгата.

Тикшерү башлана. Юрама өстенә юрама туып кына тора. Шикнең берсен ачыкларга өлгермиләр, шыксыз кара күләгә булып, икенчесе каршыга баса. Күпләргә шик төшә. Тикшерми калырга ярамый, ә тикшерү — кемнәрдәндер сорашу, төпченү, эзләнү ул. Казандагы «Урак һәм чүкеч» заводыннан килгән шофер белән сөйләшү була. Кибетченең иреннән шикләнәләр. Донбасстан кайткан кунаклар, читтән килеп эшләүче төзүчеләр, шоферлар — барысы да бик нечкәләп тикшерелә. «Урлашуда катнашмаганмы? Караклар турында белмиме?» Җинаять йомгагының тотыныр очы булмагач, эзләү озакка сузыла.

Көек авылы бу вакыйганы авыр кичерә. Гомердә булмаган хәл бит! Ә җинаятьченең кем булуын белүчеләр Сорыга биргән антларын истә нык тота. Җинаятьчеләрнең икесе Казанга шыла, берсе — Мәләкәскә, Илдус белән Таһир тел чишми, алар үзләрен гаепле итеп күрми.

Әнвәр Баһаветдинов: «Без урлашуда катнашмадык. Урланган әйберләрдән дә берни алмадык. Алар бөтенесен дә үзләре белән алып китте».

Таһир Шәйхаттаров: «Бергәләп коньяк эчтек. Ничә шешә булгандыр — әйтә алмыйм. Исерек булганмын. Эчкәннән тыш, Соры безгә тагын яртышар коньяк калдырды, шунысын хәтерлим...»

Көек егетләренең өчесе дә, сакта торып, җинаятьтә катнаша. Закон шулай карый. Җинаять турында тиешле урынга хәбәр итмичә, алар үзләренең гаепләрен тагын да арттыралар.

Ил законнарыннан тыш, авыл халкы үз күңелендә саклаган, борын-борыннан күчеп килә торган изге тәртип-йолалар бар. Көектә — намус, вөҗдан, тыйнаклык барыннан да өстен куела. Бу авыл илгә соклангыч батырлык күрсәткән кешене — Абдулла Алишны биргән. Аның тыйнаклыгы, батырлыгы белән бөтен авыл горурлана. Өч егет шушы авыл битенә кара яга. Көек халкы җинаятькә шулай карый.

Ниһаять, тикшерүчеләр Соры ташлап киткән босоножкаларны табып ала. Шул аяк киеме һәм кибет идәненнән кырып алынган балчык кантарлары экспертизага җибәрелә. «Кибеттә шушы босоножканы кигән кеше булган» — экспертиза нәтиҗәсе шундый. Милиция инде шул кешене эзли.

Өч егет Соры турында бер сүз дә ычкындырмый. Ә Ковалев үз эшендә. Көек кибетен талап киткәннән соң ай ярым узгач, Казан урамнарының берсендә берәүгә пычак белән кадый. Гадәттәгечә, исерек була. РСФСР җинаять кодексының 108 статьясында күрсәтелгән җинаять. Җәзадан курыккан Соры качып-посып яши башлый.

Тагын өч атна уза. Степан Ковалев нәүбәттәге корбаны итеп Үсмер Усмановны сайлый. Сорының йомышларын үтәп йөри-йөри, бу малай укуын ташлый, эчәргә-тартырга өйрәнә, кечкенә «бүре» булып китә. Көннәрнең берендә Ковалев аңа «эш» куша: квартира таларга. Милиция аларны шул кара шөгыльләре вакытында эләктереп ала. Соры, гадәтенчә, бөтен гаепне Усманов өстенә өяргә маташа. Үзе җиңел генә котылмакчы. Бу вакытта инде Куйбышев район милициясе аны кибет басучы карак буларак кына түгел, өч тапкыр урлашкан җинаятьче итеп эзәрлекли иде. Кешегә пычак белән кадаган Сорының Казанда Ленин районы халык судында да җинаять эше ябылмаган була әле. Шулай итеп, Степан Ковалевның кара гамәлләре барысы бергә җыйналды. Үзе сак астында, судта утыра.

*
* *

— Гаепләнүче Ковалев!
Ул торып басты, судьяга карап, аның ни әйтүен көтеп калды.
— Кузгатылган җинаять эше хакында ни әйтәсез?
— Гаебемне таный алмыйм, гражданин судья. Булмаган нәрсәне ничек икърар итәсең? Бурак авылындагы урлашуларны Илдус белән Әнвәр оештырды. Көек кибетен дә алар Таһир белән бергә таладылар...
Җинаятьченең бу сүзләрен ишеткәч, прокурор аңа төбәлебрәк карады. Юк, ул үзен тыныч тотарга тырыша.
— Гаепләнүче Ковалевка сорау бирергә рөхсәт итегез, — дип мөрәҗәгать итте прокурор судка. Ризалык алгач, алдындагы кәгазьгә күз салды.
— Сез сөйләгәннәрнең барысы да дөресме, Ковалев?
— Шикләнмәгез, дөп-дөрес, гражданин прокурор.
— Алай булгач, мәнә бу хатны ничек аңларга соң? — Солнцев кәгазьне алып, судтагы кешеләр күрсен өчен, күтәрә төште.
— Нинди хат? — Ковалев сискәнеп куйды.
— Бу сезнең кул белән язылганмы? — дип, прокурор кәгазьне аңа якынайтып күрсәтте.
— Я, минеке дә булсын, ди... — Ковалевның уттай янган күзләре алдагы гаепләнүчеләр эскәмиясенә текәлде. Анда Газиев, Баһаветдинов, Шәйхаттаровлар утыра иде.
— Сез «Илдус, Әнвәр, Таһир, Гена» дип башланган бу хатыгызда үзегезнең башлык булуыгызны күрсәткәнсез.
— Кайда ул «мин башлык» дигән сүз? — «Соры» тагы аягүрә басты.
— Дөрес, андый сүз юк, — прокурор гаепләнүче белән килеште. — Ләкин башкалары бар.
— Нәрсә бар?
— Судка килгәндә һәммәсенә иллешәр сум акча китерергә боердыгызмы?

— Илле түгел, гражданин прокурор, кырык.

— Үтәмәсәләр, барыгызны да «төрмәгә утыртам» дип янадыгызмы? Әллә укып күрсәтимме?

Бу юлы җинаятьчедән җавап булмады.

— Акча бирсәләр, бөтен гаепне үз өстегезгә алырга булдыгызмы? — Җавап ишетелмәгәч, прокурор үзе үк өстәде. — Әйе, нәкъ шулай язгансыз. Гади хат түгел бу, башлык хаты, үзенә күрә боерыгы да, инструкциясе дә бар.

Гаепләнүчеләрнең башкалары бер-берсенә карашып алдылар. Берсе дә бу хатны белми иде, чөнки аларга ирешкән нәрсә түгел. Прокурор Солнцев та хатның ничек прокуратурага эләгүен әйтмәде. Аны милиционерлар төзегән акт белән милиция начальнигы майор Ибраһимов тапшырган иде. Хат кулга алынган Ковалевны тентегәндә фуфайка эченнән табылган.

Ковалев ничек кенә боргаланмасын, җинаять йомгагы тиешенчә сүтелде. Сорының да, башкаларның да гаебе, гөнаһлары мыскалынача төгәл ачыкланды. Барлык җинаятьчеләр дә тиешле җәзаны алды.

Судья хөкем карарын укыганда, прокурор Солнцев залдагы кешеләргә күз салды. Мария Бусарева шаһитлар арасында утыра иде. Аның башы түбән иелгән. Улының язмышын да, аны кемнәр «юлдан яздыруын» да белде ул хәзер. Үз кулындагы тәрбия тезгенен кайда йомшартуын да абайлагандыр, ихтимал. Хәсрәт тә, өмет тә бар ана йөзендә. Бәлки улы Анатолий бозык юлдан читләшер, кеше булып кайтыр. Шулай булсын дип хөкем итәләр ләбаса...

Андрей Солнцев үзенең гаепләү сүзендә җинаятьчеләр эше турында гына түгел, ваемсызлык һәм гамьсезлек хакында да сөйләде. Бер философ әйткәнчә, кешелек дөньясының начарлыгы кайберәүләрнең әшәкелегеннән генә түгел, бәлки мәкер алдында йомшаклык күрсәтүчеләр булганлыктан да килеп чыга. Төптәнрәк уйласаң, дөньядагы бөтен җәбер-золым һәм җинаять кемнәрнеңдер сүзсез тамаша кылып торуы аркасында эшләнә бит.

# ҺЕНРИХ ҺЕЙНЕ ШИГЫРЬЛӘРЕ

## Килеп кенә җитсен

Яшен булып янып суга алам,
Бу — кулыннан килми кемнең дә,
Дип ялгыша алар! Оран салам,
Сөйли алам Зевс телендә.

Килеп кенә җитсен кирәкле көн,—
Кисәтәм мин алдан үзләрен,—
Көчле күкрәү булып гөрләр өнем,
Яшен булып сугар сүзләрем.

Бөек давыл купкан бу сәгатьтә
Йомычкага ярылыр имәннәр,
Иске дивар килер һәлакәткә,
Хәрабәләр җиргә иңәрләр.

## Миннезингерлар[1]

Юлга чыкты иртә таңда
Миннезингерлар торып.
Ярыш башларлар калада,
Бер гаҗәп мәйдан корып.

Хыял алар янында гел,
Ул — толпар, очар, атлан.
Кылыч хезмәтен үтәр тел,
Ә сәнгать булыр калкан!

Ханымнар балконга чыгар...
Ярын күрмәсә анда
Ямансу булыр җырчыга,
Бик моңсу булыр җанга.

Егет сынашка чыкканда
Көч уйный беләгендә.

[1] Урта гасырларда герман илләрендәге рыцарьлар мәхәббәтенә дан җырлаучы шагыйрьләр.

Ә жырчы мәйдан тотканда
Кан саркый йөрәгендә.

Кемнең жыры ал кан төсле
Йөрәктән агып килер,
Тик шуңа сылу, хуш исле
Чәчәкләр таҗын бирер.

●

Мин ышанмыйм фәләккә,
Тәуратына яки Инҗиленә,—
Мин ышанам фәкать күзләреңә,
Тик алардан миңа якты иңә.

Мин ышанмыйм тәңрегә,
Кирәк түгел аның вәхыйләре,—
Мин ышанам синең йөрәгеңә,
Тик син генә минем өчен тәңре.

Мин ышанмыйм явыз рухка,
Җәһәннәмдә — утта көйрәвемә,—
Мин ышанам фәкать күзләреңә,
Мәрхәмәтсез, усал йөрәгеңә.

●

Гүзәл, әйт, яшермә бер дә,
Син хыял бит, пәри зат,
Бөркү, эссе җәйге көндә
Бер шагыйрь иткән иҗат?

Хәер, юк, мондый иреннәр,
Бу тылсымлы күзләрне,
Тудыралмый шагыйрь ирләр,
Көчсез шагыйрь сүзләре.

Коточкыч юха, аждаһа,
Төрле албасты, кәлтә
Сурәтләрен тудыра ала
Шагыйрьләр шигъриаттә.

Ә синең фәрештә сынлы,
Ялган астыртын бәндә,
Ике йөзле сурәтеңне
Ясый алмый берәү дә.

●

Телләрендә гайбәт ни чаклы!
Зәвыксыз бит буш җаннар:
Шуңа сиңа кушаматны
Әхлаксыз дип кушканнар.

Телләрендә гайбәт ни чаклы!
Аңлаучылар юк кына:
Иреннәрең нинди татлы,
Үбүләрең ут кына.

●

Егет бер кызны ярата,
Ә кызый ятны сөя.
Ят егет бу кызны түгел,
Бүтәнне «ярым» дия.

Шуннан кыз башка берәүгә
Тота да иргә чыга,
Ә сөйгән егет уфтана,
Гомергә газап чигә.

Бу һич яңа тарих түгел,
Гел кабатланган язмыш.
Тик сезгә дә җиңел булмас,
Тап булса мондый сагыш.

●

Белә калса әгәр йөрәгемдә
Авыр яра барын чәчәкләр,
Юатырга теләп, шунда бергә
Минем белән яшь түгәчәкләр.

Сандугачлар әгәр белсә иде
Газапларда янган-көйгәнне,—
Юатырлар иде сайрап мине,
Яңгырап торыр иде көйләре.

Йолдызлар да төшәр иде күктән—
Белсә кара бәхтем турында,—
Юатыр һәм юар иде түккән
Ярам канын саф яшь нурында.

Ничек белсен алар хәсрәтемне?
Белә ялгыз сылу яр гына:
Йөрәгемә нәкъ ул үзе инде —
Төзәлмәслек яра салды да!

●

Торбаларда уенчылар уйнап,

Барабан бәрәләр.
Бу бит минем кәләшемне туйлап
Киявгә бирәләр.

Оркестрда контрабас аһ орa,
Литавралар чыңлый.
Моңнарыңда безнең кайгыбызга
Фәрештәләр елый.

## Кандала

1

Бер кандала, басып бакыр акчага,
Банкир сыман болай диеп мактана:
«Әгәр акчаң булса, ди, капчык-капчык,—
Кая гына барма сиңа юл ачык.
Акчаң бар — син ирнең менә дигәне,
Гаҗәп гүзәл хатыннарның сөйгәне.
Ханымнарның тәмам китәрә исен
Бәреп керсә борыннарга хуш исем.
Королева белән дә ятканым бар,
Аның куенында да тәм тапканым бар:
Җылы түшәктә ул тәмам шашынды —
Бер туктамый төне буе кашынды».

Бу сүзләрне ишетте шаян чыпчык,
Туктасын, диде, кандала мактанчык:
Ул томшыгын кайрап, ачы өздереп,
Мыскыл итеп бер җибәрде сызгырып.
Ә кандала, кабих, үзенчә итте,
Үч алды сасы ис бөркеп һәм әйтте:
«Бу мыскыллауга болай тап килгәнем
Бары шуннан гына — акча бирмәдем».

2

Кандалалар, кая гына карама,
Изге берләшмәләр төзгән үзара.
Начар романслар язучылар да
Төрле альянслар төзгән шуларча.
(Алар шундый талантсызлар, буш миләр,
Шлизинглер сәгате күк — йөрмиләр).
Бар үз Моцартлары — эстет-кандала,
Аның кандалаларча манер белән,
Мактау лавры алган Мейербер белән
Интригасы инде ничә ел бара!
Ә бөҗәктән тагын нәрсә көтәсең?
Гәҗит бете яза рецензиясен.
Ә гәҗиткә үтә бары да, ялган да,
И шатлана бет гонорар алганда,
Тик кылана, имеш, уйчан карашлы.

Бигрәк рәнҗетәләр күк, карачы,
Ди публика, ышанып та кызганып,
Йөрәкләре авырта, дип, сызланып.
Болай булгач түзми хәл юк ялага.
Шаулама, карышма — ул бит кандала.
Сытып карарга иде дә үзен бер,
Чынын әйткәндә кагылмавың хәер.
Юкса андыйны сытып кына кара:
Сасы исен җәер бөтен дөньяга!
Менә шуңа күрә башка бер вакыт
Мәкаль серен бирермен бер аңлатып.

**НУРИ АРСЛАНОВ** тәрҗемәләре

# 1979 ЕЛ—ХАЛЫКАРА БАЛАЛАР ЕЛЫ

*Мәгълүм булганча, Берләшкән Милләтләр Оешмасы 1979 елны балалар елы дип игълан итте. Журналның бу санындагы кайбер язмалар дөньякүләм әһәмиятле шушы вакыйгага багышлана. СССР Педагогия фәннәре академигы Мирза Мәхмүтов белән үткәрелгән әңгәмәбездә дә сүз — балалар хакында.*

**Мирза Мәхмүтов**

*СССР Педагогия фәннәре академиясенең профессиональ-техник педагогика фәнни-тикшеренү институты директоры, академик.*

## САБЫЙЛАРНЫҢ БӘХЕТЕ ХАКЫНА

**Сорау.** Тулы бер елның дөнья күләмендә балаларга багышлануы, сезнеңчә, кай яклары белән мөһим?

**Җавап.** Берләшкән Милләтләр Оешмасы соңгы вакытларда елларны аерым бер мәсьәләгә багышлый торган булып китте. Тарихи истәлекләрне барлау, табигатьне саклау, хатын-кызлар өчен аерым еллар билгеләнде. Димәк, кешелекнең алга таба үсешендә әнә шул мәсьәләләргә аеруча игътибар таләп ителә.

Мондый игъланнарга карата кешелекнең быелгыча игътибарын, актив катнашуын хәтерләмим мин. Ел балаларныкы дип әйтелүгә, бөтендөнья җәмәгатьчелеге йокысыннан уянгандай булды. Газета-журналларда берсеннән-берсе үтемлерәк хәбәрләр чыга, радио-телевидение һәр көнне махсус тапшырулар бирә, бик абруйлы политик эшлеклеләрнең чыгышлары оештырыла.

Мәсьәләнең гаять җитди төс алуы табигый, чөнки җир йөзендә артык чыдап тора алмаслык аяныч хәлдә яшәүче балалар бар. Аларны ачлык, ялангачлык, наданлык газаплый. Кешелекнең киләчәге булган газиз җаннар кайбер илләрдә бүген шундый фаҗига кичерә икән, дөнья җәмәгатьчелеге моңа, әлбәттә, тыныч карый алмый.

Балаларга тиешле тәрбия таләп итеп чаң сугарлык хәлләр — капиталистик дөньяга хас күренеш. Әмма без дә, ягъни үзара дус яшәүче социалистик илләр вәкилләре дә, нарасыйлар фаҗигасенә битараф калмаска, бу җинаятькә карата үз фикеребезне ачыктан-ачык әйтергә тиешбез. Миңа калса, фән һәм техника бүгенгедәй алга киткән көннәрдә балаларны бер телем ипигә тилмертү — акылга сыймастай вәхшилек.

Бу турыда уйлана башласам, минем күз алдына иң әүвәл Бразилиядәге сабыйларның көнкүреше килеп баса. Монда миллионнан артык бала бөтенләй күзәтүчесез яши. Кайда ул аларга дигән ясленләр, бакчалар, мәктәпләр?! Аларның кунар җирләре дә юк. Өйләреннән чыгып киткәннәр дә ничек җитте шулай яши бирәләр. Алар хәтта әтиәни, әби-баба нәсихәтен ишетүдән дә мәхрүм. Көн туганда, башыннан сыйпап: «Гор, балам!» — диюче кешеләре дә юк аларның. Тау куышы табалармы, ташландык каралты-кура очраталармы, куерак тәлгәшле агач төбенә туры киләләрме — шунда төн уздыралар, иртән исә аларны шул ук кичәге кайгы көтә — тамакны ничек туйдырырга?

Соңгы елларда Бразилиядә миграция бик көчәйде. Кешеләр, ачтан үлмәс өчен, туган-үскән җирләрен ташлап, шәһәрләргә килә. Әйтерсең лә аларны шәһәрдә кочак җәеп каршы алучы бар?!

1970 елда, Чилига барышлый, Бразилиянең Сан-Паулу шәһәрендә самолетыбыз тукталыш ясаган иде. Төшкәндә дә, күтәрелеп киткәндә дә самолет шәһәр өстеннән урап бик озак очты. Түбәннән генә. Контрастны күреп хәйран калдык. Матур гына шәһәрнең чит-читләре коточкыч ямьсез хәерче алачыклары белән чуарланган. Йөзләрчә, меңнәрчә алачыклар... Авыллардан җыелган крестьяннар, кунар урын таба алмый интеккәч, шәһәр читендә үзләренә шундый куышлар кораштырганнар.

Хәзер Сан-Паулудагы кешеләр саны ун миллионга җитә дип хәбәр итәләр. Бу турыда ишеткән саен, йөрәк кысылып куя: кайсы агач төбенә барып сыеналар икән ул бичаралар?!

Кызганычка каршы, капиталистик дөньяда мондый илләр байтак. Иң зур кыенлыгы балалар язмышына киртә булып төшә торган миграция Мисырда да бик көчле. Әле кайчан гына Каһирәнең халык саны ике миллион исәпләнә иде. Хәзер анда җиде миллион кеше яши диләр. Аларның шактый өлеше — ач-ялангач балалар бит. Мисырдагы ярлы ата-аналар үз балаларының кай тарафта, ни белән шөгыльләнүен дә белми. Аягына басарлык хәле булган бала урамга чыгып китә дә, үз язмышына үзе хуҗа булып, тик йөри. Ничек туена, кайда йоклый, гомумән, исән-саумы ул—гаиләсендә моны белмиләр дә. Сәадатның дуамал политикасы илне, сабыйларның язмышын әнә нәрсәгә китереп җиткерде.

Аяусыз бер хакыйкать бар — адәм баласы белән болай ваемсыз шаяру чик-чамасыз була алмый. Моны без Ирандагы вакыйгалардан да күреп тордык. Мин 1972 елда Иранга барып кайткан идем. Тәһран келәм туку остаханәләрендәге күренешләрне ачык хәтерлим. Келәмнәренең гүзәллегеннән күзләр чагылырлык. Ул төсләре, ул нәкышләре, ул ныклыгы — келәмнәр өч йөз елга кадәр үзгәрми саклана ала икән! Үзләре җип-җиңел, очып тора, үзләре шул кадәр тыгыз тукылган, төеннәре арасына энә дә керми. Келәмнәрне мин соңыннан шәһәр урамнарына чыгарып салынган килеш тә күргәләдем. Тукучылар аны юлга чыгарып җәяләр: узган-барган таптап үтсә, келәм тагын да ныграк була, ә өстендәге эзләрне соңыннан кагып кына төшерәләр икән. Икенчедән, урамга җәелгән келәмгә кызыгучы, сатып алырга теләүче дә табылуы ихтимал. Бик кыйммәткә төшкән бу затлы товарны алырдай кеше сирәк.

Әмма безне иң гаҗәпләндергәне болар гына түгел иде. Ерак илләрдән килгән бай сәяхәтчеләргә тәкъдим ителә торган асыл мал җитештерүче осталар арасында сигез-ун яшьлек балалар күреп шаккаттык. Кулларыннан гөл түгелә — үзләре ач, карашларында моң, сагыш...

Быел, телевизор тапшыруларын караганда, Иран шаһын бәреп төшерүче революционерлар арасында меңнәрчә яшүсмерләрне күреп, мин кабат әнә шул келәм тукучы меңләгән балаларны искә төшердем. Алар инде үсеп җиткәннәрдер, күңелләренә кечкенәдән җыелып килгән ачуларына чыдаша алмыйча, демонстрантларга кушылганнардыр. Сабый чактагы кимсетелүләр йөрәккә, ай-һай, тирән уелучан бит ул. Иран яшьләренә, әнә, тулып-ташыган ачуларын эшкә җигү өчен, дини өндәмәләр дә ярап куйды...

**Сорау.** Балалар елы уңаеннан безнең ил балалары турында да берничә сүз әйтсәгез икән.

**Җавап.** Һәрнәрсә тарихи яктан чагыштырып караганда яхшырак аңлашыла. Россиянең егерменче гасыр башларындагы хәленә күз салсак, андагы балалар хәле сөйләп узган илләрдәге фаҗигадән аерып алгысыз. Бөек Октябрь революциясеннән соң, күзәтүчесез калган балаларны дәүләт карамагына алу — минемчә, Октябрь казанышларының бик әһәмиятлесе. Егерменче еллардагы фоторәсемнәргә карасаң, ышана алмый торасың: курчак кадәр генә балаларның аягында чабата, өстендә сәләмә сырма, башында колакчыны өзелгән бүрек. Ун-унике яшьлек малай сука сукалый, кыз балалар урак ура, киндер суга, җеп эрли — барысы да эштә, башка чара юк.

Белем ягына килсәң, хәл тагын да аянычрак. Статистика 1917 елда Россиянең 70 процент халкы надан булган дип белдерә. Ул елларны чагылдырган сәнгать әсәрләренә, әдәбиятка мөрәҗәгать итсәң дә, балалар язмышындагы коточкыч каршылыкларны күрергә мөмкин. Татар балаларының хәле Тукай иҗатында аеруча ачык тасвирлана. Мәшһүр шагыйрь әсәрләренең буеннан-буена мең төрле кыерсытылулар белән биртелгән бичара татар баласының яктыга, аң-белемгә, ирекко-азатлыкка омтылышы сурәтләнә.

Педагог буларак, миңа Тукай иҗаты сабыйларга белем бирү кирәклеген алга сөрүе һәм, гомумән, тәрбия-педагогикага гаҗәеп игътибарлы булуы ягыннан кадерле һәм кыйммәт.

...Яз, газиз углым, кара тактаны сыз акбур белән!
Һәм кара көнлеңне ялт иттер сызып ак нур белән!
Өч наданга алмашынмас бер язу белгән кеше,
Мәгърифәт эстәр, иренмәс һич кеше булган кеше.

Бәхеткә каршы, безнең иң халыкчан әдипләребез мәгърифәт яктысын армый-талмый таратканнар. Иң борынгы төрки язмаларда да педагогик кыйммәте мең алтынга алыштыргысыз юллар бар. Әмма ул өйрәтмәләрне тормышка ашырырга, халыкка иңдерергә мөмкинлекләр җитмәгән — иҗтимагый шартлар бөтенләй башка булган.

Хәтта совет власте урнашып, наданлыкка каршы гомум көрәш башлангач та илдәге уку-укыту эшләрен җайга салып җибәрү ифрат кыен шартларда барган. Без бары тик 1930 нчы елда гына дүрт еллык гомуми мәҗбүри уку турында закон кабул итә алдык. Кайбер капиталистик илләр мондый законны алтмыш-җитмеш ел элек тормышка ашырганнар иде инде: Япония, Англия, Франция...

Тарих өчен 50—60 ел вакыт — бик кечкенә нәрсә. Әгәр дә без илнең бүгенге һәм моннан 50—60 ел элек яшәгән балаларын, аларның яшәү шартларын рәттән куеп, чагыштырып карый алсак, гаҗәпләнүдән аптырап калыр идек. Җир белән күк аермасы кебек. Бу бит — пропаганда өчен генә әйтелә торган сүзләр түгел, хакыйкать бит бу!

1979 ЕЛ — ХАЛЫКАРА БАЛАЛАР ЕЛЫ

Җир шарындагы бер генә илдә дә СССР балалары кебек рәхәт яшәүче балалар юк. Моны бөтен дөнья белә, таный, кызыга, көнләшә!

Сорау. Әлеге гыйбарәгезне дәлилләр белән дә баетып, бу хакта киңрәк сөйләмәссезме?

Җавап. Рәхим итегез! Безнең илдәге балаларга, яшүсмерләргә күрсәтелгән кайгыртучанлык, материаль чыгымнар турында, шагыйрь Сибгат Хәким әйтмешли, «барлык-барлык парламентларда» горурланып сөйләргә була. Бездә балалар турындагы кайгыртучанлык алар дөньяга килгәнче үк башлана. Әни булырга җыенган хатын-кызларыбыз өчен законлаштырылган җиңеллекләрне истә тотам мин. Инде бала туган икән, аңа шул минуттан ук санап бетергесез уңай шартлар булдырыла.

Әйтик, безнең балаларның 17 миллионы яслеләрдә һәм бакчаларда тәрбияләнә. Соңгы елларда салынган бакчаларның ниндилеген белсәгез иде! Еракка китмичә, үз Татарстаныбызның Чаллы шәһәрендәге бакчаларын гына алыйк. Бассейннары, кышкы гөлбакчалары, спорт заллары бар. Йокы бүлмәләрен, музыка салоннарын, күңел ачу мәйданнарын әйтеп тә тормыйм. Андый тәрбия йортлары, әбиләр әйтмешли, патша балаларына да эләкмәгәндер, мөгаен. Бала караучы кызлар — ап-ак халаттан, ак калфактан гына йөри. Алары да чибәр, сәламәт, укымышлы — совет чынбарлыгында укып өлгергән тәрбиячеләр.

Әле 30—40 ел элек безнең андый тәрбиячеләребез дә юк иде. Болар бөтенләй башка, әйбәт шартларда, дөрес тәрбия алып үскән белгечләр. Аларга авырлыклар тимәгән инде, алар өс-баш, ашарга җитмәүне сизмәгәннәр. Матур киенеп, тәмле ашап, спорт белән шөгыльләнеп үскәннәр. Һәр яклап мөкәммәл алар. Без, ниһаять, әнә шундый кадрлар үстереп җиткердек. Ниһаять, дим... Безгә бит сугышлар бик нык комачаулады. Соңгы сугыш, минемчә, мәгариф өлкәсендәге эшләребезне егерме-утыз елга артка чигендерде.

Шулай да без җиңдек. Октябрь куйган максатка ирештек без! Хәзер бездә ун еллык гомуми мәҗбүри уку законлаштырылган. Бу—зур җиңү! Безнең 44 миллион бала — мәктәпләрдә, 5 миллион яшүсмер — техникумнарда, 3,5 миллионы профессиональ-техник училищеларда укый, 5 миллион студентыбыз бар.

Кыскасы, безнең җәмгыять 60 миллионга якын кешене, бернинди эш эшләтмичә, бары тик киләчәк өчен генә әзерли — укыта, өйрәтә, һөнәрле итә. Барысы да бушлай. Стипендияләр бирелә, тулай тораклар салына, тагын әллә нинди җиңеллекләр ясала. Кайда, кайчан, кайсы патшалыкта балаларга мондый шартлар булган? Юк. Беркайчан да, беркайда да күренгән хәл түгел бу!

Сорау. Тәрбия өлкәсендә Татарстанда башкарылган кайбер яңалыкларга тукталсагыз иде!

Җавап. Хәтта Татарстандагыларны гына да санап бетерү мөмкин түгел. Хәзер колхозларда музыка мәктәпләре, хореография, сәнгать мәктәпләре ачыла. Җәен пионер лагерьлары эшли. Күбесе бөтенләй бушлай. Мәктәпләрдә бушлай ашатулар кертелә.

Илдә ике йөз педагогия институты бар. Ел саен меңнәрчә югары белемле педагоглар безнең мәктәпләргә дә кайтып тора.

Казанда педагогия буенча махсус фәнни-тикшеренү институты ачылу да — Татарстан өчен зур яңалык. СССР Педагогия фәннәре академиясендә мондый институт бердәнбер. Институтыбыз зур, аның йөз илле хезмәткәре, унике лабораториясе бар. Аспирантурага яшь көчләрне күпләп кабул итәчәкбез. Чөнки бу институт ифрат катлаулы, бик кирәкле, тормышчан проблемаларны фәнни яктан өйрәнә.

Бездә хәзер урта белем бирә торган профессиональ-техник училищелар барлыкка килде. Димәк, эшчеләр сыйныфы урта белемле булуга

йөз тота. Шунсыз булмый. Производство үзгәрде, катлауланды, эшчедән белем таләп итә ул. Яшүсмер урта белемне училищеда ук алып чыга икән, аңа әхлак тәрбиясен дә шунда ук бирергә кирәк була. Училищелардагы эш комплекслап: эстетик, әхлакый, хезмәт, идея-политик тәрбия төсендә төрле яклап алып барылырга тиеш. 1980 нче елга илдәге училищеларның 80 проценты заман таләп иткән, урта белем бирә торган программага күчәчәк.

Училищелар, гаҗәеп сизгер, катлаулы механизмнарга нигезләп корылган бүгенге производство ихтыяҗларын күздә тотып, яшүсмерләрдән югары квалификацияле, киң профильле осталар әлгертергә тиеш. Безнең фәнни-тикшеренү институты исә алдынгы тәҗрибәне өйрәнергә һәм, фәнни нәтиҗәләр ясап, практикларны коралландырырга бурычлы.

Яңа салынган гигант заводларда ике-өч айлык курсларда гына укып чыккан кешене эшләтү — зур гөнаһ, дияр идем мин. Квалификациясез эшче зур әзерлекле һөнәр иясе генә «тыңлата» алырдай автомат линияләрне, кыйммәтле станокларны күз ачып йомганчы ватып-сындырып бетерәчәк. Дәүләт, халык милкенә күпме зыян! Безнең институт эшчәнлеге бүген-иртәгә эшче булачак яшүсмерләрне дөрес тәрбияләү, әнә кайларга барып тоташа ул!

**Сорау.** Безнең илдә балалар тәрбияләүгә зур игътибар бирелү, күп чыгымнар тотылу — бәхәссез. Моны безнең иң явыз дошманнар да таный. Тәрбия эшләренең нәтиҗәсе канәгатьләнерлекме соң? Бүгенгедәй рәхәт шартларда, уйнап-көлеп кенә үскән сабый балалардан җәмгыятьнең өметләрен aклардай намуслы кешеләр үсеп җитәрме?

**Җавап.** Бу сорауның төбендә безнең тәрбия эшләрендәге кайбер кимчелекләргә ишарә сизелә. Әмма мин иң алдан, һичнинди икеләнүләргә урын калдырмыйча, өзеп шуны әйтергә тиешмен — безнең чынбарлыкта, безнең тәрбияне алып үскән балаларның иң зур күпчелеге, һичшиксез, илнең иң ышанычлы таянычы булып җитешә. БАМнар, КамАЗлар, «Атоммаш»лар алар җилкәсендә калка. Мин, бу сүзләремә дәлилгә Татарстан мәктәп һәм вузларында белем алып, үсеп җиткән йөзләрчә, меңнәрчә белгечләрне санап китәр идем. Алар арасында дөньякүләм дан яулаганнары да күп. Фатих Әмирханның «Гарәфә кич төшемдә» хикәясендә хыялланып телгә алынган «укучы, студент, профессор, артистка, уйлап табучы, электрик, адвокат, инженер-архитектор» кебек һөнәр ияләре инде бик күптән гадәти күренешкә әйләнделәр. Безнең хәзер атом серләрен ачучы физик-академикларыбыз, мәшһүр геологларыбыз, Арктиканы иңләүче кыю диңгезчеләребез, астрономнарыбыз, тагын әллә нинди сирәк очрый торган һөнәрләргә ия уңганнарыбыз бар, татарлар. Совет Татарстанында тәрбияләнгән кешеләр!

Шулай да без тынычлана алмыйбыз, без әле һаман канәгать түгел. Чөнки барлык кешеләребезне дә бөтен яктан мөкәммәл итеп күрергә телибез. Әлегә тәрбиячеләребезнең дә кайберләре замана педагогикасы таләпләренә җавап биреп бетерә алмый. Хәл ителмәгән мәсьәләләр җитәрлек. Укучы белән укытучы мөнәсәбәте нинди рәк булырга тиеш? Без йомшак мөгамәләне алга сөрәбез. Ә ул «йомшаклык» ни дәрәҗәдә йомшак булырга тиеш соң? Чик кайда? Өзеп кенә кем әйтеп бирә ала? Бу — этиканың иң четерекле ягы.

Быел югары белем алып чыккан педагогларыбызга ун-унбиш елдан соң нинди балалар белән очрашырга туры килер? Гомумән, алдагы ун елда безнең балалар нинди булыр? Хыяллары, омтылышлары, нәфесләре, бәхет төшенчәсенә мөнәсәбәтләре?

Без күп еллар буена өс-баш бөтенлеген, тамак туклыгын бәхет тулылыгының иң кирәкле шартларыннан санап килдек. Өлкән буын педагоглар, мәсәлән, тук балалар белән эшләргә бик кыен җайлашалар.

Бүгенге балаларга ач торырга да, ялангачлыкны кичерергә дә туры килмәгән. Алар тамак туклыгын бәхет дип тануны һич кабул итә алмый.

Без кешенең бәхетен теләсә нинди шартларда хезмәткә бәйләп аңлатабыз. Әмма сүзебез кайчак эштән аерыла. Телдән эшне мактыйбыз, әмма мәктәпләрдә типсә тимер өзәрлек 16—17 яшьлек егетләргә атнасына нибары ике сәгатьлек хезмәт дәресе билгеләнгән. Анда да алар үзләре башкарган эштән тәм тапмыйлар, чөнки беләләр: бу дәрестә алар ышкылаган тактаның берәүгә дә кирәге юк. Бу — юри, программа үтәү өчен генә оештырылган нәрсә. Кеше ләззәтләнсен өчен аның хезмәте җитештерүчән, кирәкле, файдасы әллә каян сизелеп торучан булырга тиеш.

Безнең училищеларда хезмәткә өйрәтү яхшы куелган, әмма яшь эшчегә ул гына җитми. Аны алдынгылыкка омтылучан итеп ничек тәрбияләргә? Аңарда матурлыкка соклану хисләрен ничек уятырга? Монда бер яклы гына тырышу һич ярамый. Яшь буынны тәрбияләүдә экономика да, политика, педагогика, мәгариф тә бердәм булырга тиеш. Мөмкинлекләр бар, шартлар әйбәт. Илдәге социаль төзелеш үзе — балаларның бәхетен гарантияли торган төзелеш.

**Сорау.** Балалар тәрбиясендә хәзерге гаиләнең роле нинди?

**Җавап.** Каршылыклар монда да җитәрлек—диалектик каршылыклар, әлбәттә. Хәзерге балалар, бигрәк тә шәһәр балалары, әти-әни, әби-баба янында аз булучан. Бу хакыйкать кеше формалашуда халык педагогикасы дигән бик мөһим нәрсәне читтә калдыра. Инсафлылык, миһербанлылык, оят белү балаларга әбисенең көнгә мең тапкыр кабатлана торган үгет-нәсихәте аша иңгән. «Олылар барында башлап тел тибрәтмә!», «Кешегә елмаеп кара!», «Күршеләргә кергәч, әүвәл сәлам бир», «Ярдәмчелекле бул!»...

Хәзер күп балалар әби-бабаларын күрмиләр. Әти-әни — эштә. Өйгә кайткач та, бала белән шөгыльләнүне кирәк санамый. Бала килешмәгәнне кылып куйса, ана кеше әбиләр кебек әхлак кагыйдәсен тәкърарлап тормый, селти дә җибәрә. Вакыты тар, янәсе. Фәнни педагогика исә, бик тырышса да, бала тормышында очрый торган барлык сорауларга җавап биреп бетерә алмый. Күп очракта, педагог кулына килеп кергәнче, баланың холкы формалашып ук өлгергән була, аны кабат үзгәртергә туры килә. Монысы — башлап дөрес тәрбия бирүгә караганда күп тапкырлар кыенрак эш.

Сабыйларыбызның, яшүсмерләрнең дөньядагы иң әйбәт кешеләр булып өлгерүенә ирешер өчен безгә халык педагогикасы белән фәнни казанышларны эзлекле рәвештә бәйләп барырга кирәк.

Җирдәге иң бәхетле балалар иленең тәрбия өлкәсендәге җаваплы кешеләре буларак, без быел үзебезгә тапшырылган бурычларга аеруча игътибарлы карыйбыз. Халыкара балалар елында башкарган эшләребез йөзгә кызыллык китермәс дип уйлыйм.

**Сорау.** Татарстан язучыларына әйтергә теләгән сүзләрегез юкмы?

**Җавап.** Нәрсә әйтим. Рәхмәт, педагогикада татар әдәбиятыннан без нык файдаланабыз. Елның балаларга багышлануын искә алып, әдипләребезне активлыкка чакырасы килә. Бик әйбәт әсәрләр язылса да, бездә әле А. Макаренконың «Педагогик поэма»сы шикелле, тәрбиячеләргә кулланма булырдай әсәрнең язылганы юк. Көтәбез.

— Рәхмәт.

**Әңгәмәне язучы КОЯШ ТИМБИКОВА алып барды.**

## Песи

Тотып алса чебенне,
Өстәл астына кертә.
Һәм шунда нишләтәдер? —
Авызын чәпелдәтә.

Муены турысындагы
Мамыгы ап-ак аның.
Мин аны шуңа күрә
«Муйнак» диеп атадым.

Бар минем бер песием —
Кечкенә, йомшак үзе.
Ялт та йолт итеп тора
Аның очкынлы күзе.

Бер чебен күрде исә,
Артыннан куып китә.
Әгәр тота алмаса,
Мыекларын селкетә.

ЗӨЛФИРӘ ТӨХФӘТУЛЛИНА,
Чистай районы, Гаделшә сигезьеллык
мәктәбенең алтынчы класс укучысы.

## Оч син, кошчыгым!

Тышта салкын кыш:
Агачлар шартлый...
Сары песнәгем
Оясын тапмый.

Килде ул якын
Минем яныма,
Үзенчә ымлап
Нидер ялына.

Керергә тели
Бу өебезгә.
— Әйдә, алайса,
Кер, — дидем, — безгә!

Песнәгем кереп,
Канатын какты.
Икмәк вакларын
Бик тәмләп капты.

Күп тә үтмәде,
Көннәр җылынды.
Минем кунагым
Тәрәзгә кунды.

Оч син, кошчыгым,
Иркен кырларда,
Аяз күкләрдә,
Рәхәт дөньяда!

РӘМЗИЛ ХӨСӘЕНОВ,
Башкортстандагы Тәтешле районы, Бүлкайпак
сигезьеллык мәктәбенең 4 нче класс укучысы.

## Сеңлем Гөлүсә

Минем сеңлем Гөлүсә
Ел да бер яшькә үсә.
Бертуктамый сөйли ул,
Үзе бик күп белми ул.

Песи белән дә уйный,
Әлифбаны да укый.
Биеп тә ала шунда,
Мин көлсәм, көлә ул да.

Нәни генә куллары
Тик тормый һич кенә дә.
Рәсемнәр ясарга ул
Өйрәнә кечкенәдән!

**ГӨЛСИРИН ИЛЬЯСОВА,**
**Чувашстандагы Батыр районы, Чкалов**
**сигезьеллык мәктәбенең 3 нче класс укучысы.**

## Минем якын дустым

Минем бик күп дусларым
Кызлардан, малайлардан.
Хатлар да язар алар
Миңа әллә кайлардан.

Минем тагын бер дустым —
Казан дигән җирләрдә.
Айга бер күрәм аны,
Ул кунакка килгәндә.

Сез беләсездер аны,
Ул бит «Ялкын» журналы!

Матур-матур шигырьләр,
Җырлар алып килә ул.
Укып һич тә туялмыйм,
Көн дә килми нигә ул?!

**ФЛЕРА ГАБДРАХМАНОВА,**
**Мари АССРдагы Бәрәңге районы,**
**Куян урта мәктәбенең 4 нче класс укучысы,**



*Татарстанның халык художнигы К. Е. Максимов — балаларның якын дусты.*

# БЕР КОЙРЫК ТАРИХЫ

ӘКИЯТ

Яшәгән, ди, булган, ди, Тиктормас исемле бер маймыл. Барлык маймыллар кебек, бик тә шат күңелле икән бу. Ләкин ул заманнарны маймыл халкының койрыклары юк дәрәҗәсендә кыска булган. Бервакыт әнисе Тиктормаска шундый вакыйга сөйләгән.

Филнең борыны бик бәләкәй, имеш. Көннәрдән бер көнне крокодил моның борынын тешләп тарткан һәм филнең борыны озынаеп калган. Шушы озын борыны ярдәмендә фил бик күп шатлыклы сәгатьләр кичергән.

Моны ишеткәч, Тиктормас елга буена чаба һәм крокодилдан койрыгын озынайтуын үтенә. Ләкин крокодил пырхылдап кына куя. Маймыл үзенең зарын бегемотларга, бүреләргә, юлбарысларга да сөйләп карый. Тик аннан көләләр генә.

Инде кич тә якынлаша, җирне эңгер-меңгер сарып ала. Тиктормасның ашыйсы килә башлый. Шунда ул йоклап яткан арслан янында ит кисәге күреп ала һәм аны әз генә кабып карый. Ит тәмле тоела моңа. Шулай капкалый торгач, ашап та бетерә бу итне. Нәкъ шул мизгелдә арслан уяна да, ит кисәгенең юклыгын күреп, иләмсез тавышы белән үкереп җибәрә. Коты очкан Тиктормас кача алмый кала — арслан аның койрыгыннан эләктереп ала.

Шулай итеп, маймылларның койрыклары озынаеп калган, ди.

**РӨСТӘМ ТУМАКАЕВ,**
**Казан шәһәрендәге 28 нче мәктәпнең**
**6 нчы класс укучысы.**

## Чәчәкләр, китаплар һәм мин

Иртә-кичен сулар сибәм,
Чәчәк ата гөлләрем,
Шул гөлләрем арасында
Китапка күмеләмен.
Сулар кипкәч — гөлләр үссен,
Китап укып мин үсим.
Гөлләр үсә минем өчен,
Мин үсәмен ил өчен.

**РЕЗЕДА МОРТАЗИНА,**
**Пермь өлкәсе, Октябрь районы,**
**Енопай урта мәктәбенең VII класс укучысы.**

## Солдат абыем

Минем абый солдатта —
Хезмәт итә еракта.
Көн дә, кайчан кайтыр, дип
Карыйм ул киткән якка.

Шинель кигән һәрбер солдат
Абыем кебек көчле.
Каршы алам мин һәрберсен
Үз сеңелләре төсле.

**ТАЛИЯ ФӘЕЗОВА,**
**Аксубай районы, Яңа Дума урта мәктәбенең**
**VI класс укучысы.**



*Советлар Союзы Герое М. П. Девятаев*
*пионерлар арасында*

# БАКА НИГӘ СУДА ЯШИ?

ӘКИЯТ

Әүвәл заманда бака гел җирдә яшәгән, ди. Үзенең бик килешле генә койрыгы да булган. Тыныч кына үз көнен үзе күреп ята икән бу.

Бервакыт, көндәгечә, бака ауга чыгып киткән. Шулай бара торгач — син күр дә мин күр — җан-фәрман кире өенә таба чаба башлаган. Ник дисәң, иләмсез зур бер тау кисәк кенә тирә-юньгә утлы ташлар атарга тотынган. Шунда баканың койрыгына бер таш килеп төшкән дә аны көйдереп өзеп ташлаган. Ул куркуыннан шунда ук су астына чумган. Шуннан бирле бака суда яши башлаган. Ул кайвакыт төннәрен генә җир өстенә дә чыга икән. Тик балкып кояш чыгуга, теге янартауны исенә төшереп, янә суга чума икән.

ГӨЛЗИРӘ ГАРИФҖАНОВА,
IX класс укучысы, Азнакай районы,

# КЫЗЛАР ШАТЛЫГЫ

ХИКӘЯ

Зөлфия үзенә күлмәк текте. Тегеп бетергәч, ул үз эшенә байтак кына сокланып карап торды. Яңа күлмәк, чыннан да, матур килеп чыккан иде.

Кыз үзе теккән күлмәкне киеп көзге алдына килеп басты. Күлмәк аңа шул кадәр килешә ки, ул бөтенләй күбәләккә охшап калган иде. Кыз, үзе дә сизмәстән, бөтерелеп биеп китте.

Аннары ул сөенечен уртаклашыр өчен сабакташ дусты Кифаяларга чыгып йөгерде.

Шатлыктан алмадай кызарып, аларга барып кергәч, ни күрсен?! Көзге алдында өр-яңа күлмәк кигән Кифая басып тора. Күлмәге шул кадәр матур инде! Дусты канатлы коштай мена-мена очып китәр төсле.

Дуслар бермәлгә өнсез калдылар. Беренче булып Зөлфия телгә килде. Ул, соклануын яшермичә: «Килеп керүгә мин сине танымый да торам. Әллә үзең тектеңме? Болай матур итеп тегәргә әниең өйрәттеме?» — дип, аны сорауларга күмде. «Юк, мин түгел. Авылдан әбием бүләк итеп салып җибәргән, — дип җавап кайтарды Кифая. — Синең дә күлмәгең бик матур, нинди килешле! Әллә үзең тектеңме?». «Әйе», — дип, Зөлфия ым какты. Аның бу сүзендә чиксез горурлык та, канәгатьләнү хисе дә бар иде. Һәм ул бөтерелә-бөтерелә биеп килде дә дустын кочаклап алды.

РУШАНИЯ СӘЛӘХОВА,
Арча районы, Иябаш авылы.

## Җәйге көн

И җәй көне, гаҗәеп көн!
Киттек, дуслар, җиләккә!
Тулып-тулып кайтсын әле
Кызыл, сары чиләкләр.
Җиләкләрне өзеп алып
Салабыз чиләкләргә.
Чиләкләрне тутыргачтын,
Менәбез тирәкләргә.
Җиләк җыя беләбез! —
Инде кайтып киләбез,
Күзләр төшә гел чиләккә:
Чиләктәге җиләккә.

**РУШАНИЯ СӘХӘПОВА,**
**Түбән Камадагы 5 нче урта мәктәпнең**
**VII класс укучысы.**

## Уйлану

Йолдыз, йолдыз!
Ачык күзләремдә
Синең нурлар гына чагыла.
Нурларыңа чумып утырам мин,
Төнге күккә уйлар агыла.
Сиңа барып җитәр микән хыял:
Калдырмаска иде ялгызың.
Сиңа якын булыр җир уллары
Һәм кадерле булыр җир кызы.
Бардыр кайнар, салкын
юлдашларың,
Тик аларда йөрәк типмидер.
Бу хыяллар кеше исеменнән
Йолдызларга менгән
илчедер...

**ГӨЛШАТ НОГМАНОВА,**
**Башкортстандагы Благовар районы,**
**Кашкалаша урта мәктәбе укучысы,**

## Роберт Миңнуллин

### Качышлы уйнаганда

Бар да мине эзлиләр:
Янда гына гөжлиләр,
Эзлиләр, и эзлиләр,
Өметләрен өзмиләр.

Ә үзләре тапмыйлар:
Тирә-якны таптыйлар,
Кая гына чапмыйлар,
Кая гына бакмыйлар,
Мине генә тапмыйлар...

Ә мин ятам тын гына,
Ә мин ятам шым гына,
Ә мин ятам тик кенә —
Тапмыйлар соң ник кенә?

Болытлар да каралды —
Төшә бугай караңгы.
Әни инде өйдәдер,
Туңдыра да нигәдер.

Була ла ул чыдарга,
Кирәк ләкин чыгарга...

Чыксам...
Кайтып киткәннәр,
Таралышып беткәннәр,
Мине мәзәк иткәннәр.

Итсәләр соң, итсеннәр,
Китсәләр соң, китсеннәр,
Шәп иттек, дип йөрсеннәр,
Рәхәтләнеп көлсеннәр,
Ләкин шуны белсеннәр:
Җиңдем мин — отылмадым,
Барыбер тотылмадым!
Вәт!

## Карбабайның борыны

1

Ясадым мин кичәгенәк
Менә дигән Карбабай.
Матур чыкты. Карбабайга
Гаҗәпләнде бар малай.

Тик ни күрәм иртә белән:
Карбабайның борыны
Юкка чыккан. Борынының
Калган бары урыны.

Эх, сакларга кирәк булган,
Берәр хәйлә корырга.
Онытканмын бит мин аңа
Таягын тоттырырга.

Таягы булса, беркем дә
Аны җиңәлмәс иде,
Ул үзенә беркемне дә
Якын җибәрмәс иде.

2

Ул борын белән, мөгаен,
Бур-куян сыйлангандыр.
Сыйлангандыр, ә шатлыгы
Эченә сыймагандыр.

Сыйлансын, әйдә, сыйлансын,
Кишер бездә җитәрлек,
Урмандагы бар куянны
Җыеп кунак итәрлек.

Бер сүзем юк, әйбәт булган
Сыйланырга ярагач.
Тик әллә ничек, борынсыз
Карбабайга карагач.

Исән микән үз борыным? —
Шул килеш, ашалмаган.
Ярый әле минем борын
Кишердән ясалмаган.

Фаил Шәфигуллин

# ЕРАКТАМЫ, ЯКЫНДАМЫ?

хикәя



Әллә кайчаннан бирле эленеп тора инде сыңар бияләй өрәңге ботагында. Юл буйларын көрт күмгән көннәрдә узгынчыларның иңбашларына тияр-тимәс тирбәлеп кала иде ул. Хәзер урамнар кардан арчылды. Бияләй күзгә күренеп биегәйде.

Тәрәзәдән карап утыра торгач, үзе өчен кызыклы бер яңалык ачты Илгиз: агач ботагындагы бияләйгә бала-чагалар, кызлар, егетләр һәм әти кешеләр бөтенләй диярлек игътибар итмиләр. Әниләр генә... Кызларын яисә улларын җитәкләп, биек йортлар эргәсеннән салмак кына атлаучы әниләр генә... өрәңге төбенә килеп туктыйлар да теге яктан карыйлар бияләйгә, бу яктан... Мондый чакларда һәр әни янындагы баласыннан: «Синеке түгелме?!» — дип сорый сыман тоела Илгизгә.

Ә бит өрәңге ботагындагы бияләй Илгизнеке. Моны берәү дә белми. Илгизнең әтисе дә, әбисе дә белми. Илгиз хәтта үзеннән дә яшерергә тырыша бияләйнең үзенеке икәнен.

Шулай бер вакыт чана шуганда Фирүзәнең елап торганын күрде малай. Күрде дә юату нияте белән баштанаяк карга буялган Фирүзәгә якынрак елышты. Ә-ә-ә! Әнә эш нәрсәдә: әнисе орыша икән Фирүзәне. Фәлән дә фәсмәтән, ачык авыз, ди, кулайсыз, җебегән, ди. Борынын тарткалап, Фирүзәне кызганып торганда, төшенеп алды Илгиз: сыңар бияләен җуйган икән Фирүзә. Шуның өчен дөнья бетереп битәрли икән аны әнисе.

Фирүзәләр кайтып киткәч, кар өемнәренә типкәләп, югалган бияләй табылмасмы дип, байтак өметләнеп йөргән иде Илгиз ул чакта. Әмма бияләй табылмады. Шунда өметле уй янына сөенечле уй да килеп өстәлде: кара, Илгизнең үз бияләйләре дә нәкъ Фирүзәнеке төсле ләбаса. Аннан соң Илгизнең күн бияләйләре дә бар. Кыскасы, әтисе белән дә, әбисе белән дә киңәшмәде Илгиз — мәсьәләне үз белдеге белән хәл итте дә куйды.

Илгиз чыгарып ташлаган сыңар бияләй берничә көн Фирүзәләр тәрәзәсе каршындагы сукмак буенда яртылаш карга күмелеп ятты. Ләкин аңа караучы да, орынучы да булмады.

Бер көнне кичкырын Илгиз бәхетсез бияләйне Фирүзә йөри торган сукмакка куеп калдырды — иртәнгә кадәр, аннары иртәдән кичкә кадәр яткан урынында ята бирде бияләй. Берничә көннән Илгизгә үз бияләе бик кызганыч булып тоелды. Карга катып, бозланып беткән



*«Йокла, кызым,*
*Күз нурым!»*

бияләне ул өйгә алып кереп җылытты, киптерде дә Фирүзәләр йорты каршындагы өрәңге ботагына чыгарып элде.

Әнә шул көннән бирле ботакта тирбәлә дә тирбәлә сыңар бияләй.

Дөрес, апрель урталарында — күләгәле урыннарда кар атаулары агарып ята иде әле — Фирүзә дә тотып карады бияләйне. Әнисе алып бирде аны Фирүзәгә. Илгиз, тәрәзә рамына ябышкан көе «нәрсә була инде?» дип уйлый гына башлаган иде — Фирүзә нидер әйтте дә, тегеләр бияләйне үз урынына элеп, ипи кибетенә таба киттеләр. Бер-берсенә карап, сөйләшә-сөйләшә, көлешә-көлешә киттеләр. Илгиз, тырнак очын тешли-тешли, алар кибет артына кереп күздән югалганчы, артларыннан карап калды.

Әллә үзен, әллә бияләен кызганып елады инде Илгиз ул көнне. Үзе, еламыйм-еламыйм, дип уйласа да, яңаклары буйлап тәгәрәгән кайнар тамчылар, елыйсың-елыйсың, дип үртәделәр аны һәм тагын да ныграк елыйсын китерделәр.

Илгизләр дә шулай җитәкләшеп йөрерләр иде микән әнисе исән булса. Илгиз әнисен бөтенләй хәтерләми. Үлгән Илгизнең әнисе. Авырган да үлгән. Әбисе дә, әтисе дә әйбәт инде әйбәтен Илгизнең. Беркайчан да нахакка рәнҗетмиләр аны, җил-яңгыр тидермиләр. Аннан соң «үлгән» дигән салкын сүз белән ахырынача килешеп җиткәне дә юк әле Илгизнең. Ничек инде «үлгән?» Олы кешеләрнең әниләре үлә. Ә Илгиз бөтенләй кечкенә бит әле. Юк, үләргә тиеш түгел аның әнисе!

Янында әнисе булса, бияләй турында әйтер иде микән Илгиз аңа? Әйтмәс иде, мөгаен. Әниләр алар усал була торганнардыр, ахры. Әнә бит теге чакта бияләен югалткач, Фирүзәне ничек орышып ташлады әнисе. Аннары урамга уйнарга чыккан саен күрә Илгиз: иң шаян, иң шук малайлар да әниләре килгәч, шым булалар. Әниләр янында малайлар басынкыланалар, юашланалар. Аларның йөзләренә кызлар кыяфәте чыга.

Фирүзәгә дә әнисе рөхсәт итмәгәндер әле, мөгаен, агач ботагындагы бияләйне алырга. Әгәр дә Фирүзәнең үз кулына тапшырса Илгиз бияләйне? Синең бияләең югалган иде кыш көне. Синең бияләең бу,

мин табып элгән идем агачка дияргә. Хәзер көннәр җылы, хәзер беләй киеп йөрмиләр инде йөрүен. Шулай да кызганыч беләй. Өр-яңа бит әле ул. Аннары бик йомшак та. Нигә генә ошатмады икән соң Фирүзәнең әнисе? Бик тә, бик тә Фирүзә кулында күрергә теләгән иде Илгиз беләйне. Теләге кабул булмады, ахры.

Ә бүген беләен өйгә алып керү нияте белән чыккан иде Илгиз урамга. Тегеләй әйләнде өрәнге тирәсендә, болай әйләнде һәм һич көтмәгәндә Фирүзә белән очрашты. Фирүзә бер кулы белән яшел башлык эченнән тузгып чыккан маңгай чәчләрен рәтли-рәтли, өрәңге ботагындагы сыңар беләйне күзәтә иде. Илгиз, чигенә-чигенә, өрәңге төбеннән ераклаша да башлаган иде инде, тик Фирүзә кычкырып өлгерде:

— Исәнме, Илгиз!

Илгизнең исәнләшергә дип ачылган авызы ябылмыйча калды. Фирүзә чәтер-чәтер тезәргә кереште:

— Синең беләең ич ул, Илгиз. Кыш көне безнең тәрәзә алдында аунап ятты, инде менә кемдер агач ботагына киертеп киткән. Буең җитә ич, ал, Илгиз.

— Минеке түгел ул, синеке түгелме соң? — дип, беләйгә бер генә күз сирпеп алды да Илгиз, кызарып, башын түбән иде.

Фирүзә Илгизнең йөзенә текәлебрәк карады. Күрше кызы эченнән генә көләдер сыман тоелды бу минутта Илгизгә. Ул башын тагын да аскарак иде.

— Минем беләйнең сулы югалган иде шул, ә бу уң беләй, — диде очлы күзләрен һаман да Илгизгә текәгән килеш. — Ә синең кайсы беләең югалган, Илгиз?

— Минемме? Минем югалмаган...

Менә эш нәрсәдә икән? Их, тиле Илгиз, тиле Илгиз!..

Беләйнең уңы һәм сулы булуын бөтенләй исеңнән чыгаргансың бит син! Менә шулдыр инде — сукыр тавыкка бар да бодай...

— Кем беләе икән соң, алайса?.. Мондый беләйләр синең белән миндә генә дип уйлаган идем мин тагын.

— Белмим...

— Синекедер, Илгиз. Син оныткансың гынадыр. Әниең булса, исеңә төшергән булыр иде. Бәхетең, әниең юк...

Кинәт кенә Илгизнең бөтен тәненә ут капты. Яңаклары гына түгел, колаклары, маңгае, күкрәкләре дә яна иде аның хәзер. Шулай да телен көчкә әйләндереп:

— Минем яңа беләйләрем бар, — дип әйтә алды.

— Әниең булса, күрсәтер иде сиңа яңа беләй. Әниең булмаганга күрә иркенләп йөрисең син. Өеңә караңгы төшкәч кенә кайтсаң да, орышучы юк сине, беләй югалтсаң да, сүз әйтүче юк.

Илгиз сискәнеп китте, капылт кына башын күтәрде, тырнакларын уч төбенә батырып, Фирүзәгә таба атлады. Кызның ваемсыз-матур күзләрен үпкә катыш нәфрәт уты беләң көйдерде. Аннары, кисәк кенә борылып, яфракка бөреләнгән өрәңгеләр арасыннан юлсыз-нисез йөгереп китте.

Сулышы кабып, әлсерәп, шәһәр читенә килеп чыккач кына туктады Илгиз. Әле һаман да язылмаган йодрыклары белән дымлы керфекләрен сыпырып алды. Күз карашы талганчы офыклардан офыкларга җәелеп, изрәп яткан язгы серле киңлекләргә сихерләнеп карап торды.

Булырга тиеш лә Илгизнең әнисе, булырга тиеш!..

Битләрне йомшак җил сыйпый, күзләргә саф садә яшеллек агып керә, күңелне тып-тын күгелҗем ераклыклар ымсындыра...

Бар ла ул Илгизнең әнисе, кайдадыр яши. Яши һәм һәр даим Илгизне күзәтеп, аның кайгы-шатлыгын уртаклашып, аңа яхшылык теләп тора. Тик ерактамы ул, якындамы — шунысын гына тәгаен белми Илгиз.

## Зәки Нури

### КУНАКТАН КАЙТКАЧ

— Кая булдың?
— Күршеләргә кердем.
Карбыз ашап утыра иделәр.
Күптән, ахры, көткән булганнардыр,—
«Син генә юк идең!» диделәр.

### ТАНЫШ АПА

— Әни, күрче, бер карачкы чыкты
Күршеләрнең әнә өеннән!
— Курыкма, балам, ул бит Бану апаң,
Үзе бүген шулай киенгән...

### ЕРАКТАН КАРАП

Алда: сәхнә. Микрофонлы апа.
Ана сорый: — Кызым, ник көлдең?
— Ә мин аны шулай җырлый-җырлый
Мороженый ашый дип белдем.

### КӨЛДЕРДЕ

— Әти, бераз вино бирче!
— Нәрсәгә?
— Бераз ал төс өстик курчак йөзенә!
— Вино бит ул буяу түгел, көлдермә!
— Ник алайса: «Синең борын винодан
Кызара», — дип әни әйтте үзеңә?

### ЗУР АЕРМА

— Диалог нәрсә ул, әти, аңлатчы?!
— Ике кеше кара-каршы сөйләшә.
— Ә монолог!
— Ул гадәттә башлана
Әгәр әнкәң... минем белән сөйләшсә!..

### ФИЛ ЯНЫНДА

— Ник филгә «Ишәк!» дидең син, әти?
— Күрдең ич, өскә күпме су сипте.
— Ник башта үзең таш аттың аңа?
— Әйдә, кузгалыйк — сүз күпкә китте!..



*«Барыбер җиңәчәкмен,*
*Беренче киләчәкмен!»*

*С. ТОКАРЕВ фотолары*

## БҮТӘННӘРДӘН КҮРЕП

Очып керде малай тыштан... Очып!
Нәрсә күрде икән ул анда?
— Озын бауга бәйләп дәү бер апай
Мәче йөртә безнең урамда?!

## НИК ШУЛАЙ ДИДЕ ИКӘН!

— Бакчада безне врач тыңлады:
Белде ул кемнең ничек сулавын.
Икенче килгәч белербез, диде,
Кемнең һәм кайчан, нигә елавын?!.

### СӘЕР АБЫЙ

— Теге абый әллә суга баткан,
Эштән качып әллә кайтамы, —
Ник чалбарын, әни, сызганган ул
Тез башына кадәр кайтарып?!.

### ҖИҢЕЛ ҖӘЗА ЭЗЛӘҮ

— Оланы колагын фил дә бора микән?
— Кирәк чакта ник бормасын... җиңелчә!
— Зур колак ул, әни, каты борсаң да
Бик әз генә авыртадыр, минемчә?

### ТӨШ КҮРГӘЧ

— Әни, бүген кем туган көн?
— Ник мондый сорау бирдең?
— Чөнки мин төнлә төшемдә
Бик зур шоколад күрдем!

### ӘБИСЕ ӨЙРӘТКӘНЧӘ

— Беләсеңме, язу таныйм мин!
Кем өйрәтте дисәң — дәү әни.
— Укып күрсәт әле, я, нәни!
— Менә китап. Менә чуар бит —
Ул язулы төш дип атала.
Ә язусыз җирләр — ак кала.

### ШӘП ЮЫНУ

— Әткәм мине бик шәп коендырды!
Кул тимәгән җирне калдырмады.
«Аягыңны яңгыр юар!» диеп,
Ботинкамны бары салдырмады.

## Тапкырларга — табышмак

### БАРЧА ТЕЛДӘ СӨЙЛӘШӘ

Барча телләрдә
Сөйләшә белә.
Сөйли — бүтәннәр
Сөйләсә генә.

(Кайтаваз)

## АК ЧЕБЕН

Ап-ак бер чебен
Кулыма кунды.
Мин сулыш өргәч —
Кинәт юк булды.

(Кар бөртеге)

## ӨЕБЕЗДӘ КЫШ БАР БЕЗНЕҢ

Өебездә бер хикмәт бар —
Үз кышыбыз бар безнең:
Анда елның ел буена
Беткәне юк кар-бозның.

(Суыткыч)

## ӨЧ КҮЗЕ БАР

Өч күзе бар — өчесе өч төсле
Әмер биреп нурлар коя белә:
Ике күзе сине алга әйди,
Ә бер күзе — бары тыя белә.

(Светофор)

## ТҮГӘРӘК ТӘРӘЗӘ

Түгәрәк тәрәзә. Түгәрәк пыяла...
Кыш көне идәндә ялтырап яталар.
Ул шундый пыяла, ул шундый елтыр күз:
Төннәрен куела, ә көндез ваталар.

(Бәке)

## АЛТЫН БАЛЫКЛАР

Төпсез диңгездә йөзәләр
Калтырап та ялтырап.
Төн караңгырак булганда
Балкулары яктырак.

(Күктә йолдызлар)

## СӨЙЛИ БЕЛГӘН ТЕЛСЕЗЛӘР

Без һәммәбез тиңнәр-тигезләр,
Бер семьяда бердәм яшибез.
Аерым-аерым чакта телсез без,
Рәттән бассак — сөйли башлыйбыз.

(Әлифба хәрефләре)



**Роберт Әхмәтҗанов**

## Республикам шагыйрьләре

Елга буйлап йөзәм. Дулкын хоры,
җырлап килә каршыга таң җилләре.
Килә гүя, кулга-кул тотынып,
Социалистик Идел шагыйрьләре!

Ерак ярлар җавап бирә яңгырап,
Кояш йөри күченеп ярдан-ярга...
Туры карап дуслык кояшына,
Көчле кораб — республикам бара.

Без синеке. Синеке — баштанаяк!
Без синеке! Вахтаң төгәл синең.
Җик син безне, кыен эшкә җик син, —
Максатыңа җитсен синең Байрак!

Флагштогың — ашкан болытлардан,
Корыч күкрәк ера заман җилен...
Без — вахтада, биек байрагыңда
балкыганда Ильич силуэты!..

Йөзә кораб ерак офыкларга,
байрагыңда уйный таң җилләре...
Бөек заман! Сезгә сүз бирелгән,
социалистик Идел шагыйрьләре!

# ТАТАР ЭШЧЕЛӘР ХӘРӘКӘТЕ ҺӘМ «СОВЕТОЛОГИЯ»

Россиянең күп милләтле пролетариаты интернационализм байрагы астында капитализмны бәреп төшерде һәм нык үскән социалистик җәмгыять төзеде. Илебезнең башка милләт эшчеләре белән бергә бу тарихи көрәштә татар пролетариаты да актив катнашты.

Әмма, өстен сыйныфларның социаль заказын үтәп, буржуаз тарих фәне пролетариат милли отрядларының интернациональ табигатенә шик белдерә яки аны бөтенләй кире кага. Дөрес, хәзерге буржуаз тарихчылар арасында Г. Ибраһимовның «Безнең көннәр» романындагы татар милләтчесе Нигъмәт казый шикелле, революциягә кадәр татарда пролетариат булмады яки юк дәрәҗәсендә иде дип раслаучылар хәзер сирәк. Буржуаз галим-«советологлар»ның күпчелеге 1914 елда саны 150 меңгә җиткән татар эшчеләр сыйныфын танырга мәҗбүр. Шул ук вакытта буржуаз тарихчылар революциягә кадәр татар эшчеләренең сыйнфый аңы, аларның оешканлыгы һәм тупланганлыгы үсешендә җитди үзгәрешләр булуын чынлыкта күрергә теләмиләр. Мисалга, француз тарихчылары А. Беннигсен һәм Ш. Келькеҗе, аерым очракларны искә алмаганда, 1917 елның октябренә кадәр милли эшчеләр сыйныфы «политик яктан зәгыйфь», «оешмаган», «пассив» иде дип белдерәләр[1].

Татар пролетариаты формалашу тарихын өйрәнгән совет галимнәре рус пролетариаты белән чагыштырганда аның профессиональ һәм гомуми белем дәрәҗәсе түбәнрәк булуын, «кендеге» авыл хуҗалыгыннан тулысынча өзелеп бетмәгән кешеләрнең шактый катлау тәшкил итүен, сыйнфый көрәшкә эшчеләрнең бер өлеше битараф каравын билгеләп үттеләр. Шул ук вакытта татар эшчеләрен революция рухы белән өреткән факторлар да искә алына. Мәсәлән, Крестовников заводында барлык эшчеләрнең унбиш, дары һәм Ушков заводларында — утызар, Алафузовныкында — кырыкка якын, Бондюг һәм Кукшән заводларында аннан да күбрәк процентны татарлар тәшкил итү губернаның эре предприятиеләрендәге хәлне күз алдына бастыра[2]. Татар эшчеләренең эре предприятиеләрдә тупланулы исә аларның сыйнфый аңы җитлегүен, оешканлыгы һәм сугышчанлыгы артуын тизләтә иде

Икенчедән, татар эшчеләренең политик активлыгы күтәрелүен аларның профсоюзлар һәм башка пролетар оешмаларга член булып керүләре, бу оешмаларның эшендә катнашулары да раслый.

Өченчедән, «советологлар»ның татар пролетариаты Казан губернасыннан читтә урнашкан иде, дип басым ясаулары да татар эшчеләрнең революционлашуы тизләнү файдасына гына сөйли ала. Донбасс шахталарында, Бакуның нефть, Әстерханның балык промыселларында, Орехово-Зуево туку фабрикалары, Лена алтын прискаларында татар эшчеләре бөек сыйнфый көрәш, пролетар интернационализм мәктәбен уздылар.

Эшчеләр сыйныфының милли отряды формалашу тарихын, буржуаз тарихчылар кебек, бөтен Россия пролетариаты чыгышларыннан аерып алып дөрес аңлату мөмкин түгел. Чөнки В. И. Ленин «шушы илдәге барлык эшчеләрнең интереслары бертөрле, солидар икәнен, алар барысы бергә җәмгыятьнең башка барлык сыйныфларыннан аерым бер сыйныфны тәшкил итүен» әйтеп киткән иде[3].

---

[1] A. Bennigsen et Ch. Quelquejay. Les mouvements nationaux chez les musulmans de Russie. Le «Sultangalievism» au Tatarstan. Paris. 1960, 47, 49, 53—54 битләр.

[2] Рубинштейн Л. В борьбе за ленинскую национальную политику. Казан, 1930, 14 бит.

[3] Ленин В. И. Әсәрләр, 2 том, 99 бит.

Татар эшчеләре, Россиянең бүтән милләт эшчеләре белән бергәләп, патшага һәм капитализмга каршы көрәшнең барлык баскычларын уза. Аларның башлангыч чыгышлары таркау, стихияле рәвеш ала, машиналарны вату, производство биналарына ут төртүгә кайтып кала һәм, В. И. Ленин сүзләре белә әйткәндә, «көрәштән бигрәк, ярсу һәм үч алу күренеше иде»[1]. Үткән гасырның 60—80 нче елларында Сембер губернасындагы Акчуриннар тукыма фабрикасы эшчеләре көрәше нәкъ менә шулай башлана. Туксанынчы елларда стачкалар инде оешканрак, аңлы һәм максатлырак төс ала. Әмма алар да әле чынлыкта стихияле хәрәкәт була, чөнки эшчеләр экономик таләпләр кую белән генә чикләнәләр. Шуның белән бергә эшчеләрнең стихияле хәрәкәте кузгалу революцион марксистлар эшчәнлеге җәелүнең зарури алшарты булып тора.

Татар эшчеләренең җитәкчеләре булмау турындагы «советологлар» раславы белән дә килешү кыен. Әкренрәк булса да, руслардагы кебек, татарның да алдынгы эшчеләреннән XIX гасыр азагы — XX гасыр башында пролетариат хәрәкәте җитәкчеләре формалаша. С. Сәгыев, Г. Исрафилов, С. Исхаков, В. Хөснетдинов, А. Таһиров, Миң. Вахитов, С. Хөснетдинев (Казан), Х. Гайнуллин (Бондюг), З. Садыйков (Әстерхан), Л. Нигъмәтҗанов (Мәскәү), С.-Д. Якубов (Баку), С. Гафуров (Сембер), З. Булышев (Донбасс), С. Сәетгалиев (Урал) нәкъ менә шундыйлардан иде. Буржуаз тарихчыларның татар эшчеләре җитәкчесе татар гына булырга мөмкин дигән шарты да дөрес түгел, әлбәттә. Ахыр чиктә, «советологлар» ленинчыл большевиклар партиясенең интернациональ асылына да шик белдерә. Мәсәлән, бельгияле буржуаз тарихчы М. Либман, Октябрьга кадәрге большевиклар партиясе бары тик рус эшчеләр сыйныфыныкы гына иде, дип раслый[2]. Хәлбуки, В. И. Ленин тарафыннан төзелгән партия баштан ук чын интернационалистлар партиясе иде. Ул, төрле милләт хезмәт ияләрен — руслар, татарлар, украиннар, әзербәйҗаннар һәм башкаларны берләштереп, илнең бөтен күп милләтле пролетариаты көрәшенә җитәкчелек итте. Партиябезнең интернациональ табигате РСДРПның Казан комитеты мисалында да ачык күренә. Төрле вакытта аңа Я. М. Свердлов, В. В. Адоратский, Н. Н. Никоряков, В. А. Тихомирнов, Х. М. Ямашев, Я. С. Шейнкман, М. Шаһиәхмәтов, Г. Сәйфетдинев, И. Н. Волков, Г. Ш. Ольkеницкий һәм башка иптәшләр сайлана.

Татар эшчеләр сыйныфының «саф татар» большевистик оешмасын төзергә теләмәвен буржуаз тарихчылар аның зәгыйфьлеге билгесе итеп карыйлар.

Мәгълүм ки, В. И. Ленин оппортунистларның милли партия оешмалары союзы рәвешендәге федератив принциптагы партия төзү омтылышларына күп тапкыр каршы чыкты. Федератив принцип сугышчан пролетариат партиясе яшәү мөмкинлеген юкка чыгара. Шуңа күрә алдынгы татар эшчеләрен партиядә милли билгегә карап оештыру, «советологлар»га ошаса да, күп милләтле пролетариат эчендә сыйнфый теләктәшлекне зәгыйфьләндерер, аның патшаны һәм капитализмны бәреп төшерү көрәшенә комачаулаган гына булыр иде.

Шул ук вакытта партияне интернациональ принципта төзү Америка тарихчысы Р. Шпорлюк[3] сурәтләвенә туры килмәвен, азчылык халык эшчеләренең милли мәнфәгатьләренә каршы булмавын басым ясап әйтергә кирәк.

Татар эшчеләренең революцион хәрәкәттә уйнаган ролен һәрьяктан киметергә омтылган «советологлар» Октябрь революциясенә кадәр аларның сыйнфый аңнары уянуын да танымыйлар. Буржуаз тарихчыларның фикеренчә, татар эшчеләренең аңы «бөтенләй милләтчел рухта» булган, имеш. Бу яла ягулы раслау бөтен татар пролетариаты гамәленә каршы килә. Бу уйдырманы большевиклар партиясенең татар эшчеләре хәрәкәтенә социалистик аң кертүдәге киң кырлы уңышлы эшчәнлеге турында сөйләүче күп санлы фактлар кире кага.

Үткән гасырның 80—90 нчы елларында ук Самара, Казан, Уфа һ. б. шәһәрләрдә марксистик түгәрәкләр оешуы яхшы билгеле. Татар хезмәт ияләре рус телен нигездә йомшак белүләрен яки бөтенләй аңламауларын искә алып, РСДРПның Казан һәм

[1] Ленин В. И. Әсәрләр, 5 том, 385 бит.
[2] M. Liebman. The Russian Revolution. New York, 1970, 288 бит.
[3] «Journal of International Affairs», 1973, vol. 27, № 1, 24—25 битләр.

кайбер башка комитетлары җирле халык телендә эшләүче социал-демократик түгәрәкләр дә оештыра. Беренче рус революциясе башлангач, мондый түгәрәкләр челтәре шактый үсә. Мисалга, 1905 елда Казанның Алафузов һәм шәһәр районнарында татар эшчеләренең марксистик түгәрәкләре булдырыла. Күренекле татар большевигы Хөсәен Ямашев җитәкчелегендә шәһәрдә берләштерелгән түгәрәк тә оештырыла.

Бу чорда татар марксистлары беренче тапкыр ана теленә РСДРП программасын, «РСДРПның өченче съезды турында белдерү»не, В. И. Ленинның «Авыл ярлыларына», «Өч конституция яки дәүләт төзелешенең өч тәртибе» һәм «Дәүләт думасына кемне сайларга?» кебек иң мөһим партия документларын тәрҗемә итәләр. Р. И. Нәфиков билгеләп үткәнчә, «бу елларда татар матбугатында беренче тапкыр К. Маркс һәм В. И Ленин исемнәре пәйда була, беренче тапкыр пролетариат диктатурасы, партия, сыйнфый көрәш, коралны восстание шикелле яңа төшенчә һәм атамалар кулланышка керә»[1].

Эшчеләр хәрәкәте тарихында беренче татар большевистик «Урал» газетасы (1907) аеруча әһәмиятле роль уйный. Ул хезмәт ияләренә аңлаешлы һәм үтемле рәвештә марксизм-ленинизм идеяләрен пропагандалый, большевиклар политикасы һәм тактикасының нигезләрен төшендерә, хезмәт ияләрен илдәге хәлләрне аңлый белергә өйрәтә. Царизмның бөек державачыл сәясәтен фаш итүдә, пролетар интернационализм байрагы астында хезмәт ияләрен буржуаз милләтчелеккә каршы туплау өчен көрәштә дә газетаның хезмәте зур.

Әмма татар массаларына марксизм йогынтысының «зәгыйфьлеген» исбатларга алынган буржуаз тарихчыларны газетаның уйнаган чын роле кызыксындырмый да. Америка тарихчысы С. Зеньковский большевикларның татар телендә социал-демократик газета чыгарырга тырышуын искә ала да «Урал»ның «утыз саны чыккач ук тукталуын» белдерә[2].

Белештермәгән кеше, бигрәк тә чит ил укучысы, бу хәбәрне ишеткәч, мөгаен, татар хезмәт ияләре арасында газета популяр булмаган икән дигән нәтиҗә киләчәк. Хәлбуки, «Урал» үзе ябылмый, патша властьлары аны массалар мәнфәгатен эзлекле яклавы, хезмәт ияләрен социаль һәм милли изүдән азат итү идеяләрен пропагандалавы өчен яба. Газета үзе дә (31 сан), редакция чыгарган кушымта-брошюралар да (5) әледән-әле конфискацияләнә тора, редакция штрафлар түли, большевистик газетаны укучылар һәм саклаучылар исә еш кына хөкемгә тартыла. Шуңа да карамастан, аңлы хезмәт ияләре тулысынча большевиклар яклы була.

Буржуаз тарихчыларның уйдырмаларына каршы килеп, большевистик листовка һәм прокламацияләрнең дә татар хезмәт ияләренең кайнар мәхәббәтен казануын әйтергә кирәк. «Гыйнварның егермесеннән егерме беренә каршы шәһәрнең барлык заводларында (Алафузов, Крестовников, Свешников, Александров, дары һ. б.), шулай ук бөтен остаханәләре һәм типографияләрендә комитетның «Казан эшчеләренә» дигән прокламациясе рус һәм татар телләрендә таратылды... Ул телләрендә чыгарылган беренче прокламацияне татар эшчеләре полициядән бүтәннәргә караганда энергиялерәк сакладылар», дип язды «Искра» газетасы 1903 елның 1 март санында.

Рус булмаган халыклар телендә агитация һәм пропаганда әдәбияты бастыру турында РСДРПның III съезды карарларын үтәп, партиянең Казан һ. б. комитетлары 1905—1907 еллар революциясе чорында бу эшнең колачын киңәйтеп җибәрде. Нәтиҗәдә татарча листовкалар Казанда гына түгел, ә Чистай, Спас, Алабуга һәм Буада да таратылды. Алар әле хәтта татар һәм башкортлар яшәгән бөтен Идел, Урал буе губерналарына да үтеп керде[3].

Татар хезмәт ияләрен политик агартуда большевикларның «бераз уңышын» таныса да, Зеньковский шунда ук аны юкка чыгарырга омтыла. «Бу листовкаларның

---

[1] Нафигов Р. И. Формирование и развитие передовой татарской общественно-политической мысли. Казань, 1964, 107 бит.

[2] S. A. Zenkovsky. Pan-Turkism and Islam in Russia. Cambridge. (Massachusetts), 1960, 52 бит.

[3] Революция 1905—1907 годов в национальных районах России. Сб. статей. М., 1949, 676 бит.

иң зур тиражы нибары 1 300 генә данә була»,— ди ул. Әмма листовкаларның тиражы ихтыяҗга гына түгел, кәгазь, яшерен типография эше өчен шартлар булуга да бәйле икәнлеге мәгълүм. Шуның өстенә, Америка тарихчысы атаган тираж һич тә «иң зурысы» түгел әле. Совет тарихчыларына мәгълүм булганча, 1905 елның апрелендә генә дә Казан большевиклары һәрберсенең тиражы 1 200 дән алып 7 515 кә җиткән сигез листовка басалар[2] һәм ул листовкаларның һәркайсы еш кына кулдан-кулга йөртеп укыла. Шуңа да карамастан, РСДРПның Казан оешмасында татарлар саны 1905 елда да, соңрак та йөзләп түгел, дистәләп кенә иде дип, буржуаз тарихчылар җирле эшчеләр арасында большевиклар алып барган үгет-нәсихәт эшчәнлегенең нәтиҗәсезлеген күрсәтергә маташалар. Массаларга марксистик партия йогынтысы көчен аңа җәлеп ителгән кеше саны белән генә билгеләүдә буржуаз тарих фәненең кимчелекле ысулы бик ачык күренә. В. И. Ленин партиясез эшчеләргә һәм крестьяннарга «аларны шундук үз ягыбызга, үз партиябезгә тарту теләге белән түгел, бу безгә әһәмиятле түгел,— бәлки... аларның ярдәме кирәклеген аңлату теләге белән кыюрак һәм кыюрак мөрәҗәгать итәргә тиешбез» икәнен әйткән иде[3].

Социал-демократик пропаганданың тәэсире хөкем сөргән тәртипләргә каршы эшчеләрнең актив чыгышларында чагылды. 1905—1907 елларда татар эшчеләре хәрәкәте Казан губернасы белән генә чикләнмәде — ул чынлыкта татар халкы тыгыз яшәгән һәрбер губернага җәелде. Стачкаларның берсе вакытында Алафузовта эшләгән алдынгы татар эшчеләре рус иптәшләре белән бергәләп куркусыз рәвештә полиция белән бәрелешеп, кулга алынган агитаторны азат иттеләр. Кукмара киез итек фабрикасы эшчеләре көрәше дә сугышчан рухы белән аерылып торды. Уфа һәм Оренбург эшчеләре политик демонстрацияләргә чыктылар. Стачка көрәше коралль восстаниегә әверелә башлагач, Казан эшчеләре (руслар һәм татарлар), полицияне коралсызландырып, халык милициясе отрядлары оештыруга керештеләр. Шахтер булып эшләгән аңлы татар эшчеләре, украин һәм рус иптәшләре белән бергә кулга корал тотып, Донбасс баррикадаларында сугыштылар. Сембер губернасындагы Акчурин фабрикасы эшчеләре исә үз революцион идарә органы — «Эшче депутатлар Союзы (Совет)» төзеделәр.

Беренче рус революциясе һәлакәткә дучар булды. РСДРПның Казан комитеты таркатылды. Х. Ямашев һ. б. татар большевиклары шәһәрдән читтә яшеренергә мәҗбүр булды. «Үз йогынтысын мөселман массаларына җәелдерүдә социал-демократлар партиясенең бөтен тырышлыгы шул рәвешле юк ителгән булып чыкты»[4] дип нәтиҗә ясый Беннигсен һәм Келькеҗе.

Революциянең чигенүе эшчеләр аңыннан марксистик идеяләрне һич тә чыгарып бетерә алмавын, 1905—1907 еллардан соң да татар эшчеләре арасында партиянең максатлы агитация һәм пропаганда эшен туктатмавын буржуаз тарихчылар игътибарга алырга теләмиләр.

«Советологлар» татар эшчеләренең 1905—1907 еллардагы һәм 1917 елдагы революцион хәрәкәте арасында ниндидер бәйләнеш барлыгын, гомумән, кире кагалар. Алар раславынча, әгәр Беренче рус революциясе вакытында татар эшчеләр хәрәкәте гәрчә зәгыйфь булса да, марксистик йогынты кичерсә, Февраль революциясеннән соң ул, имеш, я меньшевиклар (Р. Пайпс)[5], я татар буржуаз милләтчеләре идеясе тәэсире астында үскән (А. Беннигсен һәм Ш. Келькеҗе). Үз тезисларын нигезләү өчен «советологлар» 1917 елда большевиклар партиясенең Казан комитеты составында татар хезмәт ияләре вәкилләре булмауны сылтау итеп күрсәтәләр.

Буржуаз тарихчылар Казан большевиклар оешмасында татар хезмәт ияләре дә булуын телгә алмыйча, укучыларның игътибарын юри Казан комитеты милли составына гына юнәлтәләр. Алар Казан комитеты пропагандалаган һәм яклаган «Власть — эшчеләргә!», «Җир — крестьяннарга!», «Халыкка тынычлык!» лозунгыларында илнең бөтен хезмәт ияләре, шул исәптән, татарларның да мәнфәгате чагылдырылуына күз йомалар.

---

[1] Zenkovsky S. A. Күрсәтелгән хезмәт, 52 бит.
[2] Нафигов Р. И. Күрсәтелгән хезмәт, 106 бит.
[3] Ленин В. И. Әсәрләр, 30 том, 223 бит.
[4] A. Bennigsen et Ch. Quelguejay. Күрсәтелгән хезмәт, 56 бит.
[5] R. Pipes. The Formation of the Soviet Union. Communism and Nationalism. 1917—1923. «New York. 1968, 156 бит.

1917 елда татар эшчеләре арасында Казан большевиклар комитеты белән янәшә Мөселман социалистлар комитеты да эш алып баруын көнбатыш тарихчылары антикоммунистик максатта файдаланырга омтылалар.

Мөселман социалистлар комитеты марксизмга караганда милләтчелеккә шактый якынрак иде дип белдереп, «советологлар» аны Казан партия комитетына каршы куялар.

Чынбарлыкта исә мондый капма-каршы куюлар өчен бернинди нигез юк. Мөселман социалистлар комитеты большевиклар белән революцион демократиянең сул канаты хезмәттәшлек иткән массачыл политик оешма була. Шушы юл белән Мөселман социалистлар комитетын оештыручыларның максаты үтәлә: татар эшчеләрен хезмәт иярәренең башка катлаулары белән берләштергәч, алар арасында социалистик идеяләр тарату мөмкинлеге арта.

Мөселман социалистлар комитеты эшчәнлеге большевиклар партиясенең идея җитәкчелеге җирлегендә җәелә. Ул РСДРП(б)ның Казан комитеты белән генә түгел, ә РСДРП(б)ның Үзәк Комитеты белән дә бәйләнгән була. Аның вәкиле партиянең кораллы восстание әзерләүне алга куйган тарихи VI съезды эшендә катнаша. Съезддан соң бу комитет большевиклар белән бергә буржуазиянең вакытлы хөкүмәтен бәреп төшерүгә дәртләнеп әзерләнә башлый.

Мөселман социалистлар комитеты милли, әмма милләтчелектән азат оешма була. Аның бөтен эшчәнлеге эшчеләрнең нинди милләттән булуына карамастан туганлыгы һәм хезмәттәшлеге рухы белән сугарыла. Аны төзү инициаторы һәм җитәкчесе Мулланур Вахитов горур рәвештә: «... Без Мөселман социалистлар комитеты байрагын күтәреп, интернациональ пролетариат сафына кушылдык...»[1] — ди.

Большевиклар партиясе эшчәнлеге белән марксизм-ленинизм, пролетар интернационализм идеяләре татар эшчеләре арасына үтеп керә, аларның сыйнфый аңы тиешле югарылыкка күтәрелә. 1917 елның көзендә татар эшчеләре массасының пролетариат революциясе байрагы астына басуы менә шунлыктан бер дә очраклы хәл түгел иде.

1917 елда башка милләт эшчеләре белән бергә татар эшчеләре дә катнашмаган бер генә политик компания дә булмады. Татар эшчеләренең күп өлеше белән Казан, Уфа, Сембер, Стәрлетамак, Оренбург, Әстерхан, Донбасс һ. б. тирәләрдә Кызыл гвардия отрядлары һәм эшче дружиналарына язылуы аларның югары аңлылыгын исбатлады. Күп кенә шәһәрләрдә һәм төбәкләрдә алар революцион солдатлар белән бергәләп, Совет властен урнаштыруга каршы көрәшкән кораллы контрреволюцияне бастыруда катнашты.

Коммунистлар партиясе чакыруына кушылып һәм Россия пролетариаты сафында татар эшчеләре үз-үзләрен аямыйча яшь совет дәүләтен төзүгә күренекле өлеш кертте. Алар Советларда эшләде, милиция һәм ревтрибуналларда, азык-төлек һәм җир комитетларында, Кызыл Армия төзү органнарында җаваплы вазифалар башкарды.

Татар эшчеләренең революцион хәрәкәте тарихы, шулай итеп, көрәшнең барлык чорларында пролетар милли отрядларының интернациональ теләктәшлеге хәлиткеч әһәмияткә ия булуын күрсәтә, аның уңышлары пролетар интернационализм принципларына турылыклы булуына бәйле икәнлеген ача. Бу хакыйкать эшчеләр хәрәкәтенең аерым бер илдәге практикасы белән дә, бөтен дөнья күләмендәге тәҗрибәсе белән дә раслана.

**МИДХӘТ АБДУЛЛИН,**
тарих фәннәре кандидаты.

[1] Вахитов М. Избранное. Казань, 1967, 44 бит.

# ЕГЕРМЕНЧЕ ЕЛЛАРДА ХАТЫН-КЫЗЛАР ХӘРӘКӘТЕ

Егерменче гасыр хатын-кыз хезмәтен киңрәк файдалану белән аерылып тора. Бу эш империалистик сугыш елларында бигрәк тә алга китә — хатын-кызлар элек тыелган тармакларга, әйтик, металлургия промышленносте һәм хәрби заводларга да аяк баса. Казан губернасы цензлы промышленностенда алар 1914 елда барлык эшчеләрнең 22,0 процентын тәшкил итә, 1916 елда инде бу сан 41,3 процентка кадәр күтәрелә[1].

Хатын-кызларның производствода катнашуы көчәю һәм аларның политик, социаль хокуксызлыгы яңа проблема калкытып чыгара. Фәнни коммунизмга нигез салучылар К. Маркс, Ф. Энгельс, В. И. Ленин күрсәтеп узганча, капитализм хатын-кызларны файдалы иҗтимагый хезмәткә җәлеп итеп, аның ирек өчен көрәшенә җирлек әзерли.

Элек хатын-кызлар теләсә нинди политик хокуктан мәхрүм ителү белән бергә, гражданлык хокукларыннан да шактый дәрәҗәдә чикләнгән иде. Иҗтимагый тормыштагы хокуксызлыкка гаиләдәге хокуксызлык та өстәлә килде. Россия империясе законнары җыелмасында: «Хатын гаилә башлыгы булган иренә буйсынырга, аны яратырга, хөрмәт итәргә һәм карусыз тыңларга, аңа ярарга тырышырга, бирелгән булырга тиеш», диелгән.

Хатын-кыз тигезсезлеген дин исә тагын да ныгытып куйган иде. Аларның кол хәлендә яшәвен ислам канун дәрәҗәсенә күтәрә. Шәригать, әгәр ир кеше расламаса, хатын-кыз шаһитларның сүзен дөрескә исәпләми, хөкемдә берничә хатын-кыз тавышы бер ирнекенә генә тиңләнә. Үлгәч тә хатын-кыз мәете ирнеке белән бер тирәнлектә җирләнми — аскарак төшереп куела иде... Россиядә хатын-кызларның 87 проценты укый-яза белмәгән. Изелү нәтиҗәсе булган наданлык һәм мескенлек аларның аңын богаулап тора иде.

Хатын-кызларның җәмгыятьтә тоткан урыны һәм аларны азат итү юллары прогрессив эшлеклеләрнең, шул исәптән, татар укымышлыларының да игътибарын үзенә тарта. XX гасыр башындагы барлык күренекле татар язучыларының әсәрләрендә хатын-кызларның мөшкел хәле яктыртыла. Г. Тукай, М. Гафури, Г. Коләхметов, М. Фәйзи һ. б. хатын-кызларны яклап актив чыгыш ясый. Ф. Әмирханның «Татар кызы» нәсерендә шәригать тарафыннан тыңлаучан, күндәм җан иясенә әверелдерелгән хатын-кызның чын мәгънәсендә нурсыз, шыксыз тормышы гәүдәләндерелә. Әсәрдә аның язмышы кара көч, хатын-кыз үзе — Тере курчак итеп сурәтләнә.

Шул ук вакытта татар әдәбиятына хатын-кызларның иҗтимагый көрәштә катнашуын, җәмгыять тормышында мөстәкыйль роль уйнавын раслаучы фикерләр дә үтеп керә. Бу җәһәттән күренекле язучы һәм җәмәгать эшлеклесе Г. Ибраһимов чыгышы аеруча игътибарга лаек. 1914 елда язылган, әмма үз вакытында патша цензурасы тыкшыну сәбәпле өлешчә генә басылган «Безнең көннәр» романында ул башка каһарманнар җөмләсеннән ирләр белән бергә революцион көрәшкә кушылучы һәм, шулай итеп, үзенең тигез хокуклылыгын даулаучы эшче Заһидәне гәүдәләндерә.

Хатын-кыз бәйсезлеген яклап, аның җәмгыятьтә тигез хокукка ия булырга тиешлеген таләп итеп, белем алырга хакы барлыгын исбатлап мөгаллимә Толбанат, Фәхерниса Сөләймания, Зөһрә Гаспринская, Мәхбүбҗамал Акчурина, Гыйффәт Туташ (Заһидә Борнашева) һ. б. хатын-кызлар үзләре мәйданга чыгу да игътибарга лаек.

Хатын-кызның җәмгыятьтәге урыны хакындагы яңа карашлар мәгариф мәсьәләләрен хәл иткәндә дә мәгълүм тәэсир ясый. Татар зыялыларының алдынгы вәкилләре кыз балаларны укыту белән шөгыльләнә, алар өчен үз көчләре белән

[1] Труд в бывшей Казанской губернии за пять лет существования Татреспублики. Казань, 1926, 9 бит.

мәктәпләр ача. Революция алдыннан Казанда да беренче махсус татар кызлар гимназиясе барлыкка килә (1916).

Күренекле җәмәгать эшлеклесе С. Сәетгалиев, татар хатын-кызларының хөррият даулавы бигрәк тә 1915 елдан соң көчәйде, ди: «Матбугатта, журналларда шәрык хатын-кызлары хәленә багышланган карикатуралар. Хатын-кызларның беренче мәртәбә ирләр йөгеннән ычкынуы. Театр, җыелышлар һәм, ниһаять, аерым мәктәп оешу». Шушы чорда ук Россиянең башка шәрык халыклары белән чагыштырганда, татарларда хатын-кыз азатлыгы хәрәкәтенең бик күпкә алга китүен ул басым ясап күрсәтә.

РКП(б) ҮК янындагы Шәрык халыклары коммунистик оешмалары Үзәк бюросы 1920 елда шәрык хатын-кыз коммунистлары конференциясен җыю мәсьәләсен күтәргәндә революция чорында хатын-кыз ирекге дәрәҗәсе Татарстанда Башкортстан белән Төркстандагыдан шактый аерылуын шулай ук билгеләп уза.

Татар хатын-кызлары язмышына аларның иҗтимагый хезмәткә күпләп җәлеп ителүе көчле йогынты ясый. Татарстан республикасы төзелгән чакта татар хатын-кыз эшчеләре өч меңгә якын булып, аларның күпчелеге Казанның Крестовниковлар һәм Алафузовлар заводларында хезмәт итә. Болак артындагы төрле кустарьларда да байтак хатын-кызлар эшли.

Хатын-кыз хезмәтенең роле һәм әһәмияте әкренләп авылда да үзгәрә. Сугыш елларында хатын-кыз авыл хуҗалыгында төп көчкә әверелә. «Эшче» газетасы язуынча, 1914—16 еллар татар хатын-кызларын мөстәкыйль рәвештә тормыш алып барырга өйрәтә.[1]

Хатын-кызлар хәлендә борылыш Октябрь революциясе җиңүеннән соң башлана. Пролетариат диктатурасын урнаштыру, җитештерүдә капиталистик ысулны юкка чыгару илебез хатын-кызларын тулысынча азат итү, аларны социалистик төзелешкә тарту өчен шартлар барлыкка китерә. 1917 елның ноябрендә, совет власте җиңүгә, «Россия халыклары хокуклары декларациясе» кабул кылына, 1918 елның гыйнварында исә хатын-кызларны хокукта ирләр белән тиңли торган «Хезмәт ияләре һәм изелгән халык хокуклары декларациясе» кабул ителә. Хатын-кызларга политик, экономик, гражданлык хокуклары бирү Совет властеның байтак декретларында һәм 1918 елның июлендә Бөтенроссия советларының V съезды кабул иткән Совет республикасының беренче Конституциясендә беркетелә. Политик тигез хокуклылык хатын-кыз хезмәт ияләренә җәмгыять тормышына актив катнашырга юл ача.

Совет чорында хатын-кыз мәсьәләсе социалистик төзелешнең состав өлешенә әйләнә. Чөнки аны хәл итмичә социализм төзү мөмкин булмый. «Совет власте тарафыннан башланган бу эш, — ди В. И. Ленин, — аңа бөтен Россиядә йөзләрчә хатын-кызлар урынына миллионнарча һәм миллионнарча хатын-кызлар катнашканда гына алга китә алачак».[2]

Аеруча артка калган катлауларның активлыгын уяту, аларны пролетариатка ят идеология йогынтысыннан азат итү, гаиләдә һәм көнкүрештә искечә мөнәсәбәт калдыкларын бетерү өчен партия һәм дәүләт үзалдына хатын-кызлар арасында системалы рәвештә ныклап эшләү бурычын куя. Аларны политик яктан тәрбияләүгә аерым игътибар бирелә. Шушы юнәлештә эшләү формалары һәм алымнарын билгеләү өчен 1918 елның ноябрендә эшче хатын-кызларның Бөтенроссия съезды чакырыла. Съезд программа кабул итә, аны тормышка ашыру ысулларын ачыклый һәм шул максатта махсус аппарат кора.

Эшче хатын-кызлар хәрәкәте күтәрелешенә коммунистлар җитәкчелек итә. Инде булдырылган милли секцияләр үрнәгендә 1919 елның апрелендә партия оешмалары составында аерым хатын-кызлар секциясе оештырыла. Казан губкомының шундый секциясе крайның барлык коммунистларын һәм аларга теләктәшләрне колачлап ала.

Тора-бара булачак республиканың барлык хатын-кызлары арасында актив эш җәелдерелә. Беренче булып, әлбәттә, коммунистлар җитәкчелегендә төп сыйныф вәкилләре оеша.

[1] «Эшче», 1920 ел, 5 апрель.
[2] В. И. Ленин, Әсәрләр, Татарстан китап нәшрияты, т. 30, 30 бит.

Татар хатын-кызлары хәрәкәтенә җитәкчелек итү өчен РКП(б) ның Казан губкомы Мөселман секциясе Зөһрә Бәембәтованы инструктор-оештыручы итеп билгели. Шуннан соң Казанның татар хатын-кызлары күп яшәгән Плэтән һәм Берләшкән-Бистә районнарында да эшкә инструкторлар җибәрелә.

1919 елның 28 сентябрендә Дары районында татар хатын-кызларының беренче җыелышы уздырыла. 70 кеше катнашкан бу җыелышта «аларның культура дәрәҗәсен һәм сыйнфый аңын күтәрү максатларында» махсус түгәрәк оештырыла. Түгәрәк президиумына Хөсниҗамал Вәлитова, Фания Иматева, Мәрзия һәм Фания Ишмәтевалар, Асия Морадинова, Фәкыя Хәмидуллина һәм Разия Уаткиналар керә. Алар җыелыш һәм митингларның регуляр үткәрелүенә булыша, лекцияләр оештыра.

Алафузовлар фабрикасында М. Җаббарова, Х. Гыйльметдинова, Х. Мөбәрәкшина, Ш. Фәхретдинова, Н. Хәйруллина, Г. Шәймөхәммәтевалардан гыйбарәт актив туплана.[1] Шушы алдынгы эшчеләргә таянып, җирле партия оешмасы хатын-кыз хезмәт ияләре массасы арасында эш җәелдерә.

1919 елның октябрендә эшче хатын-кызлар хәрәкәте белән җитәкчелек итү партия комитетлары составындагы махсус хатын-кыз бүлекләренә тапшырыла. 1920 ел башында инде Үзәк комитеттан башлап барлык район (шәһәрләрдә) һәм өяз комитетларында хатын-кыз бүлекләре төзү төгәлләнә. Казан губкомының хатын-кызлар бүлегенә беренче җитәкче итеп Н. А. Ванькова билгеләнә.

Хатын-кызлар бүлекләре эшче һәм крестьяннарны партия, совет, кооператив һәм профсоюз төзелешенә җәлеп итү буенча зур оештыру һәм пропаганда эшләре алып бара.

Хатын-кыз массаларын илебезнең хуҗалык тормышына тартуда Мәскәү эшчеләре инициативасы белән оештырылган партиясезләр конференцияләре һәм җыелышлары да зур роль уйный. В. И. Ленин аларны югары бәяләп, партиянең икенче ярдәмчеләре, дип атады.

Съездлар һәм конференцияләр уздырып, хатын-кызларны оештыру татар хезмәт ияләре, шул исәптән, крестьяннары арасында эшләгәндә дә киң кулланыла. Тормыш рәвешләре һәм хезмәт шартлары аркасында үтә таркау хәлдә яшәгән крестьяннар өчен башлангыч чорда съездлар һәм конференцияләр аеруча әһәмияткә ия иде.

Казан хатын-кызларының беренче шәһәр партиясезләр конференциясе 1920 елның 8 мартында 500 кеше катнашында уздырыла. Конференциягә барлык милләтләрнең дә вәкилләре җыйнала һәм алар хатын-кыз эшчеләр алдында торган бурычларны тикшерә. Шагыйрь һәм җәмәгать эшлеклесе А. Безыменский «Совет власте хатын-кызларга ни бирде, бирә, һәм бирәчәк» дигән темага доклад ясый.

Бу чорда конференция һәм җыелышлар уздыру киң колач ала. Крестьян хатын-кызларны политик тормышка активрак катнаштыру өчен хатын-кызлар бүлекләре эшче һәм крестьяннарның уртак өлкә конференцияләрен дә уздыра. Аларны өзерләгәндә әһәмиятле политик һәм хуҗалык мәсьәләләрен тикшерүдә массаларның катнашуы зарурлыгын күрсәтеп, җыелышлар һәм аңгәмәләр үткәрелә. Бу эшкә партияле хатын-кызларның барысы да дип әйтерлек тартыла.

Республикабыздагы хатын-кызлар бүлекләре эшендә грамотасызлыкны бетерү һәм дини хорафатларга каршы көрәшү дә мөһим урын тота. Гражданнар сугышы чорында ук губерна хатын-кызларын укырга-язарга өйрәтү буенча беренче адымнар ясала һәм бу эш хәтта ачлык шартларында да тукталмый. Грамотасызлыкны бетерү турында 1919 елның 26 декабрендә кабул ителгән декрет хатын-кыз делегатлары җыелышларында, җирле интеллигенция, аеруча мөгаллимнәр арасында киң тикшерелә.

Өяз шәһәрләрендәге һәм бигрәк тә авыллардагы мөгаллимәләр крестьян хатын-кызлары арасында эшне җанландыруда күренекле роль уйный. Партия җитәкчелегендә Абруй Сәйфи, Зөһрә Бәембәтова шикелле яшь укытучыларның кайбер

[1] В. Смирнова. Женщины Татарии в борьбе за власть Советов. Казань, 1963. 1 чыгарылыш. 21 бит.

ләреннән талантлы оештыручылар — татар хатын-кыз хезмәт ияләре хәрәкәтенең беренче эре эшлекләләре үсеп чыга. Зөя кантонының Норлат авылы укытучысы Азатова кантон хатын-кызлар бүлегенә инструктор итеп күчерелә. Партиянең Чистай өяз комитеты каршында хатын-кызлар арасында эшли башлаган укытучы Елена Павлова соңыннан Татарстан республика хатын-кызлар бүлегенә җитәкчелек итә.

Эшче хатын-кызларның укырга-язарга өйрәнүләре хезмәт квалификацияләрен күтәрү белән бергә алып барыла. Фабрика-заводларда өйрәнчеклек узу, профсоюз мәктәпләрендә уку, производствода үзлегеннән һөнәр үзләштерү кебек формалар аларны иҗтимагый хезмәткә әзерләүдә һаман киңрәк таралыш таба. Татарстанда фабрика-завод өйрәнчеклеге мәктәпләре беренче тапкыр 1923 елда ачыла.

Хатын-кызларны югары белем алуга җәлеп итү эше дә елдан-ел көчәя. Бөтен илдәге кебек, республикабыз югары уку йортлары каршында да рабфаклар ачыла. 1923—1924 уку елында гына да аларга 116 кыз укырга җибәрелә.

Бу чорда делегатлар җыелышы хатын-кызлар арасында эшләүнең төп формасына әйләнә. Делегатлыкка алар мәгълүм бер срокка сайлана. Бу җыелышларда системалы рәвештә РКП(б) ҮК пропаганда бүлеге һәм Үзәк хатын-кызлар бүлеге эшләгән программалар буенча политграмота дәресләре бирелә. Делегатлар җыелышлары хатын-кызларның киң массасын халык хуҗалыгын торгызу, ачлык нәтиҗәләрен бетерү, караучысыз балаларны тәрбиягә алуда республикабыз партия оешмаларының ышанычлы таянычына әверелә.

РКП(б)ның XIII съезды карарларын үтәп, республикабыз партия оешмалары советлар составына хатын-кызларны күбрәк тәкъдим итә башлыйлар. Крестьян хатын-кызларын хезмәткә тартуга аерым игътибар бирелә. Делегат җыелышлары системасында тәҗрибә туплый башлаган хатын-кызлар җәмәгать эшләрен шактый уңышлырак башкара.

Хатын-кызларның сайлауларда катнашуы тора-бара аларны политик һәм гражданлык хокуклары тиңлегенә күнектерә. Бу җәһәттән Бөгелмә кантоны Кандыз авылында яшәүче Мифтахетдинованың фикер йөртүе кызыклы. Авыл советына сайланганнан соң ул: «Элекке депутатлар начар эшләде, җирнең күп өлеше кысыр калды. Без бу кимчелекне төзәтергә тиеш. Авыл советында эшләгәндә мин хатын-кызларның җәберләнмәве, совет властеның бөтен декретларын белеп торуы өчен тырышачакмын»,— ди. Крестьян хатын-кызлары үзләрен тормышка һәм дәүләткә хуҗа итеп шулай тоя башлый.

Республикабызның хөкем органнарына да хатын-кызлар торган саен күбрәк сайлана. Бу чорда Әминә Мөхетдинова республика прокуроры, Ягъфарова, Акбирдина һ. б. халык судьялары булып хезмәт итә. 1925 елда халык утырышчылары итеп 1870 хатын-кыз, шул исәптән, 598 татар сайлана. Адвокатлар коллегиясендә 9 хатын-кыз, шул исәптән, ике татар эшли.

Хатын-кызларның политик аңы үсешен республикабыз партия оешмаларында аларның саны арту да раслый. РКП(б) сафларына татар хатын-кызларын алуга аерым бер игътибар бирелә. Бу җәһәттән Бондюг заводы эшчесе Мөхәммәдиева Бәдәрнең 1923 елда партиягә кабул итүне сорап язган гаризасы кызыклы. «Мин үземне кадерле партиябезгә ихлас күңелдән теләктәш саныйм, — ди ул. — Пролетариатның чын вәкиле гаризасын кире какмавыгызны үтенәм. Бары РКП(б) гына хатын-кызларны азат итүне хәл итә ала, мин шул гаиләнең бер әгъзасы булырга телим». 1926 елның 1 декабренә республикабызның 1273 хатын-кызы партиягә кандидат һәм член итеп кабул ителә. Шуларның 245 е — татар хезмәт ияләре була.

Партия оешмалары хатын-кызларны интернациональ чыныктыруга да зур әһәмият бирә. Күп милләтле республика шартларында илебез халыкларына, бөтен дөнья хезмәт ияләренә хөрмәт һәм дуслык хисләре тәрбияләү гаять мөһим була. Моның өчен күп төрле чаралар тормышка ашырыла. Башка илләрнең хезмәт ияләренә теләктәшлек рухында политик компанияләр уздырыла. Хатын-кызларны революция көрәшчеләренә ярдәмләшү Халыкара оешмасы әгъзасы итеп кабул итәләр. Алар халыкара пролетариатны яклап уздырылган эшләрдә катнаша, коминтернның халыкара конгресслары, бөтен илләрнең коммунистлары халыкара конференцияләре чакыруларына кушылалар.

1921 елның 7 декабрендә дүртенче өлкә конференциясе делегатлары алдында АКШ Компартиясе ҮК әгъзасы иптәш Кар Америкадагы эшчеләр хәрәкәте хакында доклад ясый. Чыгыш тәмамлангач, конференциядә катнашучылар Америка хатын-кыз эшчеләренә мөрәҗәгать кабул итәләр. «Без, Россия хатын-кызлары, — диләр, — сезгә дусларча, иптәшләрчә сәлам җибәрәбез. Өч еллык гражданнар сугышында ирләребезне һәм балаларыбызны Кызыл фронтларда югалтуга карамастан, Татарстан республикасында ачлык аркасында тормыш шартларыбыз авыр булуга карамастан, барыбер рухны төшермибез, кызыл әләмне алга алып барып, тормышта яхшы киләчәккә, социализмга омтылабыз.

Кадерле иптәшләр, Америка эшче хатын-кызлары! Бездән үрнәк алыгыз. Революциянең кызыл факелын үз илегездә кабызыгыз, чөнки без, эшче хатын-кызлар — бер гаилә, бер гомуми бердәмлек булып капитал изүеннән котылырга, социализм патшалыгына барып җитәргә тиешбез».

Бу мөрәҗәгатьнең эшләнеше үзе үк элек хатын-кыз эшчеләр тормышында мисалы юк бер вакыйгага була: алар олы дәүләт проблемаларын тикшерә, шуларны чишүгә үзләреннән өлеш кертергә омтыла.

Октябрь революциясенең хатын-кыз язмышына үзгәреш кертүе татар әдәбиятында да чагылыш таба. А. Шамовның «Рәүфә» хикәясендә гаиләдә җәберләнгән Рәүфәгә шәһәрдән килгән «шәлле хатын»ның булышуы сурәтләнә. Совет власте изелгәннәргә ярдәм кулын шулай суза. Татар кызының революциягә кадәрге һәм совет чорындагы тормышы турында егерменче елларда әдәбиятка килгән шагыйрә Зәйнәп Бәширова болай яза:

**Яшьлегемдә кош кебек**
**Читлектә тоткын иттеләр.**
**Якты дөньяга чыгармый**
**Күкрәгемне черттеләр.**

**...Ә хәзер инде азат,**
**Мәңге азат, мин — эшчемен,**
**Күкрәгем гайрәтле, дәртле,**
**Мин иманлы, көчлемен.**

Татарстанның данлы кызлары шәрыктәге кардәшләрен хөрриятккә чыгаруда һәм социализм төзүчеләр сафына тартуда да зур роль уйный. Татарстан вәкилләре көнчыгыш республикаларда эшләр өчен әледән-әле юнәлтеп торыла. Урта Азиягә, Әстерхан, Саратов, Оренбург губкомнарына хатын-кызлар арасында таратыр өчен татар телендәге әдәбият, методик кулланмалар даими җибәрелә. Чувашия һәм Мари өлкәләре хатын-кызлар бүлекләренә һәр вакыт практик ярдәм күрсәтелә.

Егерменче еллар — хатын-кызларны күпләп иҗтимагый хезмәткә җәлеп итү дәвере. Бер үк вакытта хатын-кыз ана, гаилә әгъзасы вазифаларын профессиональ хезмәт белән бәйләп алып барырлык социаль көнкүреш шартларын булдыру өчен күп кенә эшләр эшләнә. Бөтен илдә аналарны саклау системасы, балалар учреждениеләре челтәрләре корыла, халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү оешмаларына нигез салына.

Халыкара балалар елында совет властеның аналар һәм балалар турында кайгыртуы әнә шулай революциядән соң ук башлануын искәртү зарур. Хәзер бездә аналар һәм балаларга бушлай дәвалау-профилактика ярдәме күрсәтелә, хатын-кыз, балалар консультацияләре һәм поликлиникалары саны Татарстанда 360 тан артыграк.

Хәзер илебездә хезмәткә яраклы хатын-кызларның туксан проценты эшли яки укый. Экономика, культура, фән өлкәләрендә бүген хатын-кыз эшләмәгән бер генә тармак та юк. Республикабыз халык хуҗалыгында югары һәм махсус урта белемле 175,6 мең хатын-кыз, шул исәптән, 60,8 мең татар эшли. Хатын-кызлар партия һәм дәүләт аппаратында да лаеклы урын алды. СССРның яңа Конституциясе аларның ирләр белән тигез хокуклылыгын гарантияли, бәхетле тормыш кичерергә шартлар тудыра.

**Т. БИКТИМЕРОВА.**

# МОСТАЙ КӘРИМГӘ 60 ЯШЬ



*Мостай Кәрим — Башкортстанның халык шагыйре — татар укучысына да яхшы таныш. Безгә дә ул якын, кадерле исем. Үз халкы өчен зур булган шагыйрь башка халыклар өчен дә шундый булып кала — бүлгәләнми, һәркемгә җитә.*

*Мостай Кәрим — олпат язучы. Аның зурлыгы СССР Дәүләт премиясе лауреаты булу һәм башка регалияләр белән чикләнми. Төрле жанрларда иҗат итә алуы белән генә дә аңлатылмый.*

*Заманында калын-калын томнар чыгара белгән кечкенә әдипләр була килгән һәм бәлки була торыр. Көнчыгышның атаклы шагыйре Гомәр Хәйям миниатюралар — робагыйлар белән бөек. Дөньяда Пушкин, Лермонтов, Такташ, Җәлил кебек, шигырьләр белән бергә, зур күләмле поэмалар, драма әсәрләре, роман-повестьлар язган киң колачлы шагыйрьләр булган һәм була торыр. Мостай Кәрим — шушы соңгылар гаиләсеннән. Минем үзем бу гаилә кешеләре күбрәк ошый.*

*Дистә-дистә шигырь һәм поэма китаплары белән бергә, халык арасында нык танылган «Ай тотылган төндә», «Салават», «Ташлама утны, Прометей» исемле трагедияләре, «Озын-озак балачак» исемле повесте Мостай Кәримне «Зур әдәбият» дигән дөнья белән тоташтыра.*

*Язучының көче, әлбәттә, киңлектән бигрәк, тирәнлектә, сәнгатькә гомумән хас сыйфатта: тойгылар чынлыгы-киеренкелегендә, милли һәм вакыт чикләрен узганда коелып төшми, кимеми торган фикерләр, образлар тыгызлыгында. Мостай Кәрим үзенең кечкенә күләмле әсәрләрендә дә, поэма һәм драмаларында да, шулай ук прозасында да киеренке, чын, бөтен килеш саклана. Кайсы аргамакта булмасын, ул — үз иярендә.*

*М. Кәримне татар укучысына якын иткән сыйфатларның тагын берсе — ихтирамның бер генә яклы булмавындадыр. Шагыйрь безнең күп кенә яшь һәм урта буын әдипләр өчен дус һәм остаз буларак хөрмәт казанса, ул мең елга якын традициясе булган татар әдәбияты патриоты икәнлеген үзе дә сиздерә килә. Аның Тукай һәм Җәлил хакында шигырь һәм мәкаләләр белән үзәк матбугатта чыгышлар ясавы — шуның матур, эшлекле галәмәте. Бу урында «киләчәктә дә шулай дәвам итсен» дигән теләк кенә өстисе кала.*

*Еллар М. Кәримгә әйтерсең кагылмый узалар. Аның иҗаты үз кайнарлыгын киметми генә түгел, киресенчә, көчәйтә генә бара. «Мәхәббәтнең дүрт мизгеле» исемле соңгы китабы — шуны аермачык күрсәткән шаһадәтнамә. Монда, тойгылар нәфислеге сакланган хәлдә, йөрәк зирәклеге арта, дөнья төсләре, тавышлары күбәя бара. Монысы инде — киләчәк уңышлар, яңа матур очрашулар вәгъдәсе. Шагыйрь үзенең 60 яшь тулу бәйрәмен эшләнгән эшләре белән бергә, шундый нигезле вәгъдәләр белән дә каршылый.*

*Иҗатында, тормышында без аңа яңа ачышлар, бетмәс-төкәнмәс яңа бәхетләр телибез.*

**ӘХСӘН БАЯНОВ.**

## Мостай Кәрим

### Ашыкма килергә, картлыгым

Уртлам суым әле йотылмаган,
Аткан угым сәпкә[1] җитмәгән лә,
Чикләвегем әле чәчкә атмаган,
Кәккүк оя корып бетмәгән лә...

Ашыкмый тор, картлык. Кабаланма.
Бер мәхәббәт җыры җырлыйсым бар.
Сагыш рәхәтенә чыдый алмый,
Җирдә аунап, әле елыйсым бар.

Ашыкмый тор, картлык. Кабаланма.
Түр башымда йомшак түшәгем юк.
Алларыңа куяр өчен әле
Ширбәт тулы алтын көршәгем[2] юк.

Әгәр килә калсаң, үкенерсең.
Минем әле малай буласым бар.
Акылыма йөрәк баш бирмичә,
Тәүбә итәрлек эшләр кыласым бар.
Ашыкмавың хәерлерәк, картлык...

●

Бүген төн мин синең янда калам,
Өзеп сәфәремне.
Кулым белән сыпырып йөрәгемнән
Бөтен хәстәремне.

Артык елларымны капка артында
Калдырып ук кердем.
Мин гамьсезмен, яшьмен, йөгәнсезмен —
Мин әле дә — минмен!

Синдә калам. Ял итсеннәр юллар
Минем табаннардан,
Йолдызлар ял итсен карашымнан.
Күпме заманнардан
Тынгылык юк дала тынлыгына
Минем тавышымнан.
Тынлык та ял итсен. Шул мәл безнең
Җаннар кавышырлар...

---

[1] Сәпкә — мишеньга.
[2] Көршәгем — чүлмәгем.

Йокласын җил, акыл, диңгез, курку —
Шымсын бар дөньясы.
Тик мәхәббәт кенә — бер ул гына —
Бүген күз йоммасын.

●

Без өчәү бу таңда —
Син, җиһан, мин.
Юк нәрсә юк монда: зыр әйләнә
Планеталар. Бал кортлары оча,
Таулар күкри, күкләр бизәкләнә.

Юк нәрсә юк монда: баш калкыта
Алчак, сабый үлән кыяклары,
Кош юлыннан чапкан боланнарның
Очкын чәчә көмеш тояклары.

Без өчәүбез бу мәл — син, җиһан, мин.
Вакыт тынсын, какма күз керфегең.
Кага күрмә. Әле таммый торсын
Керфек очындагы яшь бөртегем —
Минем яшь бөртегем...

Син хәйрансың —
Җиһан сыйган синең карашыңа.
Ә мин сокланамын бары сиңа —
Замананың бер кыз баласына.

●

Мәхәббәтем һәлак булыр дип гел куркам.
Һәр вакыт ул сугыш кырында.
Мәкер, хыянәтнең күпме тубы
Аңа атар өчен корылган.

Яла мылтыклары тәте тарткан,
Гайбәт обрезлары тоскалган[1],
Көнчелекнең утлы сөнгеләре
Аны чәнчү өчен очланган.

Баш өстендә кизәнүле тора
Гаепләүнең «гадел» чукмары.
Йөрәгенә килеп бәреләгел
Шик-шомнарның тупак уклары.

Җәрәхәтләр ала. Каннар тама,
Җәрәхәте җөйсез уңала[2].
... Чая мәхәббәтем яу кырында,
Бәлки исәндер ул шуңа да...

---

[1] Тоскалган — төбәлгән.
[2] Уңала — төзәлә.

## Кич килә

Юлга иртә чыктым. Эңгердән үк.
Чулпан нуры төште сукмагыма.
Юлым уңды. «Иртә юл уңар» дип
Әйтмәгәннәр икән юкка гына.

Юл башымда дүрт як кыйбла иде.
Кояш чыкты җирнең дүрт ягыннан.
Күз тимәсен! Алдан йөгереп китте
Шау ялтырап торган өр-яңа дан.

Бара торгач белдем: дөнья үзәге
Түгел икән кыйбла тарафында.
Көнчыгыш бар, янә көнбатыш бар —
Калган яклар шулар арасында.

Бара торгач дан таушалып бетте,
Укалары коелып, тоныкланды.
Мин атлыймын бер көй. Ул, өшәнеп,
Чак иярер хәлгә торып калды.

Урау юллар адаштырмый икән
Иртә таңнан чыккан гамьле ирне.
Юлым уңды. Мин үземне таптым.
Сөйгән ярым, язмыш сине бирде.

Хәзер менә тыныч карап торам
Көн гомере кичкә авышканын.
Якты белән Җылы аерылышып,
Шәүлә белән шәүлә кавышканын.

Кояш бата. Туфрак куенына
Җем-җем итеп көн җылысы сеңә,
Әйтерсең лә төнге бер мизгелдә,
Бер сәгатьтә мин сыенам сиңа.

Бер пар ак күбәләк (без түгелме?)
Туй сәяхәтеннән кайтып килә.
Бөтен гомерләре, шул туй булып,
Көн эчендә узды елый-көлә.

Иртән очар бүтән күбәләкләр...
Мин басармын тагын сукмагыма.
Ә шулай да, монау кичкә карап,
Уйлануым түгел юкка гына.

●

И Мәхәббәт! Тилерткеч бер язда,
Сандугачлы язда
Чагылда
Исемеңне ак каенга уйдым
Әле малай гына чагымда.

Зәһәр кышта, тере күмер тотып,
Бозга яздым — түгел заяга.
Җилләр белән яздым диңгезләргә,
Яшен белән яздым һавага.

Гомер буе ак кәгазьгә язам
Я әрнүле, я шат мәлләрдә.
Язарларга миңа язмасын тик
Исемеңне кара мәрмәргә.

●

Кешеләр төнгә узалар
Парлап я берәм-берәм.
Кемдер чыга ялгызлыктан,
Мин ялгызлыкка керәм.

Меңнән берәү идем көндез.
Хәзер инде башкамын —
Ялгызлык дигән буш илдә
Мин бер боек патшамын.
Минем чиксез биләмәмдә
Давыл да юк, сил дә юк.
Анда бушлык. Анда син юк.
Син булмагач, мин дә юк.

Төн үзәге сынды. Вакыт
Таңга авышыр менә.
Бу мәл уяу бик бәхетле,
Бик сагышлылар гына.
Бәхетлеләр — хәтерсезләр —
Искә алмаслар безне.
Сагышлылар! Бер мин генә
Аңлыймын хәлегезне...

●

Эшләнмәгән эшләр кала,
Калган эшкә карлар ява.
Үтелмәгән юллар ята,
Ул юлларга таулар ава.
Үткәннәргә карлар ява,
Тыңланмаган җырлар кала,
Йөрәкләргә каннар сава.

●

Дөньяның йөзе күренми —
Дөньяга томан төште.
Иртә томан, кич тә томан —
Мәңге таралмас төсле...

Төшкән томан күтәрелде,
Булган да кебек түгел.
Аязуыңны сабыр көт,
И күңел!
Күңел...

●

Намус белән безнең ара сәер.
Миңа рәхәт. Ә ул хафалы.
Мин җәфалар чигәм, газапланам.
Ә ул тыныч. Хакны-хатаны
Һәр беребез үзенчәрәк саный.
Мин җөп дисәм, анда так чыга.
Минем бизмән артыграк тартса,
Аның үлчәү төгәл, хак чыга.
Мин инсафлы, кечелекле булсам,
Намусымның башы югары.
Мин масаеп, һаваланып китсәм,
Ул бөтенләй кала югалып.
Ара бозылганда мин шәрабтан
Бурыч шатлык алып, куанам.
Я башымны тансык сөйгән ярның
Беләгенә салып, юанам.
Ә, ихтимал, килер шундый бер көн:
Ярым ташлар, бокал ватылыр,
Намус белән күзгә-күз калырбыз.
Менә ул чак ниләр татылыр?

Геннадий Муханов

# ӘДӘБИ ПРОЦЕСС ҺӘМ СОЦИАЛИСТИК ЯШӘҮ РӘВЕШЕ

Социалистик яшәү рәвеше турында сөйләгәндә, сүзне аның әхлакый нигезеннән башлыйсы килә. Бу төшенчә кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең иң күркәм сыйфатларын бер төенгә бәйли. Әйтик, тигез хокуклылык, дуслык, туганнарча ярдәмләшү әнә шундыйлардан санала.

Ул асылы белән интернациональ. Аның тамыры бик тирәнгә, җәмгыятебезнең барлык катлауларына үтеп керә. Советча яшәү рәвешендә илебез халыкларының какшамас бердәмлеге, олы максатка омтылышы, җиңелмәс көче, оптимизмы көзгедәгедәй ачык чагыла. Бездә һәр халык, һәр шәхес социалистик яшәү рәвешен баетуга, аның яңадан-яңа күркәмрәк сыйфатлар алуына үзеннән мөмкин кадәр зуррак өлеш кертергә омтыла.

Бу төшенчәнең эчтәлеген дөрес аңлаганда гына аның тулы картинасын күз алдына китерергә мөмкин. Барыннан да элек, ул һәр халыкка хас. Шул ук вакытта тирән эчтәлекле әлеге тарихи күренеш аларның уртак казанышы, гомуммилли горурлыгы да булып тора. Социалистик яшәү рәвеше халыкларның милли үзенчәлеген чикләми. Киресенчә, ул аларның прогрессив милли традиция һәм йолалары исәбенә һаман тулылана бара.

Һәр заман халыкларның яшәү рәвешенә яңа сулыш алып килә. Әлбәттә, бу хәл әдәби процесста чагылмыйча кала алмый. Чөнки әдәбиятның бурычы да нәкъ менә яңалыкны тотып алудан, заман героена хас сыйфатларны күрә белүдән гыйбарәт бит. Шуңа да ул һәр әдәбият өчен иксезчиксез илһам чыганагы ролен үти. Совет кешеләре тормышында һәм яшәү рәвешендә барган үзгәрешләр әдәби геройны яңа, матур сыйфатлар белән баета. Ә әдәби агым табылган белән генә канәгатьләнеп калмыйча, замандашыбызның рухи йөзен яңарак яклары белән ачарга, һәр милләтнең бәхетле язмышын олы, калку итеп күрсәтергә омтыла. Соңгы ун-унбиш елда дөнья күргән әсәрләрнең оптимистик рухын нәкъ менә шуның белән аңлатырга мөмкин.

СССР халыклары әдәбиятын күздән кичергәндә, социалистик яшәү рәвешенең, барыннан да элек, хезмәт кешесе образында, аның эшләрендә һәм уйларында чагылуына игътибар итәсең. Хәер, бу бик табигый дә. Чөнки хезмәт кешесе, эшче образы — совет әдәбиятының төп, типик герое. Ул күп кенә әсәрләрдә коммунизмны актив төзүче, югары иҗтимагый аңга ия булган хезмәт сөюче шәхес буларак тасвирлана. Шуңа да ул һәр халык тормышында бара торган тирән үзгәрешләрнең иң алдыннан атлап килә, яңага юл яра. Эшчеләр тормышы хакында материалның күп һәм төрле булуы язучыларга киң иҗат мәйданы ача. Алар эшче образы аркылы халыклар дуслыгы идеясен үткәрәләр, интернационализм темасын яктырталар, тормышыбызның катлаулы социаль-политик, фәлсәфи проблемаларын күтәреп чыгалар.

СССР язучыларының VI съездында хаклы рәвештә әйтеп үтелгәнчә, совет җәмгы-

яте тормышындагы яңа процессларны, шул җөмләдән социалистик яшәү рәвешен үзләштерүдә хәзерге күп милләтле әдәбиятыбыз мактаулы роль үти. Бүген байтак философ, социолог һәм экономистларның материал эзләп әдәби әсәрләргә мөрәҗәгать итүе үзе генә дә күп нәрсә турында сөйли. Кызганычка каршы, әдәбият эшлекләләре социаль фәннәр казанышын йомшак үзләштерәләр, философ һәм социологлар өчен бик гадәти булган терминологияне әдәби әйләнешкә бик акрын кертәләр. Бу җәһәттән, В. Роговин, Н. Шамота, Ю. Суровцев, Ф. Кузнецов кебек тәнкыйтьчеләрнең эстетик аспектларны өйрәнүдә язучыларның «кыюсызлыгын» тәнкыйтьләп чыгулары бик тә урынлы [1].

Әлбәттә, советча яшәү рәвешенең эстетик аспектларын өйрәнү каләм ияләренә бу өлкәдә яңа офыклар ачачак, үз геройларының эштә, көнкүрештә үзара аралашу һәм якынаю процессын ачыграк күрергә ярдәм итәчәк. Аларны бер төенгә бәйләп, ягъни эчке органик бердәмлектә күрсәтүгә ирешү дә зур әһәмияткә ия. Ни дисәң дә, әдәби әсәрнең төп тукымасын тәшкил итүче бу бердәмлек, барыннан да элек, геройның социаль яшәештәге милли һәм интернациональ формалар белән бәйләнешенә килеп тоташа. Совет кешесенең әхлак йөзе, дөньяга карашы, рухи культурасы аның холкында, үз-үзен тотышында, хәтта иң нечкә интим хисләрендә чагыла. Әмма монда төп рольне социаль мохит уйный. Кеше үзенең бөтен тулылыгы белән нәкъ менә шул мохитта ачыла да инде. Шуңа да совет әдәбиятының алдынгы вәкилләре конкрет тормыш материалына социаль яңгыраш бирергә, аны шул җирлектә гомумиләштерергә омтылалар. Шул ук вакытта алар иҗатында геройның социаль мөнәсәбәтләре шәхси, интим, психологик мөнәсәбәтләр белән дә аерылгысыз бәйләнештә бирелә. Бу уңайдан эшчеләр сыйныфы турында язылган күп кенә күләмле әсәрләр авторы Михаил Колесниковның фикере игътибарга лаек. Ул индивидуаль мөнәсәбәтләрнең социаль мөнәсәбәтләргә һәм, киресенчә, социаль мөнәсәбәтләрнең шәхси мөнәсәбәтләргә якынаюының әхлак

[1] В. Роговин. Яшәү рәвеше — сәнгать коралы.— «Литературное обозрение», 1973, 10 сан; Н. Шамота. Әдәбият һәм җәмгыятьнең яшәү рәвеше.— «Радуга», 1976, 1 сан; Ю. Суровцев. Социалистик яшәү рәвеше һәм әдәбият.— «Литературная газета», 2—9 июнь, 1976; Ф. Кузнецов. Яшәү рәвеше, әдәбият, идеологик көрәш.— «Литературное обозрение», 1976, 4 сан.

проблемаларына бик зур этәргеч бирүе турында язып чыккан иде [2]. Әлбәттә, язучы бөтенесен әхлак мәсьәләсенә кайтарып калдыруы белән хаклы түгел, диясе килә. Социаль мөнәсәбәтләрнең шәхси мөнәсәбәтләргә якынаюы, мәсәлән, халыкларның дуслык, туганлык идеаллары чынга ашуда бик зур әһәмияткә ия. Герой прогрессив милли һәм интернациональ сыйфатлар белән ныграк баый барган саен, социалистик милләтләрнең чәчәк ату һәм үзара якынаю процессын тагын да ачыграк итеп күз алдына китерәсең. Тормыш материалына сәнгатьчә сурәтләү ачкычы табу, художникның хәбәрдарлыгы, мөстәкыйльлеге менә шунда күренә дә инде.

Чыннан да, күп милләтле совет әдәбияты әсәрләренең байтагында социалистик милләтләр тормышындагы бөек үзгәрешләр тулы күрсәтелә. Мәсәлән, Камадагы автомобиль төзелеше, Братскидагы энергетика промышленносте комплексы кебек гигант индустриаль объектларны салуга багышланган әсәрләрдә геройның югары әхлак сыйфатлары, совет кешеләренең дустанә мөнәсәбәтләре, интернационализмы беренче планга куела. Яки Татарстан, Башкортстан һәм Төмәндә нефть байлыгын үзләштерүгә, бүгенге фән-техника прогрессын тормышка ашыруга багышланган әсәрләрне алыйк. Аларда да хезмәт кешесе беренче урынга куеп сурәтләнә. Чөнки ул — җәмгыятебезне төзүче, аны алга җибәрүче көч булып тора. Бер үк вакытта хезмәт кешесе образында ул яшәгән социаль мохитның барлык төп компонентлары гәүдәләнә. Чөнки «хезмәт ситуацияләре һәм конфликтлары аерым бер элементлар булып түгел, бәлки **типик геройны** чолгап алган **типик шартлар** (ассызык авторныкы — Г. М.) булып торалар» [3].

Әйе, әдәби герой үзен чолгап алган мохит белән катлаулы бәйләнештә булганда гына бөтенлеккә ирешә. Шуңа да күпчелек язучылар төп игътибарны герой яшәгән чынбарлыкны, социаль шартларны тасвирлауга юнәлдерәләр. Бу исә аерата зур әһәмияткә ия. Мәсәлән, безнең илдә элекке милли киртәләр халыкларның бер-беренә нәфрәте һәм дошманлыгы урынына хезмәт кешеләренең интернациональ бердәмлеге белән характерланучы

[2] М. Колесников. Хәзерге конфликтның табигате.— «Литературная Россия», 1976, 20 август.
[3] Ю. Оснос. Әдәбият һәм ФТР. Эзләнүләр. Табышлар. Икеләнүләр.— «Вопросы литературы», 1977, 4 сан, 6 бит.

яңа җәмгыять төзелдә. Советча яшәү рәвеше барлык өлкәләргә тирән үтеп керә һәм, әлбәттә, бу күренеш геройның милли һәм социаль үсешендә дә чагылмыйча кала алмый. Мәсәлән, төрки телле әдәбиятларыбызда Идел буе, Урал һәм Урта Азия республикаларында эшчеләр сыйныфының яңадан-яңа отрядлары формалашу процессын күрсәтүгә зур урын бирелә. Мисалга М. Гусейнның «Апшерон» һәм «Кара кыялар», Ә. Бикчәнтәевнең «Аккошлар Уралда кала», Б. Кербабаевның «Небит-даг», Ә. Мохтарның «Язмышымда — вакыт», Г. Ахуновның «Хәзинә» кебек киң катлау укучыларга билгеле романнарын китерергә мөмкин. Рус әдәбиятында да төрле милләт геройларының психологиясен уңышлы ачып биргән, аларның хезмәт һәм рухи бәйләнешларын яктырткан әсәрләр юк түгел. Моны А. Коптяеваның Татарстан һәм Башкортстан нефтьчеләренә багышланган романы раслый ала. Әсәрнең төп геройларыннан берсе — гади авыл егете Ярулла Низамов нефтьче булырга хыяллана. Ләкин кайнар теләк булу гына аз әле. Чөнки Ярулла бу өлкәдә әлепне таяк дип тә белми. Алай гына да түгел, хәтта кешеләр белән аралашуны читенсенә. Шуңа да бораулау вышкасының хуҗасы, мастер әзербайҗанлы Җаббар Самедов белән очрашу аны яңа урында эшләүгә караганда да ныграк куркуга төшерә. Тора-бара егетне берни дә: начар эшләгәне өчен мастерның тиргәве дә, ачуланып кычкыруы да үз алдына куйган максатыннан читкә тайпылдыра алмый. Ләкин ул башта Җаббардан үзен эшкә өрләшмичә генә өйрәтүен үтенә. Ә тегесе аңа болай дип җавап кайтара: «Тфү, тәкәбберлегән кара моның! Беләсеңме, Бакуда мине ничек өйрәттеләр? Борынга сугып, кара каны чәчрәп чыкканчы.

— Шулай итү яхшы идемени? Сиңа шулай эшләү ошый идемени?»[1] Ярулланың бу сүзләрендә аның, барыннан да бигрәк, тәҗрибәле оста йөзендә киңәшче, дус табарга омтылышы сизелә. Язучы үз әсәрендә төрле милләт вәкилләре арасында кайнар дуслык хисләре урнашуын күрсәтә алган.

Ярулла, Зариф һәм романдагы башка образларның да шәхси язмышы иҗтимагый тормыш белән үрелеп бирелә. Кеше дуслыктан, бер-беренә мәхәббәттән һәм бер-берен хөрмәт итүдән башка бәхетле була алмый. А. Коптяева романында нәкъ менә шундый идея алга сөрелә.

Социалистик җәмгыятьтә кешеләрнең шәхси язмышы, рухи үсеше һәм социаль хәле нинди милләттән яки сыйныфтан булулары белән билгеләнми. Монда сиңа эшеңә, хезмәтеңнең иҗтимагый әһәмиятенә карап бәя бирәләр. Төрле милләт кешеләренең интернациональ бәйләнеше дә шулай ук иҗтимагый хезмәткә килеп тоташа. Хезмәт процессында яңа гомумсовет традицияләре һәм йолалары барлыкка килә, бердәм яшәү рәвеше формалаша. Иптәш Л. И. Брежнев әйткәнчә, милли мөнәсәбәтләр җитлеккән социализм җәмгыятендә дә тормышыбызның төп билгесе булып калалар. Алар һаман үсә баралар, алдыбызга яңадан-яңа проблемалар куялар[2]. Бу—табигый процесс. Шуңа да язучыларның төрле милләт кешеләре арасындагы дуслык элемтәләрен күрсәтүгә зур урын бирүләре яхшы аңлашыла. Мәсәлән, бу проблеманы күренекле башкорт язучысы Ә. Бикчәнтәев үзенең «Аккошлар Уралда кала» исемле романында уңышлы гына хәл итә алган. Автор төрле милләт эшчеләренең дустанә мөнәсәбәтләре турында сөйли, эшчеләр сыйныфының крестьяннар белән тыгыз бәйләнешен, милли кадрлар формалашуын, башкорт халкының яңа социалистик культурасы үсешен күрсәтә. Әсәрдә нефтьчеләр белән колхоз авылы кешеләре арасындагы «конфликтны» чишүгә зур урын бирелгән. Авыл халкы баштарак нефтьчеләргә «чит кешеләр» итеп карый. Ләкин тиздән, авылның кайбер кешеләре нефтьче булып эшли башлагач, бу бербереңне аңламаучылык киртәсе акрынлап җимерелә. Ә инде ахырга табан алар арасында чын-чынлап дуслык элемтәләре урнашып җитә. Характерлы бер мисал: бораулау вышкаларының берсендә авария булгач, авыл халкы бердәм ярдәмгә килә. Әсәр геройларыннан берсе — Ясәви болай ди: «Бездән башка аларның эшләре барып чыкмас. Алар бит безнең өйләрдә яшиләр, без сауган сыер сөтен эчәләр, без яккан мичтә җылыналар. Бәс, шулай булгач, булышырга кирәк, бу бит безнең дә уртак эшебез»[3]. Әлеге сүзләр тирән социаль мәгънәгә ия. Крестьяннар Башкортстан нефтен үзләштерүнең бөтен

---

[1] А. Коптяева. Җир бүләге. М., 1965, 43 бит.

[2] Л. И. Брежнев. Ленин юлыннан. 4 том. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1975, 70 бит.

[3] Ә. Бикчәнтәев. Аккошлар Уралда кала. М., 1973, 221 бит.

совет халкының интернациональ мәнфәгате булуын тирәннән аңлауга ирешәләр. Чөнки безнең илдә авыл халкы да, шәһәр халкы да бер үк экономик, социаль-политик һәм рухи шартларда яши. Димәк, авыл кешеләренең мәнфәгате ил мәнфәгатеннән аерым була алмый. Нәтиҗәдә әсәр геройлары үзләре үк тормышыбызны социалистик нигездә үзгәртеп коручы ролен уйныйлар. Әйе, совет язучысының геройны тормыштан аерылган, үз читлегендә генә яшәүче кеше итеп сурәтләргә хакы юк. Болай эшләү тормыш дөреслеген бозып күрсәтү булыр иде.

Күп милләтле совет әдәбиятында уңай герой һәр вакыт типик шартларда сурәтләнә. Ул үзендә төрле хезмәт ияләренең какшамас бердәмлеге хисен гәүдәләндерә. Шуңа да геройның иң күркәм милли сыйфатларын ачып бирү белән беррәттән, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрдә яңа интернациональ яшәеш нормаларын калку итеп күрсәтү язучының изге бурычы булып кала. Бу җәһәттән Б. Кербабаевның «Су тамчысы — алтын бөртеге» исемле романы игътибарга лаек. Әсәрдә участок начальнигы Артык Бабалы коллектив ышанычын югалткан, тупас, эчкече, әрәм тамакларга каршы рәхимсез көрәш ача. Мәсәлән, Володя кебек «кешелеген югалткан» эчкечеләрне эштән генә куарга кирәк. Ләкин Бабалы бу юл белән бармый. Ул зур әдәплелек саклап, олы тыйнаклык белән, күп көч куеп, Володяга кире коллективка кайтырга ярдәм итә, аңарда үзенә һәм иптәшләренә карата ышаныч тудыра. «Иң мөһиме,— ди Бабалы,— кешедә кешелек хисен уяту». Бу сүзләр язучының төп иҗат принцибын билгели.

Ш. Бикчуринның «Каты токым» романында да шушы ук идея буйдан-буйга кызыл җеп булып сузылып килә. Автор үз геройларының катлаулы психологик үзгәрешләрен күрсәтә алган. Нефтьче хезмәте аларның һәркайсына тормышта үз урынын, үзенең яраткан эшен табарга ярдәм итә. Беркем дә үзен чит, кимсетелгән, нинди дә булса хокуктан мәхрүм ителгән итеп сизә алмый. Бу сүзне хәтта эштә артык тәҗрибәсе булмаган яшь кенә казакъ егете Сапарбайга карата да әйтеп булмый. Әмма шуны да онытырга ярамый: аның бердәнбер теләге — ярәшкән кызы Рәйханга калым түләү өчен мөмкин чаклы күбрәк акча эшләү. Нәкъ менә комсызлык аңа бригадада уртак тел табарга комачаулый, нефтьче һөнәрен үзләштерүдә төп киртә булып тора. Ләкин Сапарбай психологиясендә дә көтмәгәндә кискен борылыш килеп чыга. Туган ягына ялга кайткач, ул үзенең бабасы тарафыннан корылган хәйлә тозагына эләгүен аңлый. Шул чак егет ерак Татарстанда да дуслары булуын искә төшерә. Беркайчан да якын була алмас кебек тоелган яңа урын аның өчен бөтенләй бүтән мәгънә ала. Шул рәвешле, егет үзен бәхетле иткән, ышанычлы дуслар табарга мөмкинлек биргән Татарстан туфрагын, казакъ даласыдай, якын күрә, үз итә башлый.

Әйе, кешеләрнең психологиясе, кәефе бары тик интернациональ җирлектә генә уңай якка үзгәрә. Интернациональ рух белән сугарылган әдәбият кына совет кешеләренең тарихи гомумилеген, интернациональ бердәмлеген бөтен тулылыгы белән күрсәтергә сәләтле. Дөресен әйтергә кирәктер, безнең җәмгыятьтә дә милли мөнәсәбәтләр проблемасы һәр очракта да каршылыксыз, шома гына хәл ителми. Шуның мисалы буларак, әсәрнең башында исерек Мотгәрәй казакъ егете Сапарбайга мондыйрак сүзләр ыргытып ташлый: «Ни эшләп йөрисең син минем республикамда? Кыяфәтсез! Нәрсә калган сиңа монда?» [1]. Автор әле безнең җәмгыятьтә сирәк булса да милли яктан чикләнгән кешеләр очраштыргалавын әйтергә тели. Ни генә димә, социалистик аң, психика, дөньяга интернациональ караш үзеннән-үзе генә, стихияле рәвештә формалашмый. Ул даими көч куюны таләп итүче дәвамлы процесс.

Совет язучылары геройларның үзара мөнәсәбәтләрендәге милли сыйфатларга нинди дә булса социаль өстенлек бирүне максат итеп куймыйлар. Нәкъ менә шушы хәл совет әдбиятының интернациональ пафосын билгели дә инде. Сюжет кыса-лары белән генә дә чикләнми интернациональ пафос. Ул язучының эмоциональ тасвирлау алымында да, геройларның бер-бере белән дустанә мөнәсәбәтендә дә ачык чагыла. Мисалга Г. Ахуновның «Хәзинә»сеннән Дияров белән Дорогомилов, Б. Кербабаевның «Су тамчысы — алтын бөртеге»ннән Володя белән Нур, Г. Әпсәләмовның «Сүнмәс утлар» романыннан Сөләйман Уразметов белән Матвей Яковлевич Погорельцев, Р. Солнцев-

---

[1] Ш. Бикчурин. Каты токым. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1974 ел, 7 бит.

ның «Яшел калкулыкта кызыл ат» повестеннан Алмаз Шаһидуллин белән Анатолий Белокуровларның һ. б. олы дуслыгын китерергә мөмкин.

Совет әдәбиятында шулай ук социаль яктан хәвефле күренешләрне, әйтик, кайбер кешеләрнең, байлык артыннан куып, рухи ярлылыкка төшүен сурәтләүгә зур урын бирелә. Әйе, кызганычка каршы, хезмәт һәр кешенең беренче ихтыяҗына әверелмәгән әле.

Бу җәһәттән Л. И. Брежнев КПССның XXV съездында бик хаклы рәвештә болай дигән иде: «Без совет халкының материаль тормыш хәлен яхшыртуда күп нәрсәләргә ирештек. Без бу бурычны киләчәктә дә эзлекле хәл итәчәкбез. Әмма материаль мөмкинлекләрнең үсүе кешеләрнең идея-әхлак һәм культура дәрәҗәсе күтәрелү белән даими рәвештә бергә барырга тиеш. Югыйсә, мещанлык, вак буржуаз психология рецидивлары алуыбыз мөмкин. Моны истән чыгарырга ярамый». Язучыларыбызга советча яшәү рәвешен җентекләп өйрәнү бурычын йөкли торган сүзләр бу. Бүгенге әдәбият инде үзләштерелгән тормыш материаллары белән генә эш итә алмый. Безгә совет кешеләренең тормыш дәрәҗәсен дөрес бәяләргә, аңа уңай юнәлеш бирергә ярдәм итәрлек яңа темалар эзләп табарга кирәк. Шул ук вакытта социалистик яшәү рәвешен яктыртканда чынбарлыкта яшәп килгән каршылык һәм конфликтларны да күз уңыннан чыгарырга ярамый. Мәсәлән, кешеләрнең материаль шартлары яхшыру кайчак кешеләрдә табыш артыннан куу омтылышы тудыра. Мондый кешеләр бәхетне акча һәм әйбергә генә кайтарып калдыралар. Ә бит хезмәт, материаль байлык кешегә, барыннан да элек, үзен кешечә тоярга ярдәм итә. Байлык артыннан куу, үз кесәңне генә калынайтырга омтылу эгоизмга алып килә. Шул уңай белән Ю. Трифоновның «Сусынны басу» исемле романыннан Нагаев образын мисал итеп китерәсе килә. Автор озын берлек артыннан гына куучы бу образның чын йөзен ачып бирә, әхлаксызлыгын фаш итә.

Әйе, язучы белән килешмәү мөмкин түгел. Материаль муллыкка ия булу гына шәхеснең рухи яктан югары үсешен аңлатмый әле. Чөнки кеше эшчәнлеген бәяләүдә, прозаик Ю. Трифонов фикеренчә, мораль факторга хәлиткеч урын туры килә. Шуңа ул Нагаев кебекләргә туган җир кадерен белүче, башкаларны хөрмәт итүче, хезмәт сөючән, намуслы кешеләрне каршы куя.

Җәмгыятькә фәкать «куллану» күзлегеннән генә карау психологиясе икенче бер әсәрдә — Мәскәү язучысы В. Поволяевның «Трасса» повестенда да үтергеч тәнкыйтькә дучар ителә. Костылев Төмәнгә бары тик акча эшләү нияте белән генә килә. Ләкин ахырда ул тормышта иң мөһиме акча түгеллеген аңлауга ирешә. Үзең белән күңел җылылыгын бүлешкән, кыен чакта ярдәмгә килгән кешеләр күзенә туры карый алу үзе генә дә ни тора! Әйе, бездә кешене бары тик хезмәт кенә бизи, аны олы итә. Социалистик яшәү рәвешенең төп кыйммәтләреннән берсе шунда. Язучы В. Поволяев үз әсәрендә әнә шундый идеяне үткәрә.

Советча яшәү рәвеше киң колач алган, социалистик иҗтимагый мөнәсәбәтләр югары камиллеккә ирешкән бүгенге көндә дә без төп игътибарны кешегә юнәлдерәбез. Ул рухи яктан сәламәтме? Чөнки без коммунизмның төп максаты һәрьяклап гармонияле үскән шәхес тәрбияләү булуын онытырга тиеш түгелбез. Шунлыктан бүген әдәбиятта рухи яктан бай, политик һәм әхлакый яктан җитлеккән шәхес образын тасвирлауга зур урын бирелү табигый булса кирәк.

Язучының эстетик идеалы геройның чын тормыш матурлыгын һәм кешелек бәхете турында фикер йөртүе аркылы чагыла. Шул уңай белән Г. Әпсәләмовның «Сүнмәс утлар» романыннан бер эпизодны мисал итеп китерәсе килә: карт эшче Сөләйман Уразметов улы Илморзаның, эшче династиясенә хыянәт итеп, буфетта сатучы булып эшли башлавы белән килешә алмый. Улы: «Элек эшче исеме белән мактанганнар, горурланганнар... Ә хәзер модада түгел бу», — дип акланмакчы булгач, Уразметовның җен ачуы чыга. «Тагын бер тапкыр тиле авызыңнан шундый ахмак сүз чыкса, телеңне йолкып алып кулыңа тоттырырмын!— ди Сөләйман абзый, ачудан калтыранып.— Мода! Мода ул кызларга күлмәк тектергәндә, менә синең кебек тәти егетләргә эшләпә сайлаганда кирәк! Беләсең килсә, эшчеләр элек тә тормышның тоткасы булган, хәзер дә бу шулай, киләчәктә дә шулай булачак. Чөнки тормыш арбасын төпкә җигелеп тартучылар алар. Ә син мичәүдә барырга да ярамыйсың, гел читкә юргалыйсың. Ник? Чөнки башың тулы капи-

тализм калдыгы... факт»[1]. Ата белән улның сүзгә килүе моның белән генә бетми. Берничә ел узып, улы чирәм җирдән, дезертирларча, дусларын ташлап кайткач, Сөләйман абзый аңа тагын да яманрак сүзләр әйтә. Ике арадагы конфликтның төп асылы шунда ки, Илморза үзенең Сөләйман малае гына түгел, бәлки эшче кеше улы да булуын һич башына сыйдыра алмый. Шул рәвешчә, романда эшчеләр сыйныфының традицияләре, буыннар эстафетасы кебек гаять әһәмиятле мәсьәлә үзәккә куелган.

Гомумән, профессиональ эшче горурлыгы мәсьәләсе күп кенә язучыларның игътибар үзәгендә. Һәм ул Г. Ахуновның «Хәзинә», А. Коптяеваның «Җир бүләге», Б. Кербабаевның «Небит-даг» романнарында, Р. Солнцевның «Яшел калкулыкта кызыл ат» повестенда, Д. Вәлиевнең «Дәвам», А. Софроновның «Гигантлар» дигән пьесаларында уңышлы хәл ителгән. Мәсәлән, «Каты токым» романында чын татар эшчесе Миргазиян Сәлимов Мотгәрәйгә болай ди: «Китәсе кешеләр китсен... Әмма мин бригаданы мондый хәлдә ташламыйм!» (152 бит.) Әйе, мондый сүзләрне бары тик эшче, эшче нәселеннән булган кеше генә әйтә ала.

Эшчеләр сыйныфының көче, автор фикеренчә, барлык милләт вәкилләренең бердәмлегендә, туганнарча теләктәшлегендә, кыен минутларда бер-беренә ярдәмгә килүендә. Менә тагын бер мисал: Зөбәеров үзенә бригада тупларга керешкәч, аңа ерак Төрекмәнстаннан Ибраһимзадә ярдәм кулы суза — үз бригадасыннан иң яхшы бораулаучы Сергей Саакянны җибәрә. Эшчеләргә хас эчкерсез ярдәмне чагылдырган шундый ук юлларны Ә. Бикчәнтәевнең «Аккошлар Уралда кала» романында да очратырга мөмкин. Яңа тормыш төзүдә катнашу кешеләрнең рухи дөньясын баета. Мәсәлән, әсәрнең геройларыннан берсе эшче рухыннан көләргә уйлаган Хәмиткә ачуланып болай ди: «Эшче рухы революция ясаган, ул тарих ясый. Эшче булу — машина янында эшләү генә түгел ул. Эшче — дөньяда иң аңлы, иң алдынгы кеше... Корыч кебек чыдам, солдат кебек тугры... Һәм җен шикелле шат күңелле».

Социалистик яшәү рәвешенең тормышыбызга һаман киңрәк үтеп керүе эшчеләр сыйныфының яңадан-яңа сыйфатларын һәм традицияләрен сурәтләүдә ачык чагыла. Болар геройлар тормышын ямьләндереп җибәрә, төрле халыклар арасында дуслык элемтәсе ныгуга ярдәм итәләр. Мәсәлән, А. Коптяеваның «Җир бүләге», Ә. Бикчәнтәевнең «Аккошлар Уралда кала», Г. Ахуновның «Хәзинә» романнарында сабан туй бәйрәме, Б. Кербабаевның «Небит-даг», Р. Солнцевның «Яшел калкулыкта кызыл ат» әсәрләрендә комсомол туйлары, Ш. Бикчуринның «Каты токым» романында, М. Хәбибуллинның «Тау белән тау очрашмаса да...» повестенда Татарстанда яшь нефтьчеләрнең республика слеты нәкъ менә шушы максатка хезмәт итәләр. Кагыйдә буларак, мондый бәйрәмнәрдә төрле милләт кешеләре якыннан катнаша. Шул ук «Каты токым» әсәрендә нефтьчеләрнең Язтургай авылы яшьләре белән күңел ачулары, кызыклы уен оештырулары укучыда җылы тәэсир калдыра. Авыл яшьләре белән бергәләп оештырылган мондый кичәләрдә Зөбәеров бригадасы вәкилләре дә үзләренең җыр-биюгә осталыкларын күрсәтәләр. Һәр милләт вәкиле Язтургай яшьләрен үз халкының сәнгате белән таныштырырга тели. Болар бөтенесе бүгенге авыл халкының социалистик интернационализм принцибы белән яшәве турында сөйли. Авыл кешеләре тугандаш милләтләр сәнгатен дә аңлый, яратып кабул итә.

Д. Вәлиевнең «Дәвам» пьесасыннан да бер мисалга тукталырга мөмкин. Яшь кызлар — Вера, Рушания, Гәүһәр, Нюра һәм Алсу батырлык һәм матурлык турында сөйләүче татар әкиятләре белән кызыксыналар. Бу исә замандашыбызның рухи йөзендә үз иленең, үз язмышының хуҗасы булган бердәм совет халкы психологиясе чагылуын раслый.

Әлбәттә, милләтләрнең бер-беренә якынаю процессы производство, культура өлкәсендә генә бармый. Бу процессны гаилә һәм көнкүрештә дә күзәтергә мөмкин. Шул нигездә бүген катнаш никахлар барлыкка килә. Мисалга Г. Әпсәләмовның «Сүнмәс утлар» романыннан Гөлчирә белән Гена Антонов, Э. Касыймовның «Чулман — оныклар елгасы» дилогиясеннән Сәрия белән Вася Землянов, Б. Кербабаевның «Су тамчысы — алтын бөртеге» әсәреннән Марина белән Аннам, Р. Солнцевның «Яшел калкулыкта кызыл ат» повестеннан Аза Кәримова белән Путятин

[1] Г. Әпсәләмов. Сүнмәс утлар. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1958, 104 бит.

мәхәббәтен китерергә була. Катнаш никах җиңел генә тумый. Моның өчен әле көрәшергә, иске кануннарны җиңеп үтәргә туры килә. Хәер, монда да интернациональләшү процессы һаман тирәнрәк үтеп керә.

Шул уңай белән Б. Кербабаевның «Су тамчысы — алтын бөртеге» романында сурәтләнгән бер эпизодны искә төшерәсе килә. Анда төрекмән егете Аннамның рус кызы Маринага өйләнүе күп кенә каршылыклар китереп чыгара. Егетнең әнисе Бостан моңа теше-тырнагы белән каршы төшә. Ул улына: «Мин сиңа ата-бабалар йоласын аяк астына салып таптарга юл куймам»,— ди. Әмма ахырда бөтенесе дә уңай хәл ителә. Шулай итеп, язучы социалистик җәмгыятьтә интернациональ бердәмлек нигезендә иске традицияләрнең яңача эчтәлек алуын, «үз милләтем», «бүтән милләт» дигән төшенчәләрнең акрынлап төшеп калуын күрсәтүгә ирешкән.

Мәсәлән, Татарстанда катнаш никахлар күптән инде гадәти хәлгә әйләнде. КамАЗда һәр өч егетнең берсе бүтән милләт кызына өйләнә. Шуңа да бу процесс татар әдәбиятында совет халыкларының экономика һәм культура ягыннан бер-берләренә якынаюының табигый дәвамы итеп яктыртыла. Мисал өчен Красноярскида яшәүче Р. Солнцевның КамАЗ материалына нигезләнеп язылган «Яшел калкулыкта кызыл ат» повестен китерергә була. Рус егете Путятин белән татар кызы Аза Кәримованың туен үткәрү өчен әсәр геройлары Алмаз Шәһидуллинның туган авылына татар йолаларын өйрәнергә баралар. Монда алар татар халкының көнкүреше, җырлары, шаян такмаклары һ. б. белән танышалар. Шуның нәтиҗәсе буларак, комсомол туе бик күңелле уза.

Совет язучылары яңа социалистик яшәү рәвешен сурәтләү белән беррәттән, искелек калдыкларына һәм һәртөрле хорафатларга каршы көрәшне дә игътибардан читкә калдырмаска тырышалар. Әйтик, диннең кешеләргә һәлакәтле йогынтысын күрсәткән әсәрләр аз түгел. Бу уңай белән «Каты токым» романындагы казакъ егете Сапарбайның аянычлы хәле, Ю. Трифоновның «Сусынны басу» әсәрендәге төрекмән егете Моратовның язмышына аваздаш булуын әйтеп үтәсе килә. Әмма авторлар тарафыннан ул геройларның язмышы төрлечә хәл ителә. Мәсәлән, Ю. Трифонов романында бригада Моратовның язмышы белән бөтенләй диярлек кызыксынмый. Герой монда үзен кимсетелгән итеп сизә. Тик икенче бригадага күчү генә Бәшим Моратов язмышын уңай якка үзгәртеп җибәрә. Ә язучы Ш. Бикчурин сурәтләгән күп милләтле коллективта исә казакъ егете Сапарбайга барысы да ярдәм кулы сузалар, аңарда тормышка карата мәхәббәт уяталар. Шул рәвешчә, әдип үз әсәрендә шәхес тәрбияләү, аның интеллектуаль һәм социаль-психологик табигатен формалаштыру проблемасына бөтенләй башка яссылыктан якын килә.

Игътибарны күп милләтле совет әдәбиятына характерлы тагын бер моментка юнәлдерәсе килә. Ул да булса — тел проблемасы. Хәзер халыклар бөек рус теле ярдәмендә һаман ныграк милли бәйләнешкә керәләр. Шуңа күрә дә язучылар үз геройларының ике телдә дә сөйләшүенә зур игътибар бирәләр. Бу җәһәттән А. Коптяеваның «Җир бүләге» романыннан бер өзек китерәсе килә. Бораулау мастеры Мостафа Гайнетдинов дусты Юра Тризнга болай ди: «Мин рус телендә кайчак ялгышам, басымны дөрес куймыйм. Аның каравы, Пушкинны оригиналда укыйм. Ә синең Габдулла Тукайны укыганың бармы?

— Әлбәттә. Әмма тәрҗемәдә генә.— Юра, үз сүзен расларга теләгәндәй, Тукай шигырьләреннән берничә өзек укып күрсәтә... Әмма Мостафаның һич кенә дә бирешәсе килми.

— Ә син миңа татарча беләсеңме соң?! Юра, гаҗәпләнеп, кулларын җәеп җибәрә.

— Юк, Советлар Союзында руслар белән татарлар гына яшәсә, бу бер хәл булыр иде. Үзең уйлап кара, анда йөздән артык милләт яши. Шулай булгач, монда уртак телдән башка мөмкин түгел...» (212 бит.)

Шул характердагы мисалларны югарыда искә алынган милли телдә иҗат итүче язучылар иҗатыннан да китерергә мөмкин булыр иде. Алар бертавыштан үз геройларының тормышында рус теленең прогрессив роль уйнавын күрсәтергә тырышалар. Чөнки рус теле белем алуда, профессиональ осталыкларын күтәрүдә, башка милләт вәкилләре белән аралашуда һәм башка өлкәләрдә төп чараларның берсе булып чыга. Шушы һәм бүтән

факторлар совет халкының ике телне өйрәнүләренә алып килә. Татар һәм бүтән милләт язучысы әсәрләрен рус теленә тәрҗемә иткәндә кайбер сүзләрне, мәсәлән, мәкаль, әйтем һәм фразеологик әйләнмәләрне шул телдә калдыру, үз чиратында рус телен баету белән беррәттән, һәр аерым халыкның тел байлыкларына да киң дөньяга чыгу мөмкинлеге ача. Моны, аерым алганда, «Каты токым» романының рус теленә тәрҗемәсендә дә күрергә була. Язучы үз геройларының характерын, холкын, көнкүреш шартларын тасвирлаганда милли тел лексикасына шактый зур урын бирә. Төрле милләт персонажлары сөйләшендә аерым татар сүзләре, тәгъбирләре очрый. Аларның мәгънәсе тәрҗемәдә бирелсә дә, аларны контексттан болай да аңларга мөмкин. Мәсәлән, «Катык», «әйрән», «түбәтәй», «рәхмәт», «бабай» «шайтан» һ. б. кебек татар сүзләрен тәрҗемә итүнең күптән хаҗәте юк. Шушы ук фикерне «аман», «кышлак», «кымыз», «кушак»ише казакъ сүзләренә, «батька» кебек украин тәгъбиренә карата да әйтеп була.

Язучы Ш. Бикчурин иҗат иткән төрле милләт геройларының сөйләше үзенчәлекле һәм оригиналь. Алар бер-берләрен аз гына да кабатламыйлар. Һәркайсының үз тавышы, үз моңы бар. Әсәрне рус теленә тәрҗемә иткәндә персонажлар сөйләшендәге бу үзенчәлекне талантлы язучы В. Чивилихин тулысынча диярлек бирә алган. Шуңа да тәрҗемәдә татар теленең җанлы агышын ишеткәндәй буласың.

Роман Солнцев та үзенең «Яшел калкулыкта кызыл ат» исемле повестенда ике тел — рус һәм татар теленнән оста файдалана. Шул рәвешчә, телләрнең бер-беренә бәйләнеше һәм йогынтысы нәтиҗәсендә аларның гармонияле үсешен тагын да ачыграк күз алдына китерәсең.

Бу мәкаләдә социалистик яшәү рәвешенең әдәби процесска йогынтысы проблемасының кайбер аспектлары гына карап үтелде. Әдәбият белгечләре һәм тәнкыйтьчеләр аның төрле якларын ныклап өйрәнүне дәвам итәрләр һәм үз ачышларын бөтен әдәбиятыбызның уртак казанышы итә барырлар дип әйтәсе килә. Яшәү рәвешебездәге прогресс һәм казанышлар моңарга ныклы ышаныч тудыра.

## Мансур Вәлиев

# КЕШЕЛЕКЛЕЛЕК ӨЧЕН КӨРӘШҮ

Авыл егетләренең тулысынча үз күңелләре иркендә калып, бөтенләе белән үз эчләрендәге моңга бирелеп, онытылып җырлап йөргән кичләре була. Караңгыга төренгән авыл өстендә барлык көйләрдән моңлырак, ягымлырак — тыңлап торучының җанына үтә якын, кадерле җыр яңгырый. Ул җырда — берничә тарсынмый, кыенсынмый ачылган кеше күңеле, тирәнлек, серле аһәң. Ул җырда — кешенең тулысы белән җырга түгелүе, үзәкләрне өзәрлек моңга әверелеп яшәү хасияте була...

Бу җыр — авыл тормышының күңелебез түрендә бик озак вакытлар яңгырап торачак, гомер юлы буйлап озатып барачак кадерле һәм сагышлы авазы. Бу җыр — безгә юлыбызда дөрес юнәлешне сиземләргә, эшләребезнең һәм омтылышларыбызның намуслыгын, ихласлыгын, турылыгын чамаларга мөмкинлек бирә торган ышанычлы аваз.

Шагыйрь Гәрәй Рәхимнең «Моңнарым» исемле китабын укыганда, мин әнә шул авазны ишеттем кебек.

Поэзия илендә бүтәннәргә охшамаска, үзен башкача тотарга теләүче шәхесләр дә очрый. Алар үзләрен реаль тормыш эчендә, язмышларының катлаулы хәрәкәте эчендә итеп түгел, ә тормыштан һәм язмышларыннан өстәрәк, югарыдарак итеп тоялар. Әмма шагыйрь шәхесенең әнә шундый «югарыдагы» халәте, аның тормышта табигый әгъза булмавы (яисә була алмавы) аның поэзиясен тере яшәешнең бихисап җепләре, ачык нервлары белән бәйләнештән мәхрүм итә. Әлеге шәхес үзенең табигый яшәешеннән ерагая: ул үзенең тормышта көчле дә һәм бер үк вакытта көчсез дә икәнен, барысын да белүче дә һәм шул ук вакытта бөек Чынбарлык каршында үтә беркатлы да булган Кеше икәнен, бары тик кеше генә икәнен оныта. Бу шигърият өчен — кеше күңеленең бердәнбер табигый һәм ирекле яшәеше өчен һәлакәтле хәл. Ул шагыйрьнең иҗатында тарлык, берьяклылык тудыра.

> Кил, минем киләчәгем,
> Син — минем күрәчәгем;
> Янәчагым, көячәгем,
> Утларга керәчәгем.

Гәрәй Рәхимнең «Кил, минем киләчәгем» шигыре аның бөтен иҗатына хас сыйфатны ача кебек. Андагы сыман, шагыйрьнең уңышлы килеп чыккан бүтән әсәрләрендә дә — эчтә, тирәндә көчле хис дәрьясы ташый. Ул һич нәрсәгә баш бирми — шаулап, ашкынып, ярсып ага. Аның хәрәкәтен, җанын шигырьнең беренче сүзеннән, интонациясеннән үк сизәсең, табасың. Ул агым укучы аркылы, рентген нурлары агышы сыман, тавышсыз-тынсыз үтә. Әмма ул күңелеңдә җыелган, тупланган барлык кичерешләр, хис дулкыннарын куптарып, үз стихиясенә ияртеп, синең рухыңны, җаныңны тетрәндереп уза. Син ул агымның үз эченнән давыллап акканына көч-хәл белән түзеп торасың. Ул өянкеләрне күтәрел китәргә теләп дулаган җәйге җил сыман, аякларыңны җирдән аерып, үзе белән каядыр югарыга алып менеп китәр кебек...

Гәрәй Рәхим иҗатының иң яхшы әсәрләреннән сайланып тупланган «Моңнарым» китабында кеше күңеле кичергән әнә шундый рухи давылларны күп очратасың.

> Мин авылга кайткач, ялгыз гына
> Чыгамын да ындыр артына,
> Караултылар ышыгына кереп
> Тынып калам.
>         Минем каршыга
> Мин бәлакай чакта уйнап йөргән
> Сукмак килә нәни инештән.
> Сабый чаклар! Тагын сезгә килдем
> Яшеренеп кенә дус-иштән.
>
> Миңа монда җайлы сезнең белән,
> Карт авылым монда, үз күгем.
> Бер ялгызым гына, яшеренеп,
> Бер еларлмын, ахры, мин бүген.
>
> Һәм елыйм мин. Ялгыз рәхәтлектән,
> Сабый чаклар хатирәсеннән.

Каралтылар белән бергә елыйм,
Үксеп-үксеп елыйм һәм көләм.
. . . . . . . . . . . . . .
Безнең чорда сабыйлыкка кайту,
Елый белү оят санала.
Җитдилек һәм салкын канлылыкны
Яратарак төшә замана.
. . . . . . . . . . . . . .
Дусларымнан яшереп ничә еллар
Җыеп йөргән татлы күз яшен
Рәхәтләнеп түгәм!
һәм уйлыймын:
Елый белəм — димәк, мин яшим!

Бу шигырь әйтерсең алда әйтелгән фикерләрне ачыклый төшү өчен махсус язылган. Минемчә, бу шигырьдә бүгенге поэзиянең туу, шытып чыгу җирлеге ачыла. Ул җирлектә барган нечкә көрәш мизгелләре күзгә чалына...

Әлбәттә, гомумирәк алып караганда моннан мең еллар элек булган кебек, хәзер дә шигъриятнең туу җирлеге бер генә: ул тормышны гаять нечкә, тирән тоеп яшәүче шагыйрь кешенең күңеле. Шигырьләр — әнә шул үтә сизгер күңелнең дөнья тибрәнешләренә җавап реакциясе. Чын, җитди шагыйрь, ул һәрчак үз күңелендәгене җырлый, үз йөрәгендәгене көйли. Әмма бу очракта Г. Рәхимнең әлеге шигырендә яңгыраган бер фикер безне уйланырга мәҗбүр итә. Ул: «Үзем уйлыйм: ярый әле димен, еракта мин шәһәр, дуслардан. Мескен хисләр, диеп, юкса алар көләр иде минем елаудан»,— ди. Шагыйрь шигъриятнең үсү, үсеп китү юлындагы иң беренче каршылыкны тотып алган.

Шагыйрь өчен иң мөһиме — һәр җирдә һәм һәркайда, һәркем белән чын булу, кичерешләренә тугры калу. Бу — шагыйрьнең бүгенге тормышта тапкан дөрес һәм ышанычлы юлы. Сыналган юл. Ләкин һаман да шомармаган, тигезләнмәгән, бару өчен җайлашмаган юл. Әнә шул ихласлык юлы шагыйрьне туган авылына, гомеренең гүзәл чагы үткән иң матур дөньяга алып кайткан. Ләкин хәзер инде аңа ул дөньяда бик-бик ямансу, бик-бик моңсу... Нишләп икән?.. Бәлки шагыйрь монда кайткач үзендәге әнә шул идеаль матурлык белән мәңгегә хушлашкан, аның белән мәңгегә ташлашкан булуын әрнеп кичерәдер. Бәлки аның бирєдә, искә төшкәч күздән яшь китерә торган хатирәләре бардыр... Әйе, барысы да мөмкин. Болар — безгә таныш тойгылар.

Шулай да төп игътибарны башка фактка юнәлтәсебез килә. Без, кадерле урыннарга кайткач, күңелебезнең үткәндәге кичерешләренә, шул нечкәргән халәтенә хәзер ни дәрәҗәдә тугры калабыз? Аңа хәзер дә якын була алу көчебездән киләме? Бирєдә миңа шунысы мөһим. Шагыйрь күңеле бу очракта бездән әнә шул көче белән аерылып тора бугай. Ул (күрәсең, үзенең сафлыкка, ихласлыкка якынрак булуы, яшияши аннан ераклашмаганлыгы аркасында) дөнья белән иң якын һәм тыгыз контактка керә ала, хәзер дә үткәннәре белән бер булып яши ала. һәм шушы кадерле мизгелләрнең бөтен нечкәлеген тасвирлаган, кешеләр өчен бик кадерле булган шигырьләр туа...

Шагыйрь үз туфрагында басып тора. Ул күңеле белән, кешелеклелек дигән киң җирлек аша, укучылар күңеленә һәм шигърияткә тоташкан. Чын шигърият бары тик әнә шулай гына туа һәм яши ала!

Шагыйрь күңеле — бик нечкә, үтә дә нәзек үсенте ул. Ул һәр тибрәнешкә, һәр авазга сизгер. Әгәр дә ул үзенең төп объектын, кеше җанына игътибарын югалтмаса, шау-шулы, ыгы-зыгылы заманнарда да яши һәм җимешләр бирә. Бары тик иң төптәге катламнарга үтеп керә алуы гына кирәк икән. Әнә шул процесста үзе өчен ят, буш, ашсыз катламнарны үтеп китә алуы кирәк. Шулай булганда гына шигъри әсәр укучыны дөньяның иң тирән төпкеленнән табылган кадерле җәүһәрләре белән сокландыра аладыр. Халыкка һәм аерым кешегә кирәкле шигърият шул рәвешчә яши. һәр заманда, һәр чорда ике төр кешеләр бер-берсеннән үтә нык аерылып торганнар. Берәүләр әзер кагыйдәләр, билгеле фикерләр һәм ачык яшәү яссылыгында тыныч кына, «йокыга талган гүзәл акыл» белән, үз фикерләрен әнә шул билгеле бер кысадан читкә чыгармыйча яшәгәннәр.

Шул ук вакытта һәр заманда кешеләрнең фикри дөньясын зурайту, кешенең яшәешен матуррак итү, аңарга күбрәк матурлык бирү, аны сокландыру өчен тырышучылар булган. Алар кешеләр иялəнгән киртәләрне җимерү яки аларны алгарак, ераккарак күчерү турында уйлаганнар. Андыйлар аша кешелекнең иң тирән катламнарга киткән үзәк тамырлары үтә, алар — кешелек агачының иң саф һаваны алып бирүче беренче ботаклары. Үткән заманнардан безгә кадәр килеп җиткән олы сәнгать әсәрләре, беренче чиратта, вакланмаган, таркалмаган, шәхесен, эш юнәлешен дөньяның вакытлы җилләре уңаена боргаламаган, үзенең кешелек үзәген кайчан да саклый һәм үстерә алган әнә шундый керсез йөрәкле кешеләрнең күңел һәм акыл җимешләре алар. Бүген без аяк астыбызда намуслы, ныклы һәм ышанычлы җирлек тоябыз икән — ул аларның гомерләре көче белән хасил ителгән бәрәкәтле туфрак. һәм анда, ул туфракны тагын да баету өчен яңа үсентеләр тагын шытып килә, борын төртеп, үсеп килә...

Әйе, һәр чор катлаулы. Ләкин безнең чор тормышы башкаларга караганда да үзгә һәм катлаулы. Андагы кискен давыллар саны гына да бүтән гасырлардагыдан чагыштыргысыз дәрәҗәдә күп һәм алар янына куеп та булмастай көчле.

Безнең чор—егерменче гасыр — иң башта үзенең төп сыйфаты: кешелек җәмгыятенең беренче мәртәбә бөтенләй яңа төрле, принципиаль рәвештә үзгә булган тормышка — озак еллар буе хыялында йөрткән социализмга аяк басуы белән башкалардан нык аерылып тора. Андый яшәүгә кешелекнең торган саен күбрәк өлеше аяк атлый бара. Бу сыйфат — безнең гасырны башка барлык чорлардан принципиаль рәвештә, чагыштыргысыз дәрәҗәдә үзгә итеп куя.

Шуңа бәйле рәвештә кеше зур социаль һәм психологик каршылыклар белән очрашты, аның шәхси яшәеше моңарчы башка чор кешеләрендә күзәтелмәгәнчә кискен катлауланды. Безнең гасырда кешелеккә никадәр сугыш, кан кою, күпме җаннарны югалту трагедиясен кичерергә туры килде. Гасырның беренче яртысында ук ике мәртәбә бөтендөнья сугышы! Кеше шәхесе өчен никадәрле тетрәнү, рухи һәлакәт һәм авыр яра! Һәм хәзер кешелекнең яңадан гаять четерекле, куркыныч хәлдә калуы — җир тарихында әле моңарчы беркайчан да булмаганча, бөтен кешелек тормышының язмышы кыл өстендә торуы яңадан психологик киеренкелек тудырды. Әле моңарчы, зур җимергеч көчле атом һәм башка кораллар табылганчы, кешелек үз тарихында мондый четереклелек, дөньяның кыл өстендә торуы белән очрашкан, андый олы трагедия булу мөмкинлеген кичереп караганы юк иде.

Егерменче гасырны нык үзгә иткән өченче сыйфат, шулай ук тарихта әле моңарчы күрелмәгән күренеш — фән-техника революциясе. Бу революция иң элек кешене чолгап алган тормышның барышын, аның рәвешен, тизлеген үзгәртә. Кешенең яшәү тирәнлеген бүтән төрле итә. Бу революция кешене зур мөмкинлекләре белән кызыктыра. Һәм аның күп омтылышларын үзенең реаль мөмкинлекләре белән ирексездән каршылыкка кертеп, алар арасында төрле дәрәҗәдәге килешмәүчәнлек, бербереен кире кагу көчләрен дә тудыра.

Кеше үзенең олы ышанычын табарга тели, ул үз-үзенә ныклап ышанырга тели. Үзенең көченә, олылыгына, табигатьтәге чын бөеклегенә. Әнә шул ышанычка илтү юллары хәзер кешелек рухы тарафыннан эзләнелә, сынала, тикшерелә.

Шигърият, кеше күңеленең иң актив яшәеше булып, әнә шул эзләнүләрнең алдында атлый. Ул тормышның яңа ситуацияләрендә кешенең үз юлына, үз асылына тугры калган хәлдә яши алуын тәэмин итәргә омтыла.

Шигърият бүгенге кешегә дөрес яшәү юнәлешен ничек күрсәтә ала соң? Әнә шул «ничек»кә җавап бирү өчен шагыйрь Гәрәй Рәхимнең тагын бер шигырен укып үтик. Ул «Сабырларга» дигән әсәр.

Яратам мин сабыр кешеләрне —
Зур кораблар кебек, алар һаман
Тормыш давылларын ерып бара
Максатлары кушкан якка табан.
«Sos»
Маякларын дулкын капласа да,
Сабырлыктан алар ялыкмыйлар.
Корабларын давыл сытканда да,
«Sos» бирергә артык ашыкмыйлар.

Зур максатлар өчен җаннарына
Алсалар да күпме авыр яра, —
Шырпы кебек чәчрәп кабынмыйлар,
Алар домна кебек салмак яна.

Күңелендәгене укучыга җиткерү өчен шагыйрь зур кораб образын ала. Зур кораблар, бер караугә, чыннан да, сакмак кебек, ләкин алар зур суларда, көчле давыллар кичеп йөзәләр. Кораб — ныклык, тукталмый алга бару, төп юлдан тайпылмау билгесе кебек. Кораб тышкы көрәшеше белән дә саф олылыкның гәүдәләнеше, символы кебек. Образның менә шушы сыйфатлары шигырьнең укучы күңеленә үтеп керүенә ярдәм итә. Үзе бик үк сабыр булмаган кеше дә, бу шигырь тудырган поэтик һаваны сулап алгач, әйләнә-тирәсендәге андый кешеләргә дикъкать белән карый. Шигырьдәге «домна кебек салмак яна» дигән сүзләр аның хәтеренә еш төшә, шагыйрьнең «тик битараф түгел, мәҗлесләрдә бәйрәм итсә күпшы фразалар» диюе аны күп нәрсәләргә күңел күзен киңрәк ачып карарга мәҗбүр итә. Шулай итеп, шигырь аерым кешеләрнең үз-үзләрен тотышлары, аларның дөньяга мөнәсәбәтләре аша зур тормышка үтеп керә. Анда кешелеклелек дигән олы байлыкка өстәлә.

Шагыйрьнең «Бәйрәм көткәндә» дигән шигыре, исеменнән үк аңлашылганча, кешенең тантана итү мизгелләре турында. Ләкин ул да җитди мәгънәгә ия. Чөнки анда да без бүгенге шигъриятнең яшәү җирлеген, аның туклану туфрагын, ягъни заман шагыйре җанының талпынышын, шагыйрь йөрәгенең тибешен тоябыз.

Шундый бәйрәм килер бүген безгә,
Без шатлыктан җырлар җырларбыз.
Тәрәзәне ачып куярбыз да,
Төнге серле өнне тыңларбыз.

Беренче юллар ук безне шагыйрь күңелендәге ярсулы хисләрнең көчле дулкынына китереп кертә. Соңгырак юлларда беренче дулкын биргән тәэсир тагын да үстерелә, көчәйтелә, укучы шагыйрь йөрәгенең тибешен тоя башлый. Шагыйрь йөрәге сүзләр дулкынын тудыра һәм аларны үзенең тибү ритмы белән безгә, тыныч ярдагыларга җибәреп тора. Без һәр шигъри юлны, һәр яңа дулкынны кабул иткән саен ул вулканның яшәешен ныграк аңлый барабыз, аның яңа халәтләрен күреп алабыз. «Шәраб исен иснисе дә килмәс, татлы хисләр безне исертер. Ягы дөнья ачык тәрәзәдән безгә җылы җилләр китерер». Шигъри юлларның һәрберсеннән безгә шатлыклы кичереш килә. Без ирексездән шул диңгезгә кереп үк китәбез. Дөресрәге, ул безне үз эченә ала. Без, бөтен барлыгыбыз белән аңа кушылып, аның яшәешен кичерә башлыйбыз...

Ул дулкыннар безне ничек алай үз стихияләренә алып кереп китә алдылар соң? Бездән көчлерәк булып чыктылар? Төп хикмәт — ул дулкыннарның эчендә безгә якын һәм кадерле көч яшәүдәдер, без рухыбыз белән шуңа таба тартылганбыздыр, аларга якынлашырга телибездер. Бирерә ул серле көч, мөгаен, мәхәббәтнең бөеклеге, шул бөеклек тәэсиредер. Тагы шунысы бар, ул юллар бик табигый, кешегә бик якын интонациядә бирелгәннәр. Шуңа күрә аларны кабул итүдә беркинди кыенлык, каршылык килеп чыкмый.

Шундый бәйрәм килер бүген безгә —
Котылырбыз гайбәт, үчләрдән.
Сөйкемле һәм җайлы булыр дөнья
Безнең татлы, рәхәт хисләрдән.

Шигырьдә, күргәнебезчә, тасвирлау чаралары юк диярлек. Ул кешеләрнең эчкерсез, гадәти сөйләшүләре кебек — гади генә. Гәрәй Рәхим гомумән шигърияттә тышкы элементларга, форма мәсьәләләренә артык зур игътибар итми. Ләкин шигырь безгә зур бәхет мизгелләре алып килә. Чөнки ул безне өскәрәк, яктыгарак, биеккәрәк күтәреп ала һәм дөньяның киңлеген, матурлыгын мулрак итеп күрсәтә.

Шагыйрь Гәрәй Рәхим поэзиясенә күңел киңлеге, бөтенлек, олы җан булып яшәүгә омтылу хас. Аның шигырьләрендә кеше үзен бөтен тирәнлегендә ачып, ачылып-түгелеп яши. Анда хис, кичереш үзенең бар реальлегендә, катлаулы чынлыгында ачыла.

Гәрәй Рәхим иҗатының сыйфаты хакында уйлану уңае белән, мин күп кенә яшь шагыйрьләрнең үз әсәрләрендә тышкы факторларга шактый зур әһәмият бирептә, тагы да киңрәгрәк бер нәрсәне күздән ычкындыргалау очраклары турында әйтергә телим. Һәм аны әйтү, нәкъ менә биредә, Гәрәй Рәхим иҗатындагы олы җанлылык, киң күңеллелекне билгеләгәндә урынлы булыр кебек. Бу мәсьәләгә тукталып үтү безнең язмабызның исеме белән дә — бүгенге шигъриятнең кешелеклелек өчен барган көрәшен күзәтү белән дә аклана сыман. Күп кенә яшьләрнең укучыга тәкъдим итә торган шигырьләрендә ритм-рифма да әйбәт, кызыклы һәм истә калырдай поэтик детальләр, образлар да бар. Ләкин әнә шул шигырьнең бер җан булып иркенләп яшәве сизелми. Күрәсең, бу авторлар әле дөньяны шактый өстән, җиңелчә генә күрә һәм тоя. Хәзергә әле ул дөньяның киңлеген үз күңеле белән, үз тәҗрибәсе белән татый алмаган. Киләчәктә язмыш аңа мондый хасиятне бирерме, юкмы? Бу — кулына каләм тоткан һәр кешенең язмышын хәл итә торган олы мәсьәлә.

Әнә шул бәхетле баскычка күтәрелгәнче күп кенә яшьләрне бер чир аптыратып ала. Аны кыскача гына: позалар белән мавыгу дияргә мөмкиндер. Позалар... Шигърияттә һәм гомумән тормышта үзеңнеке булмаган ниндидер бер кыяфәт, ят рәвеш алырга тырышу... Бәлки ул кайдадыр үзеннән акыллырак кешенең сөйләвенә, фикерләү манерасына, үз-үзен тотышына соклнып калгандыр, үзе дә шуны кабатлый башлагандыр. Ләкин моның иҗат кешесе өчен нәтиҗәсе начар. Теге яисә бу позаны алу белән иҗат кешесе табигый үсеш юлын югалта. Шуңа күрә позалар яшь кеше өчен аеруча куркынычлы, хәтта һәлакәтле нәрсә. Ул — диңгездәге кораб өчен юнәлешне югалтып, матур, әмма сай култыкка килеп керү сыман.

Иҗат кешесе өчен, әлбәттә, иң ышанычлы юл ул — табигыйлегеңне, үз асылыңны югалтмау, аны саклаган хәлдә үстерү, аңа тугры булу.

Шагыйрь Гәрәй Рәхим поэзиясе, иң беренче чиратта, кешенең әнә шул сыйфатына, табигыйлегенә таянганда нинди матурлыкларга, нинди җитдилеккә ирешә алуына бик ачык мисал булып тора.

Шагыйрьнең дөнья, тормыш белән нинди мөнәсәбәттә булуын түбәндәге юллар да ачык билгели төсле:

> Дөньяда ничә мизгелгә
> Әҗәткә алган кеем!
> Китәсең кире дөньяга,
> Сүзләрдән киеп кием.

Биредә шигъриятнең мәгънәсе дә объектив рәвештә дөрес билгеләнә — «әҗәткә алган кеем!» Бу сүзләрдә иҗат өчен тормышның төп чыганак, нигез булуы да, поэзиянең реаль яшәештән килеп чыгуы да һәм иҗатның тормыш өчен бик кирәкле икәне дә чагыла. Шагыйрь җанының тормыш каршындагы олы җаваплылыгы да гап-гади һәм чын хакыйкать итеп әйтелгән. Чөнки, әҗәткә алган кеше ул җаваплы була. Шигъриятнең дөнья белән катлаулы бәйләнеше бу әсәрдә тагын да остарак тотып алынган.

Гәрәй Рәхим китабында уңышлы гына кыска шигырьләр дә байтак. Ләкин үзләренең мәгънә зурлыклары, биргән тәэсирләре ягыннан алар һич тә әлеге көчле кичереш шигырьләреннән ким түгелләр. Аларда гадәттә салмаграк агыш, саллырак сүз, кыскарак интонация була. Ашыкмый торган, гап-гади, бераз гына кырыслана төшкән шигъри атмосфера сизелә, Менә шундыйлардан берсе:

> Гел хәвеф белән көтәм сөюне...
> Хәрби аэродром һөҗүмгә киткән
> Самолетларын көткән шикелле.

Монда инде ярсу хис акмый, укый башлагач, безне көчле стихия үзенә суырып алмый. Бер психологик халәт кенә тасвирлана. Ул халәтнең сиңа бар нечкәлеге, чынлыгы, бөтен төсмерләре аңлашыла. Шигырьдәге «гел хәвеф», «хәрби аэродром», «һөҗүмгә киткән», «самолетлар» дигән сүзләр һәрберсе күңелдә зур киеренкелек, психологик тыгызлык хасил итәләр. Әлеге үтә җитди сүзләр шагыйрьнең сөюгә ихлас һәм тирән өметләр белән каравыннан. Бу да шагыйрь натурасының аерылгысыз бер сыйфаты.

> Кыр өстеннән көтү-көтү тузганаклар
> Очып бара кошлар киткән якка таба.

Дүрт юллык шигырьдән бер өзек. Ә шигырьнең исеме — «Өмет». Күрәсезме, өмет шигырьдә ничек ачыла: тузганаклар да кошлар артыннан юлга чыкмакчылар... Нинди чагыштыру — кыска гомер һәм озак яшәү матурлыгы, өмет һәм реаль чынбарлык, бер мизгел һәм алдагы киләчәк. Дүрт юллык шигырьгә барысы да сыйган. Иң әһәмиятлесе, бу күренешнең чынлыгы бөтен тамырлары белән сизелеп тора.

Гәрәй Рәхим иҗаты безгә, укучыларга, чын поэзия тамырларының тагын берсен ачып бирә. Ул — гади яшәешкә игътибарлы булу, аны тоеп һәм сизеп тору. Әнә шунда инде синең натураңның кем икәнлеге ачык сизелә. Син ул гадилектә нәрсә тоясың, нәрсә аңлыйсың? Әгәр дә син үзең бик примитив шәхес икән — синең

өчен ул тормышта бер нәрсә дә булмас. Үз эчендә зур гарасатлар, кичереш давыллары бара икән — ул чагында син әлеге гап-гади тормыштан үз күңеленә килеп ялганган меңнәрчә, миллионнарча җепләр табарсың һәм язганнарыңа ирексездән шуларның авазы килеп керер — син үзеңнән-үзең әнә шуларның моңлы яңгырашын җырларсың. Ул җырлар — синең үз күңелеңнең ихлас тавышы булыр. Синең җырларың әнә шуларның икесен тоташтыручы моңлы бер нечкәлек булыр.

Кыскача нәтиҗә ясап әйтергә кирәк булса, без ул иҗатның иң беренче сыйфаты итеп, мөгаен, табигыйлеккә нигезләнгән кешелеклелекне атар идек. Шуннан килеп дөньяны, тормышны тою тулылыгы, тирәнлеге дияр идек. Шагыйрьнең тагын башка үзенчәлекле якларын саный башласак — шигырьләрендәге көчле хис ташуын, аның өстенлек итүен, шигъри әсәрнең укучыга шул халәт аша тәэсир итүен күрсәтер идек. Һәм яңа сыйфатлар итеп, шагыйрьнең тормышны тоташтан шигърият итеп тоюын, бөтен вакыйгаларда, фактларда аның поэзия күрүен әйтер идек. Без укыган «Моңнарым» китабындагы һәр шигырь — әнә шул җанның чагылышы һәм аның яшәү мизгеле...

Гадәттә, шагыйрь үзенең шигырьләрен кешеләргә юллагач — балаларын еракка озаткан ана кебек — алар өчен борчылуда, уйда кала. Ул аларның «исән-сау барып җиттек» дип хәбәр бирүләрен көтә. Шигъриятттәге табигый моңлылык — укучыларга бик кадерле. Ул моңлылык — кешелеклелекнең аерылгысыз юлдашы. Кешенең табигыйлегенә, аның күп еллар буена тупланып килгән матурлыгына төрлечә хилафлыклар ешаеп киткәндә, ул безгә тагын да кирәгрәк. Чөнки андый хәлдә табигый моңлылыкка нигезләнгән шигърият кешене яклаучы, аның өчен көрәшче булып кала. Бу мактаулы вазифа — кешенең табигый асылындагы байлыкларны яклау һәм саклау миссиясе — шигъриятнең үзе өчен дә төп үсү юнәлеше, үзәк һәм иң мөһим булган, бердәнбер юл. Аңа зур перспективалар ача, олы табышлар китерә торган юл. Бу юл — кешелеклелек өчен көрәш юлы.

## Геннадий Ивлев

# РӨСТӘМ КУТУЙНЫҢ ЛИРИК ПРОЗАСЫ

Рөстәм Кутуйның шагыйрь һәм прозаик буларак әдәбиятта беренче мөстәкыйль адымнарын атлавы илленче еллар ахырларына туры килә. һәм яшь каләм иясенең үз стилен табуы, язучы буларак формалашуы шул заманның кайбер яңа таләпләре, әдәбият тормышында барган үзгәрешләр тәэсиреннән азат түгел, билгеле.

Илленче еллар урталарыннан башлап, әдәбиятта лирик проза дип исем алган стиль агымы барлыкка килә һәм тиз вакыт эчендә күзгә күренеп көчәя. Бу агым, аның отышлы яклары хакында бәхәсләр һәм дискуссияләр озак вакытлар тынмый. Әдәбият галимнәре һәм тәнкыйтьчеләрнең күпчелек өлеше лирик прозаны әдәби үсешнең закончалыклы һәм характерлы күренеше дип бәяли. Тискәре фикерләр күбесенчә шушы стильдә язылган кайбер уңышсызрак әсәрләргә нигезләнеп әйтелде.

Алтмышынчы елларда инде лирик проза совет әдәбиятында үзенә гражданлык хокукы яулый һәм киң таралыш ала. Каләм ияләре совет кешесенең рухи-эмоциональ яшәеше, күңел дөньясына тирәнрәк үтеп керә, аны кыюрак яктырта башлыйлар. О. Берггольцның «Көндезге йолдызлар», В. Солоухинның «Чык тамчысы», Ю. Смуул әсәрләре әлеге лирик стильнең зур гына күләмле әсәрләр, яңа әдәби җәүһәрләр тудыруга сәләтле булуын ачык раслады. Күп кенә яшь язучыларның да иҗаты нәкъ менә шушы юнәлештә үсеп китте. Кайбер аерым әсәрләр турындагы фикерләр бәхәсле булса да, лирик башлангыч М. Алексеев, В. Астафьев, Ю. Нагибин, В. Федоров иҗатларында да ачык чагылды.

Лирик проза рус әдәбиятында гына түгел, башка милли әдәбиятларда да үзенә юл ярып күркәм иҗади җимешләрен бирде. Лирик башлангыч белән бәйле стиль үзенчәлекләрен М. Стельмах, М. Слуцкис, И. Друце, Н. Думбадзе, Э. Межелайтис, Я. Брыль, Ч. Айтматов, Ю. Шесталов прозасында күрәбез. Әдәбият белгече Ч. Гусейнов язганча, «лирик проза, рус әдәбиятында туып (О. Берггольцның «Көндезге йолдызлар»ы), бөтен совет прозасына үтеп керде. Сүз бу очракта бер әдәбиятның башкаларга йогынты ясавы хакында бармый, биредә әдәби процессларның эчке үсеш законнары төп рольне уйнады. Иҗтимагый ихтыяҗ булу әдәбиятта лирик агымның, аерым алганда, күңелнең иң нечкә һәм интим хисләрен сурәтләү юнәлешенең көчәюенә китерде». (Бүгенге бердәм әдәби процессның асылы һәм формалары. Кара: «Әдәби процесс һәм тәнкыйть». «Мысль» нәшрияты, Мәскәү, 1975 ел.)

Әсәрләрен рус телендә яза торган татар язучысы Рөстәм Кутуй да менә шушы лирик проза өлкәсендә уңышлы иҗат итеп килгән һәм бөтенсоюз укучысына танылган каләм ияләренең берсе.

Р. Кутуйның беренче проза әсәрләрен туплаган китабы («Малайлар») 1961 елда дөнья күрә. Тагын бер елдан шигырьләр җыентыгы басылып чыга. Димәк, аның

прозасы шигърият белән бик табигый рәвештә үрелеп бара башлый. Лирик проза өлкәсендә эшләүче башка күп кенә авторлар өчен дә уртак сыйфат бу. Аның проза әсәрләренә хас мул образлылык, символик алымнар, шигъри бизәкләр поэзия йогынтысы белән аңлатыла. Инде иҗат гомеренең ике дистәгә якын елы узып киткән, шул вакыт эчендә дистәдән артык яңа шигырь һәм проза җыентыклары чыгарган язучы лирик юнәлешкә һаман да турылыклы булып кала.

Кешенең хис-кичерешләре дөньясына үтеп керүгә, тормышның эмоциональ сферасын тирән үзләштерүгә омтылышы Р. Кутуйны, үзеннән-үзе дип әйтерлек, кешенең кеше булып өлгереп килгән чоры — бала чакка, яшүсмерләр дөньясына алып китә. Аңлашыла ки, рухи тәҗрибә орлыклары кешегә бала чактан салына, нәкъ шул чорның кичерешләре, хис-тойгылары аның рухи-әхлакый яшәешенең нигезенә ята. Саф та, сизгер дә бала күңеле, тормыштагы бар яхшылык, изгелеккә һәм, шуның белән бергә, гаделсезлек күренешләренә дә үтә нечкә мөнәсәбәте лирик проза белән эш итүче каләм иясенә кирәкле ачкычны — хикәяләү юнәлешен бирә. Р. Кутуйның «Малайлар», «Яңгыр булыр», «Кар бабасы ясыйм» дигән хикәя җыентыклары геройларының эчке кичерешләрендә язучының үз буыны, яшьтәшләре тәҗрибәсе чагыла. Ә ул буынга исә бик яшьли килеш сугыш еллары ачысын, якын кешеләрен югалту фаҗигасен татырга туры килде, ахрысы, шуңа күрәдер, алар тормышта тизрәк өлгерде, яхшылык, намуслылык, гаделлекнең кадерен белергә иртәрәк өйрәнде.

Р. Кутуйның 1969 елда басылып чыккан «Юлда» исемле хикәяләр һәм повесть-новеллалар китабын аның иҗатында яңа этап булды дияргә мөмкин. Биредә язучының геройлары да үсә-житлегә төшкәннәр, тормыш материалын иңләү колачының да шактый киңәюе күренә. Шушы елларда ул үзе өчен яңа булган повесть-новеллага мөрәҗәгать итә (жанрны автор үзе әнә шулай атый). Әсәрләрендә конфликтлар тирәнәя, индивидуаль стиль үзенчәлекләре ачыграк сизелә. Болар барысы Р. Кутуйның язучы буларак җитлегү чорына керүе турында сөйли иде.

«Р. Кутуй — рус һәм татар әдәбиятлары чигендә калкып чыккан нечкә стилистларның берсе»,— дип язды Л. Аннинский («Р. Кутуй прозасы» исемле мәкалә. «Наш современник», 1970 ел, 9 сан). Р. Кутуй хакында язган башка тәнкыйтьчеләр дә аның иҗат индивидуальлеген билгеләп үтәләр. Язучы үзе «Литературная газета»да урнаштырылган бер мәкаләсендә («Шигърият дип нәрсә атала?» 1964 ел, 3 декабрь саны) полемик тонда шигъриятне ничек аңлавы хакында язып чыкты. Мәкалә авторның прозадагы индивидуаль иҗат йөзен төсмерләргә ярдәм итә. «Поэзия, күрәсең, кеше гаҗәпләнергә өйрәнгәндә тугандыр», — дип башлый ул мәкаләсен. Чыннан да, дөньяга, кешеләргә карап гаҗәпләнә белү Р. Кутуй өчен образлы фикерләүгә этәрә торган эмоциональ импульс ролен уйный. — «Чын шагыйрь — үзе бер дөнья ул. Бердәнбер, үзгә дөнья. Кабатларга мөмкин түгел. Күккә карап, аның төсле булырга тырышу — мәгънәсезлек. Үз күгеңне булдырырга кирәк... Шигырь язарга өйрәнергә мөмкин, әмма шигъриятькә өйрәнеп булмый».

Традицияләрне дәвам иттерүне Р. Кутуй сәнгатьтә яңаны эзләү, үз иҗат йөзеңне табу дип саный. Милли традицияләр бөтен дөнья культурасы белән үзара тыгыз бәйләнештә тора. «Милли традицияләр — бик мөһим нәрсә, әмма алар гына да җитми. Дөнья культурасы традицияләрен дә исәпкә алырга кирәк. Ул төрле халыкларның иң алдынгы милли традицияләреннән үсеп чыккан агач кәүсәсе кебек».

Язучы күңеле аның үзен урап алган тормыш тәэсирләреннән мөлдерәмә тулып тора. Әдәби иҗатка сусау, ихтыяҗ сизү художникның «кешеләр тормышына яктылык өстәүгә» омтылуыннан килә. «Шушы яктылыкны үзеңдә тудырырга да, соңгы сулышыңны биргән кебек, тормышка бирергә. Һәм менә син үз җирлегеңне табып алдың дигән сүз, шуннан читкә борылу — ул инде хыянәт булыр иде. Мин үз нурланышымны таптым», — ди Р. Кутуйның «Ел алкалары» исемле повестеның лирик герое. Иҗатчы буларак, Р. Кутуйга тормышны үткен эмоциональ хисләр белән кабул итү хас, әнә шул сыйфаты әсәрләренә күчеп, хикәяләүдә рухи бер киеренкелек тудыра да инде. Язучы бөтен нәрсәне үз йөрәге аша үткәрә, әсәрләрен үтәдән-үтә үз хис-кичерешләре белән сугарып чыгара. Шуңа күрә аның әсәрләренең сәнгатьчә яңгырашында әхлакый-этик критерий өстенлек ала. Хикәяләрдә автор үзе, аның позициясе ачык сизелеп тора, чөнки ул тасвирланган вакыйгалар, персонажлар, тормыш күренешләренә үзе үк эмоциональ бәяне биреп бара.

Язучының эмоциональ хәтере бик ассоциатив, бу хәл шулай ук аның сәнгатьчә фикерләвен, сурәтләү рәвешендәге лирик башлангычны көчәйтә. Ассоциативлык образлар структурасына да, хикәяләү рәвешенә дә нык тәэсир итә. Хикәяләрдәге вакыйгалар, геройлары кичерә торган фикер һәм хисләр, эзлекле тестә тасвирланмыйча, сайланып кына бирелә. Автор катлаулы сюжетка корылган әсәрләрендә дә геройларның хәл-әхвәлләрен бәйнә-бәйнә сөйләү юлыннан бармый. Язучы өчен иң мөһиме — геройның гомер юлындагы иң драматик моментлар, кешегә рухи тәҗрибә бирә алырлык хәлләрне эләктереп алу.

Рөстәм Кутуй әсәрләрендә даими яши торган бер образга тукталмый мөмкин түгел. Ул образ аша язучы гүя үзе гәүдәләндергән яшь буын вәкилләренең рухи ныклыгын сыный, бүгенге уңай геройның эчке дөньясын шул образ белән янәшә куеп, буыннар бердәмлегә гармониясен күзәтә. Дөрес, сугышта һәлак булган әтисе образы язучының бер әсәрендә дә турыдан-туры һәм тоташ сурәтләнмәгән. Күбесенчә, Гадел Кутуй шәхесенең чалымнары әсәрләрдә бөртекләп кенә чагылып китә. Әмма эчке асылы белән ул Р. Кутуйның бөтен иҗат гомерендә һәм тормышында җуелмаслык эз калдырганлыгы сизелеп тора. Тормышта актив позиция биләгән, һәртөрле гаделсезлек, тар күңеллелек, явызлыкка килешмәүчән булган әлеге образ Р. Кутуй әсәрләренең яшь геройларына да тәэсир ясый, яшь буынны, тәнкыйтьче Р. Мостафин сүзләре белән әйткәндә, «намуслы, туры җанлы, бөтен характерлы кешеләр, ленинчыл революцион хакыйкатьне үзләренең табигый бер эчке ихтыяҗына әверелдергән шәхесләр итеп тәрбияләргә булыша». (Яхшылык һәм гаделлеккә сусап. «Литература и жизнь», 1962 ел, 23 сентябрь саны.)

Әнә шулай итеп, күренекле татар язучысы Гадел Кутуй үз улының иҗатына юл күрсәтүче булып китә. Әтисе Бөек Ватан сугышына киткәндә Рөстәмгә алты яшь кенә була. Шулай да хәтер күп нәрсәне саклап калган, әтисенең китаплары, кульязмалары, фоторәсемнәр, хатлары (ә алар бик күп һәм ифрат кызыклы) бар. Болар өстенә татар халкының үз әдибенә мәхәббәте бар... Ата шәхесе, аның иҗади янулары, теләк-идеаллары Р. Кутуйның рухи дөньясы һәм характерына да ныклы тәэсир ясаган. Мәсәлән, аның әхлак проблемаларына тартылуында татар әдәбияты һәм аеруча Г. Кутуй иҗатының йогынтысы сизелә. «Тапшырылмаган хатлар» авторының искелек калдыкларына карата килешмәүчәнлеге, тормыш күренешләрен бәяләүдәге үткенлеге Р. Кутуйның иҗат психологиясендә дә эзен калдырган дип әйтә алабыз.

Р. Кутуйның тасвирлау стиленә хас лирик субъективлык кайбер тикшеренүчеләргә аны романтик язучы дип бәяләргә җирлек бирде. Л. Аннинский, мәсәлән, аның иҗатына шундый карашта. Әмма, язучының сәнгатьчә фикер рәвешендә кайбер романтик сыйфатлар булуга да карамастан, тулаем алганда ул реалистик җирлектә тора.

Лирик субъективлык романтик язучы субъективлыгыннан аерыла. Романтик художник чынбарлыктан читләшә, ул аны үз хыялы яктылыгында тудыра. Бу исә Р. Кутуйга хас түгел. Аның геройлары дөньяны образлы итеп күрәләр, бу сыйфат аларның хисси-эмоциональ дөньясын киңрәк ачарга ярдәм итә, әмма алар үзләре реаль кешеләр булып калалар. Әсәрләрдә һәр геройның диярлек социаль хәле анык күренә. Әйтик, «Җилсез көнне» хикәясендә авыл карты Василий Никодимович, «Митрич» әсәрендә эшче Дмитрий, «Җир йөзендә аю бар» новелласында рәссам Радик һәм башкалар реаль кешеләр буларак яшиләр. Р. Кутуй үз геройларының тормыш шартларын сурәтли, геройның характеры һәм психологиясен шул шартларга бәйле рәвештә ача.

Искә алынган мәкаләсендә Л. Аннинский үзе үк Р. Кутуй әсәрләренең «тормышчан җирлеге хикәяләүнең әкияттәгечә романтик бизәкләре аша үтәдән-үтә күренеп тора. Бу җирлек гадәттә әсәр ахырында көтелмәгәндә калкып чыга», — дип күрсәтеп үтә. Рациональ һәм хисси башлангычлар, шул рәвешчә, хикәяләрдә билгеле бер гармониягә килә. Р. Кутуй повестьлары һәм хикәяләрендә романтик фантастика да, гадәттән тыш характерлар да юк. Акыл һәм хисләрнең очынулы-хыялый халәте, кешенең рухи дөньясын шигъри буяулар аша яктырту әсәрдә романтик настроение тудырса да, моны чынбарлыкны образлы чагылдыруның романтик тибы дип әйтә алмыйбыз.

Рухи тәҗрибә һәр чак хәрәкәт эчендә, төрле каршылыклар, конфликтлар аша туа һәм формалаша. Р. Кутуй төп игътибарны әнә шундый хәлләргә юнәлтә дә. Конфликтларның олы гуманистик идеаллар позициясеннән торып хәл ителүе аларга аеруча үткенлек, саллылык бирә. Мәсәлән, «Беренче көрешү» исемле новеллада һуш китәрлек зур конфликт та юк кебек: бары тик шул — кыз вәгъдәләшкән урынга очрашуга килмәгән. Әмма автор егетнең беренче мәхәббәт хисләренең сафлыгын, гүзәллеген мәңгелек идеал югарылыгына күтәреп сурәтли алган. Кызның әхлакый сукырлыгы әнә шул идеалны җимерә. Бу ике яшь кешенең рухи дөньясы арасындагы каршылыкны күрсәтүе белән язучы новеллага драматик яңгыраш бирә. Үткән ситуация геройларның эчке дөньяларын барлык кечене «эшләргә» мәҗбүр итә, шуның нәтиҗәсендә барлык тормыш ваклыклары артка чигенеп, иң тирән бәйләнешләр генә торып кала.

Геройның үз рухи дөньясы белән бер ялгызы торып калуы лирик әсәрләргә гомумән хас сыйфат. Мондый «ялгызлык» геройның эчке рухи байлыгын күрсәтергә мөмкинлек бирә. «Беренче көрешү» новелласының герое иң тәүге мәхәббәтендә алданып, ялгыз калганнан соң кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләренең катлаулылыгын төшенә башлый. Егетнең эчке дөньясы әрнүле, әмма олы һәм саф хисләр белән сугарыла. Күңел нечкәрүе, каршылыклы кичерешләрдән әзгәләнү яшь геройның рухи дөньясын үзенчә баета. Автор сюжет линиясендәге борылышлар, хикәяләүдәге аерым детальләр ярдәмендә героен тирә-юньдәге тормыш-көнкүреш белән дә бәйләп барырга өлгерә, герой ялгызы килеш тә читкә тибәрелеп калмый. Әлеге әсәрдә егеткә күршесе ярдәм итә, урамнан узып баручылар белән дә ул өзлексез рухи бәйләнештә тора.

Р. Кутуй әсәрләренең геройлары кешеләрдәге күңел юмартлыгын, җан җылысын һәрнәрсәдән диярлек өстен күрәләр, башкаларның рухи тәҗрибәсен үзләштерәләр. Язучы кешеләрдәге хисси-эмоциональ башлангычны яклый, шуннан башка хаклык, изгелек, матурлыкның кадерен белү дә, актив шәхесне формалаштыру да мөмкин булмавын күрсәтә. Р. Кутуйның бай рухлы геройлары дөнья малы белән сыналуга бирешмиләр, шикле юллар белән максатка ирешү, кемдер башка бирәү исәбенә җиңел тормыш алып бару, ничек тә булса җайлы яшәү коткысына бирелмиләр. «Җир йөзендә аю бар» новелласында рәссам Радик, мәсәлән, Носов тәкъдим иткән эшнең матди яктан файда китерәчәген, моның өчен тирә-юньдәге кешеләрнең үзенә телтеш тидерә алмаячагын белгән килеш тә үз әхлак принципларына хыянәт итми.

Р. Кутуй үз геройларының әхлакый сыйфатларын аларның дөньяны образлы итеп күрү, сурәтле фикерләү сәләте белән бәйләнешкә куя дигән идек. Шушы образлылык, хисләр байлыгы тискәре персонажларда гап-гади исәп-хисапка корылган теләкләр, коры акыл сату, кичерешләр фәкыйрьлеге белән алышына. Андый образ хәрәкәтчәнлектән, рухи үсештән мәхрүм, аның хис-тойгылары бер ноктада диярлек катып калган. Әхлак мәсьәләләрендә коры исәп белән, артык рациональ фикер йөртүе персонажны вак җанлылык, дорфалык, ваемсызлык, ә кайчакта явызлыкка илтә. «Люстра» хикәясендәге мещанка Серафима Петровна — нәкъ әнә шундый персонажларның берсе.

Лирик прозада монолог һәм диалог, сурәтләү чаралары буларак, үзенчәлекле функцияләр кабул итә. Болар, гомумән, Р. Кутуйның герой психологиясен ачуда яратып куллана торган чаралары. Лирик монолог, мәсәлән, аның күп әсәрләрендә хисси хәтерне чагылдыруга, герой тормышында әлегрәк булып узган вакыйгаларны хикәя кылу алымына әверелеп, кечкенә бер новелла булып китә. Герой кичерешләренең эчке хәрәкәте, эчке вакыйга ролен уйнавы әсәрдә психологик характеристиканы тирәнәйтә. Ә кичерешләр соңрак конкрет бер гамәл, эш-хәрәкәткә китерә. Кискен диалогларда персонажлар үзара бәхәс алып баралар, бу бәхәстә катнашучылардан берсенең сүзләрендә һәрчак диярлек бәхәс предметыннан киңрәк булган мәгънә ята, текст артында зуррак мәгънә белдерелә.

«Лотереягә маймыл оту» исемле новеллада Женя исемле яшь бер кыз кичерешләре сурәтләнгән. Аның бирәү белән үзара эчкерсез саф мөнәсәбәтләр коруга омтылуы уңышсыз тәмамланган. Үзара мөгамәләдә эчкерлелек, хәсетлек, ялганы өчен ул аны кире каккан. Һәм менә сыкрау-рәнҗүле хисләре белән ул — шәһәрдә бер ялгызы. Укучы алдында кызның пакь, риясыз, изге күңеле ачыла. Күңелендә тирән уелып калган кадерле бала чак хатирәләре күз алдыннан үтә. Аның кылачак гамәл-

нәренә психологик җирлек шулай тудырыла. Җан әрнүләре геройняны яхшылыкка карата тагын да сизгеррәк итә, яхшылыкның бетмәс-төкәнмәс көченә ышанычын арттыра. Укучы каршында Женя образының мөлаем сыйфатлары, сөйкемлелеге тагын да арта төшә.

Биредә шунысын да әйтергә кирәк, герой шәхесенең рухи-эмоциональ ягына гына игътибарны туплау Р. Кутуйны кайбер кимчелекләргә дә китерми түгел. Реалистик лирик прозада образ структурасын синтетик характердарак, күп кырлырак итеп күрәсе килә. Р. Кутуй кайчак геройның рухи дөньясын тасвирлау белән артык дәрәҗәдә мавыгып китә, нәтиҗәдә аның тышкы чагылышына ачыклык җитенкерәми, хискичерешләр үз эчендә йомылып кала. Образның эчке яшәеше лирик хикәяләү дулкыннары эчендә күмелеп калгалый.

Лирик проза хикәяләүнең лирик һәм эпик ысулларын үзенчәлекле нисбәттә файдалануны, аларның үзенә генә хас бер кушылмасын булдыруны таләп итә. Дөрес, Р. Кутуйның «Ел алкалары» кебек әсәрләрендә сәнгать материалын оештыруның лирик ысулын гына файдалану да үзен аклый. Жанр ягыннан аларны проза белән язылган лирик шигырьләр дип атарга мөмкин. Әмма мондый әсәрләр — лирик проза агымының бик аз өлеше генә. Төп урынны исә персонаж-образлары булган әсәрләр алып тора. Андый әсәрләрдә эпик хикәяләү элементлары шактый роль уйный, вакыйгалар, геройларның кылган гамәлләре сурәтләнә, характерлар гәүдәләнә. Безнең язучыбыз, кайбер әсәрләрендә, күрәсең, менә шушы таләпне искә алып җиткерми. Р. Кутуй повестьларыннан берсендә («Один на дороге с желудями») сурәтләнгән Гривцов образында нәкъ әнә шундый кимчелек сизелә. Заманның тирән әхлакый проблемалары куелган әлеге әсәрдә автор яшь кешенең рухи йөзе, әхлакый дөньясы формалашуын, шушы процессның иң җаваплы, киеренке моментларын күрсәтүне бурыч итеп алган. Гривцов үз әтисеннән яхшылык өчен көрәшергә, «явызлыкның борынына кундырырга», чын тормыштан мещанлык оясына качмаска өйрәнгән. Ләкин герой конкрет вакыйгаларда күрсәтелми, аның кылган гамәлләренә юл арасында гына ишарә ителә. Эпик хикәяләү элементларының җитенкерәмәве Гривцов образын сәнгать бөтенлегеннән мәхрүм итә. Эпик хикәяләү алымнары урынлы кулланылган әсәрләрдә исә образ сәнгатьчә төгәлләнгәнлек ала. Мисал рәвешендә язучының «Митрич», «Люстра», «Балерина», «Җилсез көнне» һәм башка хикәяләрен атарга булыр иде.

Лирик проза тормыш материалын башка жанрлардан азрак сыйдырмый. В. Воронов бик хаклы күрсәтеп үткәнчә, Р. Кутуй да «лирик жанрларда үз-үзенә чикчикләр куярга теләми һәм нәфис эшләнгән новеллаларын саллы тормыш материалы белән бик уңышлы тутыра». (В. Воронов. Олы дөнья яссылыклары. «Мәскәү» журналы, 1964 ел, 4 сан.)

Чынлап та, язучы буларак, Р. Кутуйны тормышның ниндидер бер катламын гына белә дип әйтә алмыйсың. Балалар дөньясы, аналарның борчу-мәшәкатьләре дә таныш аңа, галимнәр, рәссамнар, эшчеләр тормышыннан да хәбәрдар ул, авыл да, шәһәр тормышы да ят түгел.

«Җилсез көнне» хикәясе герое Василий Никодимович бөтен гомерен авылда үткәргән. Кызу ритмлы шәһәр тормышы ят аңа. Шәһәрдә яшәүче кызларының эчке дөньясын аңлау да ансат түгел. Тормышның яңа тизлек, яңа мәгънәләр алуын карт сизә, күнегелеп беткән авыл тормышы, гадәтләренең үзгәрә баруын да күреп тора. Язучыны авыл чынбарлыгының аерым яклары, яшәеш табигыйлеге, олы мәгънәви кыйммәтләре, табигатькә якынлыгы җәлеп итә. Василий Никодимовичның кызлары өчен авыл табигате эстетик ләззәт чыганагы, ял урыны булса, карт үзен шул тирәлекнең аерылгысыз бер өлеше итеп тоя, аның күңел гармониясе әнә шуннан да килә. Табигать күренешләре хикәядәге фаҗига мотивының сафлыгын тоярга ярдәм итә. Василий Никодимовичның үлеме олы бер гомернең табигый рәвештә очлануы булып кабул ителә. «Каз канатлары» әсәрендә дә кеше күңелендәге яхшылыкның яңаны тудырырга сәләтле булуы раслана. Зур эшләр, ачышлар ясарга, бәхет яуларга бары яхшы һәм көчле кешеләр генә сәләтле.

Р. Кутуй әсәрләрендәге төрле милләт кешеләрен тормышның социалистик асылы берләштерә, Ватанга мәхәббәт, гаделлек һәм кешелеклелек, хезмәт сөю һәм намуслылык, киләчәккә ышаныч туганлаштыра. Кыскасы, безнең авторыбызның лирик прозасында бүгенге заманның әхлакый тәҗрибәсе хакында киеренке сөйләшү бара.

Рафаэль Мостафин

# АНАЛАРНЫҢ ЧӘЧЕ НИК АГАРА?

„Бер ананың биш улы» повесте — Хәсән Сарьянның соңгы әсәре. «Соңгы» сүзе монда туры мәгънәсендә кулланыла. Кечерәк буйлы, базык гәүдәле, искиткеч сабыр холыклы Сарьянны без инде беркайчан да Матбугат йорты коридорларында очрата алмабыз. Ул инде беркайчан да, калын күзлек пыялалары артындагы кысыграк шаян күзләрен елтыратып соңгы командировкадан алып кайткан тәэсирләре белән уртаклашмас, беркем белән бәхәскә кермәс. Тукай клубының трибунасына басып, тел-стиль мәсьәләләренә кагылышлы кызыклы докладлар ясамас. Укучылар белән радио аша теге яки бу сүзнең мәгънәсе, дөрес кулланылышы турында әңгәмә дә алып бармас...

Ул безнең арада юк инде...

Чордашыңны, каләмдәш дустыңны югалту бервакытта да җиңел түгел. Ләкин бу очракта үлем (Хәсән Сарьян әле иллесен дә тутырмаган иде) аеруча рәхимсез кыланды. Чөнки аның беркемнекенә дә охшамаган үзенчәлекле таланты әле чынчынлап ачылып кына килә иде. Ул моннан ун еллар чамасы элек язылган «Әткәм һөнәре» исемле повестенда бер ялтырап алып, барыбызны да сокландырган иде. Шуннан соң Сарьянның күләмле әсәрләре күренми торды. Ниһаять, 1977 елда журналда «Бер ананың биш улы» повесте дөнья күрде[1]. Бу аның иң җитди, иң тирән мәгънәле әсәре. Алай гына да түгел, бу әсәре белән язучы татар совет прозасының алгы рәтләренә килеп чыкты, танылган прозаиклар белән бер сафка басты. Без аңардан киләчәктә тагы да тирәнрәк, тагы да җитдирәк әсәрләр көтә идек...

Хәзер инде язган кадәресе белән канәгатьләнергә туры килә. Шуңа да мин күләме белән әллә ни зур булмаган, әмма ифрат тирән эчтәлекле, ихлас күңелдән язылган бу повестька әледән-әле кабат әйләнеп кайтам, авторның укучыларга әйтеп калдырган соңгы сүзе, әсәрдә күтәрелгән мәсьәләләр турында еш уйланам.

[1] Хәсән Сарьян. Бер ананың биш улы, Татарстан китап нәшрияты, 1979.

«Бер ананың биш улы» — авторның үз тәҗрибәсенә таянып язылган әсәре. Монда без язучы туып үскән Башкортстан якларының матур табигате, аның туганнары, абый-энеләре, авылдашлары белән танышабыз. Хәсән Сарьян үз башыннан кичкән вакыйгалар, үзе татыган хисләр турында яза. Шуңа да әсәре аеруча тәэсирле, ышандыргыч булып чыккан. Автор чынлыкка һәм бары тик чынлыкка табына, аңа бер кайда да хилафлык кылмый. Әсәрдәге тирән лиризмны, эчкерсезлек хисен, үзгә бер җылылыкны шуның белән аңлатырга кирәктер.

Шул ук вакытта бу — истәлек тә, автобиографик повесть та түгел. Иҗади максаттан чыгып, автор тормыштан алынган персонажларының тышкы кыяфәтен дә, характерларын да, биографияләрен дә нык үзгәртә. Повестьның төп идеясенә хезмәт итми торган очраклы моментларны алып ташлап, геройларның гомуми, күпләргә хас булган сыйфатларын көчәйтә, аларны типиклаштыра. Әйтик, повестьның төп герое Сирин (хикәяләү аның исеменнән алып барыла) язучының үзенә бик тә якын. Шулай да Сирин — Сарьян түгел. Сирин — озын буйлы, баһадирдай таза гәүдәле. Аның холкы да, биографиясе дә авторныкы белән тәңгәл килми. Х. Сарьян Бөре педучилищесын тәмамлый, аннан соң, Уфа педагогия институтының тарих-филология факультетында укый. Сирин исә геология техникумында укый, армиядә хезмәт итә, аннан спорт белән мавыгып китә...

Әгәр язучы фәкать үзе турында, үз гаиләсе турында гына язса, повестьның әһәмияте шактый тараеп калыр иде. Бер гаиләдә ниләр булмас та, нинди генә кешеләр очрамас! Юк, безнең алдыбызда чын мәгънәсендәге әдәби әсәр. Һәм аның персонажларын да типик геройлар итеп кабул итәргә тиешбез. Типик икән, бу инде әсәр конкрет бер факттан ераклашып, күпләр өчен хас булган күренешләрне дә чагылдыра, аларның асылына төшенергә ярдәм итә дигән сүз.

Беренче кат укыганда мине күбрәк

әсәрдәге мәхәббәт сызыклары әсир иткән иде. Чыннан да, Сиринның беренче мәхәббәте искиткеч оста, мавыктыргыч итеп тасвирланган. Без әлеге олы хисснең нинди сихри кечкә ия булуын күрәбез, аның күңелдә мәңге төзәлмәс яра булып калуын аңлыйбыз. Мәхәббәт драмасы герой язмышында эзсез калмый. Сирин белән Любовь Васильевна аерылырга мәҗбүр булсалар да, бу олы хис геройның бөтен тормыш юлын яктырта, аны гел алга, яхшыга өнди, аңа үсәргә, кыенлыкларны җиңәргә булыша.

Инде, әсәргә яңадан әйләнеп кайтып, кат-кат укыгач, анда күтәрелгән башка мәсьәләләргә дә игътибар итә башладым. Хәтта күңелдә шундый шик туды: әсәрнең төп герое Сирин микән әле? Ә бәлки, бөтен бер гаиләдер, семья мәхәббәте, семья татулыгыдыр? Әсәрнең исеме үк шуңа ишарәле түгелме? Социалистик җәмгыятьнең беренчел ячейкасы булган гаилә мондый игътибарга бик тә лаек һәм мохтаҗ бит...

Бер ананың биш улы була. Әсәр ахырына таба аларның бары тик икесе исән кала. Сиринның өч абыйсы бер-бер артлы вафат булалар. Җитмәсә, тыныч вакытта, сугышсыз-нисез чорда, ул гына да түгел, тормышның яхшырган, мул һәм иркен чагында. Аларның үлеме герой күңелен телгәли, аналарының чем-кара чәчләренә ап-ак кар кебек чал төшерә. Ирексездән: ни өчен? Нигә? Кем гаепле? — дигән сораулар туа.

Беренче булып нечкә җанлы, шагыйрь күңелле Хәвадис абыйсы дөнья куя. Сәбәбе ачык кебек — үпкә авыруы, туберкулез. Әмма чирнең сәбәбе ераккарак китә, сугыш вакытларына барып тоташа. Кар астында калган эскерт төпләреннән чүпләнеп, бер капчык башак җыеп алып кайтканда, язгы ташу вакытында Хәвадис боз катыш аккан салкын суга бата, һәм үпкәсенә суык тидерә. Вакытында кирәкле дәвасы да, тиешле тәрбиясе дә булмый.

Димәк ки, Мәһибәдәр апаның ике улы сугыш кырыннан исән-сау, хәтта бер ярасыз кайтса да, шул ук сугыш афәте бер улының, күбәләк кебек изге җанлы Хәвадисның башына җитә.

Күп тә үтмәстән, исерек бандитлар икенче улын — милициядә эшләгән Мирзасын — пычак белән чәнчеп үтерәләр. Беренче карашка очраклы булып күренсә дә, бу үлемнең дә тирән мәгънәсе бар. Чөнки Мирза батырларча һәлак була. Бандитлар бер хатынны талап ятканда, тегеләр бишәү булуына карамастан, ул коралсыз-нисез ярдәмгә ташлана. Шуңа да соңыннан Казанның бер урамына аның исемен кушалар.

Автор артык басым ясамыйча гына бандитларның исерек булуын әйтеп китә. Исереклек, эчкечелек... Менә нәрсә үтерә Мирзаны. Әлбәттә, бандитлар кулы белән. Әмма шуны да истән чыгармыйк — статистика мәгълүматларына караганда, барлык җинаятьләрнең туксан проценты исерек хәлдә эшләнә.

Мәһибәдәр апаның өченче улының башына да шул ук эчкечелек җитә. Сиринның зур абыйсы, гаять кешелекле, эшчән, киче күңелле, искиткеч эшчән Раббани башта аз-азлап, күңел өчен генә эчә. Ахырдан, тыела алмыйча, көн саен эчә башлый. Аракыга акча җиткерә алмагач, одеколон чөмерә. Күпләргә таныш, безнең заманда шактый киң таралган аяныч хәл. Раббани үзе тавыш чыгармаса да, акчасын туздырып кайткан өчен хатыны, әлбәттә, рәхмәт әйтми. Шуннан китә өйдә тавыш, китә гауга... Ахыр чиктә аракыдан җиңеләя башлаган Раббани дүрт баласы белән хатынын өйдән куып чыгара, әллә ниләр кыланып бетә. Аны көчләп дәваланырга мәҗбүр итәләр. Өч-дүрт айдан ул тәмам төзәлеп, матурланып, менә дигән кеше булып кайта. Ләкин... күп тә үтми, тагы «кычкына». Һәм — котылгысыз нәтиҗә:

«— Раббани абый, сикермә! Утырып кына кит! — дип кычкыруым булды, — абый ике кулын да алга сузып, дебаркадерга сикерде. Ләкин култыксасына ябыша алмады, ике арага шатырдап төшеп китте. Халык«а-ах!» итте. Капитан өстән: «Стоп! Полный ход вперед!» дип кычкырды. Ләкин соң иде инде...»

Бу күренешнең символик мәгънәсе дә бар, минемчә. Әйе, Раббани яңа тормышка, аек, бәхетле тормышка талпыныш ясап карый. Ләкин соң була инде. Култыксага тотынып өлгермичә, упкынга төшеп бата. Докторның аңа дәваланып чыкканда әйтелгән сүзләре искә төшә: «Безнең дәваның синең гомер буена җитәрлек көче юк. Ул көч үзеңдә. Эчүдән тыелсаң — үзең тыеласың, тыелмасаң — көкрәеп катасың».

Ике туган — ике төрле үлем. Берсе исерек бандитлар белән батырларча көрәшеп һәлак булса, икенчесе салган баштан, кесәләренә сыра шешәләре тутырып чыккан вакытта суга төшеп үлә. Ләкин сәбәбе бер—аракы, дөресрәге, эчкечелек.

Эчүчелеккә каршы язылган әсәрләрдә гадәттә сәрхүшләрне булдыксыз, мораль яктан таркалган, хәтта җирәнгеч кешеләр итеп күрсәтәләр. Раббани андый түгел. Ул чын мәгънәсендәге хезмәт кешесе, яшьтән үк эшләп, тормышның ачысын-төчесен күреп үскән кеше. Аек чакта ул намусына бер тап та төшерми. Исегезгә төшерегез — салларны агызып кайтканда аңардан бер-ике бүрәнә булса да сатуын сорыйлар. Башкалар риза була кебек. Ләкин Раббани дәүләт милкенә кул тидертми, катер өчен үз кесәсеннән түләп булса да, салны сау-имин алып кайтып җиткезә. Ә аның энеләрен кайгыртуын, Тәрҗимәне ничек сөюен искә төшерегез...

Автор язганча, бу гаиләнең тамыры искиткеч нык, нәселләре җиде бабайдан бирле мәйдан тоткан көрәшчеләр була. Инде кырыкка җитеп килә торган, җитмәсә әле яңа гына больницадан чыккан Раббани да сабан туе вакытында нинди нык, таза җилкәле батырга бирешми. Һәм шундый кеше, әле утыз-кырык ел гөрләтеп яши алырлык кеше, балаларын

ятим калдырып, күпме кешегә кайгы китереп үз аягы белән диярлек гүргә керә.

Кайдан, ничек килеп төшә соң аның башына бу афәт? Аталары, сирәк-мирәк бал эчкәләгән булса да, аракыны үз гомерендә кабып та карамаган. Аналары аракы булган табын янына якын да килми, чыгып ук китә.

Бәлки кибетчеләр гаепледер? Әсәрдә моңа берникадәр ишарә бар: «...Үзебезнең авыл кибетенә кердек. Яртыны гына сорагач, сатучы кыз Җәмилә майлы елмаеп, Әдрәнгә карады: кит әле моннан, тау чаклы гәүдәгезгә бер ярты сорап торасың, оялмыйча! Әллә нигә бер кайткан абыеңа ящигы белән ал. Синең бер ярты белән мин ничек план тутырыйм ди?» Типикмы бу хәл? Һичшиксез! План тулсын дип, исерек кешегә аракы сату, бала-чага кулына эчемлек бирү, билгеләнгән сәгатьләрне бозу — болар әле барысы да, кызганычка каршы, шактый еш очрый торган күренешләр.

Әмма язучы әлеге иң өстә яткан сәбәп белән генә чикләнмичә, тирәнгәрәк керә.

Һәрбер нәрсәнең башы бар, ахыры бар, дигәндәй. Ахырын без инде беләбез. Башы кайда соң?

Повестьны яңадан актарыйк. Менә япь-яшь туганнарның эчемлекне беренче татып караулары:

«Әдрән белән минем алга да өстендә колмак чүбе йөзеп йөргән кызгылт бал куелган иде. Безнең эчми утырганны күреп алган Раббани абый:

— Бәй, сез нишләп эчмисез әле, апайлар? — дип яныбызга килеп җитте.

— Эчегез, апкачайларым, эчегез. Бал гына ул, — дип, Мирзә абый да безнең иңбашлардан кочып алды.

Без ык-мык килеп баш тартырга итеп карадык, ләкин абыйлар ихтыярга куймады. Өстәл янында өни юк. «Эчкән табынга утырмыйм, аллам сакласын!» дип, өй белән ике арада гына йөри. Зур абый минем янга, Мирзә абый Әдрән янына баскан — инде стаканнарны авызга ук китергәннәр. «Ярамый» дип әйтүче юк, һәммәсе ашаудан туктап, дәрт биреп тора.

— Апайларыгыз менә дигән!

— Эчсеннәр әйдә, эчсеннәр, ул гәүдәгә...

— Мондый шатлыкта да эчмәгәч...

...Стаканнарны бер кул белән без, бер кул белән абыйлар тоткан — эчереп бетермичә кулларын алмадылар».

Әсәрнең буеннан-буена мондый күренешләрне шактый күп очратабыз. Эчмәгән кешегә бөтен табындагылар дәррәү ябырылалар, тын алырга ирек бирмиләр. Иптәшләреңне ихтирам итмисең, дип бәйләнәләр. Тавык та эчә, имеш, дип өстәп куялар. Кайдан килгән безгә шундый начар гадәт? «Барыемени ул сугышка тикле аракы эчү! — ди Шәрифулла карт. — Күрше авылның Кәҗә Талип кына җиде бала өчен акча алган көнне бер чүлли эчеп, шуңа исереп кайтырые. Анысы да — елына бер!» Хак сүзләр. Ләкин шул ук Шәрифулла карт, Раббани аның янына хәл белергә кергәч, авызыннан алмыйча, кыстый-кыстый эчерә, үзе шуңа куанып бетә алмый.

Соңгы елларда эчүчелек шундый гадәти күренешкә әйләнеп китте, хәтта иң изге борынгы йолалар да аракыга көйләнә башлады. Раббаниның яңа йорт салу күренешен исегезгә төшерегез. Бура бураліп, матча күтәргәндә Шәрифулла абзый биленнән бәйләп аракы шешәсе күтәрергә ниятләнә. Димәк, яңа салына торган йортның нигезенә үк аракы салып керергә җыеналар. Ярый әле Мәһисәрвәр апа күреп кала:

— Карт башың белән, борынгылар йоласыннан чыгып, нишләп алай матчага шул хәсис аракыны элеп күтәрергә котыртып йөрисең? Мин бит шуңа дип икмәк салырга йөрим, яңа нигезгә башта яңа икмәк керсен.

Шәрифулла абзый да аңгыра түгел — аңлый, аракының зарарын бик яхшы аңлый. Башка авыл агайлары да, хәтта үзләре чөмереп эчүчеләр дә аракының агу икәнен бик яхшы беләләр. Әмма барыбер эчәләр. Чөнки бу инде гадәткә кереп киткән. Башкача ял итүне дә, дус-иш белән сөйләшеп утыруны да, кунакны ничек кабул итүне дә күз алдына китерә алмыйлар.

Хәсән Сарьян үзенең әсәрендә без күнеккән эчүчелекне «фаш итми», бармагы белән төртеп күрсәтми. Ул фәкать тормыштагын гына яза — шуннан укучы үзе нәтиҗә ясарга тиеш. Әмма шул ук вакытта язучы бу мәсьәләгә битараф карый дип тә әйтеп булмый. Әсәрдән тагы бер өзек китерәсем килә.

Сирин авылга кайткач, абыйсы Раббаниның төнлә белән уянып, йоклый алмый интегеп йөргәнен күрә. Ул хәзер төн уртасында торып эчмәсә, яңадан йокыга китә алмый икән.

«Раббани абый ут кабызмыйча гына тәрәзә янына китте. Тәрәзәдән, упкындай, болытлы кара төн күренеп тора иде. Беленер-беленмәс кенә яктылык төшкән. Аны да абыйның караңгы өйдә зураеп киткән кара гәүдәсе каплады. Өнсез тынлыкта тирән стаканга, шешәдә ч тын да алдыртмыйча, аракы агызган тавыш ишетелде».

Шомлы, аяныч күренеш. Ирексездән эчүчелек кешене йота торган караңгы упкын булып күз алдына баса. Бу упкын тагы күпме кешенең башына җитәр? Ничә гаиләне җимерер, тату гына башланган бәхетле тормышны чәлпәрәмә китерер? Нихәтле балаларны ятим калдырыр, аларның киләчәгенә, булачак тормышларына мәңге җуелмый торган кара тап төшерер?

Әлбәттә, Х. Сарьян әсәре, күп планлы әдәби әсәр буларак, моңардан тыш башка фикерләр дә кузгата. Әмма повестьның бер сызыгында автор вакыйгаларга җентеклерәк тукталган һәм мин дә аңа ныклабрак игътибар иттем. Чөнки бу сызыкта, минемчә, язучының үлем алдыннан әйтеп калырга теләгән бик мөһим, җитди фикерләре чагылган.

# ЯҢАРЫШ ЧИШМӘЛӘРЕ

XX гасыр татар поэзиясенең сәнгатьчә җитлегү һәм чәчәк атуындагы үзенчәлекле этаплар әдәбият фәне тарафыннан шактый җентекле өйрәнелгән. Әйтик, гасыр башы поэзиясенә һәм совет поэзиясенең аерым чорларына багышланган зур-зур хезмәтләр бар. Алар арасында профессор Хатип Госман каләменнән чыкканнары да аз түгел. Ләкин шигъриятнең бер дәвереннән икенчесенә күчү чоры, иске классик шигърияттән совет поэзиясенә сузылган күпер чын мәгънәсендә фәнни тирәнлек һәм колач белән яктыртылмаган иде дияргә. Шунсыз совет поэзиясендә күчемлелек һәм новаторлык мәсьәләләрен тулы ачу мөмкин түгел иде.

Бу — читен мәсьәлә. Шигъриятттәге җитлеккән күренешләрне алып тикшерүгә караганда күчү чорларындагы сыйфат ярылгыларын, үзенчәлекле тенденцияләрне күреп алу өчен аеруча үткен күз, таләпчән зәвык, эрудиция һәм хәзерлек кирәк. Бу проблемага нәкъ менә Хатип ага Госманның алынуы бер дә гаҗәп түгел. Татар совет поэзиясенең иң югары ноктаmларыннан булган Такташ иҗатын җентекләп тикшергән зур хезмәте, поэзиябезнең күп гасырлык тарихи бәйләнеш җепләрен туплап, барлап һәм ачып биргән антологиягә кереш һәм башка мәкаләләре галимнең киң колачлы шушы тикшеренүгә килүендә зарури баскычлар булды.

XX йөз башы поэзиясеннән совет поэзиясенә чаклы аралыкта гаять катлаулы, буталчык, төрле идея һәм эстетик мәктәпләрнең килешмәүчән көрәшеннән һәм үзара бәйләнешләреннән гыйбарәт булган бер чор — беренче бөтендөнья сугышы чоры ята. Ул дәвердә иҗат иткән шагыйрьләр аерым-аерым күпмедер тикшерелеп, мәгълүм бәясен алса да, поэтик хәрәкәтнең гомуми панорамасы ачык түгел иде.

Хатип ага Госманның рус телендә 60 нчы еллар башында дөнья күреп, камилләштерелгән варианты буларак татар телендә 1978 елда басылып чыккан «Шигърият гомере» дигән хезмәте ике чор арасындагы поэтик хәрәкәтнең тарихи контекстын фәнни төгәл ачып бирүе белән кыйммәтле. Галим, поэзияне татар халкының иҗтимагый-сәяси җитлегүе фонында карап, шагыйрьнең дөньяга карашында, эстетик идеалында булган сәламәт якларны яктырта, җитлекмәгән, кире сыйфатларны аерып күрсәтә. Аның фәннитеоретик зирәклеге аеруча иҗат методын тикшергәндә күренә. Романтизмның прогрессив һәм реакцион агымнары ясссылыгында аерым шагыйрьләр иҗаты төгәл бәяләнә. Романтизмның реализм белән аралашу моментларын күзәткәндә поэтик хәрәкәтнең перспективасы шактый ачык булып күз алдына килә. Галим реакцион романтизм агымында пессимизмның кайдан килүен, бөтен эшнең шагыйрь һәм халык мөнәсәбәтенә кайтып калуын ышандырырлык итеп ача. Бер үк вакытта ул көндәлек вакытлы матбугатта чыккан, китап буларак басылган полемик чыгышларга, архив мәгълүматларына, тарихи дәлилләргә таянып эш итә. Нәтиҗәдә иҗтимагый тарих белән поэзия тарихының берберсенә тыгыз үрелгән тулы картинасы күз алдына килә. Бу бигрәк тә төрле социаль катлауларның империалистик сугышка мөнәсәбәтен ачканда һәм шагыйрьләр иҗатының объектив һәм субъектив рәвештә шул мөнәсәбәтне ничек гәүдәләндерүен күрсәткәндә чагыла.

Тикшеренүче ике чор арасында урын алган поэтик күренешләргә хас аерым зарарлы якларны, әйтик, ил демократик һәм социалистик революциягә юл тотканда феодаль үткәннәрне идеаллаштыру кебек реакцион романтизм күренешләрен, зур принципиальлек белән тәнкыйтьли. Ул шушындый идея буталчыклыгы хөкем сөргән бер чорда алдынгы рус иҗтимагый фикеренең һәм большевикларга якын торган революцион поэзиянең татар халкына һәм поэзиясенә сәламәт таяныч булуын, идея җитлегүенә ярдәм итүен күрсәтеп үтә. Аерым алганда, Сәгыйть Рәмиевнең Демьян Бедный мәсәлен тәрҗемә итү фактына югары бәя бирә.

Поэзияне иҗтимагый тормышка бәйләп тикшергәндә, галим иң четерекле мәсьәләләргә дә кыю үтеп керә, аларны зирәк акыл белән аңлатып бирә. Ленин хезмәтләре — аның бу эштә иң ышанычлы һәм куәтле таянычы. Россиядә ике чор арасында барган иҗтимагый һәм эстетик хәрәкәтнең бер генә зур мәсьәләсен дә аннан башка төгәл аңлату мөмкин түгел.

В. И. Ленинның илдә барган иҗтимагый хәрәкәтнең дүрт агымы хакындагы (сугышны туктату өчен гомумдемократик хәрәкәт, милли азатлык хәрәкәте, крестьяннар хәрәкәте һәм пролетариатның революцион көрәше, ягъни социалистик хәрәкәт) өйрәтмәсе поэзия тарихындагы буталчык һәм катлаулы мәсьәләләрне ачыклауда фәнни нигез булып тора. Галим шушы өйрәтмәгә таянып эш итә һәм татар поэзиясен өйрәнүдә яңа ачышлар ясый. Бу бигрәк тә Бабич иҗатындагы эволюциянең үзенчәлеген тикшергәндә әйбәт нәтиҗә биргән. Тикшеренүче татарбашкорт шагыйренең Октябрь революциясе һәм гражданнар сугышы елларында буталып калуын, азатлык хәрәкәтенең демократик өч баскычын үтеп, аның шунда тотнарлануы белән аңлата. Бабичның Гафури «Кызыл байрагы»ннан соң язылган шигырендә эшче темасының яктыртылуы да шуны күрсәтә. Хатип ага Госман шагыйрь күтәргән теманың әһәмиятен күрсәтү белән генә чикләнмичә, аның асылына төшеп, мөһим кимчелеген дә ача. Мәсәлән:

Аңла, эшче, үзеңне,
Ачып кара күзеңне,
Бөтен дөнья мөлкәте
Кем кулыннан төзелде?

— дигән юлларга карата галим болай ди: «...ул... эшчеләрне чорның искелекне аткалаучы беренче геройлары итеп алмый, бәлки шагыйрьнең нәсихәтенә мохтаҗ сыман катлам итеп күрә». Бабич иҗатын иҗтимагый-тарихи һәм поэтик процесс белән бәйләнештә тикшерү хезмәтнең иң әһәмиятле казанышы дияр идем.

Х. Госман бигрәк тә Мәҗит Гафури иҗатындагы эволюцияне күзәткәндә теоретик тирәнлек һәм эстетик нечкәлек белән эш итә. «Гафури иҗаты халыкның тарихи эшчәнлегенең көзгесендә чагылган җанлы сурәте буларак мәйданга чыкты. Шул ук вакытта бу татар социалистик реализм поэзиясенең чишмә башы да иде», — ди галим.

Хезмәттә дистәләгән һәм дистәләгән исемнәр телгә алына, моңарчы күзгә-колакка чалынмаган, берәр генә әсәр белән матбугатта ялтырап алган авторлар да игътибардан читтә калмаган. Бары бөртекләп җыелган бихисап шушы фактлар нигезендә генә поэзиядәге тенденцияләр хакында сүз алып барырга, андагы яңа сыйфатларның яралгыларын барларга мөмкин. Шулар арасында галим аеруча үзенчәлекле талантлардан Ф. Бурнаш, С. Кудаш һәм яшь Такташны аерып күрсәтә. Бигрәк тә Ф. Бурнашның «Таһир-Зөһрә» трагедиясе сюжетның башка эшкәртмәләре белән чагыштырмада кызыклы булып ачыла. Әсәрнең тууында тарихи-иҗтимагый шартларның роле мәсьәләсен галим фәнни ышандырырлык итеп аңлата.

Социалистик революция алып килгән яңа поэзия классик шигърият традицияләре нигезендә туды һәм үсте. Аңардагы яңалык сыйфатларын тәгаен күрсәтү дә ансат түгел. Галим: «Әдәбиятны, сәнгатьне яңарта торган чишмә кайда?» — дигән сорау куеп, аңа: «...ул — тормышта искелекне таркатучы яңалык үсентеләрендә һәм кешеләр күңелендә шушы үсентеләр тәэсирендә туган яңа тойгыларда», — дип җавап бирә. Шул рәвешчә, поэзиянең яңалык сыйфатларын барлау өчен әһәмиятле, төгәл критерий билгеләнә. Галим шушындый сыйфатлардан куәтле мотив буларак «Ватан» төшенчәсенең активлашып китүен, рус революцион җырларын тәрҗемә итү нәтиҗәсендә көчәеп киткән интернационализм идеясен күрсәтә.

Поэтика өлкәсенә караган мөһим нәтиҗәләрнең берсе — Октябрь революциясе чоры поэзиясендә антитезаның активлашуын ачу. Җәмгыятьтә каршылыклар кискенләшкән чорда, чыннан да, поэзиядә контраст буяулар көчәя. Беренче рус революциясе чорында да (Тукай лирикасы), социалистик революция елларында да бу шулай булды.

Хезмәт ни чаклы гына әтрафлы башкарылмасын, анда һәр нәрсә хәл ителеп беткән һәм бәхәсләргә урын калмаган дип булмый. Мәсәлән, Ш. Бабичның:

Күктә алла, җирдә иблис, мин—малай!
Берсе «дин» дип, берсе «мин» дип тарткалай,
Белмимен,
Әллә алла, әллә иблис алдалай.

— дигән шигъри юлларын шәрехләгәндә бүтәнчәрәк нәтиҗәләр сорала кебек. Монда «ирекле рухына беркемне дә хуҗа итәргә теләмәгән горур кеше» гәүдәләнүдән бигрәк, рухани бәйсезлеккә омтылучы шәхеснең ике ут арасындагы драматик халәте чагыла, безнеңчә. Шулай ук Октябрь революциясе алдыннан һәм революция елларында Нәкый Исәнбәт иҗаты да шактый үзенчәлекле, эзләнүчән булуы белән күренекле урын тота. Хезмәттә ул тиешле бәясен алмый калган. Дөрес, 20 нче еллар поэзиясенә багышланган икенче бер хезмәтендә галим аңа лаеклы урын бирә.

Автор иҗат лабораториясенә, иҗат психологиясенә тирән үтеп керә, шигырь технологиясендә ул иң абруйлы белгечләрдән санала. Хатип ага Госман фәннитеоретик анализда масштаблы, зирәк фикер йөртүче галим буларак ачылса, аерым әсәрнең сәнгатьчә тукымасына үтеп кергәндә үзен шушы әсәрнең иҗатчысы булган шагыйрь урынына куеп карый, шигырьне язган авторның үзе булып та кичкем йөртә. Бу хәл гаять кызыклы һәм җитди фәнни-эстетик стильне барлыкка китерә.

Тикшеренү контекстуаль планда башкарылган. Монда Х. Госманның фәнни эшчәнлегенә хас бик мөһим бер үзенчәлек — аның киң эрудициясе, поэзиянең күп гасырлык юлын тирән белүе, рус һәм Көнбатыш Европа культурасыннан зур мәгълүматка ия булуы чагыла.

Хезмәтнең әһәмияте үзәккә алынган тикшеренү чоры белән генә чикләнми, әдәбият фәненең алга таба үсеше өчен дә ул мөһим. Аңарда поэзия тарихының якты маяклары билгеләнгән. Махсус тукталып тикшермәстән, юл уңаенда әйтелгән фикерләрдә дә гаять бәрәкәтле орлыклар, нәтиҗәле тикшеренү юнәлешләрен күрсәтеп куюу бар.

Галим хезмәтне документаль мәгълүматлар, аерым алганда, революцион дәүләт оешмаларының яңа поэзия формалашуга уңай йогынтысы хакындагы кызыклы материаллар белән ныгыткан.

Китап татар поэзиясендәге бөек яңарыш чишмәләрен ачучы хезмәт буларак кызыклы һәм әһәмиятле.

**НУРМӨХӘММӘТ ХИСАМОВ**

Мәсгуд Гайнетдинов

# ДАСТАННАР КИТАБЫ

*Язылуына 300 ел тулу уңае белән*

Моннан өч гасыр элек татар әдәбиятында урта гасыр карашларыннан арыну юнәлешендәге беренче адымнар, беренче яңару төсмерләре билгеләнә башлый. Бу чорда татарлар күп санлы «чирмеш кузгалышлары»нда, XVII йөз башы чуалышларында, Җангали, Степан Разин хәрәкәтләрендә актив катнашканнар. Нәтиҗәдә шул заман проблемаларын халыкчан формада гәүдәләндереп күрсәткән әсәрләргә ихтыяҗ туа. Кызганычка каршы, бу хәрәкәтнең хәзерлек яки башлангыч чорларын күзалларлык әсәрләр әлегә мәгълүм түгел. Урта гасыр хроникаларының бай традицияләрен, проза өлкәсендәге зур тәҗрибәләрен шул яңару процессы белән тоташтырып торучы Кадир Гали бәк «Җәмигъ әт-тәварих»ы (1602 ел) гына әдәбиятка мәгълүм.

Ул чорларның башка әсәрләреннән аермалы буларак, басып таратылу, тикшерелү, өйрәнелү ягыннан караганда, «Дастаннар китабы» бәхетле язмышка ия. «Дастаннар»ның соңгы бүлеге 1737 елда ук инде, В. Н. Татищев соравы буенча, русчага тәрҗемә ителә. Аерым бүлекләр (1, 2, 4, 5, 6 нчы дастан) исә 1822 елда Ибраһим Хәлфин тарафыннан аерым китап итеп басыла. Әсәрдән өзекләр рус ориенталисты Х. М. Френның 1816 елда Болгар патшалыгы турында Венада чыгарылган мәкаләсендә немец телендә дә дөнья күрә. Беренче дастанның русчасы 1835 елда «Сын Отечества» журналында басыла. «Дастаннар»ның аерым өлешләре белән рус укучысын таныштыруга К. Фукс, И. Березин, Н. Ф. Катановлар да зур өлеш кертканнәр. Өченче дастан — «Әмәт дастаны» С. Кукләшев хрестоматиясенә кертелә (1859). Ниһаять, 1882 елда Рәхимҗан Җиһанша улы «Дастаннар»ны тулы күләмендә китап итеп чыгара. Әсәрнең аерым өлешләрен бастыру һәм тикшерү эшләре XX гасыр башларында һәм революциядән соң да дәвам итә. Бу эштә Н. Ф. Катанов (1904, 1905), Г. Газиз (1913), Гали Рәхим (1930), В. А. Панов (1934) кебек галимнәр катнашкан. Алар байтак кына кызыклы күзәтүләр ясаганнар һәм дәлилле фикерләр әйтеп калдырганнар. Ләкин «Дастаннар китабы»на карашларда бүгенге көнгә кадәр бер зур кимчелек яшәп килә: бу — аны тарихи әсәр, фәнни әсәр итеп санау. Н .Ф. Катановның җиңел кулы белән хәтта фәнни әдәбиятта да ул «Татар елнамәсе» («Татарская летопись») дип атап йөртелгән. Бу исә әсәрнең асыл мәгънәсен — әдәби әсәргә хас төп проблемаларны — идеясен һәм эчтәлеген тикшерүне игътибардан читтә калдыра.

«Дастаннар китабы» алты фасылдан (бүлек-дастаннан) тора. Китапның башында ук авторның тарихка мөнәсәбәте билгеләнә. Аның максаты үзенә билгеле тарихи белешмәләрне укучыга ишеттерү, яки төрле таркау фактларны системага салып тарих язу түгел. Китапның башка урыннарында да ул үзенең «тарихы» — шул чор тормышындагы ниндидер билгеле фактларга ишарә генә икәнлеген күп мәртәбәләр сиздереп үтә. Әсәргә кертелгән легендаларны фольклор калыбы нигезендә автор үзе «иҗат иткән» булуы да бик ихтимал. Ул хикәятләр һәм дастаннарның герое тылсымлы әкиятләрдән алынганга да охшый. Тик автор аларга сәнгать көче белән җан өрә алган. Шулар аркылы автор укучыга сизелмәслек рәвештә генә, сүзне халык язмышына («халык уллары»), дәүләт язмышына күчерә һәм нәкъ шул мәсьәләне төп темага әйләндерә. Нәтиҗәдә, геройларны «нурландырулар», сюжеттагы әкият элементлары халык эпосының традицион сурәтләү алымы булып кала. Әсәр халыкның эстетик зәвыгына яраштырып язылган бай шигърияте, якты идеаллы чын дастан яңгырашына ирешә.

Әйткәнебезчә, дастан үзгенә халык язмышы, дәүләтчелек турындагы уйланулар куелган. Әсәрнең төенләнеш ноктасы вакыйгалар, эпизодлар, проблемалар белән

гадәттән тыш баетылган: киек аулау; Хитайдан качкан ач юлаучылар белән очрашу; кол малай алу һәм башка шундый мотивлар да үзәк проблемага — әнкәләрен рәнҗеткән, «халык углының кадерен белми» торган патшалардан котылу темасына кайтып кала.

Әсәрдә күтәрелгән «казак чыгып китү» мотивы гомумән «Дастаннар китабы»ның үзәк темасына әйләнә. II—III дастаннарда да ул беренче планга чыгарылган. Бу «казак чыгып китү» идеясенең шул дәрәҗәдә актуальләшү сәбәбен ул еллардагы хәлләрне искә төшерү аша якынча билгеләп була. XVII гасырның 70 еллары башында (1667—1671) казак Степан Разин җитәкчелегендәге крестьяннар хәрәкәте ак патша властен дер селкеткән иде. «Дастаннар китабы» шул идеяне популярлаштыру максатыннан чыгып язылганга охшый. Ә «Нурлы» легендалар исә аның эчтәлеге билгеле бер максатка ирешер өчен әсәрдәге идеягә халыкны ышандырыр өчен эшләтелгән чара (киная, символ) гына. Шуңа күрә дә автор ул материалны «ирекле» файдалана: үзенә кирәк чамада «нурлый», дастанны үз идеясен яктыртырлык әкият сюжетлары белән баета.

II фасыл — дастанның баштагы өлеше — идеаль «казак-герой» образын тасвирлау. Әмма максатын идеаль геройны гәүдәләндерү мөмкинлекләрен эзләү белән генә чикләсә, авторның бу эше эчтәлексез, мәгънәсез, буш хыял белән мавыгу булып кына калыр иде. Юк, аның дәртен югары иҗади киеренкелек били, күңелендә ил, халык язмышы турында уйланулар төзәлмәс җәрәхәт булып көйри. Шул дәрт аны каләмгә тотынырга мәҗбүр иткән. Шул дәрт — иле, халкы турында борчылулы уйланулар, актуаль әһәмиятле бер фикерне халкына җиткерү теләге аның иҗатының төп пафосы булып тора, бу иҗатның халыкчанлыгын билгели, әсәренә шиңмәс сәнгатьчәнлек төсмерләре бирә.

...«Казаклык» юлына чыккан Аксак Тимер Идел буена килә, Болгар гаскәрен җиңә, җиде ел камап торганнан соң, шәһәрне басып ала. Болгарда 124 олуг бәк булган, аларны кырып бетерә, «серле энҗе бөртекләредәй» хатыннарын әсир итә. Болгардан Аксак Тимер Буләргә килә. Автор Буләр халкының килеп чыгышы турында бер риваять китерә. Ул халык ике кабиләдән тора, имеш. Бараҗ халкы дигәне элек Зәй тамагында яшәгән. Әмма бу якларга килеп ч ккан Бараҗ дигән аждаһа явызлыгы, золымы, көчләүләре белән халыкны шул кадәр интектерә, халык аңа каршы көрәшкә күтәрелергә мәҗбүр була. Аждаһаны җиңә алмагач, барысы да Болгар ягына кача. Качкыннар Буләр суы буенда шәһәр салалар. Инде Бараҗдан көчлерәк Аксак Тимер шәһәрне алырга килгән. Самат хан: «Нишлибез?» дип халыкка мөрәҗәгать итә. Халык: «Син ни әйтсәң, шул»,— дип җавап кайтара. Шәһәрдә бер әүлия бар икән, хан шуңардан киңәш сорый. Әүлия бер манарага менеп Аксак Тимер гаскәрен карый да: «Аксак Тимер гаскәре сафында Хызыр да бар. Карышу — файдасыз. Алланың тәкъдире шул»,— дип, шәһәрне сугышсыз тапшырырга киңәш итә. Капкаларны ачалар. Шәһәргә кереп, Аксак Тимер халыкны кырдыра. «Әүлия», «хызырлар» мотивы эчкерсез беркатлылык белән җиңелүне акларга теләүме, әллә авторның «изге көрәшкә» ышанырга кирәкмәс иде дип раславымы — өзеп кенә әйтүе дә кыен.

Тикшеренүчеләр Бараҗ турындагы риваятькә аеруча игътибар бирәләр, шуңа нигезләнеп, «Дастаннар»ның тарихи әһәмиятен билгелиләр. Башка тарихи риваятьләрдә «Аждаһа Бараҗ», «Бараҗ халкы»н хәтерләткән нинди дә булса хәбәр барлыгы әлегә билгеле түгел. Бу риваятьне «Дастаннар» авторы гына иҗат иткән булуы да бик ихтимал. Автор стиленә хас рәвештә, биредә дә Бараҗ сюжеты — әкият өлгесеннән күчермә генә; факт түгел, аның эчке мәгънәсе әһәмиятле. Ул мәгънә охшаш ситуацияне хәтерләтү аша аңлашылырга тиешле. Шулай, кинаяләр белән, автор укучы игътибарын билгеле бер проблемага юнәлтә. «Зәй тамагы» — Зөя тамагы белән аваздаш. Зөя тамагыннан ерак түгел генә урнашкан Казан шәһәренең халык риваятьләрендә «еланнар» белән бәйләнеше бар. Ул бәйләнешне хәтерләмәгән тәкъдирдә дә Бараҗ хикәяте якын үткәндәге хәлләрне халыкка яхшы ук ачык төсмерләтә ала. Безнеңчә, аждаһа Бараҗ образы ул—патша. Бараҗның аждаһалыгында ук шул мәгънәгә киная бар дип уйларга мөмкин. Билгеле булганча, халык ышануы буенча, елан йөз яшь яшәсә, аждаһага әйләнә. Бараҗның аждаһа икәне — колониаль коллыкта интегүләрнең йөз елдан артканына ишарәдер. Аждаһа символы гомумән XVIII йөз азатлык хәрәкәте идеологиясендә киң файдаланылган. Мулла Морад китабында (1770 еллар) аждаһа образы бар. Әсәрнең планына һәм сюжетына бәйләнешсез рәвештә ул Т. Ялчыголның «Рисаләи Газизә» (1796) китабына да килеп кергән. Дөрес, Т. Ялчыгол инде аның XVIII йөздәге асыл мәгънәсен тукмап-селкеп читкә ташларга тырыша, аны үз китабында урыны бәхәсле булган әкияткә генә калдыра кебек. Кыскасы, «Дастаннар китабы»ндагы Бараҗның да, «Рисаләи Газизә»дәге аждаһа, юхаларның асыл мәгънәсе бу әсәрләрдә поэтик бизәк кенә булмавы китапларның үзләреннән үк ачык сизелеп тора.

Аксак Тимернең Владимирга походы — халык азатлык хәрәкәтенең җиңү мөмкинлегенә ышаныч уятырга тиешле ишарә. Мондый четерекле темага кагылганда, автор, билгеле, иң гомуми пландагы ярым мистик кинаяләрдән уза алмаган.

Күчмәнче Әмәт һәм Самат ханнар турындагы эпизод — шул еллардагы татар иҗтимагый хәрәкәтендәге кимчелекләргә, һәм, өлешчә, казак, нугай урдаларындагы хәлләргә сатира итеп язылган. Ил өстенә куркынычлы дошман явы (Аксак Тимер) килә. Халык киңәшкә җыела. Анда кайсы үзенең этен, кайсы атын, кайсысы хатынын мактый. Ашыйлар да таралалар. Тикшерелергә тиешле проблеманы истән үк

чыгарып җибәрәләр. Ә дошман явы якынлаша. Әмәт һәм Самат ханнар кача. Моны күреп халык та күтәрелә. Юлда, артка борылып караганда, бер карчыкның башыннан бүреге төшә. Аның артыннан килүче тайга атланган бер малай, бүрекне алып бирим дип иелгәндә, ияре авып, тай дулый. Бу хәл елкыларны өркетә. Яу килеп җитте курәсең дип, юктан куркып халык төрле якка тарала башлый. Ул арада Аксак Тимер гаскәрләре килеп җитеп, боларның һәммәсен тотып алалар... Шуннан соң Аксак Тимер Урта Азияне яулап алган вакытта, «әҗәл җитеп», «Сәмәркандта» үлә. Автор бүлекне, халык гыйбрәт алсын диптер, «беттек» дигән сүзләр белән тәмамлый.

Өченче бүлек — Гайса улы Әмәт турында хикәят. Алтын Урда ханы Җанибәк бичәсе Тайдула бала табар көннәрдә ауга китә һәм: «Малай тапсаң, сөенеч белән кеше җибәр; кыз туса, мин кайтканчы үтерт», — дип боерык биреп калдыра. Хан гаиләсендә кыз бала дөньяга килә. Тайдула, билгеле, үзенең газиз баласын үтертә алмый. Җанибәк аудан кайткач, бала тормышы хәвеф астында калганнан соң, ул кызын үзенең олы улы Бирдебик карамагына җибәрә. Үзсүзле Җанибәк хан кызны һәм Бирдебикне ничек булса да Сарайга кайтарырга тели. Бу эшне ул Гайса улы Әмәткә тапшыра. Үзара киңәш һәм килешү буенча, бер көнне Әмәт ханның ачуын чыгара. Җанибәк хан: «Тотып асыгыз үзен!» дип боерык биргәч, Әмәт Сарайдан Бирдебик янына качып китә. Бирдебик аны үзенә кабул итә. Берничә ел эчендә Әмәт Бирдебикнең тулы ышанычын казана. Бер арачы карчык ярдәмендә Әмәт Бирдебикның хатыны белән дуслаша. Бер көнне хатынга ул: «Шаярган булып, иреңнең кул-аякларын бәйлә. Мин килеп аны үтерермен дә, икәү качып китәрбез. Мин сиңа өйләнермен», — ди. Хатыны, шаярган булып, Бирдебикне бәйләп салганнан соң, кылыч тоткан Әмәт килеп керә — һәм... бәкне бәйдән коткара. Хәлне аңлатып биргәннән соң Әмәт: «Хатын-кызга ышанырга ярамый. Бер кыз бала өчен этиең белән ачуланышма», — дип, Бирдебикне Сарайга кайтырга күндерә. Арачы карчык белән хыянәтче хатынны җәзалап үтерәләр дә, кызны алып, Җанибәк хан алдына кайталар. Хан инде кызын үтерми, Минкәй улы Тимер дигән бер байга кияүгә бирмәкче була. Әмма Әмәт кызны үзенә алырга тели. Хан кызын яу белән килеп алмакчы булып, Әмәт гаскәр сорап Кырымга, Кашгарга, Кызылбашка мөрәҗәгать итә. Берсе дә гаскәр бирмиләр.

Әмәт дастанында авторның иҗат принциплары тагын да ачыграк төсмерләнә. Дастаннарга автор өчен бик әһәмиятле, чорның зур проблемаларына кагылышлы идеяләр йөкләтелә. Язучы, бер яктан, ул идеяләрне сәнгатьчә гәүдәләндерергә, аларның публицистик шәрәлеген мөмкин кадәр тирәнрәк яшерергә тырыша, икенче яктан, шул төп фикернең укучыга аңлаешлы, бигрәк тә ышандырырлык булуы да һәр чак аның игътибар үзәгендә тора. Мәсәлән, Әмәт дастанында да ул «казак чыгып китү» хәлләрен һәм шуның нәтиҗәлеген калку сурәтли. Бу алым актуаль мәсьәләләрнең шәрәләнеп, тырпаеп калуыннан да коткара, әсәргә эпик колачлылык, сәнгатьчә тәгәллек төсмерләрен бирә. Ярсу көрәш дәртендә кайнаган бер чорда тема төрлелеге самодержавие шымчыларының сиземен таркатып, эзәрлекләүләрдән саклануда да аз роль уйнамагандыр. Автор сюжетка күп проблемалылыкны йөкли алуда җитлеккән талант осталыгын күрсәтә. Язучының хикәяләүгә таләпчәнлеге аның художестволы сурәтләүләргә, поэтик фигураларга осталарча мөрәҗәгать итүендә дә күренә. Әсәрдә бизәкле сүзләр дә, риторика да аз түгел. Тик үзләренең «бар»лыкларын укучыга гына сиздермиләр. Алар әсәр тукымасына органик өлеш булып урнашкан.

Дастаннарда тарихи белешмәләр дә күп, төрле легенда һәм риваятьләр дә бар. Анда халык язмышы да, герой язмышы да, азатлык хәрәкәте турында уйланулар, шул юлда актив эшчәнлек, төрле планнарны дәлилләү, үрнәк күрсәтү — һәммәсе шул ярым мифологик сюжетларга сыйдырып бирелгән. Бу сюжетларда, беренче карашка, мантыйкка сыймаслык хәл: фольклор язучы иҗаты белән үткен фикер — канатлы хыял белән табигый бер эретмә хәленә китерелгән. Мәгънәләргә гадәттән тыш байлыгы белән бу әсәр күп тикшерүчеләрнең игътибарын җәлеп иткән. Мәгънәви байлык дастаннарны хәтта фәнни хезмәт — тарихи язмалар итеп күрсәткән. Шундый үзенчәлекләре дастаннарны XVII йөздә татар әдәбиятының иң күренекле әсәрләреннән берсе итеп таныта.

«Дастаннар китабы»ның соңгы бүлекләре «Фасыл фи бәяни дастани әл-мөҗалис вә әл-мәкян», «Фасыл фи дастани фи-т-тарих» шул автор тарафыннан иҗат ителгән бер үк әсәрнең аерым бүлекләре булулары хакында шик һәм бәхәс уятмасалар да, баштагы өч дастаннан сизелерлек аерылып торалар. Аларда сюжетлар җансыз схема итеп кенә бирелә. И. Хәлфин китабында бу бүлекләр исемендәге «дастан» дигән сүз хәтта бөтенләй төшереп үк калдырылган.

Бер үк әсәр эчтәлегендә шундый зур үзгәреш, әлбәттә, аның баштагы йөкләмәсе (замысел) үзгәрү нәтиҗәсе буларак кына килеп чыгарга мөмкин һәм ул, чынлап та, нәкъ шулай булгандыр. Күрәсең, әсәрнең баштагы өч дастаны Степан Разин восстаниесе белән Сәед Җәгъфәр кузгалышы арасындагы вакытта — 1671—1681 еллар арасында язылган. Китапның соңгы өч бүлеге исә Сәед Җәгъфәр восстаниесеннән соң язылган булырга тиеш. Автор һаман әсәрен логик тәгәллеккә җиткерергә омтыла. Ләкин инде тормышта зур үзгәрешләр булып үткән: якты өметләр сүнгән, иҗтимагый идеал тоныкланган. Элеккеге азатлык идеалыннан ятырган конкрет тарихи максатлар булмагач, бу зур әдипнең олы таланты да инде аның язмаларына кайнар дәрт җан өрә алмый. Әсәрнең соңгы бүлекләре шәҗәрәләр традициясен кабатлау, элек урта гасыр хро-

никачыларының тарихи вакыйгаларны теркәү («вакыйганамә») рәвешләрен җанландырудан ары үтә алмаган. Алар дастан булудан да һәм чын мәгънәсендә хикәя булудан да ерак. Әмма бу һич тә әсәр әдәбият чикләреннән чыгып, фәнни хезмәткә әйләнеп киткән дигән сүз түгел. Бу бүлекләрдә дә — сәнгатьчә проблемалар: халыкның үз тарихи-географик җирлеге барлыгын раслау; үткән вакыйгаларны искә алу аша халыкны активлыкка өндәү, халыкта үз көченә ышаныч хисе тәрбияләү, аларны билгеле бер юнәлештә эшчәнлеккә (көрәш юлына) чакыру бар. Автор «халык улы»ның көрәш юлыннан читләшүен «бозыклыкка бирелү» дип бәяли дә: «Гомазларның (ренегатларның) эше һәмишә ушандаг торыр», дигән сүзләр белән китабын тәмамлый.

«Дастаннар китабы»ның авторы — талантлы әдип, үз чоры өчен гаять югары эрудицияле галим, җиңелгәндә дә, үз заманының алдынгы идеяләренә турылыклы булып кала белгән актив көрәшче булып хәтердә кала. Аның татар әдәбияты һәм гомумән иҗтимагый фикеребез тарихындагы урынын шул фактка карап та билгеләргә була. «Дастаннар китабы» һәм аның авторының татар әдәбияты тарихында күренекле урыны бар. Тарихка игътибары буенча «Дастаннар» авторы Ш. Мәрҗани, Р. Фәхретдинов кебек галимнәрнең элгәре булып тора.

Бу ун еллыкта әдәбиятыбызның шушы күренекле әсәре язылуга 300 ел тула. Бик күп нөсхәләре билгеле булуга да карамастан, аның әле һаман җентекләп фәнни тәгаллеккә китерелгән тексты эшләнмәгән. 300 еллыгы уңае белән шул юнәлештә эшләрне активлаштырып җибәрү, һичшиксез, күп кызыклы ачышларга китерер иде. Кем белә, шул җентекләүләр процессында бәлки авторның да, әсәренең дә үз исемнәре табылыр иде. Төгәл текстын хәзерге укучыга җиткерү, әсәрнең идея-художество үзенчәлекләрен өйрәнү дә әдәбиятыбыз тарихының мөһим үзенчәлекләрен ачыклау юнәлешендә байтак кына кызыклы ачышларга китерүе мөмкин.

# ГАБДЕРӘХИМ УТЫЗ ИМӘНИНЕҢ ТУУЫНА 225 ЕЛ

1979 елның 1 августында күренекле татар шагыйре һәм галиме Габдерәхим Утыз Имәни әл-Болгариның тууына 225 ел тулды. Г. Утыз Имәни иҗаты әдәбиятыбыз тарихында зур урын алып тора, татар әдәбиятының XVIII йөздән XIX йөзгә күчү чорында аерым бер этап булып карала. «Гавариф әз-заман» («Замананың укымышлылары»), «Тәнзиһ әл-әфкяр фи нәсаих әл-әхъяр» («Фикерләрне пакьләндерә торган игелекле үгетләр») поэмаларында һәм «Фасыл фи фазыйләт әл-гыйлем вәл-гакыл» («Гыйлем һәм гакылның өстенлеге турындагы бүлек») шигырендә ул гыйлем-мәгърифәт мәсьәләләрен күтәреп чыкты, үз замандашларын укырга, белем алырга чакырды.

Габдерәхим Утыз Имәни иҗатын өйрәнү юлында яңа чыганаклар эзләп миңа соңгы елларда шагыйрь тормышы белән бәйле күп авылларда булырга туры килде. Шул вакытта авыл картлары «Габдерәхим хәзрәт» тормышыннан күп кенә вакыйгалар сөйләделәр. Шагыйрьнең тапкырлыгы, үткенлеге, зирәклеге ул яшәгән авылларда халык арасында риваять итеп сөйләнә.

Укучыларга шул риваятьләрнең кайберләре тәкъдим ителә.

**ӘНВӘР ШӘРИПОВ,**
**филология фәннәре кандидаты**

## МӘДРӘСӘГӘ БАРУ

Бала чактан ук Габдерәхим үксез ятим бала булып үсә. 2—3 яшьтән алып ул үзенең кардәш тиешле бер җиңгәсендә тәрбияләнә. Ул монда дөньяның барлык ачысын татып, фәкыйрьлектә үсә.

Габдерәхим кече яшьтән үк туган авылының Вильдан мулла мәдрәсәсенә укырга йөри башлаган. Өстенә кияргә юньле киеме, аягына оегы булмаган. Ул хәтта кыш көне дә ялан аяк йөргән. Кыш көннәрендә мәдрәсәгә барганда тәлпәгенә өйдән җылы көл тутырып чыга икән дә, йөгерә икән. Аяклары туңа башлагач, кар өстенә җылы көл салып, басып тора икән. Аягы җылынгач, тагын йөгереп китә икән. Мәдрәсәгә кадәр ул шулай йөгерә торган булган.

## УКЫМЫЙ БЕЛӘ ТОРГАН ШӘКЕРТ

Габдерәхим кечкенәдән үк тиз үйлаучан, җитез табигатьле бала булган, үзенең зирәк һәм бик шаян булуы белән аерылып торган. Дәресне ул бик игътибар белән тыңлаган, тиз отып алган һәм соңыннан үз иптәшләренә аңлатып бирә алырлык шәкерт булган. Шуңа күрә аны «укымый белә торган шәкерт» дип атап йөрткәннәр.

## НАДАН МУЛЛАЛАР

Бервакыт Бохарада мәчеткә баргач, Габдерәхим намазны мәчетнең тышында, ишек алдында укыган. «Нигә намазны анда укыйсың?» дип сорагач, Габдерәхим: «Анда кереп муллаларның наданлыгын күрәсем килми, алар минем намазымны гына боздыралар», — дип җавап биргән.

## ҖӘМӘГАТЬ СУДЫ

Бохарада вакытта Габдерәхим Могак мәчетендә мәзиннең азан әйтүен тыңлап торган да, азанның җиде урыныннан хата тапкан. Бу хәбәрне әмиргә җиткергәннәр. Әмир Габдерәхимгә җәмәгать суды ясарга булган. Зур итеп мәҗлес җыярга һәм шунда Габдерәхимгә күп кенә сораулар биреп, халыкның үзеннән җаза бирдертергә уйлаган. Мәҗлескә ныклап хәзерләнгәннәр: ишаннар, муллалар мәҗлес буласы йортның ишек төбенә күп итеп ташлар китереп өйгәннәр — сорауларга җавап бирә алмый башлагач, Габдерәхимне ташлар атып үтерергә уйлаганнар. Чыннан да, мәҗлестә аңа бик күп сораулар биргәннәр. Әмма Габдерәхим аларның барысына да төпле җаваплар бирә барган. Шулай итеп, ул дин фанатикларының үтерүләреннән котылып калган.

## СИН БЕЗНЕҢ АВЫЛ КЕШЕСЕ ТҮГЕЛ

Күп илләр күреп, дөнья гизеп йөргәннән соң бервакыт Габдерәхим яңадан үзенең туган авылы Яңа Кадигә кайтып төшкән. Туган-тумачалары, дус-иптәшләре белән күрешеп сөйләшкән һәм авылда төпләнеп калырга булган. Ләкин авыл старосталары аңа: «Синең атаң Яңа Кади кешесе түгел, Тимәшнеке иде. Шулай булгач без сиңа йорт корырга җир бирә алмыйбыз, әнә Тимәшкә барып ал», — дигәннәр. Габдерәхим моңа бик кайгырган, ләкин нишләсен. Ул үзенең бөтен китапларын бәләкәй арбага төягән дә, хатынын, балаларын ияртеп авылдан чыгып киткән. Киткән вакытта шагыйрь:

— Сау бул, сау бул, Утыз Имән, урман-күлләрең белән,
Мин дә сине сагынырмын, кайгылы көннәрең белән,

— дип җырлаган.

Авылны чыккач ул мәһабәт булып үсеп утыручы утыз имән яныннан үткән. Алар янында туктап, кулы белән аларның кайрыларын сыйпаган, күтәрелеп, зәңгәр күккә үрелгән очларына караган. Шунда Габдерәхим: «Утыз имән түгел бу, алтын Имән», — дип әйткән[1].

Аннан соң ул туган авылына соңгы караш ташлаган да, көнчыгыш ягындагы урнең урман ачыклыгыннан чыгып киткән. Ул урман ачыклыгы анда хәзер дә бар, халык аны «Габдерәхим хәзрәт ачыклыгы» дип йөртә.

## ИМӘННӘР

Үз гомерендә Габдерәхим туган авылы Яңа Кадигә берничә тапкыр кайтып киткән. Яңа Кади табигатьнең бик матур урынында урнашкан. Аның тирә-ягын ул вакытта калын-калын урманнар уратып алган булган. Авылдан ерак түгел мәһабәт утыз имән үсеп утырган. Шуңа күрә авыл үзе дә элегрәк Утыз Имән авылы дип аталып йөртелгән. Габдерәхим ул имәннәрне бик яраткан. Еш кына ул:

— И-и, имәннәр, имәннәр! Мине Кадига тартып кайтаручы сез бит! — дип әйтә торган булган.

[1] Икенче бер вариантта Габдерахим: «Утыз имән түгел бу, алмалы имән», — дигән.

## БЕР МИЗГЕЛ ЭЧЕНДӘ БЕР ШИГЫРЬ

Бервакыт Габдерәхимгә дошманрак кешеләр аны халык алдында оялтырга, аптырауга калдырырга сүз куешалар. Кешеләр алдында аңа барып әйтәләр: «Бер минут эчендә бер шигырь әйт, ул татарча, русча, гарәпчә сүзләрдән торсын», — диләр. Габдерәхим каушап калмый, шунда ук экспромт рәвешендә түбәндәге шигырьне әйтеп бирә:

**Әйдә барыйк мунчага,**
**Бер баруда ничего.**
**Бу шигырьне сезгә әйтәм,**
**Шәрган хилаф булса да.**

## КЕМ АРБАСЫНА УТЫРСАҢ, ШУНЫҢ ҖЫРЫН ҖЫРЛАРСЫҢ

Бервакыт Габдерәхим кырдан кайтып килә икән, юлда аны ат белән баручы бер кеше куып җиткән. Габдерәхим аның арбасына утырган. Икесе дә бик гади киенгән, аякларында чабата икән. Бераз сөйләшми барганнар. Бервакыт теге кеше аны-моны уйлап тормыйча, кычкырып җырлап җибәргән. Аның җырлавы Габдерәхимгә бик ошаган, һәм ул үзе дә аңа кушылып җырлый башлаган. Теге кеше бик кызыксынып: «Син кем буласың, кайсы авылныкы син?» — дип сораган. Габдерәхим аңа: «Үзең дә ишетә беләсеңдер инде, Габдерәхим хәзрәт диган кеше булам мин», — дип җавап биргән. Теге кеше моны ишетеп: «Ай, хәзрәт, бик оятлы булдым, зинһар гафу ит. Тышкы килешең белән, гадилегең белән без аңлаган хәзрәткә бер дә охшамагансың бит», — дип, гафу үтенә башлаган. Габдерәхим аңа: «Чү-чү, тавышланма! Кем арбасына утырсаң, шуның җырын җырларсың, дигәннәр. Менә җырлавың миңа бик ошады, мин сиңа ярдәм. Инде син дә минем фикерләремәияр» , — дип шуннан танышып киткәннәр.

## КЫРЫК БЕРЕНЧЕ ФАРЫЗ — РУСЧА БЕЛМӘК КИРӘК

Бервакыт Габдерәхим ат-арба белән рус авылыннан узып бара икән. Бер елганың күперен чыкканда моның арбасы каршы килүче бер рус кешесе арбасының күчәренә бәрелеп туктаган. Боларның алга да барырлык рәтләре юк, артка да чигенеп булмый ди. Аңлашырлар иде — берсе икенчесенең телен белмиләр. Икесе ике телдә бер-берсен тирги башлаганнар. Шуннан көч-хәл белән аңлашып, аерылып киткәннәр. Шушы вакыйгадан соң Габдерәхим Утыз Имәни: «Русиядә яшәүче мөселманнарга кырык бер фарыз — кырык беренчесе — урысча белмәк кирәк,» — дип әйтә башлаган, имеш.

## ГЫЙЛЕМЛЕКТӘ МӘСКӘҮНЕҢ ҮЗЕНДӘ ЯШӘҮЧЕ КЕБЕК

Бервакыт Габдерәхим Казанга барган. Бер байга фатирга төшкән. Ул байны икенче бер бай мәҗлескә чакырган. Әлеге бай мәҗлескә үзенең кунагы Габдерәхимне дә алып барган. Мәҗлескә Казанның барлык 36 мулласы да җыелган, ди. Габдерәхим фатирга төшкән байны мәҗлеснең түренә, ә Габдерәхимне ишек төбенә генә утырткannар. Менә бервакыт муллалар арасында бәхәс чыга. Муллалар даулаша башлыйлар. Шулвакыт ишек төбендәге Габдерәхим тыныч кына муллаларга ул мәсьәләне аңлатып бирә. Мәҗлес тып-тын кала.

— Нәрсә, бүредән курыккан эт кебек койрыгыгызны кыстыгыз? Нигә сөйләшмисез? — дип сорый Габдерәхим муллалардан.

Шуннан муллалар әкренләп кенә сөйләшә башлыйлар. Бер мулла Габдерәхим фатирга төшкән байга сорау бирә:

— Син Мәскәүнең ничә урамын беләсең?

— Биш-алты урамын, — ди бай.

— Әгәр Мәскәүнең үзендә торсаң, ничә урамын белер идең?

— Мәскәүдә торсаммы? Мәскәүдә торсам, бөтенесен дә белер идем,— ди. Шунда әлеге мулла әйтә:

— Менә шул-шул. Габдерәхим хәзрәт Мәскәүнең үзендә торучы шикелле — белемдә дә, гыйлемлектә дә. Ә менә без синең белән белемдә дә, гыйлемлектә дә салада яшәүчеләр кебек кенә...

# НӘҖИП МАДЬЯРОВ



Һәр художникны иҗат орбитасына чыгарган бер старт мәйданы — гомеренең ул иң яхшы белгән өлеше — тормышы була. Нәҗип Мадьяров өчен бу — авыл. Аның шигырьләре дә авыл көен хәтерләтә: гади, тыйнак, ихлас күңелдән. Ясалмалылык, купшылык аларга ят нәрсә. Үзе кичергәнне, үзен дулкынландырганны гына җырлый Нәҗип. Шушы сыйфат аны, гомуми сөйләшү кебек, иҗат чишмәсен корыта торган чирдән саклый.

Шагыйрь үзенең кыска, җыйнак шигырьләрендә зирәк авыл кешесенең уй-фикерләрен, бик үк тышка ташып тормаган тирән хисләрен укучыларга тулы җиткерә белә.

Соңгы елларда Нәҗипнең шигъри авазы тагын да ачыла һәм ныгый төште, осталыгы артты, офыклары киңәйде. Лирика белән бергә, юмор-сатира жанрында да даими эшләп килә, тормышның эчендә кайнап, өлгергән, актуаль мәсьәләләргә үзенең актив гражданлык мөнәсәбәтен белдереп килә.

Нәҗип балалар өчен дә китаплар чыгарды, бу өлкәдә дә үзенчәлекле табышларга ирешер дип уйлыйм.

Нәҗип Мадьяровның «Рәшәле офыкларым» дигән, иҗатының төп әсәрләрен туплаган җыентыкны укып чыккач, поэзиябездә үз урыны булган тыйнак һәм тырыш бер шагыйрьне күрдем.

**ШӘҮКӘТ ГАЛИЕВ,**
**Тукай исемендәге**
**Дәүләт премиясе лауреаты.**

# ӘХМӘТ РӘШИТОВ



Әхмәт Рәшитов иҗатын күптәннән күзәтеп киләм. Баштарак матбугат битләредә чыккан аерым шигырьләрен өметләнеп, ә 1972 елда басылып чыккан «Хатирә» исемле беренче җыентыгын сокланып һәм өметемнең акланачагына ышанып укыган булсам, 1978 елда чыккан «Сәяхәтнамә» китабын, шулай ук матбугатта чыгып торган аерым әсәрләрен чын күңелдән шатлану, зур канәгатьләнү һәм шагыйрьнең киләчәгенә тулы ышаныч белән укып чыктым.

Әхмәт Рәшитовның «Минем шәҗәрәм», «Варислар» һәм «Тормыш әлифбасы» исемле поэмалары, минемчә, соңгы ун еллардагы поэзиябездә, һичшиксез, уңышлы әсәрләрдән саналырга хаклылар. Аларда шагыйрьнең дөньяга, заман барышына һәм поэзиянең

бурычына карашы ачык һәм тулы чагыла, заманнарның һәм буыннарның бер-берсенә аерылгысыз бәйләнеше гәүдәләнә. Шагыйрь барлык әсәрләрендә дөньяда һәм тормышта булып торган вакыйгаларга һәр вакыт үз күзе белән карый, кабатланмаган, үзенчәлекле образлар тудыра. Шагыйрьнең мәхәббәт лирикасы да үзенчәлекле сафлык белән аерылып тора. Шул ук вакытта үзенең алымнарында гадилекне максат итеп куя, аның иҗаты башваткыч һәм шаккаттыргыч алымнардан бөтенләй азат. Әхмәт Рәшитов язучылар коллективының тулы хокуклы әгъзасы булырга күптән лаек.

**ӘХМӘТ ИСХАК.**

# РАЗИЛ ВӘЛИЕВ



Разил Вәлиев — мул талантлы, үткер күзле, үтә образлы фикерле торган шагыйрь. Аның шигырьләрен укыгач, бер чакта да битараф кала алмыйсың. Яшь шагыйрь поэзиягә эзләнүләр, икеләнүләр, югалтулар һәм табышлар мәктәбен үтеп, үз-үзенә ныклы ышаныч белән килә.

**Я дөньяны үзгәртәм мин бүген,**
**Я булмаса... үзем үзгәрәм,**

— ди ул. Аның шигырьләренә кешелеккә мәдхия җырлау, горурлык хисләре, тирән оптимизм хас.

**«Кеше» атлы нәни материк мин —**
**Батырлык бар миндә, матурлык!**
**Күпме тырышсаң да, булмый мине**
**Тормыш диңгезендә батырып!**

Шагыйрьләрнең язмышы бер-берсенә һич тә охшамый. Берәүләр поэзиягә метеор кебек атылып керә дә тиз генә балкып сүнә, икенче берәүләр, киресенчә, үз-үзен тапканчы озак эзләнә, катлаулы юл уза. Разил Вәлиевне мин соңгылары рәтенә кертер идем. Аның шигырьләре риторик, буш сүзләрдән азат, аның һәр җөмләсе, һәр фикере саллы.

Разил Вәлиев исеме инде укучыларга яхшы таныш: аның шигырьләре татар телендә шактый күп басылды, русчага да тәрҗемә ителде. Сүз ахырында мин шагыйрьнең тагын бер сыйфатына тукталып үтәсем килә. Әдәбият институтында укыган чагында ул үзенең яшьтәшләрен: комык, алтай, латыш, якут, әзербәйҗан һәм башка милләт шагыйрьләрен тәрҗемә итеп «Казан утлары» журналында бастырган иде. Разил хәзер дә тәрҗемә эше белән шөгыльләнә... Бу инде — чын әдипләргә хас сыйфат.

Шагыйрь үзенең эзләнүләрен киләчәктә дә дәвам итәр, тормыш катламнарына тагын да тирәнрәк үтеп керер дип ышанам.

**ЛЕВ ОШАНИН,**
**СССР Дәүләт премиясе лауреаты.**

# ЯХЪЯ ХАЛИТОВКА 50 ЯШЬ



Тәрҗемәче кавеменә мактауга караганда матбугат битләрендә гадәттә тәнкыйть сүзен ешрак «татырга» туры килә. Гаҗәп тә түгел: тәрҗемәченең «гөнаһлары» өстә күренеп ятучан була. Әсәрнең оригиналы һәм тәрҗемәсен теләсә кайчан янәшә куеп чагыштырырга, ялгышлар, төрле төгәлсезлекләрне тиз тотып алырга мөмкин. Әйтик, М. Шолоховның «Тын Дон» әсәрен укыган кеше аның тәрҗемәсенең оригиналга тулысынча тәңгәл килүен тели. Әгәр тәңгәллек җитенкерәмәсә, аның кәефе кырыла, күңеле рәнҗи, ул ризасызлыгын белдерергә ашыга. Тәрҗемәнең оригиналга торышлы, аны алыштыра алырлык булуын укучы үзеннән-үзе аңлашыла торган табигый хәл дип кабул итә. Ә нигә? Хаклы түгелмени ул? «Тын Дон»ның оригиналына тиң булырлык колач һәм гүзәл сурәт чараларын, эпик киңлекне бирүгә ирешү өчен тәрҗемәчедән нинди зур осталык, талант, никадәрле хезмәт таләп ителүендә аның ни эше бар? Тәрҗемәче үзенең бурычын үтәгән—бары шул гына. Ул үзе күзгә күренмичә пәрдә артында кала икән, монысы да начар түгел. Димәк, ул үз эшен сизелмәслек итеп, авторның әсәренә һичбер хилафлык китермичә башкарып чыккан.

Яхъя Халитов тәрҗемәләренә карата мәкалә-рецензияләрне матбугат битләрендә бик сирәк очратасың. Хәлбуки, Яхъя Халитов бүгенге көндә актив эшләп килгән тәрҗемәчеләребезнең иң хәзерлекле һәм сәләтлеләреннән берсе. Һәм иң тәҗрибәлесе дә. Бу өлкәдә ул инде чирек гасырдан артык эшли. Шул еллар эчендә Я. Халитов Европаның атаклы әдипләре, рус совет язучылары, тугандаш халыклар әдәбиятлары вәкилләренең зур күләмле дистәдән артык роман һәм повестьларын, берничә дистә хикәя тәрҗемә итеп бастырган. Хикмәт күләмдә һәм санда гына да түгел. Я. Халитов тәрҗемәсендә без М. Шолоховның бөтен дөньяга мәшһүр роман-эпопеясы «Тын Дон»ның беренче һәм өченче китапларын, «Күтәрелгән чирәм» романын, В. Каверинның «Ике капитан», В. Лацисның «Яңа тормышка» романнарын, Ч. Айтматов повестьларын, Бельгия язучысы Шарль де Костерның «Уленшпигель турында риваять», француз әдибе А. Дюманың «Өч мушкетер» кебек атаклы әсәрләрен укыдык. Татар әдибе М. Галәүнең үз вакытында рус телендә генә дөнья күрергә өлгергән «Муть» («Болганчык еллар») романы белән дә татар укучысы Я. Халитов тәрҗемәсендә танышты.

Болар арасында, әлбәттә, М. Шолоховның «Тын Дон», «Күтәрелгән чирәм» романнары аерым урын тота. «Тын Дон» эпопеясының беренче һәм өченче китабын Я. Халитов, ә икенче һәм дүртенче китабын язучы Гариф Ахунов тәрҗемә итте. Аңлашыла ки, моңарчы ун еллап кына тәрҗемә эше, редакторлык хезмәте белән шөгыльләнгән әдипнең профессиональ каләм остасы белән рәттән торып совет әдәбиятының җуелмас энҗеләреннән булган «Тын Дон» кебек олы эпопеяны тәрҗемә итәргә алынуы, телисеңме-теләмисеңме, танылган прозаик белән иҗади ярышка чыгуы да иде. Тәрҗемә практикасында гомумән сирәк очрый торган тәҗрибә булды ул. Һәм әйтә алабыз: көтелгәннән дә уңышлырак тәҗрибә булып чыкты. Тәрҗемәчеләр бер-берсе белән дә, эпопеяның авторы белән дә уртак тел табып, әсәрнең оригиналына якын торган, аның рухын, сурәтләү рәвешен төгәл чагылдырган, эпик колачны, хикәяләүнең талгын, мәһабәт һәм нәфис агылышын би-

рүгә ирешкәннәр. Тәрҗемәнең дөньяга чыгуына унбиш елдан артык гомер узып китсә дә, аңарда искерү галәмәтләре юк, яңгырашы һаман да саф, китаплары кулдан-кулга күчеп укыла.

Шушы иҗади казанышган соң тәрҗемәче тагын да канатланыбрак китә, тагын да кыюрак, активрак эшли башлый. Берничә ел эчендә Ч. Айтматовның «Анам кыры» повесте һәм М. Шолоховның икенче зур күләмле әсәре — «Күтәрелгән чирәм»нең тәрҗемәсен башкарып чыга. Җитмешенче елларда исә ул Майн Ридның «Башсыз җайдак», Ш. де Костерның «Уленшпигель турында риваять», А. Дюманың «Өч мушкетер», Ч. Айтматовның «Бәхил бул, Гөлсары!», «Дөя күзе» повестьларын, бүгенге заман рус, кыргыз, казакъ, удмурт, чуваш һәм башка милләт язучыларының күп санлы хикәяләрен тәрҗемә итеп дөньяга чыгарды. Төрле характердагы, стильдәге бу әсәрләрнең һәммәсе тәрҗемәдә дә бердәй якты, бердәй тигез нурланыш алганнар дип расларга җыенмыйбыз (төрле якка чәчелү әдип иҗаты өчен гомумән хәтәр нәрсә). Әмма, тулаем алганда, тәрҗемәче Я. Халитовның иҗади сиземлелеген, нечкә һәм нәфис кодрәтен танырга туры килә. Ш. де Костер әсәрендәге тапкыр сүзлелек, җорлык, чит бер халыкның күңеле, аның фольклорына хас рух, А. Дюманың маҗаралы романына хас хәрәкәт киеренкелеге, хикәяләүнең савыктыргыч елгыр агышы ачык сизелеп тора һәм укучыга җиңел барып җитә.

Бу җылы сүзләрнең һәммәсе Ч. Айтматов повестьларының тәрҗемәләренә карата бигрәк тә юш килүен әйтергә кирәк. Тугандаш халык художнигының сурәтле сөйләм үзенчәлекләрен, эчке тоемын, дөньяны күңел күзе белән ничек күрүен тәрҗемәче биредә аеруча нечкә һәм төгәл чагылдыра. «Бәхил бул, Гөлсары!» повесте тәрҗемәсендә дә, «Анам кыры»нда да, бернинди искәрмәсез-чыгармасыз диярлек, Чыңгыз Айтматов иҗаты җимешләренең нәкъ үзләрен татыйсың. Күрәсең, әлеге әсәрләрнең фикер сөреше, хис-кичерешләр гәүдәләнеше ягыннан татар совет әдәбиятына аваздашлыгы да тәрҗемәчегә нык ярдәм иткәндер. Тәрҗемәләрендә ул автор белән бергә хикәяләүгә кушылып китә кебек — кичерәсен аның белән бергә кичерә, куана яисә чын күңелдән кайгыра.

Әйтергә кирәк, лирик кичерешләргә бай, психологик яктан тирән, ниндидер иркенлек рухы белән өртелгән әсәрләр, тәрҗемәче буларак, Я. Халитовның хезмәтенә аеруча ятыша төшә. Садә һәм саф хисләрне җырлаган, югары әхлаки сыйфатлар, яхшы зәвык тәрбияли торган әсәрләргә ул бик теләп алына, аларны аеруча бер ихласлык белән, яратып һәм бирелеп эшли кебек. Моңа мисал итеп Ю. Казаковның «Болан мөгезе», М. Байҗиевнең «Елмаю», А. Җакыпбековның «Ай кашка» исемле хикәяләрен китерергә булыр иде. Кешенең эчке гүзәллеген, күңел сафлыгын үзәккә куеп, шул күркәм сыйфатларны калку итеп сурәтләгән проза әсәрләре әдәбиятыбызда гомумән мактаулы урын алып тора. Бу агым ерактан ук— Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимовлардан килә, Г. Бәширов, Ә. Еники, М. Әмир иҗатларында да матур чагылыш таба. Укучы күңеленә аеруча һуш килә торган әнә шул агымны тәрҗемә өлкәсендә дәвам иттерүе, үстерүе белән Я. Халитов әдәбиятыбызга бик тә кирәкле, файдалы эш эшли.

Ә бүген исә тәрҗемәченең рус, казакъ, кыргыз совет язучыларының, шул исәптән, соңгы еллар совет әдәбиятын онытылмаслык әсәрләр белән баеткан В. Астафьев, В. Распутин, П. Проскурин, Ю. Бондарев, Ч. Айтматовның хәзерге чорга багышланган әсәрләрен үз вакытында татар укучысына җиткерүгә омтылышы, шушы өлкәдә иҗат эшен дәвам иттерүе аеруча хуплауга лаек.

Яхъя Халитовка быел илле яшь тулды. Каләм иясе, бигрәк тә тәрҗемәче өчен, бу — иң җитлеккән, тәҗрибә туплап җиткергән игелекле чор. «Казан утлары» журналында, Татарстан китап нәшриятында озак еллар проза буенча редактор хезмәтен башкарып, үз тәҗрибәсен каләм тибрәтүче чордашлары, бигрәк тә яшь язучылар белән мул уртаклашуы, танылган каләм осталарыннан, телебез байлыгы һәм гүзәллегенең бетмәс-төкәнмәс чыганагы — халык сөйләм теленнән даими өйрәнүе бөтен иҗади хезмәте, әдәбият дөньясына ихлас күңелдән бирелгәнлеге, чынбарлыктагы матурлыкка гашыйклыгы бу остадан киләчәктә тагын да зуррак иҗат казанышлары көтәргә ышаныч һәм нигез бирә. Һәм без аңа озак-озын иҗат еллары телибез.

**РИМ ШИРИЯЗДАНОВ.**

# ТЫЛМАЧ КЫНА ТҮГЕЛ

Моннан берничә ел элек укучыларга Мәскәү нәшриятларының берсендә Әмир Нәҗипнең ике том, дүрт китаптан торачак «XIV гасыр төрки телләренең тарихи-чагыштырмалы сүзлеге» басылачагын хәбәр иткәннәр иде. Анда һәр сүзнең нинди мәгънә белдерүе, кайсы чыганактан алынуы, нинди тезмәдә килүе, хәзерге егерме ике тере әдәби төрки телләргә мөнәсәбәте күрсәтелә. Гарәп, латин, рус — әллә ничә төрле хәреф, әллә ничә телдәге язулар...

Шундый тарихи истәлекләрне уку, аларны бөртекләп тикшерү, тәрҗемә итү һәм һәр сүзен системага салуны Әмир Нәҗип бер үзе башкарган! Җитмәсә, бу хезмәт быел сиксән яшь тулуын билгеләп үтүче галим эшчәнлегенең бердәнбер җимеше дә, аның акылы һәм белеменең бердәнбер таныклыгы да түгел әле.

«Югары уку йортлары өчен язылган һәм Мәскәүдә өч мәртәбә басылган, соңыннан инглизчәгә дә тәрҗемә ителгән «Уйгыр теле» дәреслегенең авторы шулай ук сезнең якташыгыз Әмир Нәҗип,— ди Алма-Ата галиме Савут Моллаудов.— Әмир ага төзегән «Уйгырча-русча сүзлек» — моңа кадәр күргән уйгыр сүзлекләренең иң күләмлесе, иң тулысы: утыз өч мең сүзне эченә ала. Географик атамалар күрсәткече, уйгыр календаре хакында тәфсилле белешмәсе сүзлекне тагын да баетып тора. Шушы энциклопедик хәзинәне җыюга унбиш еллап гомерен багышлаган профессор әледән-әле уйгыр теле һәм әдәбияты мәсьәләләре буенча матбугатта чыгышлар да ясый. Шунлыктан без аны күптән үзебезнең Мәскәүдәге илчебез итеп саныйбыз!»

«Профессор Әмир Нәҗип бервакыт Бакуда әзербайҗан телендә доклад укыды,— ди шагыйрь Абдулла Аббас.— Ул шул кадәр төзек, матур әдәби телдә сөйләде ки, мин аны Мәскәүдә яшәүче үзебезнең галимдер», дип уйладым.

Нукистә кардәш халыкның артистлары Мәскәү Дәүләт театр сәнгате институтында каракалпак телен Әмир Нәҗип укытуын, Ташкенттагы үзбәк галимнәре үзләре файдаланган югары математика, физика, химия, теоретик механика дәреслекләре ана телләренә Әмир ага тарафыннан тәрҗемә ителүен, аларның кат-кат (берсе — егерме алты тапкыр!) басылуын хәбәр иттеләр. Үзбәк һәм каракалпак телләренең орфография, атамалар сүзлекләрен төзегән икән әле шул ук галим. Аның төрле конгресс, конференцияләрдә җәмәгатьчелек игътибарын җәлеп итә торган чыгышлар ясавын, таҗик, хакас, шор, ойрат теле әлифбаларын барлыкка китерүдә катнашканлыгын да белгәч, галим эшчәнлегенең колачына таң каласың.

Әмир Нәҗип Казагыстанның хәзерге Семипалат өлкәсе, Бахты авылында туа. Аның бабасы Идел буендагы Яңа Әмзә авылында иген иккән, атасы Семипалатта үсеп, бер якташы ярдәмендә шундагы татар мәдрәсәсендә укыгач, Бахтыга мөгаллим итеп җибәрелгән.

Бу вакытта Бахты халкының күпчелеген казакъ белән татар тәшкил итә. Авылдагы уйгырлар, руслар да аларның телен үзләштерә, думбырасын чиртеп, җырын җырлый.

Башлангыч белемне әтисеннән алган малай 1913 елда Семипалатка килеп, Мисырда гыйлем җыеп кайткан туганы Габдулла Фәизев мәдрәсәсенә укырга керә. Монда гарәп-фарсы телләренә зур игътибар бирелгәнлектән, зиһенле Әмир белемен шактый тулыландыра. Киләсе елда инде ул бишенче класстан башлап гимназиядә укырга керешә. Латин, инглиз телләрен үзләштерүгә аеруча ихлас куеп, 1917 елда урта белем алуын тәгәлли.

Әмирнең атасы 1916 елгы казакъ кузгалышын оештыручыларның берсе булганлыктан, баш күтәрү бастырылгач, Нәҗипләр гаиләсе эзәрлекләүдән качып, озакла-



мый Чәүчәккә күчеп китәргә мәҗбүр була. Тормыш авырая, Әмир тамак ялына тепәсә нинди эшкә алына. Бу вакытта Россиядә революция җәелә, аның шаулы дулкыннары ерак чик буена да кагыла — Чәүчәккә, акларны эзәрлекләп, совет отрядлары килеп керә. Менә шул кызыл эскадроннарның берсендә хезмәт итүче җизнәсе белән очрашу Әмир язмышын котелмәгәндә сөенечле якка үзгәртеп куя. Хөррият тамыр җибәргән Семипалатка кайткач ук, Әмиргә Мәскәүнең шәрык телләре үзәк институтында укырга тәкъдим итәләр.

Егет монда фарсы һәм төрки телләре бүлегендә белем ала. Гарәп телен Сүриядән килгән О. Гаттая, фарсычаны иранлы М. Гаффар, төрекчәне атаклы В. А. Гордлевскийдан өйрәнә. Институтта үз тармагын яхшы белүче күренекле галимнәр болардан башка да күп булганлыктан, һәвәс студент әлеге төлләр дөньясына бөтен барлыгы белән чума. Институтны тәмамлагач исә аны 1923 елда Бохара халык республикасына эшкә җибәрәләр. Монда аңа үзбәк, таҗик телләрендә аралашу, аңлашу насыйп була. Бохарада яшь белгеч Мәгариф халык комиссариатында мәктәпләр бүлге мөдире, Бохара укытучылар институты, совет партия мәктәбе мөгаллиме итеп билгеләнә. Бохарада беренче дәүләт басмаханәсен оештыру да аңа йөкләнә, «Азат Бохара» газетасының редактор урынбасары булу тапшырыла.

1924 елда Әмир Мәскәүгә, СССР халыклары үзәк нәшриятына Казагыстан һәм Урта Азия секторы мөдирлегенә эшкә чакырыла. Монда ул татар бүлегендә хезмәт итүче Мәхмүт Максуд, Нәҗип Гасрыйлар белән аралашып, туган әдәбияты белән якыннанрак танышуга ирешә.

Әмир аганың моннан соңгы эшчәнлеге дә Урта Азия белән Мәскәүгә бәйләнә. Партия идеяләренә чын күңелдән бирелгән төпле белемле кадрлар бу чорда кайда да җитешми. Төрки халыкларда исә алар тагын да әзрәк була. Шунлыктан үзен эштә уңай яктан танытканнарын, берсен бишкә бүлеп дигәндәй, партия-совет аппараты хезмәтләренә тарталар. Мәсәлән, 1927 елда Әмир Нәҗип Сәмәркандка килеп үзбәк нәшриятында, 1928 елдан алып Ташкентта таҗик нәшриятында бүлеккә җитәкчелек итә, бер үк вакытта үзбәк һәм таҗик теле дә укыта. 1933—39 елларда Мәскәүнең ВКП(б) ҮК янындагы партия нәшриятында бүлек мөдире вазифаларын башкара, Кызыл профессура институтында тел белеме кафедрасы мөдирлегенә тәгаенләнә, марксизм-ленинизм классикларын тәрҗемә итүчеләр һәм редакцияләүчеләр курсында үзбәк теленнән сабак бирә. 1940—44 елларда Ташкентта Тел, әдәбият һәм тарих институтында фәнни сотрудник, гыйльми секретарь, директор, Үзбәкстан Фәннәр академиясе басмаханәсе мөдире хезмәтләренә билгеләнә.

Күп төрле мәшәкатьле вазифалар йөкләнүгә карамастан, Әмир ага фәнни хезмәт белән шөгыльләнергә дә вакыт таба — 1944 елда ул «Хәзерге заман уйгыр матбугаты лексикасы» темасына кандидатлык диссертациясе яза. Шушы елда СССР Фәннәр академиясе президиумы аны бөтенләйгә Мәскәүгә чакыртып ала. Башта ул чит телләр институтында уйгыр теле һәм әдәбияты укыта, кафедра мөдире итеп билгеләнә, аннары Мәскәү университетының шәрык телләре институтында уйгыр һәм төрек телләре, әдәбиятларыннан, тарих факультетында исә гарәп теленнән сабак бирә. 1949 елда ул уйгыр һәм башка төрки телләр тарихы буенча лекцияләр укый, шәрык телләре институтының доценты итеп сайлана. Аннары СССР Фәннәр академиясенең тел белеме һәм шәрыкне өйрәнү институтларында өлкән фәнни хезмәткәр буларак тикшеренүләрен җәеп җибәрә. Шуның нәтиҗәсендә 1966 елда «XIV гасыр Мәмлүк Мисырының кыпчак-угыз әдәби теле» темасына докторлык диссертациясе яклый.

Бүгенге барлык төрки телләрне иркен колачлавы, аларның тарихи катламнарын яхшы үзләштерүе белән танылган Әмир Нәҗип әдәбият тарихындагы катлаулы проблемаларга мөрәҗәгать итәргә ярата. Күп кенә әсәрләргә тирән анализ ясап, буталчык мәсьәләләрне ачык һәм эзлекле чишә. Мәсәлән, татар әдәбиятының XIV гасыр истәлекләрен ул үзара чагыштырып өйрәнә дә атаклы галимнәр П. Куртейль, С. Е. Малов, А. Н. Самойловичларның XIII гасыр истәлеге «Миражнамә»не «Нәһҗел фәрадис» тәрҗемәсе дип таңытуларының ялгыш икәнлеген исбатлый. Якташыбыз моның өчен «Нәһҗел фәрадис»нең мәгълүм барлык нөсхәләренә һәм аларга багышланган хезмәтләргә җентекле күзәтү ясый, әсәрнең кайчан һәм кем тарафыннан язылуына да ачыклык кертә.

Соңгы дәвердә уяну һәм куәтле үсеш кичергән кайбер төрки халыклар үзләренең әдәби мирасларын барлаганда, теге яки бу хосусиятенә нигезләнеп, күренекле әсәрләрне үз милләтенә беркетү белән мавыга башлыйлар. Алар өчен авторның фәлән кабиләдән чыгуы яки әсәрдә фәлән сүзнең кулланылуы гына да җитәрлек дәлил санала. Төрки әдәбиятларны һәм аларның телен, аерым әсәрләр барлыкка килгән чор һәм мохитне әтрафлы өйрәнгән Ә. Нәҗип, бу мәсьәләгә сак карарга чакырып, матбугатта чыгыш ясый.

Галим төрки телләр тарихын өйрәнүдәге кимчелекләргә багышлап матбугатта махсус мәкаләләр бастыра. «Кыйссаи Йосыф»ны, мәсәлән, Җ. Алмаз борынгы татар теле истәлеге итеп карый, Н. А. Баскаков исә аны чыгытай олысы әдәби телендә иҗат ителгән, ди. К. Брокельман дастанны борынгы госманлы телендә язылган саный, Х. Флейшер «татарча-угызча» ди! Әмир Нәҗип бер үк әсәрнең телен төрлечә классификацияләү, аңа бер-берсенә каршы килә торган төрле атамалар бирү, шуның аркасында авторның кайда, нинди шивә нигезендә иҗат итүен билгеләү кебек күп кенә күренешләргә туктала, бу өлкәдә фәннилеге көлке дәрәҗәдә чамалы тикшеренүләр ясалуына байтак мисаллар китерә, төгәл, эзлекле булырга кирәклекне искәреп, галимнәрнең чираттагы бурычларын ачыклый. Яшь тикшеренүчеләрнең вак, әһәмиятсез темаларга тотынуларын күрсәтә, бер мәкалә язарлык проблеманы диссертация итеп күпертүләрен хөкем итеп, тарихны киңрәк, тирәнрәк колачларга чакыра.

Котыбның «Хөсрәү вә Ширин», Хәрәзминең «Мәхәббәтнамә», Сәйфи Сараиның «Гөлестан» әсәрләре, төрекмән дастаны, гагауз һәм кыргыз сүзлекләре, Орхон-Енисей рун язмалары, Алтын Урда әдәби теле... — Әмир Нәҗипнең матбугатта дөнья күргән йөздән артык гыйльми хезмәтендә күтәрелгән темалар даирәсе әнә шулай киң. Үзенә хас эрудиция, колач, төпченүчән рух белән ул тюркология өлкәсендәге казанышларны, җитешсезлекләрне һәм вертикаль, һәм горизонталь буенча барлап системага сала, диалектолог, лексикограф, текстолог, филолог һәм, хәтта этнограф, тарихчы буларак хезмәттәшләренең тикшеренүләренә таләпчән фикер белдерә. Абруйлы галимнең фикерен ишетү исә яшь белгеч өчен генә түгел, бу өлкәдә чәч агарткан затларга да бик кирәк. Шуңа күрә күп кенә галимнәр, Әмир агага үзләре мөрәҗәгать итеп, аның фикер һәм киңәш әйтүен үтенәләр.

...Кыскасы, Әмир Нәҗипнең филология фәне докторлары арасында күпләрнең берәве генә түгел, күренеклесе икәнлеге көн кебек ачык. Аның исемен тюркологиядә мәшһүр В. В. Радлов, Л. З. Будаговлар янәшәсенә икеләнмичә куярга мөмкин. Чөнки аның әлегә кадәр дөнья күргән хезмәтләре айсбергның су өстендәге өлешен генә хәтерләтә. Ул әсәрләрнең күзгә күренмәгән зуррак кисәге исә хәзер нәшриятта басылып ята яки кулъязма хәлендә авторның өстәлендә тора.

Төрки телләрнең энциклопедиясе саналган атаклы Радлов, Будагов сүзлекләре хәзинәсе тупланганнан соң инде йөз еллап вакыт үтте, аннан соңгы дәвердә фән күп кенә яңа чыганаклар ачты, элеккеләре гыйльми яктан дәреслап укылды, әтрафлырак итеп эшкәртелде. Нәтиҗәдә, төрки телләр үсешен бүгенге казанышлар югарылыгыннан чыгып яктырту көн тәртибенә килеп басты. Әмир Нәҗип менә шушы ихтыяҗны канәгатьләндерү йөзеннән гаять күп көч таләп итә торган эшен төгәлләүгә ирешкән. «XI—XV гасырлар төрки теленең тарихи-чагыштырмалы сүзлеге» дип аталган бу хезмәт төрки телләр тарихын күзаллау өчен гаять олы әһәмияткә ия. Радлов, Будаговлардан аермалы буларак, галим монда фольклорга кагылмый, бары язма чыганакларга гына таяна. Әмма үткәнгә сәяхәт бу сүзлектә бермә-бер

тирәнрәк, тел катламнарын актару монда чынлыкта сигезенче гасырдан ук башлана. 1944 елда җыйнарга тотынган картотекасына галим йөз меңләп берәмлек туплаган. Алар төрле шивәдән генә түгел, төрле хәрефле чыганаклардан чүпләп алынган. Сүзлекнең тулаем күләме өч йөз басма табак чамасы, ягъни уртача күләмле унбиш роман кадәр булачак! Бөтенсоюз тюркология комитеты төрки халыкларның теле, әдәбияты, тарихы һәм гомумән бөтен культурасы өчен вакыйгага әйләнәчәк бу олы хезмәтне бастырып чыгару хакында махсус карар кабул иткән.

Галимнең киеренке фәнни эшчәнлеге, тюркологиядә уйнаган мәртәбәле роле халыкара танылуын һәм югары бәяләнүен белү күңелле яңалык. Галим үзе:

— Ниятем — «Кыйссаи Йосыф»ны өйрәнүне дәвам итү иде,— дип белдерде.— Бер кеше генә «Йосыф кыйссасы»ның кайсы халыкныкы булуын тәмам хәл итми, әмма аның әдәби мирасны тирәнрәк, җентекләбрәк өйрәнергә этәргеч бирүе мөмкин. Чөнки бәхәскә керүчеләр яңа дәлилләр китереп, әдәби мирасны көтелмәгән тарафлардан яктырта.

Галимнең китап киштәсендә бүләк итеп бирелгән хезмәтләр байтак. Мин аларның берничәсендә «Әмир Нәҗип әфәндегә хөрмәт белән Г. Ярринг» дигән багышлауны күргәч:

— Израил белән гарәпләрне килештерү өчен йөргән Берләшкән милләтләр оешмасы вәкиле шушы түгелме соң? — дип сорадым.

— Әйе. Ул Мәскәүдә Швеция илчесе чагында дуслашкан идек, — диде якташыбыз. — Гуннар әфәнде төрки телләр белгече иде, элемтәне СССРдан киткәч тә өзмәде, яңа китапларын гел җибәреп торды.

Якташыбызның хөкүмәт бүләкләрен, мактау кәгазьләрен караганда, игътибарымны аеруча бер таныклык җәлеп итте.

«Төрек теле җәмгыяте.

Бу таныклык белән төрки телләрне тикшерүгә кыйммәтле өлеш кертүе өчен хөрмәтле профессор, доктор Әмир Нәҗип улы Нәҗипкә хәбәрче исеме алуына куанычын тойгысын белдерәбез, моннан соңгы эшчәнлегендә дә җәмгыятебезгә ярдәмче булуын телибез. Анкара, 28 январь, 1978 ел».

— Димәк, Сезне Төркия тармак академиясенә член-корреспондент итеп сайлаганнар?

— Әйе, көтмәгәндә хәбәр иттеләр, — ди якташыбыз.

Төркия илчесе Юлга әфәнде Әмир Нәҗипкә сокланып: «Сез төрекчә кичә генә Истанбулдан кайткан кеше шикелле матур сөйләшәсез», дигән икән. Галим, гомере буе Татарстаннан читтә яшәвенә карамастан, туган культурасы белән тыгыз бәйләнгән. Илленче елларда ул Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтының кураторы хезмәтләрен дә башкара. Туган телен инәсеннән җебенәчә белә. һәм шундый ук дәрәҗәдә тагын бик күп телләрне! Аларның бүгенге барлык стильләрен дә, мең елдан артык дәвердәге үсеш-үзгәрешләрен дә! Кайчандыр күп тел үзләштергән ата-бабаларыбыз тылмач булудан уза алмаса, якташыбыз Әмир Нәҗип, берсеннән-берсе җаваплырак эшләр башкарып, халыкара атаклы галим булуга ирешкән. Аның кызыклы тикшеренүләре бүген дә уңышлы дәвам итә, укучылар түземсезләнеп көткән хезмәтләре бер-бер артлы дөнья күрә.

**ТӘҮФИКЪ ӘЙДИ.**

# КӨРӘШТӘ БАЛКЫГАН ГОМЕР

Тугандаш үзбәк һәм татар халыкларының дуслыгын гәүдәләндергән фактлар, вакыйгалар тормышның һәр тармагында, тарихның һәр сәхифәсендә бар. Урта Азиянең борынгы җирләренә яңа культура, мәдәният, революцион рух алып килүчеләр арасында татар халкының уллары һәм кызлары аз булмады.

Үзбәкстанда совет чоры вакытлы матбугатының үсешен өйрәнгән чакта мин шундый фидакарь көрәшчеләрнең исемнәренә юлыктым. Шуларның берсе — Рәшит Вәлидов. Ул — үзбәк җирендә Ленинчыл Коммунистик яшьләр союзының партия эшенә җаны-тәне белән бирелгән бер вәкиле, яшьләр матбугатын оештыручылардан иң активы булган.

Рәшит Вәлидов элекке Самара губернасының Богырыслан өязенә кергән Ашир авылында крестьян гаиләсендә туа. Шундагы татар мәктәпләренең берсендә башлангыч белем алып, 1917 елда Богырыслан шәһәрендәге урта мәктәпкә укырга керә һәм аның икенче дәрәҗәдәге ике классын тәмамлый. 1918 елда Богырысланда эшче-крестьян яшьләре союзының җирле оешмасы барлыкка килә. Р. Вәлидов анда гаять зур эшчәнлек күрсәтә. Тагын бер елдан исә ул инде РКСМның Самара губерна комитеты каршындагы татар-башкорт яшьләре арасында эш алып баручы бюроның председателе итеп билгеләнә. Монда да бөтен энергиясен яшьләрне политик яктан тәрбияләүгә бирә.

1920 елда Яшьләр союзының Үзәк Комитеты Вәлидовны Мәскәүгә чакыртып алдыра һәм аңа зур вазифа йөкли: тынгысыз җанлы көрәшче көнчыгыш яшьләренең Бөтенроссия конференциясен үткәрү оешмасына председатель итеп билгеләнә. Бу конференция 1920 елның сентябрь аенда чакырыла. Рәшит Вәлидов анда яшьләргә политик тәрбия бирү хакында доклад сөйли. «Шәрыкка — йөз белән!» дигән өндәмәне ул күтәреп чыга. Көнчыгыштагы ерак өлкәләрдә эшләргә теләк белдергән яшьләр исемлегенә аның үз фамилиясе беренче булып языла.

Төркестанга килүгә (ул елларда урта Азия якларын гомумән Төркестан дип йөрткәннәр) Рәшит Вәлидов яшьләр матбугатын яхшырту, юлга салу эшенә керешә. Яшьләр өчен үзбәк һәм кыргыз телләрендә беренче газета-журналлар аның җитәкчелегендә чыгарыла. Замандашлары һәм безнең тарихчыларыбыз аның бу өлкәдәге фидакарьлегенә һәм тырышлыгына сокланалар. Үзбәк журналистикасының күренекле вәкиле Зыя Сәет «Төркестан» газетасының 1921 елгы 21 июль санында басылган «Кызыл яшьләр матбугаты вә аның тарихы» дигән мәкаләсендә болай дип яза: «Журнал (сүз «Яшь шәрык» дигән басма хакында бара) мөстәкыйль чыгарыла башлаганнан соң татар яшьләренең иң актив эшлекләреннән Рәшит Вәлидов иптәш матбугат эшен юлга салды. Берүзе генә калганы хәлдә дә, мөмкин булганның барысын да башкарып, газета эшен яңа җанландырып, аның 5—6 санын чыгаруга иреште».

Журналист буларак, Рәшит Вәлидов бик күп төрле матбугат органнарында — «Яшь шәрык», «Коммунист», «Кызыл байрак» һәм башка газета-журналларда актив катнашкан.

Төркестан яшьләренең бурычларын аңлатуга багышланган чыгышында Рәшит Вәлидов көн тәртибендә торган җитди политик мәсьәләләрне күтәрә. «Төркестандагы яшь коммунистларның һәр оешмасы коммунизм мәктәбе булсын... Ул оешмалар үз вазифаларын әгъзалар санын арттырудан гына гый-

барәт дип санамаска, бәлки яшь коммунистларны политик һәм культура ягыннан тәрбия итәргә, аларның экономик хокукларны үзләштерүенә ирешергә тиешләр», дип яза ул. Халыкара темага язган бер мәкаләсендә Вәлидов яшьләрне Октябрь революциясе казанышларын якларга чакыру белән бер үк вакытта, белем алырга да, үзләренең фидакарь хезмәтләре белән кызыл сугышчыларга булышырга да чакыра. «Эчке тормыш тышкы фронтка багышлансын. Шуның өчен без, Төркестан яшьләре, бер кулыбызда корал вә революция байрагын, икенче кулыбызда аңбелем бирүче китап тоткан хәлдә бөтен дөньяга аваз салабыз».

Рәшит Вәлидов яшьләр матбугатының тугрылыклы дусты, аны оештыручы һәм пропагандалаучы булып кына да калмый, Төркестан Коммунистик яшьләр союзы Үзәк Комитеты янындагы матбугат бүлеге мөдире вазифаларын да үти. Бу хактагы документлар Үзбәкстан Коммунистлар партиясе Үзәк Комитеты каршындагы марксизм-ленинизм институтының архивында саклана. Рәшит Вәлидов үзбәк матбугаты бүлегенең мөдире итеп Төркестан Коммунистик яшьләр союзы башкарма бюросының 1922 елның 26 январьдагы утырышында расланган. Шул ук союзның икенче өлкә съездында ул Үзәк Комитет члены итеп тә сайлана. 1921 елда, Үзәк Комитет члены сыйфатында, басмачыларга каршы көрәш оештыру өчен, Фергана өлкәсенә җибәрелә һәм шунда губерна комитеты председателе вазифасын үти.

Рәшит Вәлидов шул ук елның сентябрь аенда вафат була. Ленин комсомолының ялкынлы көрәшчесе, татар халкының эшчән бер улы, Төркестан яшьләренең якын дусты һәм сафташы Рәшит Вәлидовның үлеме үзбәк җирендә күпләрнең йөрәкләрен тетрәтә. Коммунистик яшьләр союзы Үзәк Комитетының органы «Юный коммунист» журналы 1922 елгы берләштерелгән 15—16 нчы санда аның эшчәнлегенә югары бәя биреп түбәндәге юлларны яза: «Без арабыздан иң яхшы иптәшебезне җуйдык, актив җәмәгать эшлеклесе Рәшит Вәлидовны югалттык. Ул бөтен Төркестан, Бохара һәм Хива яшьләренең бер оештыручысы, тәрбиячесе һәм җитәкчесе иде».

**А. СӘЙФЕТДИНОВ,**
**тарих фәннәре кандидаты,**
**Ташкент шәһәре.**

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## РЕСПУБЛИКАБЫЗДА СОВЕТ ӘДӘБИЯТЫ КӨННӘРЕ

4 июльдә Казанга Татарстанда уткәрелә торган совет әдәбияты көннәрендә катнашу өчен кадерле кунаклар — Мәскәү һәм Ленинград, союздаш һәм автономияле республикалардан килгән язучылар делегациясе килеп төште. Тимер юл вокзалында башланган каршы алу митингысында Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Гариф Ахунов болай диде: «Хөрмәтле кунакларыбыз! Сез әле генә кояшлы Татарстан җиренә аяк бастыгыз. Бу җирдә кешелекнең бөек даһие В. И. Ленин укыган, Горький үзенең тормыш университетларын узган, бу җирдә халык шагыйре Тукай иҗаты колач җәйгән, легендар Муса Җәлил яшәгән һәм иҗат иткән.

Рәхим итеп, бүгенге Татарстан белән, аның экономикасы һәм культурасы белән танышыгыз!»

Аннары СССР Язучылар союзы идарәсе секретаре Ю. И. Суровцев җавап сүзе сөйләде. «Татарстанда совет әдәбияты көннәре халыклар дуслыгын, әдәбиятлар дуслыгын тагын да ныгытуга хезмәт итәр дип тирән ышанабыз»,— диде ул.

Кунакларны каршылауда КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев, Татарстан Министрлар Советы Председателе урынбасары М. Х. Хәсәнов, КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин, КПССның Казан шәһәр комитеты секретаре А. Г. Кадыйрова булдылар.

## КПСС ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНДА ОЧРАШУ

Шул ук көнне КПСС өлкә комитетында Татарстанда уздырыла торган совет әдәбияты көннәренә килгән язучылар белән очрашу булды. Очрашуда КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев республикабызның экономикасы, культурасы турында сөйләде, аның казанышлары һәм алда торган бурычлар турында мәгълүматлар бирде.

Очрашуда ТАССР Министрлар Советы Председателе Г. И. Усманов һәм ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе Г. А. Ахунов катнашты.

## ТАНТАНАЛЫ КИЧӘ

Кичен Муса Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театрында Татарстанда совет әдәбияты көннәре ачылуга багышланган тантаналы кичә булды. Кичәне кереш сүз белән КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев ачты. Җавап сүзе белән делегация җитәкчесе, СССР Язучылар союзы идарәсе секретаре Ю. И. Суровцев чыкты. Кичәнең әдәби бүлегендә шагыйрьләр С. Хәким, Ш. Галиев, Р. Фәйзуллин, Зөлфәт, кунаклардан — Н. Доризо (Мәскәү), С. Санбаев (Казагыстан), М. Львов (Мәскәү), Р. Сафин (Башкортстан) һ. б. чыгыш ясадылар. Соңыннан симфоник оркестр, Муса Җәлил исемедәге татар дәүләт опера һәм балет театры, филармония артистлары көче белән концерт бирелде.

*

* *

5 июль иртән союздаш һәм автономияле республикалардан, Мәскәүдән һәм Ленинградтан килгән язучылар В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетындагы Ленин мемориалында булдылар, яшь Ульянов һәйкәленә чәчәкләр салдылар. Кунак язучылар бу иртәдә шулай ук А. М. Горький, Г. Тукай һәм М. Җәлил һәйкәлләренә дә чәчәкләр салдылар.

Аннары кунаклар һәм татар язучылары, җиде төркемгә бүленеп, башкалабызның җиде районы предприятиеләренә һәм уку йортларына юнәлделәр.

Язучыларның Ленин районына юнәлгән группасында Ю. Бедзик (Украина), Л. Сорокин (Свердловск), Л. Щасная (Иваново), А. Ячменов (Мәскәү), татар язучыларыннан Х. Халиков, Разил Вәлиев, Р. Хәмидуллиннар бар иде. Башта аларны райком секретаре Г. И. Карунин кабул итте һәм районның промышленность предприятиеләре турында сөйләде, сорауларга җаваплар бирде.

Көннең икенче яртысында язучылар моторлар төзү заводында булдылар, цехларда йөрделәр, эшчеләр белән таныштылар. Соңыннан кунаклар һәм татар язучылары эшчеләргә үзләренең яңа әсәрләреннән өзекләр укыдылар.

Илнең төрле почмакларыннан килгән кунаклар Мәскәү районы предприятиеләре белән дә таныштылар. Райком секретаре Х. Н. Нуруллин аларга районның казанышлары турында сөйләде. Аннан язучылар фотожелатин заводында булдылар. Предприятие белән танышкач, заводның культура йортындагы әдәби очрашуда шагыйрә Мәүҗидә Хәкимова (Дүшәнбе), Михаил Львов (Мәскәү), Ягмур Пиркулиев (Ашхабад), Равил Фәйзуллин, Марсель Галиев (Казан), Тулепберген Каипбергенов (Каракалпак АССР) чыгышлар ясадылар, кыска хикәяләрен һәм шигырьләрен укыдылар.

Сүз осталарының Совет районында булып узган очрашулары да бик җанлы үтте. Райком секретаре И. С. Донская аларны районның промышленносте һәм культурасы белән таныштырды.

ЭВМ заводы коллективы язучыларны бик куанып каршы алды. Биредә алар катлаулы производство һәм эшләп чыгарыла торган продукция белән таныштылар, цехларда булдылар, эшчеләр белән сөйләштеләр. Заводның конференц-залында үткәрелгән җыелышта Одессадан килгән С. Стриженюк, Ижевск шагыйре В. Ившин, Адыгея шагыйре И. Машбаш, татар шагыйрьләреннән Ренат Харис, Нәби Дәүли һәм Роберт Миңнуллин үзләренең иҗади планнары турында сөйләделәр, шигырьләрен укыдылар.

Язучыларның М. М. Колосов, Л. А. Жарова, В. Г. Дагуров (Мәскәү), Р. А. Сафин (Уфа), С. Хәким, М. Садри, И. Юзеев, Ш. Галиев (Казан) составында булган группасы шәһәребезнең Идел буе районында булдылар. Райком секретаре И. Х. Галиев белән очраштылар. Ул әдипләргә районның киләчәккә булган перспективалары турында сөйләде.

Кунаклар М. Вахитов исемендәге химия комбинатында булып, аның производствосы, продукциясе белән танышып йөрделәр, эшчеләр һәм инженер-техник хезмәткәрләр белән очраштылар. Соңыннан комбинатның кызыл почмагында эшчеләргә үзләренең әсәрләрен укыдылар.

Бауман районының беренче секретаре А. В. Сафиянов сүзен совет әдәбияты көннәренә килгән кунакларны районның казанышлары белән таныштырудан башлады. Әңгәмәдән соң Ф. Годжа (Баку), Н. Нурзуллаев (Үзбәкстан), В. Оскоцкий (Мәскәү), Р. Бухараев (Мәскәү), Фаннур Сафин, Туфан Миңнуллин, Фәрваз Миңнуллиннан торган язучылар группасы костюмнар тегү берләшмәсенә юл тоттылар. Берләшмәнең дүртенче цехындагы конвейер янында әдәби очрашу булды.

Билгеләнеп куелган программа буенча белорус шагыйре Н. Л. Аврамчик, Свердловскидан килгән прозаик Г. К. Бокарев, Мәскәү шагыйрәсе Д. А. Терещенко, татар язучыларыннан Диас Вәлиев, Рафаэль Мостафин, Әхмәт Рәшитов башкалабызның Вахитов районында булдылар. Аларны химия-технология институтының ректоры П. А. Кирпичников кабул итте. Биредә кызыклы әңгәмә башланды. Ректор язучыларны студентларның фәнни эшләре белән таныштырды. Кунаклар институтның лабораторияләрендә, лекция залларында, китапханәсендә, спорт базасында булдылар. Көннең икенче яртысында делегация халыкара спорт лагере «Волга»га юнәлде. Биредә кызыклы очрашулар дәвам итте.

Язучыларның Киров районында булган группасы иң элек райкомның беренче секретаре Э. А. Канчурин белән очрашты. Ул әдипләргә районның данлыклы традицияләре турында сөйләде. Соңыннан делегация вертолетлар төзү заводы коллективы белән танышты, очрашулар вакытында дулкынландыргыч сүзләр, яңа шигырьләр яңгырап торды.

Вертолетчылар каршында СССР Язучылар союзы идарәсе секретаре Ю. Суровцев, ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе Г. Ахунов, А. Шевелев (Ленинград), Марина Некрасова (Дүшәнбе), Рәдиф Гатауллин (Казан), С. Санбаев (Алма-Ата), завод шагыйре Георгий Ворошилов чыгыш ясадылар. Соңыннан кунаклар заводның музее белән таныштылар.

## БӨГЕЛМӘДӘ ОЧРАШУЛАР

Әдәби эстафетаны республикабызның коньяк-көнчыгышындагы иң эре промышленность, фән, культура үзәге — Бөгелмә шәһәре кабул итте. 6 июльдә бирегә совет әдәбияты көннәрендә катнашучыларның зур бер төркеме килде.

Каләм осталарының шәһәр һәм аның хезмәт сөючән халкы белән танышуы үзәк мәйдандагы В. И. Ленин һәйкәленә чәчәкләр куюдан башланды. Аннары КПСС-ның шәһәр комитетында очрашу булды. Шәһәр комитетының беренче секретаре М. К. Рәмиев язучыларны каланың үткәне, бүгенге олы эшләре, киләчәккә билгеләнгән планнары белән таныштырды. Очрашулар Татарстан нефть фәнни-тикшеренү һәм проект институтында дәвам итте. Көннең икенче яртысында кунаклар танылган чех язучысы, Бөгелмә шәһәренең хәрби коменданты ярдәмчесе булып эшләгән, шәһәрне акгвардиячеләрдән азат итүдә актив катнашкан Ярослав Гашек музеен карадылар. Предприятиеләрдә, мәктәпләрдә, культура учреждениеләрендә булдылар.

Кичен Техника йортында әдәби кичә булды. Аны Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Гариф Ахунов алып барды.

## ЯЗУЧЫЛАР — АРЧА ЯГЫНДА

Совет әдәбияты көннәренә килгән кунакларның бер төркеме, татар язучылары белән берлектә, шул ук көнне Арча районына килделәр. Кунакларны район җитәкчеләре һәм Арча эшчеләр поселогы җәмәгатьчелеге вәкилләре якты йөз, күпереп пешкән бодай күмәче белән каршыладылар. Делегация җитәкчесе — рус шагыйре Михаил Львов аларга кайнар рәхмәт әйтте һәм: «Тукай туып үскән туфракта якташларының хәләл көче белән үстерелгән икмәк тәме авыздан гомер буена китмәс»,— диде.

КПССның Арча райкомы беренче секретаре Х. З. Зәйнуллин кунакларга районның экономикасы, культурасы, киләчәккә булган планнары турында сөйләде. Аннан соң кунаклар Арча милли аяк киемнәре тегү берләшмәсендә булдылар, аның эше белән таныштылар.

Тукай-Кырлайда каләм осталары район колхозлары һәм совхозларыннан килгән хезмәт батырлары белән очраштылар. Ку-

нелле башланып киткән әдәби бәйрәмдә Ю. Бедзик (Украина), М. Хәкимова (Таҗикстан), М. Львов, М. Колосов (Мәскәү), А. Шевелев (Ленинград), Р. Сафин (Башкортстан), И. Нурзуллаев (Үзбәкстан), Я. Пиркулиев (Төркмәнстан), татар язучыларыннан — С. Хәким, Ш. Галиев, И. Юзеев, Т. Миңнуллин, Ш. Максудова, Ф. Мусин, М. Галиев һ. б. катнашты.

Нәфис сүз остасы, Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Айрат Арсланов рус һәм татар телләрендә Габдулла Тукай, Муса Җәлил һәм М. Львов шигырьләрен укыды. Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе урынбасары Фәрваз Миңнуллин авыл уңганнарына яңа уңышлар теләде.

Аннары Г. Тукай мемориаль музеенда шагыйрь һәйкәленә чәчәкләр салынды. Кунаклар музейның филармония дәфтәренә үзләренең тәэсирләрен теркәделәр.

## НЕФТЬ ЧЫККАН ЯКЛАРДА

Совет әдәбияты көннәрендә катнашучы эдипләрнең бер төркеме 7 июльдә Бөгелмәдән Әлмәткә килде.

Көннең беренче яртысында кунаклар КПССның шәһәр комитетында булдылар. Шәһәр комитетының беренче секретаре В. Е. Борисов аларны Әлмәт белән таныштырды.

Биредә совет әдәбияты алдында торган бурычлар, әдәбиятта заманчалык принциплары турында җанлы әңгәмә булды. Язучыларга бай программа тәкъдим ителде. Алар картиналар галереясында булдылар, үсеп килүче шәһәрнең кварталларында йөрделәр. Аннары О. Павлычев җитәкчелегендәге бораулаучылар бригадасының эше белән кызыксындылар, нефть промыселларына бардылар. Кичен Техника йортына йөзләрчә әдәбият сөючеләр җыелды. Монда кунаклар катнашында әдәби кичә булды. Делегация җитәкчесе, СССР Язучылар союзы идарәсе секретаре Ю. И. Суровцев чыгыш ясады. Кичәдә илебезнең төрле шәһәр һәм республикаларыннан килгән шагыйрьләр, прозаиклар үзләренең әсәрләрен укыдылар. Тантаналы кичәне Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Гариф Ахунов алып барды.

## КУНАКЛАР — ЯШЬЛЕК КАЛАСЫНДА

Шул ук көнне кунакларның бер төркеме Түбән Камага килеп төште.

Очрашу вакытында КПССның Түбән Кама шәһәр комитеты беренче секретаре И. Х. Садыйков кунакларга мөрәҗәгать итеп болай диде: «Кадерле дуслар! Сезнең алдыгызда — мәгърур корылмалар. Совет яшьләре корган ак шәһәр. Яшьлек каласы Түбән Кама. Рәхим итегез, танышыгыз! Совет кешеләренең хезмәттәге тиңсез батырлыгы сезнең иҗатыгызга бетмәс-төкәнмәс илһам бирсен».

Төштән соң кунаклар «Нефтехим» берләшмәсе заводларында булдылар, цехларда йөрделәр, эшчеләр белән таныштылар.

Кичен язучылар әле былтыр гына сафка кертелгән Техника йортында әдәбият сөючеләр, шинчылар һәм төзүчеләр белән очраштылар.

## СОВЕТ ӘДӘБИЯТЫ ВӘКИЛЛӘРЕ КамАЗ ТУФРАГЫНДА

Ике төркемгә бүленеп республикабызда йөргән язучылар 9 июльдә бергә кушылып, легендар КамАЗ һәм яңа кала белән танышу өчен, Чаллыга килделәр.

Кунакларны КПССның Яр Чаллы шәһәр комитеты беренче секретаре Р. К. Беляев кабул итте. Ул күп милләтле совет әдәбияты вәкилләрен Чаллы шәһәре төзелеше белән таныштырды. Аннары Кама зур йөк автомобильләре житештерү берләшмәсе һәм аның кешеләре турында сөйләде. Шушында ук совет әдәбияты алдында торган олы бурычлар, бүгенге әдәбиятта эшчеләр темасы турында җанлы сөйләшү булды.

Соңыннан бер төркем кунаклар һәм татар язучылары «КамАЗ төзелеше ударнигы» дигән истәлек медале белән бүләкләнделәр. Делегация җитәкчесе Ю. И. Суровцев һәм шагыйрь Н. Доризо җавап сүзе белән чыктылар. Аннан кунаклар «Энергетик» культура сараена күчтеләр. «Кама ярларында батырлык» һәм «Сабан туе» дигән төсле фильмнар карадылар. Төштән соң кунаклар Түбән Кама ГЭСы корылмалары белән таныштылар.

Кичен язучылар «Энергетик» культура сараена килделәр. Биредә аларны йөзләрчә әдәбият сөючеләр көтә иде. Кичәдә делегация җитәкчесе Ю. И. Суровцев чыгыш ясады. Ул камазлыларга күп милләтле совет әдәбияты вәкилләре исеменнән кайнар сәлам тапшырды, уңышлар белән котлады.

Аннары илебезнең төрле шәһәрләреннән һәм республикаларыннан килгән язучылар — Н. Доризо, М. Львов (Мәскәү), Г. Бокарев, Л. Сорокин (Свердловск), Н. Аврамчик (Минск), С. Стриженок (Одесса), А. Шевелев (Ленинград), Ю. Бедзик (Киев), М. Хәкимова (Дүшәнбе) үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар. Тантаналы кичәне Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе, СССР Верховный Советы депутаты Гариф Ахунов алып барды.

Әдәби кичәдә КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин катнашты.

*
* *

10 июльдә Казанның Химиклар культура сараенда Татарстанда совет әдәбияты көннәре ябылуга багышланган тантаналы кичә булды. Культура сараеның иркен залында шәһәр хезмәт ияләре вәкилләре, сәнгать эшлеклеләре, әдәбият сөючеләр җыелды.

Кичәне кереш сүз белән Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Г. А. Ахунов ачты. Аннары әдәбият көннәрендә катнашучы язучылар делегациясе җитәкчесе Ю. И. Суровцев чыгыш ясады. Ул үзенең чыгышында тамашачыларны совет әдәбияты көннәренең барышы белән та-

ныштырды. Казан промышленность предприятиеләрендә, Арчада, Бөгелмәдә, Әлмәттә, Түбән Камада, Кама автогигантында, автомобиль төзүчеләр каласы — Чаллыда хезмәт иняләре белән очрашуларда күп милләтле совет әдәбияты вәкилләре гаять зур тәэсирләр алуларын билгеләп үтте.

Кичәнең әдәби бүлегендә кунаклар һәм татар язучылары үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар, очрашуларда алган яңа тәэсирләре белән уртаклаштылар.

Соңыннан Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле концерты булды.

## ЗУР ҖИҢҮ ТАНТАНАСЫ

10 июльдә зур йөк автомобильләре җитештерүче Кама берләшмәсенең баш конвейерыннан йөз меңенче машина төште. Бу тантанада совет әдәбияты көннәренә килгән кунаклар да катнашты. Күп милләтле совет әдәбияты вәкилләре Г. Ахунов (Казан), М. Львов (Мәскәү), Ю. Бедзик (Киев), Д. Терещенко (Мәскәү), Л. Щасная (Иваново), Н. Нурзуллаев (Үзбәкстан), Л. Сорокин (Свердловск) берәмберәм камазлыларны олы җиңү белән котладылар.

## ФИКЕР АЛЫШУ

11 июльдә Татарстан Язучылар союзының Габдулла Тукай исемендәге клубында «КПСС Үзәк Комитетының «Идеология, политик тәрбия эшен тагын да яхшырту турында»гы карарында билгеләнгән бурычлар яктылыгында язучыларның иҗтимагый-политик тормышта катнашуларын активлаштыру» мәсьәләсенә багышланган җыелыш булды.

Җыелышта татар совет язучылары һәм Татарстанда совет әдәбияты көннәренә килгән кунаклар катнаштылар. Фикер алышуны СССР язучылар союзы идарәсе секретаре Ю. И. Суровцев ачты. Фикер уртаклашуда Г. Ахунов (Татарстан), М. Колосов (Мәскәү), Ю. Бедзик (Украина), В. Оскоцкий (Мәскәү), С. Хәким (Татарстан), З. Нури (Татарстан), М. Львов (Мәскәү), Р. Мостафин (Татарстан), Т. Каипбергенов (Каракалпак АССР), Н. Доризо (Мәскәү), Д. Вәлиев (Татарстан), Л. Щасная (Иваново), С. Санбаев (Казагыстан) катнаштылар. Ю. И. Суровцев сөйләшүне йомгаклады.

Җыелышта КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин катнашты һәм совет әдәбияты көннәрендә катнашкан кунакларга КПСС өлкә комитеты һәм ТАССР Министрлар Советының Почет грамоталарын тапшырды.

*
* *

Татарстан Язучылар союзының Габдулла Тукай исемендәге клубында КПСС Үзәк Комитетының 1978 ел июль Пленумы карарларының үтәлешенә багышланган партия җыелышы булып узды. Доклад белән язучылар союзы идарәсе секретаре М. Хәбибуллин чыкты. Чыгышларда язучылар Г. Ахунов, Г. Бәширов, С. Хәким, А. Расих, Х. Хәликов, композитор С. Садыйкова катнаштылар.

*
* *

Республикабызда үткәрелгән совет әдәбияты көннәрен «Яшь ленинчы» газетасы да тулы яктыртып барырга тырышты. Шул уңай белән СССР Язучылар союзы идарәсе секретариаты редакция коллективына рәхмәт белдереп хат җибәрде.

## ТУКАЙ МУЗЕЕНДА — ГЫЙЛЬМИ КИҢӘШМӘ

Яңа Кырлайдагы Габдулла Тукай мемориаль музеенда Татарстан Дәүләт музееның әдәбият бүлеге гыйльми советының күчмә утырышы булды. Анда СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты фәнни хезмәткәрләре — филология фәннәре докторлары Н. Юзиев, Г. Халит, филология фәннәре кандидаты Ш. Абилов, шагыйрь һәм прозаик Ә. Баян, Татарстан дәүләт музееның әдәбият бүлеге мөдире Д. Баһаутдинова һәм башкалар катнашты.

## КАМАЛЛЫЛАР — КАЗАКЪ ДУСЛАРДА

Ленин орденлы Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры коллективы Казагыстан ССРның башкаласы Алма-Ата шәһәрендә гастрольләрен башлап җибәрде. Чирәм җирләрне үзләштерүнең 25 еллыгына багышланган бу гастрольләрне ачу тантанасы М. Ауэзов исемендәге Хезмәт Кызыл Байрагы һәм Халыклар Дуслыгы орденлы казакъ дәүләт академия театры бинасында булды. Анда КПСС Үзәк Комитеты Политбюросы члены, Казагыстан коммунистлар партиясе Үзәк Комитетының беренче секретаре Д. А. Кунаев, Казагыстан ССР Верховный Советы Президиумы Председателе И. А. Абдукәримов, Казагыстан коммунистлар партиясе Үзәк Комитеты секретаре С. Н. Имашев, Казагыстан ССР культура министры Җ. Е. Еркимбеков, ТАССР культура министры И. Н. Алиев, Казагыстан башкаласының партия, совет һәм җәмәгать оешмалары вәкилләре, культура-сәнгать хезмәткәрләре катнашты.

Татар артистлары уйнавында Т. Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» спектаклен тамашачылар яратып кабул иттеләр. Алдагы көннәрдә камаллылар «Татар хатыны нилэр күрми» (Г. Ибраһимов), «Кол Гали» (Н. Фәттах), «Талак-талак» (Х. Вахит), «Дуслар җыелган җирдә» һәм «Диләфрүзгә дүрт кияү» (Т. Миңнуллин), «Сүнгән йолдызлар» (К. Тинчурин) һәм башка спектакльләр куячаклар.


Аннан соң татар артистлары гастрольләр белән Целиноградта һәм Ташкентта булачаклар.

# СОЛДАТ БУЛДЫМ

**РИНАТ ЕНИКЕЕВ** музыкасы

**ҖӘҮДӘТ ДӘРЗАМАНОВ** шигыре

Каеш будым билемә,
Тасма тактым җиңемә,
Йолдызлы бүрек кидем:
— Мин солдат булдым! — дидем.
Иңемә мылтык астым,
Әти каршына бастым:
— Килдем, иптәш командир,
Әйдә, берәр фәрман бир.
— Смирно! — диде әти дә, —
Печән ашат бәтигә.
Бераз утын ярырсың,
Аннан... суга барырсың!
— Була! — дидем кырт кына,
Һәм борылдым фырт кына.
Шуннан китте, и китте...
Мине чын солдат итте.
Бетте ялкау гадәтем,
Санаулы һәр сәгатем:
Иртүк торам, юынам,
Сөлге белән уынам,
Ялт иттерәм тешләрне,
Аннан эшлим эшләрне.
Бүлмәмдә тәртип хәзер,
Ни кирәксә, шул әзер.
Солдат булу шулай ул,
Өйрәнгәч, бик уңай ул.



# Хөрмәтле укучылар!

Журналыбызның киләсе ел саннарында сез татар әдипләренең күп кенә яңа әсәрләре белән танышачаксыз алырсыз. Бөек юлбашчыбыз В. И. Ленинның тууына 110, Татарстан АССР төзелүгә 60 ел тулуга багышланган әсәрләргә аерым урын биреләчәк.

## ПРОЗА

Повестьлар:

Гариф Ахунов. **«Йолдызлар калка».**
Мөхәммәт Мәһдиев. **«Ут чәчәге».**
Барлас Камалов. **«Актуган Гапсаттары».**
Ибраһим Салахов. **«Мәхәббәт картаямы!»**
Әнәс Галиев. **«Шелтә».**
Разил Вәлиев. **«Яшисе килә».**

Романнар:

Эдуард Касыймов. **«Шиңмәс гөлләр».**
Мәхмүт Хәсәнов. **«Шөгеровлар».**

## ПОЭЗИЯ

Х. Туфан, С. Хәким, Н. Арсланов, З. Нури, Г. Афзал, Г. Рәхим, С. Гәрәева, Н. Измайлова, Р. Мингалимов, Зөлфәт, М. Әгъләмов, Ф. Сафин, Р. Миңнуллин шигырьләре;
И. Юзеев. **«Мәхәббәт китабы».** Поэма.
Р. Фәйзуллин. **«Чор турында поэма».**
**Яшьләр иҗаты:** Чаллы, Түбән Кама, Лениногорск һәм Апас төбәгендә яшәүче яшь шагыйрьләрнең яңа әсәрләре.

## ОЧЕРКЛАР ҺӘМ ПУБЛИЦИСТИКА

Р. Ишморат. **Яңа документаль повесть.**
Ш. Хамматов. **Ленин һәм Татарстан партия оешмасы.**
Р. Беляев. **КамАЗ — горурлыгыбыз.**
Г. Ахунов. **Чистай сәгатьләре.**
«ВАКЫТ ҺӘМ КЕШЕ» конкурсына килгән яңа очерклар.

## ПЬЕСАЛАР

Ә. Гаффар. **Җиләк вакыты бер генә.** Драма.
Ю. Әминов. **Яңа комедия.**

Журналда урта буын язучыларының иҗат портретлары биреләчәк.
Әдәбият һәм культура тарихына караган кызыклы язмалар әзерләнә.
Классик поэзия үрнәкләре, әдәби мирас, «Елмаеп та, көлеп тә», «Мәсәлчеләр мәҗлесе», «Нәниләр дөньясы» бүлекләренә урнаштыру өчен әсәрләр, язмалар туплана.
Җыр сөючеләргә ноталары белән яңа җырлар тәкъдим ителәчәк.
**«Укучы сүзе» бүлегендә** укучыларыбызның бүгенге татар әдәбиятына, аерым әсәрләргә, язучыларыбызның иҗатына карата фикерләрен туплаган язмалар, әдипләргә адресланган теләк һәм тәкъдимнәр урнаштырылачак.

**Журналга язылу 1 нче сентябрьдән башланды**

«Казан утлары» Бөтенсоюз каталогына кертелгән, индексы **73210.** Аңа Советлар Союзының теләсә кайсы төбәгендә язылырга була.
Урындагы «Союзпечать» агентлыклары һәм элемтә бүлекләрендә ниндидер сәбәпләр аркасында журналга яздырмасалар, еллык язылу хакын — 6 сум — Казанга, түбәндәге адрес белән җибәрергә мөмкин:

**420066. Казань,**
**ул. Декабристов, д. 2**
**республиканское агентство «Союзпечать».**
**(для подписки на журнал «Казан утлары»)**

Язылуны соңгы көннәргә калдырмыйча, хәзер үк рәсмиләштерергә тырышыгыз. Соңгы көннәргә калдыру журналга язылуда төрле аңлашылмаучылыклар, кыенлыклар тудыра.